ISSN 0206-1189

# КАЗАН УТЛАРЫ

6. 1994



# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ

# УКАЗЫ

**1994 ел өчен**
**Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге**
**Дәүләт бүләкләрен бирү турында.**



Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре буенча комитетның тәкъдимнәрен караганнан соң, карар бирәм:

1994 ел өчен Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен:

1. **Зарипов Илдар Касыйм** улына, «Буяуларда халык моңнары» рәсемнәр сериясе өчен;



2. **Мансуров Фоат Шакир** улына, Татарстан Республикасы дәүләт симфоник оркестрының 1991—1993 еллардагы концерт программалары өчен;



3. **Фәттахов Нурихан Садрильман** улына, «Сызгыра торган уклар» романы өчен (Татарстан китап нәшрияты, 1991 ел) бирергә.

Казан, Кремль.
1994 ел, 25 апрель.

Татарстан Республикасы
Президенты **М. Ш. ШӘЙМИЕВ.**

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**6**

**(860)**

**1994**

КАЗАН


## *Бу санда*


ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

ЗӨЛФӘТ. Тылсым. *Шигырьләр* ........ 3
Л. БАДЫЙКШАН. Мәртәт. *Роман* ........ 10
Р. ЗАКИРОВ. «Аккош күле дәфтәреннән». *Шигырьләр* ........ 103
И. ИКСАНОВА. Яшәү серен ачтым. *Шигырьләр* ........ 110
Т. МИҢНУЛЛИН. Шундый хәлләр ........ 113
Р. ШИҺАП. Рәхмәт, кәккүк! *Шигырьләр* ........ 123
Р. РАХМАН. Торна җиле. *Шигырьләр* ........ 127

ӘДӘБИ ОЧРАШУЛАР

Сагынып килделәр. Яратып киттеләр. *(Балык Бистәсе районында узган әдәби очрашу көндәлеге)* ........ 131

ДӨНЬЯ ӘДӘБИЯТЫ ҮРНӘКЛӘРЕННӘН

С. ЧОКУМ. Розалия Ана. *Хикәя* ........ 136

ХАЛКЫБЫЗ ТАРИХЫНА

Б. СОЛТАНБӘК. Канлы эзләр ........ 144

ТАТАР ХАЛКЫ ТӨРЛЕ ТӨБӘКЛӘРДӘ

Т. ӘЙДИ. «Аһ, туган каумем газиз!» *Эссэ* ........ 155

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Т. ГАЛИУЛЛИН. Кичерерләр безне, кичерерләр... *(Әдәби тәнкыйтьче Фәрваз Миңнуллинның иҗат портретына штрихлар)* ........ 165

ЖУРНАЛДА — ТАТАР ШИГЪРИЯТЕ АНТОЛОГИЯСЕ

Ф. ЯХИН. Әхмәт Ясәвинең мирасы ........ 171
Н. ИСМӘГЫЙЛЬ. Г. Тукай иҗатында дини һәм мифологик мотивлар ........ 179

ЧИТ ИЛЛӘРДӘГЕ МИЛЛӘТТӘШЛӘРЕБЕЗ

Ф. ФӘТХЕЛИСЛАМОВ. «Телдә, фикердә, эштә берлек» ........ 183

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕНДӘ — ТАТАР ШӘХЕСЛӘРЕ

Ф. ИБРАҺИМОВА. Ибраһим Биккулов ........ 188

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ........ 190


Җәйнуллина

*Баш мөхәррир*

**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**
**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**
**Тәлгат Галиуллин**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Зиннур Мансуров**
**Рөстәм Мингалимов**
**Фәрваз Миңнуллин**
**Минтаһир Минһаҗев**
**Мөхәммәт Мәһдиев**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Индус Таһиров**
**Наис Гамбәров**
*(җаваплы сәркатип)*
**Тәүфикъ Әйди**
*(бүлек мөхәррире)*
**Марсель Әхмәтҗанов**

Безнең адрес: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән, хатлар — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, сәнгать, тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.

# В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: окончание романа Л. БАДИКШАНА «Вероотступник», веселые рассказы Т. МИННУЛЛИНА; стихи ЗУЛЬФАТА, Р. ЗАКИРОВА, И. ИКСАНОВОЙ, Р. ШИГАПОВА, Р. РАХМАН.
«Литературные встречи»: репортаж о днях татарской литературы в Рыбно-Слободском районе.
«Из страниц мировой литературы»: рассказ С. ЧОКУМ.
«К истории народа»: статья Б. СУЛТАНБЕКА «Кровавые следы».
«Татарский народ: в разных регионах»: эссэ Т. АЙДИ «Дорог мне народ родной».
«Литературная критика»: Т. ГАЛИУЛЛИН. Штрихи к портрету Ф. Миннуллина.
«Антология татарской поэзии в журнале»: статья Ф. ЯХИНА «Наследие А. Ясави».
Статья Н. ИСМАГИЛОВА «Религиозные и мифологические мотивы в творчестве Г. Тукая».
«Татары за рубежом»: статья Ф. ФАТХЕЛИСЛАМОВА «Единство в мыслях, в делах».
Дневник общественно-культурной жизни.
«На наших обложках»: «Вечерний азан» — картина художника Ш. Шайдуллина; известный поэт и общественный деятель Разиль Валиев.

# IN OUR ISSUE.

«Prose and Poetry»: the end of L. Badikshan's novel «The Apostate», merry stories of T. Minnulin; the verses of Zulphat, R. Zakirov, I. Iksanova, R. Shigapov, R. Rakhman.
«The Literary Meetings»: the reporting from the day of Tatar literature in Ribno-Slobodsky region.
«From the pages of the World Literature»: S. Chokum's story.
«To the History of Nation»: B. Sultanbek's article «The Bloody Tracks»
«Tatar Nation in Different Regions»: T. Aydi's essay.
«Literary Critique»: T. Galiullin: the traits to the Ph. Minnulin's portrait.
«The Anthology of Tatar Poetry in the magazine»; Ph. Yakhin's article «The Heritage of A. Yasavi», N. Ismagilov's article « The religious and mythological Motifs in the G. Tukay's Creative Work»
«Tatars Abroad»: Ph. Phathelislamov's article «Unity of language in Thoughts and Deeds»
«The Diary of the Social and Cultural Life»
In our covers: Sh. Shaydullin's picture «The Eevening Prayer»; the eminent poet and public figure Razil Valiev.

● Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.
● Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
● Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Гөлназ Хөснетдинова.

Производствога бирелде 6.05.94 ел. Басарга кул куелды 15.06.94 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учетн.-изд. табак 19,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 22 171. Заказ А-245. Бәясе 330 сум.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1994 ел.

# ШИГЪРИЯТ



## Зөлфәт

### Тылсым

Изсәләр дә, кылыч чапсалар да,
Юлыкса да юлда мең үткел,
Шигырьле тел
фанилыкка бәйсез,
Үлемгә баш бирми андый тел!

Гамәлендә азат адәми зат
Амин тотсын яки чукынсын —
Тик сүзендә шигъри куәт булса,
Ул сүз, димәк, үзе бер тылсым.

Шигъри сүзем минем — саф тылсымым
Авыр чакта сезгә кагылсын —
Савыктырсын, горур итсен берүк,
Кеше итсен сезне бу тылсым!

Кардәшләрем! Сезнең җанда туган
Шигырьләрне әйтер сүз көчен
Ни өчендер Ходай миңа биргән —
Өлешемә тигән көмешем...

Дөньялыкта яман сүзләр булмый,
Яман әйтүчеләр булмаса —
Булсын сүзем
сүзләр чишмәсендә
Сүзләр чылтыратыр
Колаша.

---

ЗӨЛФӘТ (1947) — *шагыйрь, «Язмышлар ярында», «Утлы бозлар», «Адашкан болыт» һ. б. китаплар авторы. Татарстанның М. Җәлил исемендәге премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Китсен сүзем фани бу дөньяга,
Йөрер юлкайлары ак булсын —
Савыктырсын, горур итсен берүк,
Кеше итсен безне бу тылсым...

*12 дек. 1992.*

## Канат җиле

*Күтәрелде кошлар иле белән...*

Наис ГАМБӘР

Безнең бәхет бары Мөслимдәдер...
Кайтыйк әле, Наис, Мөслимгә бер —
Өшәнгән бу бәгырь җылынсын...
Барыйк әле иртүк Ык ярына,
Тездән чумып салкын чыкларына,
Авыз итик каен сулышын!

Сукмакларга үлән үскәндер бит,
Тик учаклар әле исәндер бит —
Сагынгандыр безне сукмаклар...
Үзебезчә тик бер сөйләш кенә,
Чылтыр чишмәләргә эндәш кенә —
Телләреңә былбыл кунаклар!

Тынып ыгы-зыгы, алкышлардан,
Колак салыйк әле шул кошларга —
Моң тәменә алар өйрәтте...
Күтәрелсен кошлар иле белән —
Шул кошларның канат җиле белән
Савыктырыйк «үф»ләп йөрәкне...

Кайтыйк әле, Наис, Мөслимгә бер!
«Кыз сукмагы» синең исеңдәдер —
Безнең ярлар асыл яр иде!
Асыльярлар һаман шунда сыман...
Тәрәзәдән — гөлләр арасыннан
Караттырган чаклар бар иде!

Шул сукмактан тик бер үтик әле,
Таныш тәрәзләрне чиртик әле
Ай калыккач, зәңгәр эңгердә —
Зарыккандыр сөйгән ярлар көтеп!
... Тибрәнмәс шул инде пәрдә чите —
Кабатланмый сөю бу җирдә...

Ә шулай да кайтыйк Мөслимгә бер!
Моң чишмәсе бары Мөслимдәдер —
Кипкән иреннәргә моң тисен!
Күтәрелсен кошлар иле белән —
Шул кошларның канат җиле белән
Җиллиселәр килә, җиллисе!

Әйдә, киен! Калсын бу мәгыйшәт!
Гомер уздырабыз монда нишләп?! —
Тормыйк, табында, дип, аш кала...
Кайтыйк әле, кайтыйк Мөслимгә бер!
Беркая да качмас мескен дәвер —
Дәвам итәр бездән башка да...

*1993.*

## Кем?

Кеше, имеш, чучкалардан
Аерыла шуның белән —
Башын күтәреп ялгаштан,
Йолдызга карый белә!

... Кем ышкынып ята Җирдә
Суларның юлын бүлеп?
Кем тоташ ялган мыркылдый
Изге мөнбәргә менеп?

Кем гөл бакчаларына кереп
Җир сөрә танау белән? —
Елгалар юлын югалткан,
Диңгезләр хәтта үлгән...

Тын җанын эзләп дөньяның
Керсәң урманга — эчкә —
Урманнары —
              асты өскә!
Дөньясы —
              асты өскә!

Җир кучәренә ышкынып
Рәхәт тапмак итәбез —
Йолдызларга карый белгән
Чучка түгел микән без?

*1989.*

## Аклык

...Кем уйлаган истә калыр диеп
Гади генә көзгә тын көнне? —
Көтү чиратында — көтүдә без
Һәм туплауга кудык көтүне.

Биштәр чишеп, табын җәеп куйдык.
«Хансыз чиру булмый!» — дип кенә
Калай башлы бер пыяла «хан»ны
Куйды әткәй түмгәк өстенә.

«Пыяла хан» тәхетеннән аугач,
Әйтте әткәй:
— Утыр яныма...
Коргылдыны кабат терелтердәй
Шигырь әйтче шушы табында...

...Мин әйткәнне тыңлады да үзе,
Баш чайкады авыр уйлардан:
— Минем дә бар иде мөнәҗәтем —
Коргылдыга атап чыгарган...

Сиңа укырмын дип йөргән идем...
Бер сүзе дә төшми хәтергә!
Китәр чагым килеп җиткән, ахры —
Моңа тагын нәрсә әйтергә?..

Бөтен гомерем шуңа сыйган иде...
Гаҗәп күркәм иде ул шигырь!
Шундый сүзләр онытылсын инде! —
Юк, тикмәгә түгел... Гомеркәйгә
Нокта куяр чагым шушыдыр...

— Алдан юк сүз сөйләмәче! — дидем,
Үземчә нык итеп, ирләрчә.—
Әйтеләсе шигырь — яшәләсе
Гомер сыман бит ул, син нәрсә?!

Мең укырсың әле шигыреңне! —
...Башын чайкап әткәй күрсенде.
Юатып мин аны күп сүз әйттем —
Әйтмәгәнмен «Ходай бирсен»не...

...Ул киткәндә Ходай тарафына —
Очраклымы, әллә түгелме —
Ап-ак чәчәк атты туган якта,
Бар дөньяга аклык түгелде.

Таҗларында күпме наз аларның!
Үзәкләре — кызган күмерле...
Менә нинди булган шигъриең, әткәм!
Мәгънәсе бу синең гомереңнең...

...Ак болыттай чәчәк таҗы ява
Язгы җилләр исеп киткәндә.
Чәчәк бураннары түгел лә бу —
Адәм балалары әйтә алмый
Калган якты моңнар икән лә...

*17 март, 1994.*

## Калыкты ай

Калыккандыр бу ай кыйссадан...
Бүтән тылсым юктыр дөньяда —
Нурларына тулып моң ага.

Ялгыз җаннарга ул охшаган,
Калыккандыр бу ай кыйссадан.

Бүтән тылсым юктыр дөньяда!
Өсти йөрәк галәм җылысын.
Айга карап килә улыйсым —
Бүре каны миндә тулгана!
Бүтән тылсым юктыр дөньяда.

Нурларына тулып моң ага...
Күк шагыйре — аем, ян гына
Бу бәхәссез дөнья алдында!
...Ай бичара уйлый, тыңлана,
Нурларына тулып моң ага.

Ялгыз җаннарга ул охшаган...
Йолдызлар да бар бит югыйсә! —
Серләремне аңа мин чишәм,
Күңелемне аңа ышанам —
Ялгыз җаннарга ул охшаган.

Калыккандыр бу ай кыйссадан.
Янсын яктың әйткән сүземдә,
Сары сагыш булып күземдә
Балкысын нур, чорлар кысса да...
Калыккандыр бу ай кыйссадан...

*6 февраль, 1993.*

* * *

Безнең яшәешкә кар явымы
Тере пәрдә итеп эленгән —
Карлар эри курай моңнарыннан,
Моңнар тибрәп ява кар белән.

Җилләр җилпеп ачты ак пәрдәне —
Мәңгелекне шунда таныдым:
Мәңгелек ул
минем таңым икән,
Үзем — мәңгелекнең таңымын.

Шуны, бары шуны аңлатырга
Без килгәнбез икән дөньяга! —
Моң уралып карлар ява җиргә,
Кар уралып якты моң ява...

И туганым! Мең гайрәтең чигеп
Качкан чакта яшел тугайдан,
Качкан чакта бу җимерек җирдән,
Һич югында
су эч курайдан...

Күрәсеңме, туган, кар ташкыны
Баш очына безнең эленгән —
Үткәннәрне безнең ташлар баскан,
Киләчәкләр — карга күмелгән...

*1989.*

## Шик

Мин ышанмас булдым хәтта чыкка —
Ялган — таңгы урам, талгын җил...
Тууым да минем ялган икән,
Ялган икән минем туган ил!

Ходай безне шулай каргадымы?
Усал язмыш шулай көлдеме?
Башкаема коеп елыйммыни
Нигеземнән калган көлемне?

Без лаектыр инде бу язмышка,
Ходай үзе шулай кушкандыр...
Болай түгел, дисәң, язмышкынам,
Киресенә мине ышандыр!

Бөҗәкләр дә үз дигәнчә яши...
Мин дә лә бит, язмыш, бер балаң! —
Киләчәгем минем ак томанда,
Үткәннәрем минем —
Югалган...

Кайсы тарафларга атласам да,
Юк, белмим бит, белмим юл җаен...
Өйрәт, кайда мин яшисе дөнья? —
Сүзең кызганмачы, Ходаем!

Беләсең бит, юкса, барлык серне —
Мәңгелекнең, мәлнең серләрен!
Шуны белгән килеш, Хак Тәгаләм,
Нигә мине Җиргә җибәрдең?

Киңәшәсем килә — Син дәшмисең.
Шикләнәм мин... Таулар уела.
... Галәмнең саф керфегеннән һаман
Көмеш яшьләр өскә коела...

*1989.*

# Изге ялвару

«Төне шомлы, юл куркыныч,
Ае да канлы-кызыл,
Кабынган сыман тоела
Минем кара йолдызым...

Зинһар, юлга чыкма бүген!
Җылы учак янында
Уйлыйк яшисе көннәрне,
Хыялланыйк тагын да.

Ул арада төн дә узар...
Калдырма беръялгызым!
Атсын таңнар, сүнсен күктә
Минем кара йолдызым!»

...Ялварды шулай хатын-кыз
Бердәнбере алдында.
Тупырдап тынды тояклар
Төннең серле юлында.

Хатын-кызларның мәңгелек
Ялваруы дөньяда:
«Берүк юлга чыкма бүген —
Афәт йолдызы яна!»

...Иртәгесен шул ук юлда
Җайдаксыз ат күренер.
Шашынып калган хатын-кыз
Аңа каршы йөгерер.

Яралы атны күреп ул
Сыгылыр кинәт кенә:
«Нигә тыңламадың, бәгърем,
Сиздe бит йөрәк кенәм...»

Кабатлана шушы язмыш
Мәңгелек каргыш сыман.
Карап тора кара йолдыз
Болытлар арасыннан...

Ирләр йөрәге саңгырау
Шул изге ялваруга:
«Зинһар, юлга чыкма бүген,
Кал минем янда гына!

Калдырма беръялгызымны —
Җылы учак янында
Уйлыйк икәү киләчәкне,
Хыялланыйк тагын да...»

Капкага кала сөялеп,
Сыза җаны, талпына!
...Еракка киткән юлларда
Тупырдый төяк кына...

*1988.*

**Локман Бадыйкшан**



# МӨРТӘТ

РОМАН

Бүтән чара калмады, арлы-бирле йөрергә тотындым. Нәрсә генә уйласам да, уйларымның очына чыга алмыйм. Яңадан яшь диңгезче Игорь исемә төште. Ул авыр минутларында Марусясын уйлап калды. Минем дә яратудан шашкан чакларым бар иде. Газаплы сәгатьләремнән азга гына котылырга теләп, бәхетле сәгатьләремне күз алдыма китерергә тырышам. Амур култыгы, Заһидуллиналар йорты. Бервакыт бик озак шәһәргә чыкмый торганнан соң, менә бәхет, флот экипажына ниндидер пакет илтергә җибәрделәр. Илттем мин аны. Ә кайтканда, кылт итеп диңгез буе урамы исемә төште.

Менә ул Амур култыгындагы зур йорт. Кояшка караган тәрәзәләре биек, иркен. Минем күңелне генә үзенә тарта алар. Чөнки өй хуҗасы Җамал апаның берсеннән-берсе гүзәл кызлары бар. Берсе Миннурый, икенчесе Бибинур. Бибинурның көйдереп ала торган күзләре, озынча ак йөзе, биленә тикле җитеп төшкән калын чәч толымнары гашыйк итте мине. Аның әле миңа бер генә дә елмаеп караганы юк. Культпоходларга чыккалаганда төркемнән качып Җамал апаларга баргалаганнарым күп булды. Ишекне һәрвакыт шул чибәркәй Бибинур ача иде. Бу юлы нишләптер әнисе ачты. Түргә узуым булды, кызны зур тәрәзә янындагы караватта ак җәймә ябынып яткан килеш күрдем. Җамал апаның да күңеле төшенке. Авыру кызына таба борылып кына карады да:

— Больницага алмадылар, терелмәс инде, өметебезне өздек, икенче аен урын өстендә ята,— дип уфтанып, бик борчылып сөйләп алды. Менә бит ул дөнья ничек! Минем булмавыма да хәтсез вакытлар үтеп киткән икән. Соңгы тапкыр диңгезчеләр клубыннан концерттан качып килгән идем. Шундый шатлыклы иде ул кич. Бибинур белән аңлаштык. Күзләремә генә карап торды. Бетмәс-төкәнмәс сорауларын яудырды. Үземнең ерак походларда күргән дельфиннәр, китләр, коточкыч көчле штормнар турында бәйнә-бәйнә сөйләп, тәмам кызның башын әйләндереп, тагын да яраттырдым үземне.

---

Ахыры. Башы журналыбызның 5 нче санында.

Мин аның сулган йөзенә карадым. Мескенем, чак кына таныдым үзен. Күзләре эчкә баткан, сулыш алуы да сизелми. Кара толымлы озын чәчләре мендәренең ике ягына җәелгән. Янына килүемне дә сизмәде. Күзләрен ачмады.

— Кызым, ач күзеңне, таныйсыңмы? Безгә Локман килде...

И язмыш, язмыш! Шундый хәрәкәтчән, җитез кыз бала нинди хәлдә калган. Йөрәгем әрнеде. Хафалы уйлар борчыды. Нинди ярдәм күрсәтә алырмын да, үлем тырнагыннан ничек коткарырмын икән? Шул уйлар зиһенемне биләде.

— Больницага нигә алмадылар?

— Кирәкле дарулары юк, булса да исән калмас, көннәре санаулы гына кызыңның, диделәр...

Җамал апаның бу сүзләре мине тетрәтеп җибәрде. Ничек инде ул алай? Шәфкать кешесенең алай дип әйтергә хакы бармыни?

— Ниндидер бер карт доктор, авыруы үпкәсенә таралып бара, иң кирәкле даруыбыз — пеницилин юк,— диде.

Кинәт корабыбыздагы миңа бик таныш хәрби врач Шилов күз алдына килде. Утыз яшьләр тирәсендәге бу зыялы егет китап укырга ярата. Әйбәт-әйбәт китапларын миңа да биреп торганы булды. Бәлки, онытмагандыр? Ә бит корабта нинди генә дарулар юк. Һаман кайтып тора. Әгәр үтенеп, ялварып карасам?

— Җамал апа, син әйткән даруны табарга тырышып карармын, таныш врач бар минем,— дидем.

— Әй улым, бик әйбәт булыр иде, үлгәндә дә онытмас идек...

Тиз генә, саубуллашып та тормастан, урамга чыгып йөгердем. Ярдан тар сукмакларны сикергәләп транспорт йөреп торган урамга килеп тә чыктым. Бәхеткә, йөк машинасы килгәне күренде. Тизлек белән барган машина кузовына ничек сикереп менгәнемне сизми дә калдым. Хәрби машина иде ул. Әрҗәсендә ниндидер тартмалар төялгән, шофер сикереп менүемне күрми дә калды. Нәкъ миңа кирәк якка, хәрби порт ягына бара. Портка якыная башлагач, кабинасына কактым. Машина туктады.

— Ничек, кайда утырып өлгердең,— дип сорады өлкән яшьләрдәге шофер аптырап.

— Гафу ит, корабльгә ашыгам,— дидем дә, сикереп төшеп хәрби порт ягына йөгердем.

Тирләп-пешеп вахтага җиткәндә адымнарымны киметеп, өс-башымны тәртипкә китереп, трап аша корабка үттем. Башта кубрикка төшеп старшина Загарулькога йөкләнгән бурычны үтәп кайтуымны әйттем. Аннан врачны эзләп югары палубага менеп киттем. Ул кабинетында да, каютасында да юк иде. Корабны аркылыга-буйга иңләп кайтып барганда, офицерлар салоны ягыннан Шиловның килүен күреп алдым. Каршысына басып, устав буенча тәбрикләдем дә:

— Сезгә бик тә мөһим гозерем бар, кабул итә алмассызмы? — дидем.

— Әйдәгез, кабинетыма керегез,— диде ул.

Яхшы кеше һәрвакыт яхшы булып кала. Врач Шилов башта мине игътибар белән тыңлады. Аннары:

— Кирәк дисең, нишләргә инде синең белән? — дип, бармакларын өстәленә суккалап алды. Нәрсә әйтер икән бу дип сабырсызлык белән өметемне баглап аңа карап торам. Җавап бирергә һаман ашыкмый. Күрәсең мин сораган дару аның кул астында санаулы гынадыр.

— Ярый, авыруның адресын бир. Башта үзем барып карыйм, аннары, бәлкем, ярдәм дә итеп карармын...

Врачның бу сүзләреннән җиңел булып китте. Якын көннәрдә шәһәргә чыгу миңа мөмкин дә түгел, ә врач-офицер, әлбәттә, кулыннан килгәннең барысын да эшләячәк. Мин ышанам. Алдан ук рәхмәт әйтеп:

— Кайчан барырсыз икән? — дип сорадым.

— Кичке аштан соң керерсең...

Канатланып кубригыма кайтып киттем. Ниһаять, кичке аш та узды. Санчастькә юл тоттым.

Врач Шилов мине, гадәтенчә, тыныч кына кабул итте. Аның беренче сүзе:

— Кулымнан килгәннең барысын да эшләдем,— кызны больницага салдырдым,— бер-ике көннән килерсең, нәтиҗәсен әйтермен,— диде. Өмет бар икән әле. Бәлки, Бибинур терелер... Мин көткән көн килеп җитте. Санчастькә барырга туры килмәде, врач үзе чакыртты.

— Кризисы үтте, кыз терелеп килә, борчылма, барысы да әйбәт булыр.

Болай итеп сөенгәнемне гомеремдә дә хәтерләмим! Сөенечемнән күзләремнән яшь бәреп чыкты. Кеше өчен кайгыра белүче, авыр минутларда хәленә керүче шәфкатьле җанлы кешеләр дөньяда күбрәк булсын иде, дип, кубригыма кайтып киттем.

... Көннәр берсе артыннан берсе актылар да актылар. Эскадрабыз белән сугышчан походка катнаштык. Тәүлекләр буена башнядан чыкмадык. Утырган килеш шунда ук йокларга туры килде.

Бу зур походка чыгар алдыннан, флот штабыннан корабыбызга моңарчы беркайчан да күренмәгән начальниклар килгәнлектән, мөһим эш башкарырга җыенуыбызны сизә идек инде.

Себер диңгез юлы начальнигы, Советлар Союзы Каһарманы Папанинны корабыбызда күреп, мин генә түгел, күпләр гаҗәпләнде. Сталин тарафыннан аның безнең эскадраны Төньяк котып диңгезләре аша Мурманскига озатып барырга билгеләнгәнлеген белдек. Ул имәндәй нык гәүдәле, уртачадан калкурак буйлы кеше иде. Күзәтү постына менгәндә якыннан күрергә туры килде үзен. Аның коңгырт күзләре әле дә хәтеремдә.

Походыбыз бик озак дәвам итте. Һаваның сизелерлек салкынаюын тойдым. Кышларын гына киенә торган эчке җылы күлмәк-ыштаннарыбызны кияргә мәҗбүр булдык.

Өченче мәртәбә күзәтү постыннан кайтып килгәндә, аскы кубрикка төшәргә борылган гына идем, корабның өлкән боцманы Семеликовны күрдем. Ул мине яхшы белә. Аның командасында ничәмә тапкырлар көймә ярышларында катнашканым бар.

— Бик ерак киттек булса кирәк, һавалар үзгәрде, Ефимыч,—дигән булдым.

— Беринг бугазына җитәбез инде,— диде ул.

— Юкка түгелдер, безнең крейсырыбызда Папанин үзе бара,— дип куйдым.

— Ахыры гына әйбәт була күрсен,— диде дә Ефимыч китеп барды.

Боцман белән сөйләшүнең икенче көнендә, диңгездә чын мәхшәр купты. Тревога арты тревога булып кына торды. Броньланган башня эчендә утырганлыктан, сугыш булып алганын соңыннан гына белдек без. Билгесез су асты көймәләре һөҗүм иткән икән. Мин болар турында кайтырга чыккач кына белдем. Югары командование эскадрабызны кире Владивостокка алып кайтырга приказ биргән...

Бу уйлар диңгезендә йөзеп күпме вакыт үткәргәнмендер, белмим. Көтмәстән карцерның тимер ишеге уртасындагы кечкенә тәрәзәчек ачылып китте. Надзирательнең башы күренде.

— Ал тизрәк, әллә көтәрләр дип уйлыйсыңмы,— дигән чәрелдәвек тавышы ишетелде.

Төрмә көне яңа башланган икән. Сикереп тордым да тәрәзәчеккә барып миңа сузылган ризыкларны алдым. Кулымда өч йөз грамм икмәк, бер кружка җылы су. Бу тоткынның бер тәүлеккә дигән сые.

Төрмә камерасы гомерем буена истә калыр. Тормышта намусым кушканча гына яшәргә, йөрәгем белән акылымны кушып фикер йөртергә,

нинди генә авыр хәл килеп чыкса да югалып калмаска, бары тик тирәнтен уйлап, үземчә яшәргә карар кылдым. Ялгыш булса да үземчә булыр, уңышка ирешсәм дә үземнеке булыр!

Карцер срогы бетүгә, мине яңадан таныш бүлмәгә илттеләр. Калын өстәл янында элекке танышым — тикшерүче Шумихин үлек кебек ай йөзен кәгазьләргә текәп хәрәкәтсез генә утыра иде. Мин кергәч тә урыныннан кузгалмады. Әйтерсен, мин дөньяда гел юк. Мине сынар өчен юри кылана бугай. Басып тора-тора аякларым арып бетте. Ә тышта нинди матур яз! Югары кат булганлыктан, каршыдагы йортларның түбәләре генә күренә. Кайсылары куе кызылга буялган, яшел түбәлеләр дә шактый. Һавада ара-тирә күгәрченнәр, чәүкәләр төркеме күренгәли. Их, шул кошлардай, күкләрне иңләп очасы иде! Юк шул, ирегемне алдылар. Кешеләр дә бит әлеге кошлар кебек үзләренчә тормыш корып яшәгәндә генә бәхетле. Кешене беркайчан да, беркем дә кол итеп тотарга тиеш түгел. Моны минем акылым, йөрәгем тоя. Уйларым әллә кайларга китте. Тагын хәтер йомгагын сүтәм...

— Утыр, ну ничек, уйладыңмы? Тәүбәгә килергә бик вакыт инде сиңа.

— Гражданин тикшерүче, тәүбә итәрдәй эшләремне, сез озаткан салкын камерада атна буе нык уйланып гомеремне үткәргән булсам да, исемә төшерә алмадым...

— Шулаймыни?

— Җәфаламагыз, гаепләрем бар икән, үзегез әйтегез!

— Әле мин синең белән кешеләрчә генә сөйләшәм, безнең сөйләттерә торган башка ысулларыбыз да бар!

— Совет законнары гадел, сез капиталистик илдәме әллә? Кыйнап, канга батырып сорау алыргамы ниятегез?

Бу сүзләрем Шумихинны ярсытып җибәрде. Үзе дә сизмәстән тавышын күтәрде.

— Синдәй кире беткәннәр өчен җаен табарбыз...

Эндәшмәдем, тешләремне кысып булса да түздем. Бу Шумихиннан барысын да көтәргә мөмкин.

Беренче булып аның түземлелеге бетте.

— Йә, сөйләгез,— дип, кинәт аягына басып җикеренмәсенме.— Аңламаганга сабышып башымны миңгерәүләттегез. Сабырлыкның да чиге була!

Гел бер сорауларны бирүдән нигә туймый икән бу? Аның тонык күзләренә текәлеп карыйм. Сизәм, ул да тынычсызлана. Ябык битендәге мускуллары вакыт-вакыт тартышып куя.

Камерама кайткач, 1937—38 нче елларда Казанда яшәгән вакытларым исемә төшеп китте. 37 нче елның 31 нче декабрендә Черек күл бозында тимераякта шуарга барган идем. Салкынча матур кич. Шугалакның сул ягында хәрби оркестр уйный. Шуучылар бик күп. Уйламаган җирдән язучы Гомәр Толымбай очрады. Аңар ул вакытларда кырык яшьләр тирәсе булгандыр. Уртачадан калкурак, киң йөзле, өстендә җиңелчә спорт киеме иде. Китапларын укып барам. Шуңадыр тартынмыйча, ачыктан-ачык сөйләштем мин аның белән. «Түбән елгада», «Кызыл Армиядән кайткач», «Фәтих Әмирхан» дигән әсәрләре турында фикерләремне әйттем. Ул мине бик якын итеп, һәр сүземне игътибар белән тыңлады. Үзем дә биш-алты хикәямне дөньяга чыгарып өлгергән идем. Кайберләрен укыган. Шуны белгәч күңелем күтәрелеп китте. Бозда озак шудык. Оркестр киткәч кенә, тимераякларны тапшырып, кайтып киттек. Саубуллашканда, иртәгәсен язучылар клубындагы бильярд залында очрашырга сүз куешып, аерылыштык. Минем ул елны Язучылар союзында консультация бюросында драматург Әнәс Камалның ярдәмчесе булып эшләгән чагым иде. Иртән шунда ашыктым. Шугалактан кайткач, башлаган хикәямне язып тәмамлаган идем. Шуны машинкада бастырып алырга кирәк. Үзенең эш урынында бик иртә килә торган тәбәнәк буйлы,

ак йөзле, зәңгәр күзле Сара апа («Совет әдәбияты» журналы машинисткасы) нишләптер мине якты чырай белән каршыламады. Һәрвакыт елмаеп торган Сара апага ни булды икән? дип уйларга өлгермәдем, ул:

— Локман, үткән төнне Гомәр Толымбайны кулга алганнар,— дип күңелсез хәбәр җиткерде. Йөрәгем жу-у-у итеп алды. Кая ул хикәямне бастыру. Бер сүз дә әйтмәстән үземнең бүлмәмә кереп утырдым. Озаклamaды, Әнәс Камал да килде. Толымбай турында ул белә икән.

— Галимҗан Ибраһимовны да Кырымнан кайтарып Плэтән төрмәсенә япканнар, нәрсә дип уйларга да белми, сак бул, туганкай,— диде Әнәс миңа.

... Менә хәзер үземне кулга алдылар. Нинди мәхшәрле замана соң бу?

Кулга алынган кешенең рухын сындырыр өчен, аны татлы йокысыннан аер икән. Ярты төндә уятып сорау алу Шумихинның гадәтенә, яраткан эшенә әйләнде. Сизәм, буыннарда хәлем көннән-көн кими. Кайсы чакларда башым әйләнеп, стенага терәләм, бөтен тәнемне тир баса, калтырыйм. Елыйсы килә башлый. Мин бит ике кулымны як-якка сузып, һәркайсына герләр күтәреп тора торган егет идем. Бетә баруым шушыдыр инде.

Ял көненә каршы, ике солдат камерамнан гел башка этажга алып менеп киттеләр. Коридор ярым караңгы иде. Бара торгач, ниһаять, иң түрдәге калын ишек янына килеп туктадык. Алдан барган сакчы ишекне ачып, миңа юл бирде.

Кабинет тәрәзәләренә ак ефәктән пәрдәләр эленгән. Каршымда шактый озын һәм киң яшел постау ябылган өстәл. Моңарчы гомеремдә дә күрмәгән, күзнең нурларын алырлык бик тә матур телефоннар тора. Урта яшьләрне узган, иң башларында генерал погоннары ялтыраган, чәчләренә чал керә башлаган зур кара күзле кеше миңа утырырга тәкъдим итте. Аны нишләптер Сталинга охшаттым. Җитмәсә мыеклары да гел аныкы кебек өске иренен каплап аска таба төшкән дә очланып туктаганнар. Охшаса да охшар икән кеше. Йөзе кара-кучкыллы. Мин имән агачыннан зиннәтле итеп эшләнгән артлы урындыкка утырганнан соң, ул икенче сүзен әйтте.

— Матросик, син инде бездә өченче аеңны яшисең, үзеңне бик тә тупас тотасың икән, алай ярамый. Без бит кешеләрне гаепләсәк тә җәбер кулланмыйбыз, үзләреннән сөйләтеп кенә эш итәбез. Өлкән лейтенант Шумихин тәҗрибәле, сыналган чекистыбыз...

— Шулайдыр шул, тәҗрибәсенә ышандым инде, атна буе көненә бер кружка су белән төрмә карцерында тотты.

— Икмәк биргәннәрдер бит?

— Гафу итегез, өч йөз грамм икмәге дә булды...

Күрәм, минем белән ачыктан-ачык сөйләшәсе сүзе бар. Ләкин ашыкмый, мине якыннан өйрәнә, үзенең зур дәрәҗәле кеше икәнлегенә нык ышанган булганлыктан, аңлатырлык итеп сөйләшәсе килә. Бүлмәдә без икәү генә. Миннән ул яше белән генә түгел, хезмәте-чины, күп кешеләрнең язмышларын хәл итә алуы белән дә бик өлкән иде. Сүзен нидән башлар дип торганда, генерал зур кара күзләре белән сул яктагы стенага карап алды. Күзләренең Советлар Союзы картасына төбәлгәнен сиздем. Ул һаман фикерләрен туплый. Мин тагын нәрсә әйтер икән дип көтәм...

Зур түрә телгә килде. Башта эчтән генә уйлаганнарын әйтә башлады.

— Тарихта булмаган зур сугыш булып үтте. Совет халкы фашизмны тар-мар итте. Ә кайбер халыклар Ватанга хыянәт иттеләр. Син... Кырымнан булмасаң да, кавемең татар бит әле...

Генералның шул сүзләреннән соң гына мин, гомеремнең сигез елын Ватанга игелекле хезмәткә биргән татар малае, моннан ерак булган Татарстанның Әлмәт төбәгендә крестьян гаиләсендә тууыма да карамастан, йөрәгемә шикле хисләр тула баруын тойдым.

Минем бит Кырымга бүгенге көнгә кадәрле бер генә мәртәбә дә аяк атлаганым юк. Аның вакыты да булмады. Үсү, уку, флотка алынып, игелекле рәвештә хәрби хезмәт итеп, Ерак Көнчыгыш су чикләрен саклауда үз өлешемне үтәүдә булды. Димәк, мине татар булганлыгым өчен кулга алганнар. Сугыш тәмамлангач, хәзер инде кирәгем калмаган. Нинди коточкыч мәрхәмәтсезлек бу?! Мине сәяси яктан гаепләп, халык дошманнары рәтенә кертергә чамалап кулга алганнар! Юк, иптәш генерал, мин сез уйлаган кеше түгел.

— Матросик, мин сезгә начарлык теләмим, гаепсезгә бер кешене дә кулга алмыйбыз. Бер генә нәрсә сорала, тикшерүчегә дөресен генә сөйләп бирергә миңа вәгъдә бирәсез, үз нәүбәтемдә мин дә сезне яхшы лагерьга җибәрергә боерырмын...

Менә сиңа мә! Яхшы лагерьлар да бар микәнни? Димәк, миңа моннан иреккә чыгу юлы юк. Күз алдыма борынгы Рим, Карфаген килеп басты. Колбиләүчеләр дәүләтләре. Камчы, сөңге ярдәмендә кешеләрдән таш ваттырганнар, сарайлар, пирамидалар салдырганнар. Барысы да җиңелгән халыклар исәбенә эшләнгән.

Димәк, мин гаепләме, түгелме, барыбер кол булачакмын. Шунысы гына яхшы, генерал миңа «әйбәт лагерь» вәгъдә итә...

— Мине аңлагансыздыр,— дип елмая төште генерал.

Нәрсә дип әйтим инде шундый зур дәрәҗәле кешегә?

— Аңладым, зур рәхмәтемне белдерәм.

— Барыгыз,— дип ул мине урыныннан кузгалып ишеккә юл күрсәтте. Теге ике солдат мине көтеп арып беткәннәр булса кирәк. Берсе:

— Бик озак сөйләштегез! — диде.

Камерама озатып куйдылар. Иртәнге ашны кертүче кизү:

— Озакламый машина килә, төрмәгә китәсең, тизрәк ашап ал,— иртәгә ял көне, бүген башка чакырып тормаслар...

Күз алдыма генерал килеп басты: «Мин сиңа яхшы лагерь вәгъдә итәм...»

## Дүртенче бүлек

Күрәсең, вакытлы рәвештә КГБ подвалында тотуларының вакыты бетте. Генералдан соң тимер түбәле машинада төрмәгә китерделәр. Кызыл кирпечтән салынган корпусның өченче катындагы бер камерасына кертеп яптылар. Миннән башка анда яңадан өч кеше бар. Күрәм, һәммәсе дә өлкән яшьтәгеләр.

— Рәхим итегез, яңа кеше,— дип берсе килеп танышып та алды.

— Нинди җилләр монда китерде диңгезчене,— диде ул, өс киемнәремә карап.

— Тын океан хәрби-диңгез флотының крейсырыннан булам, ябылуда өченче аем, моңарчы КГБ подвалында тоттылар.

— Нинди кош икәнлегең күренә...

— Бер карават буш иде, сине көткән икән.

Барысы белән дә танышып өлгердем. Өчесе дә хәрбиләр. Иң өлкәне власовчы, чины — армия капитаны, моннан дүрт ай элек Харьковтан китергәннәр. Тикшерү эшләре беткән, егерме биш ел срок биргәннәр үзенә. Лагерьга җибәрүләрен көтеп ята. Сугышның беренче көннәреннән башлап сугышкан. Яралы килеш әсирлеккә эләккән. Аннары лагерьда ачтан үлүдән куркып, РОАга язылган. Бу тип — чын сатлык җан, дип уйлап куйдым. Оялмый-нитми шундый явызлык белән совет хөкүмәтен сүгә, «Сталин режимы мәңгегә яшәмәс, илдә азатлык җиле исәр»,— ди.

Икенче тоткын утыз яшьләрдән чак кына өлкәнрәк булыр, танкист. Курск дугасында каты сугышларда катнашкан. Танк янгач, аскы люктан чыгып исән калган. Госпитальдә яткан. Яралары төзәлгән, яңадан

фронтка җибәргәннәр. Маршал Рокоссовский армиясендә сугышны тәмамлаган. Алар частен Ерак Көнчыгышка сугыш беткәч кенә күчергәннәр. Каядыр Тоньякка, Совет Армиясе японнардан азат иткән атауларга барырга пароход көткәннәр. Көннәрнең берендә, часть командиры ике танкист белән шәһәргә ялга чыккан булган. Шунда исерек килеш аларны диңгезчеләр патруле эләктергән. Бу хәлне күреп калган иптәшләре, уйлап-нитеп тормастан, кайтып танкларын кабызганнар да командирларының ябылган җирләренә килеп орудиеләрен төзәгәннәр:

— Йә, кичекмәстән безнең танкистларны чыгарасыз, йә көлегезне күккә очырабыз,— дип кисәтеп, залп биргәннәр. Эшнең зурга китүен күреп, начальник, Рокоссовский танкистларын чыгарып җибәрергә мәҗбүр булган һәм бу вакыйганы шәһәр коменданты Лавроненкога хәбәр иткән.

Лавроненконы хәтерлим. Ул мин Рус Атавында кораллар мәктәбендә укыганда ротабыз командиры иде. Усаллыгын, тәртипне үлеп яратуын яхшы, беләм. Рокоссовский танкистларына рәхмәт әйтмәгәндер, трибуналга биргәндер... Уйларым дөрес булып чыкты. Әлеге вакыйгага катнашкан танкистларның һәммәсенә, шул исәптән бу егеткә дә, унар ел хезмәт белән төзәтү лагерына җибәрергә хөкем чыгарганнар. Өченчесе минем яшьләр тирәсендә. Сугыш корабыннан, Павел Коваленко. Тумышы буенча Кавказдан — Нальчик дигән шәһәрдән. 1939 елны флотка алынган. Тын океан флотының шактый зур сугыш корабында хезмәт иткән җиреннән төнлә килеп алып киткәннәр аны. Берничә ай тикшерү астында җәфалап интектергәннән соң, советка каршы агитациядә гаепләп, 58 нче статьяның 10 нчы пункты белән ирегеннән мәхрүм иткәннәр. Күңеле бик тә төшенке. Миңа, үзе кебек диңгезче булганыма күрә генә, өстән-өстән үз хәле турында сөйләп алды. Икебез дә Рус атавында кораллар мәктәбендә укыганбыз. Тик аралашмаганбыз гына.

Павел ике сүзнең берендә, туган яклары Кавказны искә ала. Алтын яшьлеге үткән тауларын сагына ул. Үзем аны тыңлыйм, ә хәтергә Казанда чакта якыннан аралашып яшәгән язучы Рахман Ильяс искә төште. Ул миңа «Таулар арасында» дигән китабын флотка китәр алдыннан бүләк итеп биргән иде. Шул әсәрләр белән бергә, язучы үзе дә хәтер тәрәзәсен кага.

... 1939 елның салкын көзе. Казанның Кольцо дигән җирендә трамвай көтәм. Караңгы төшеп килә. Карыйм, янымда гына өстендә күзгә пальто кигән мәһабәт гәүдәле кеше басып тора, шундук танып алдым мин аны.

— Сәлам, Ильяс абый,— дидем беренче булып.

— Сәлам, сәлам! Күрми дә торам, Бадыйкшан икәнсен. «Бүләк» дигән китабыңа рецензияне мин язган идем бит.

— Нәшрият редакторы Зәкия Садыйкова миңа Абдулла Әхмәтнең язганын гына укытты.

— Мин хәзерге нәшриятның матур әдәбият секторында эшлим. Зәкия апаң еш кына янымa кергәләп тора. Әле бүген генә күрдем, китабыңның корректурасы да килгән инде. Рәсемнәре дә бар... Шундый сөендем, аның әйткәннәрен мин зур яңалык итеп кабул иттем. Рахман абыйның әсәрләре Баку нефтьчеләре турында. Татар әдәбияты бу темага бик тә ярлы.

Мин янә сүз башладым:

— «Штык» дигән роман хакында ишеткәнем бар, укырга туры килмәде, ул сезнеке түгелме?

Ильяс абый көлеп куйды. Нәрсәдер әйтмәкче иде, өлгерә алмады, трамвай килеп туктады. Миңа да Ирек мәйданы ягына барысы булгач, без бер үк вагонга утырдык.

Ленин бакчасын уздык. Опера театры салына башлаган иде инде, зур төзелешкә карап барам. Ул җирдә «Бакыр бабай бакчасы» барлыгын беләм. Мин Казанга килгән елны ул «бабайны» каядыр алып киткәннәр.

Ирек мәйданы тукталышында без бергә төштек. Аннары Кольцода өзелгән сүзебезне дәвам иттек.

— «Штык» романын мин язмадым, аны абыем язды. Күпләр хәзер дә безне бутыйлар...

— Ильяс абый, минем китабымның рәссаме кем?

— Нәшриятның талантлы яшь рәссамы Байназар Альмеев.

Иртәгә нәшриятка кереп, Рахман Ильяс әйткән яңалыкларны үз күзем белән күреп чыгарга ниятләп, язучы белән саубуллаша башладым.

— Әле вакыт кичке алтылар тирәсе генә, миңа кереп чык, ничек яшәгәнемне күрерсең...

Каршы килмәдем. Тельман урамында гына яши икән. Шактый зур ике катлы агач йорт. Яфраклары коелып беткән биек агачларның ботаклары йортның тәрәзәләренә үк тиеп тора. Килеп кергәч:

— Мәрьям, менә яшь язучы алып кайттым әле, чәй әзерли тор, аңарчы без сөйләшеп алырбыз,— диде.

Җәмәгате гәүдәле генә, мөлаем йөзле, җитез хәрәкәтле кырык яшьләр чамасындагы ханым иде. Ул үзенә генә хас матур елмаю белән миңа баштанаяк карап алды да, кухня ягына чыгып китте. Өстебезне салып икебез дә язу өстәле янына килеп утырдык. Кая карама китаплар, ниндиләре генә юк. Кызыксынып күз йөртәм...

— Менә шулай яшибез инде, Локман энекәш, язабыз-сызабыз, шак-катарлык шедеврлар тудыра алмыйбыз әле...

Мин тыңлыйм, ә ул үзенең иҗаты белән таныштыра. Сокланып, аның сөйләгәннәрен күңелемә беркетеп барам.

— Менә «Кеше» дигән роман тәмамлап киләм. Бик авыр языла. Ул шунда өстәленең бер читендә, өелеп торган кульязмаларын алып минем алдыма китереп куйды. Калын гына, өч-дүрт йөзләп бит булыр. Матур тигез хәрефләр белән язылган. Нефтьчеләр тормышыннан икән.

Озакламады, Мәрьям апа безне чәйгә чакырды. Өстәл янында да сүзебезне дәвам иттек.

Азактан зур рәхмәтләр әйтеп, саубуллашып кайтып киттем. Бу минем язучы Рахман Ильяс белән соңгы очрашуым булган икән...

Төрмә камерасында кешеләр белән аралашкач, бераз үз хәлемә кайта башладым. Йөрәкнең ялгызлыктан сыкрануын, акылның шашар дәрәҗәгә җитүен бары тик үз башыннан кичергән кеше генә аңлыйдыр. Әйе, мин кешеләр арасында үземне кеше итеп тоя башладым. Тормышка карашым, кулга алынгач кешеләргә булган барлык мөнәсәбәтләрем тамырыннан үзгәрде. Хәзер беркатлы кеше түгел инде мин. Барысына да шикләнеп карыйм, әйткән сүзләренең мәгънәсенә зур игътибар биреп, кайбер чакта: «Әйдә шапырын, барыбер мине ышандыра алмассың»,— дип уйлап куям. Бер өлкән яшьтәге агайның: «Кеше йоклаганда гына әйбәт, аны тыңла да, үзеңчә эш ит»,— дигән канатлы сүзләре исемә төште. Ә мин җүләр бала булганмын. Бергә хезмәт иткән кешеләрне — чын дусларым, фикердәшләрем дип, йөрдем. Дөньяга карашымны, эч серләремне, мәхәббәтемне сөйләдем аларга, язган, килгән хатларымны укыттым. Шул ук кешеләр зәһәр көнләшү белән минем турыда кирәкле урынга җиткереп торганнар. Шуларның мәкерле уклары һаман йөрәгемә төртеп тора, вакыт-вакыт шул агулы уклардан котыласы, күзләремне мәңгегә йомып, явызлык белән агуланган бу дөньядан югаласым килеп китә...

Генерал яныннан чыкканга бер тәүлек вакыт үткәннән соң, тикшерүче Шумихим янына китерелдем. Иртәнге вакыт булуга карамастан, көн нишләптер караңгы. Машинадан төшкәч тә, һаваның бозылып китүенә игътибар иткән идем. Әйтерсең, салкын көз. Диңгез ягыннан куе кара болытлар Көньякка берсе өстенә берсе атланып агалар. Шумихин, мине күрмәмешкә салышып, ниндидер кәгазьләргә күзләрен текәгән. Укып чыкты булса кирәк, миңа күтәрелеп карап алды.

— Әйткәнне генә көтмә, кергәч тә утырырга кирәк,— дип куйды.

Әрсезлегем юк минем. Ни әйтсәң дә, тәртип дигән, кешедәге иң мөкатдәс сыйфат миңа әнием сөте белән бирелгән. Нинди генә авыр хәлдә калсам да, түзәм, үз җаныма гына ышанам.

— Йә, башлыйбыз, генералыбызга дөресен сөйләп бирергә вәгъдә биргәнсең, бик яхшы.— Мин дә үз нәүбәтемдә сине кыерсытмам...

— Гафу итегез, нәрсәдән башлап җибәрим соң?

Тикшерүченең ак чырае кызарып китте. Ләкин тавышын күтәрмәде, баягыча тыныч кына:

— Гаебеңне яшерүең язмышыңны гына авыр хәлгә куя, азагы күңелсез булыр!— дип ашардай булып күзләрен миңа төбәде.

— Кайда, кайчан, нинди җинаять эшләгән соң мин? Әгәр әйтсәгез, имзамны куеп раслар да идем.

— Менә документлар, монда синең җинаять эшләрең. Без үзең сөйләп бирерсең дип көткән идек. Теләмәдең.

— Нәрсә сөйләргә кирәклеген белмим.

Күрәм, ул бүген тыныч, текәлеп карап-карап торды да, кәгазь өемнәреннән бер битен тартып алды:

— Корабыгызда дусларың кемнәр? Исемнәрен әйтә аласыңмы?

Көтелмәгән бу сорауга ничек дип тә җавап бирә алмый тордым. Кем соң әле минем чын дустым? Хәзерге хәлемдә кешегә ышанырга, чын дус дип атарга буламы берәрсен? Миемне шул сорау кыздыра. Кемнәрне күрсәтә алам соң? Һәммәсе дә күз алдымнан үтә. Авыр вакытымда сердәш, теләктәш булырлык кемем бар соң?

Бер якташымны исемә төшердем. Ул да Татарстанның мин туган Әлмәт районы Бишмунча авылыннан. Калку буйлы, коңгырт йөзле, сүлпән карашлы зур авызлы егет. Ачыктан-ачык дөнья хәлләре, кызлар, үзебез белән мәж килеп яшәгән иптәшләр турында да сөйләшүләр күп булды үзе белән. Менә хәзер аны чын дустым дип әйтсәм? Кинәттән бер нәрсә искә төшеп китте. Моннан ике ел элек, ул егетнең әнисе үлүе турында телеграмма килеп төшкән иде. Шуны тотып яныма килеп басты. Йөзе бик тә борчулы үзенең.

— Хәзер гариза язып бирәм, сиңа кайтырга кирәк булыр,— мондый хәлдә, югары командование сугыш вакытында да кешенең хәленә керә белә,— дидем. Егетнең күңеле күтәрелеп китте. Мин шундук гариза яздым да телеграммасын кулына тоттырып:

— Бар, политбүлек начальнигы Яков Гурьевичка йөгер,— дидем. Шул көнне үк якташым Моталлап Хөсәеновка юлын-иген санамастан ун көнлек отпуска да бирделәр. Кичке катер белән аны озатканда:

— Әгәр вакытың булса, кайтканда минем авылым аша үтәсең бит, ничәмә еллар хатлар алышып торган сөйгән кызыма да кереп чык әле,— дидем.

— Аны гына үтәрмен,— үзеннән сәлам дә алып килермен,— дип егет минем белән саубуллашып кулын болгап китеп барды. Менә шулар күз алдыма килеп баскач, күңелсез бер хәл искә төште. Әйе, Хөсәенов әйләнеп кайтты, сөйгән кызыма да кереп чыккан. Кыз миңа балда катырылган чәкчәк белән каклаган каз җибәргән булган. Тик кадерле күчтәнәчләрне алып килеп җиткерә алмады ул.

— Йоклап киткәнмен, вагонда солдатлар күп иде, алар сиңа дигән күчтәнәчләрне ашап бетергәннәр,— диде. Соңыннан сөйгәнемнән хат алдым. «Синең белән бергә хезмәт иткән егет һәрбер сүзендә сине яманлады, ул сиңа тиң түгел, кызлардан аңа хатлар күп килә дип сөйләде» дигән җөмләне исем китеп укыган идем. Юк, юк аны дустым дип әйтә алмыйм. Урыс егете Владимир Пантуров бар. Ул бик гади, кешелекле, авыр вакытларда хәлеңә керә белә. Аның да миңа ошамаган ягы бар — туры әйткәнне яратмый. Ә болай гел янымда сагызланып йөри. Бергә укыдык. Комсомольск шәһәрендә крейсерны төзүгә өлеше-

безне керттек. Зур походларда булдык. Буйларыбыз икебезнең дә йөз алтмыш биш сантиметр. Аның мин яраткан бер ягы бар. Көрәшергә бик ярата. Владивостокның хәрби көрәшчеләр клубына йөри. Шулай бервакыт, кораб палубасында үзе белән көч сынашырга туры килде. Мин татарча көрәшәм, ә Владимир диңгез клубында өйрәнеп кайткан самбо алымнарын кулланмакчы була, иптәшләр карап тордылар. Көчләребез бер чама булганлыктан, тирләп-пешеп беттек. Ул да җиңәргә тели, мин дә бирешмим. Ул арыды, мин дә ярыйсы гына сулпәнләдем. Билләребездән алышкан килеш бер урында таптанабыз. Җаен китереп башаркан палубага ордым бит моны. Владимир тын да ала алмый сузылып ята. Шүрләп тә куйдым. Кемдер башына салкын су китереп койгач кына күзләрен ачып җибәрде, аягына басты. Киткәндә:

— Моны исеңә төшерермен әле,— дигән иде.

Көннәр, айлар, еллар үтте, дуслыгыбыз элеккегедәй дәвам итте... Йә, тагын кемнәрне искә төшерим соң?

— Мин күп егетләрне беләм, бергә яшәдек, төрле чак булгандыр,— дидем тикшерүчегә.

— Март башында көймә чистартканда, матросларга язучы Михаил Зощенконың бер хикәясен мактап сөйләгәнсең. Ә бит Зощенконың иҗатын партия идеологик яктан зарарлы дип махсус карар чыгарды, анда Анна Ахматова да бар. Шундый карарлар чыгуын белә торып, син нигә аларны пропагандалап йөрисең?

— Әйе, истә, ул чакта Михаил Зощенко турында сүз булды. Мин аның хикәясендәге маймылның мунчадагы мәҗаралары турында сөйләдем. Алар эчләре катып көлделәр. Моның өчен сез мине җинаятьче дияргә хакыгыз юк.

— Мә, сөйләгәннәреңне раслап кулыңны куй,— дип, Шумихин өстәлдәге беркетмәне миңа табан шудырды. Өстәп язмаган микән дип җентекләп укып чыктым. Барысы да сөйләгәнемчә. Раслап, кәгазьгә имзамны салдым.

Сорау алу дәвам итте. Тикшерүче яңадан-яңа дәлилләр китерде. Походларда бергә булган кайбер бәндәләрнең, сөйләгән сүзләремне органнарга җиткерә баруларын белгәч, бик күңелсезләндем. Махсус мине әнә кемнәр чолгап алган булган икән. Ә мин бернәрсә дә сизмәгәнмен...

Үткән ел октябрь бәйрәме көнендә мин кубрикта дежурда торганмын. Ялгызым гына радиодан бәйрәм концертын тыңлаганда, икенче генә елын хезмәт итүче Мордвинов дигән егет кайтып керә дә, радионы туктатып куя. Иптәш Сталинның пластинкага язылган ниндидер бер нотыгын потефонда тыңлыйсы килеп кайтуы булган икән. Әйләндерә башлый ул аны. Кубрикта икәү генә булганбыз. Шундый күңелле концертны туктатуына ачуым килеп киткән.

Түзмәгәнмен, аны Сталинның нотыгын тыңлаудан мәхрүм иткәнмен...

— Булдымы бу хәл?— дип сорау бирде тикшерүче.

Хәзер генә аңлый барам, кемдер үз тирәсенә яшь, тәҗрибәсез малайларны туплап, алдан ук минем өстемнән күзәтү оештырган! Болар барысы да соңгы өч ай дәверендә. Нигә, кемгә кирәк булдым икән соң мин? Туган ягыма кайту алдыннан гына. Һәрбер әйткән сүземә кире мәгънә салып, тозак кордырганнар. Тикшерүченең канәгать икәнлеген тоям. Шулай да:

— Өстәп, бер-ике сүз язып куегыз әле,— дидем.

— Ничек булган шулай язылган бит инде, тагы нәрсә өстәмәкче буласың?

— Бәйрәм көне булганлыктан, политикадан арынып торырга теләдем, шуңлыктан, яшь диңгезче Мордвиновка иптәш Сталин нотыгын башка вакытта тыңларсың, дидем.

Бер сүз дә әйтмәстән, Шумихин беркетмәгә сүзләремне теркәп куйды. Аннан соң матрос Моталлап Хөсәенов белән югары палубада йөргәндә, дәүләт һәм коммунистлар партиясе турында арабызда сүз чыккан.

— Син ризасызлык белдергәнсең һәм урысларны гына мактап язалар дигәнсең.— Сугыш беткәч, иптәш Сталинның Кремльдә банкет вакытында: «Беренче нәүбәттә бөек рус халкы өчен тост күтәрәм» — дигән сүзләрен хурлагансың. Синең ни эшең бар юлбашчының кемнәр өчен эчүендә, маңка!..

Менә бит ул кая таба борыла сүзләр. Яшермим, сөйләшүләр булгандыр, әмма ләкин алай ук әйтмәгәнмендер. «Бу тостны бөтен совет халкы өчен күтәрәм»,— дигән булса, әйбәтрәк булыр иде, дигәнмендер. Рәсәй өчен, каһарманнарча сугышкан татар, чуаш, мари, яки башка халыкларның уллары кемнән ким иде соң?

— Сөйләшү булды, мин Хөсәеновка, иптәш Сталинның җиңү уңае белән әйтелгән сүзләрен бөтен совет халык өчен әйтелгән дип аңларга кирәк,— дидем. Чөнки районлашым Хөсәеновның белеме бик түбән. Ул Бишмунча авылы мәктәбенең башлангыч классын гына бетергән...

Яңадан ябык машинада төрмәгә китереп яптылар. Мин кайтканда власовчы гына юк иде. Аның урынына урта яшьләрдәге кара чәчле, бераз кысынкырак күзле, киң кара кашлы, яңаклары суырылган яңа тоткын килгән. Мин кергәч тә ул торып басты. Киемнәре бик үк таушалмаганлыктан, күптән түгел генә кулга алынганлыгын чамаладым.

— Ничек, авырттырырлык итеп селкемәделәрме? Хәер, алар сак кылана хәзер. (Бу сүзләрне танкист егет әйтте.)

— Советка каршы агитация алып баруда гаеплиләр. Әле бүгенгә чаклы җикеренү, каты сөйләшүдән башка кул якмадылар,— дидем. Павел Коваленко исе дә китмәстән:

— Әйттем бит, миңа чәпәгән статьяны ябыштырачаклар сиңа. Менә көт тә тор, срок бирәчәкләр...

Сөйләшәсем килми иде. Дүрт сәгать буе тикшерүче кабинетында утырып арылган. Төшке әбәт булган, миңа калдырылган аш суынып беткән. Ашарга кирәк, көчем бетмәсен.

— Лагерьга бергәрәк эләксәк, күңеллерәк булыр иде,— дип, Павел яныма елышты. Күрәм, бик тә сөйләшәсе килә аның. Дәшмәдем. Башым болай да тубалдай...

Яңа тоткынның язмышы бигрәк тә катлаулы икән. Ул чексит, дошман җирендә эшләгән. Японнар тотып төрмәгә япканнар. Кырык үлем аша котылган. Ләкин совет разведкасы кулга алган. Менә хәзер тикшерәләр...

Мин тагын камерада «ялгызбаш калып», тирән уйларга чумам, үзем турында түгел, Кеше турында уйлыйм. Әдәм баласы барысына да түзә икән. Кинәттән зоопарк күз алдыма килә. Анда арысланнар, юлбарыслар, тагы әллә нинди ерткыч җанварлар, кошлар бөтен гомерләрен читлекләрдә үткәрәләр, җан газабында арлы-бирле йөреп торалар. Ә кешеләр аларны күрергә бала-чагаларын алып килә. Ә шул карап торучылар арасында: «Нигә болар иректә түгел, алар бит табигать балалары, тоткынлыкта тормасыннар, туып-үскән урманнарына, дала-тауларына яшәргә җибәрергә кирәк үзләрен»,— дип уйлап караучылар бар микән?! Менә бу минутта без, дүрт кеше, тоткынлыкта яшибез. Дөньядагы иң кадерле нәрсә — ирек ләззәтеннән мәхрүм ителгәнбез. Хурлыкка дучар ителү күпмегә чаклы дәвам итәр? Белмим, башкалар ничектер, мин бу нахак газапларга түзә алмам. Тиз арада моңа чик куярмын...

— Тоткын Бадыйкшанов, әйдәгез,— дигән калын тавыш мине сискәндереп җибәрде. Уйларга бирелеп, ишектән надзирательнең керүен ишетмәгәнмен икән. Чыгу юлына атладым.

Түбәле машинаның эчендәге тар бер бүлмәчегенә ябып куйдылар. Тагын кемнәрнедер керттеләр. Ишекләрнең ачылып бикләнүләрен санап тордым. Бу юлы сигез кеше. Озакламый машина сикәлтәле юллардан бара башлады.

Шумихин бүген яңа погоннар таккан. Хәзер инде ул капитан. Күрәсең, зур эшләр башкарган, үзенең корбаннарын атналар, айлар буена судка озатып торган.

Тикшерүче өстәлдәге папкаларның берсеннән дәфтәр суырып алды. Шундук таныдым — минеке. 1940 елда яза башлаган идем. Яңа алфавитка күнегеп җитмәгәнлектән, латин хәрефләре белән язылган анда. Күрәсең, татар кешесе танышып, укып чыккач, кайбер битләренә кәгазь кыстырган. Кызыл карандаш белән беренче битеннән алып актыгына кадәр сан куеп чыгылган. Язганнарымның күп кенә битләре кара белән язылган булганлыктан, теләсә кем укырлык иде. Шумихин көндәлегемнең 32 нче битен ачып, алдыма куйды. Анда Уралның Чиләбе өлкәсендәге Копейск шәһәрендә яшәүче шагыйрь Габдрахман Теләштән 1941 елның 14 мартында хат алуым турында язылган. «... Фәтхи Бурнаш ун елга хөкем ителгән, ул яхшы кеше иде. «Таһир-Зөһрә»не язган, күп кенә поэмалар авторының «халык дошманы» булуына ышанасым килми. Зур язучыларның югалулары бик тә кызганыч. Бурнаш тиз акланырга тиеш. Шагыйрь Хәсән Туфанның да язмышы үкенечле, ул да кулга алынган. Һич тә аңламыйм, нәрсә бу?» — дип язып куйганмын.

Шумихин миннән күзен алмый, көндәлегемнән сызылган юлларны укыганымны карап тора. Беләм, ул инде күптән тиешле нәтиҗәгә килгәндер. Ә мин һаман укыйм: «Унсигезенче июль, кырык икенче ел. Шулай итеп, акрын гына эссе июльнең икенче яртысы да үтеп бара. Тормышымнан тәм таба алмыйча яшәвемне дәвам итәм. Кая карама, гаделсезлек, тормыштан тую, кешеләр, дошманнар, дуслар — барысы да кояш кызуыннан качарга тырышалар. Ә мин, киресенчә, үземнең бөтен омтылышым белән алга, бу авыр елларны ничек кенә булмасын үткәрергә тырышам. Ләкин бик каты җәберләнәм».

Менә бит ул ничек! Хәзер, язмаларның язылуына алты ел үткәч, шуларны искә төшерәләр, гаеп эзлиләр. Кемнәргә кирәк булды икән минем ул вакытта нәрсә уйлаганнарым? Кеше уйсыз, хыялсыз яши алмый бит инде. Укуымны дәвам итәм: «Миргали Монасыйпов — үз халкының көрәшен кире кагучы эгоист, ләкин тазалыгы, ныклыгы белән теләсә кемгә ярый белә торган кеше. Миңа шундый нахал дус кирәкми. Габдулла Галиев, Шәрәф Мөдәррис, Үзбәк Саттаров, Кадиков һәм шулар кебек халкыбыз өчен өзелеп торган олы җанлы кешеләр кирәк».

Көндәлегемне укыганда сыкрыйм, өзгәләнәм. Ничек инде бу фикердәшләремнән бизәргә! Һич тә мөмкин түгел, мин алар белән мәңгегә бергә...

Өч ай дигәндә Шумихин эшемне тәмам итте. Аның җилкәсеннән тау төшкәнен үзеннән бигрәк мин аңладым. Соңгы сорау алулары вакытында ул элеккеге көннәрендәге кебек борчылмады. Үзен тыныч тотты. Хәтта өстәлендәге өелеп торган биш көндәлегемне һәм кулъязмаларымны укырга мөмкинлек бирде. Күрәсең, соңгы мәртәбә генә булса да, тоткын үзен тынычландырсын, күңелен юатып калсын, дип уйлагандыр...

Калын-калын көндәлек дәфтәрләремдә хәрби хезмәткә алынган вакытымнан алып, кулга алынганчы үткән көннәремнең иң әһәмиятле мизгелләре теркәлгән. Аларны язар өчен күпме йокысыз төннәр үткәнен бары тик үзем генә беләм. Менә бу минутларда шуларны искә төшерәм дә әрнеп-әрнеп үземне каһәрлим. Нигә мин аларны вакытында илгә, туганым Рәхимәгә яки сөйгән кызыма юлламадым, дим. Редакцияләргә дә бик аз җибәрдем шул! Фронтовик дустым Шәрәф Мөдәррис ике хикәямне Көнбатышта үзе эшләгән газетада бастырды. Аңа мең рәхмәтемне укыйм. «Совет әдәбияты» журналына шактый гына зур документаль повестемне җибәргән идем. Бәхетсезлеккә күрә, аны миңа язучы Фатих Хөсни, төзәтергә дип, яңадан үземә кайтарды. Әнә, шул кулъязмам да, башка әсәрләрем белән бергә, тикшерүче алдында ята. Кызганыч! Минем белән берәр хәл була калса, барысы да юкка чыгачак ич алар...

— Җитәр, озак укыдың, язмаларың бездә югалмас! — дип, Шумихин укуымны бүлдерде.

Аның миңа яңа соравы бар икән:

— Сафар Сәрдәров дигән кешене беләсеңме?
— Нигә белмәскә, бик яхшы беләм. Хәрби портта хезмәт итә, якташым була.
— Алай икән...
— Әйтегез әле, аның турында нигә сорадыгыз?
Шул мизгелдә кылт итеп Сафарның мине квартирасына чакырып кунак итүе, өстәл тартмасын ачып, тутырылмаган хәрби билетлар, пистолет күрсәтеп: «Әле синең хезмәтеңнең кайчан бетәсе билгеле түгел, әллә бу нәрсәләрдән файдаланып каласыңмы?» — дигән сүзләре исемә төште. Менә ышан кешегә. Бер корабта якташым Моталлап кебек үк, тагын бер агулы елан дус булып йөргән микәнни? Ләкин капитан Шумихин минем соравыма:
— Болай гына әйтүем иде,— дип җавап бирде.
Алдыма гаепләү өчен куелган язмаларга игътибар итәм: үзем кул куйган беркетмәләр, кораб китапханәсеннән алып укыган китаплар исемлеге — барысы да бар.
— Эшеңне ябарга да булыр иде. Ләкин син үзеңне начар тоттың. Тәкәбберләндең, кирәген сөйләп бирмәдең. Гаепләреңне үземә ачарга туры килде,— диде Шумихин.
— Сез артыграк та кыландыгыз әле...
Җавабым тикшерүчегә ошамады, шундук алдымдагы кәгазьләрне үзенә тартып куйды. Өстәле астындагы кнопкасына басуга, сакчы килеп тә керде. Мине алып чыгып киттеләр.
Камерага кайткач, исем китте. Барысы да — яңа торкыннар. Танышу, аңлашулар башланды. Мине бигрәк тә дядя Ваня кызыксындырды. Яше белән җитмешләр тирәсендә булыр. Ябык карт, күзләре зәңгәр, бите балавыз сыман куе сары үзенең. Ул:
— Егетем, синең эшең пустяк. Тик — срок бирәчәкләр. Диңгезчеләр арасында советка каршы агитация алып баргансың. 58 нче статьяны көт тә тор. Синдәй яшь егетләрне дә җыймагач, Сталин ничек коммунизм төзесен? — дип, Советлар иленең төрмә, лагерьлар белән тулганлыгын, иртәме, соңмы монда чик куелачагына, чын демократия башланачагына ышандырырга тырышты. Аның белән сөйләшү үзе бер гыйбрәт булды.
Шушы яшемә җитеп, дөньяны алай ук аңлый алмавыма сызланып куйдым. Өлкән кешенең һәрбер сүзе сәясәткә булган карашларымны үзгәртә барды. Әмма аның бүгенге көнгә карашы, коммунистлар партиясенә нәфрәтле булуы миңа ошамый. Мәскәүдә күп нәрсәләрне белми булырлар, дигән уй һаман борчый. Үземне дөрес гаепләмәүләрен җиткерәсем килә.
Караватыбыз янәшә булу дядя Ваня белән арабызны тагын да якынайтты. Тавышы ягымлы. Каяндыр бик еракта килгән кебек. Ашыкмыйча, һәрбер сүзен йөрәккә җиткереп сөйли...
— Тикшерүчеләрнең төрлесен күргән абзаң булыр бу,— дип яңадан башлап китте ул.— Берәүләре сине ялгыз камерага утыртып, бик озак чакырмый тора. Шуның белән рухыңны төшереп тинтерәтә, аннары шул вакыттан файдаланып, синең турыда белешмә, фактлар туплый. Аннан чакырып ала да: «Болардан баш тарта алмыйсың»,— дип кул куйдыра. Бу инде аның үзенә күрә кешене өйрәнүе, гаебен танытуга ирешүе. Карышсаң, киреләнсәң, өченче номерны кулланырга юл ачыла.
— Нәрсә соң ул өченче номер?
— Җәзалау. Брезент капчык кидереп, салкын су коюю, типкәләп һушыңнан яздыру, аннары янә, бастырып, кулыңа каләм тоттыру.
— Совет төрмәсендә монда кем рөхсәт бирә? Бу бит фашизм!
— Әй, беркатлы сабый! Кызганам мин сине! Монда эләктеңме, закон табармын дип уйлама. Төрмәдә закон юк. Кулга алганнар икән, димәк, син кирәк аларга. Гаепләме-түгелме, аларның анда эше юк.

— Һич аңламыйм.
— Аңларсың, башың яшь әле, аңлатырлар...

## Бишенче бүлек

Япон диңгезенең көнбатышында Путятин дип аталган шактый зур атау бар. Ул диңгездән колакчын бөрек сыман калкып тора. Безне Владивосток төрмәсеннән тимер баржада буксир пароходы белән шунда сөйрәп китерделәр. Бәхетебезгә, диңгездә давыл булмады. Вак-төяк чайкалуларга барыбыз да түздек. Мин үзем хезмәт иткән сугыш корабымны исемә төшереп бардым. Кайчан гына мин дә иректә, иптәшләрем белән көлешеп, шаярып, илгә кайту өмет-хыяллары белән яши идем.

Баржадан ярга чыгарып тезгәннән соң, безне берәм-берәм тентеделәр. Аннан бишәрләп җиргә утырттылар. Алдагы сафка туры килгәнлектән, миңа тирә-як яхшы күренә иде. Ялкау дулкыннар вак таш өелгән ярны юа. Диңгездә бернинди кораб та, көймә дә күренми. Ерактa беленер-беленмәс кенә зур җир күренә. Аның да әле тауларын гына чамаларга мөмкин. Әйтерсең, үзләрен һавага элеп куйганнар. Аякларыбызга басарга боерык бирелде. Вак ташлы ярдан сак астында өскә таба менеп киттек. Озак барырга туры килмәде, юлыбыз нинди дер корылмаларга борылды. Ярга менеп җитүгә, атауның бөтен җире ачылып китте. Сулдан урыны-урыны белән агачлыклар, каралып беткән ташлыклар, ә уң якта, диңгез буенда, озын-озын итеп салынган келәтләр. Шунда пристань да күренә. Янында берничә шхуна да бар. Инде барыбыз да балык комбинатына китергәннәрен сизәбез. Килгәндә тоткыннарның ун елдан артмаган сроклылар гына икәнлеген чамалаган идем.

Лагерьга җиттек. Шактый зур үзе, дүрт почмагында да сыерчык оясы сыман итеп такталардан ясалган каравыл манарасы күренә. Коймалары бер-берсенә терәлеп, җиргә кадалган киртәләрдән гыйбарәт. Мәйдан эчендә берничә барак бар. Вахта янында туктатып, янадан тентергә тотындылар. Аннары гына ишек алдына кертеп, баракларга бүлә башладылар. Мин капка белән каравыл манарасына якын торган баракка эләктем. Эче чиста, икешәр катлы сәндерәләр, яннарына берәр тумбочка да куелган. Салам мендәр белән матраслар күзгә ташланды. Күрәсең, бирегәге тоткыннарны каядыр башка җиргә күчергәннәр. Каршылаучы миңа тиешле ятагымны күрсәтте. Урнашып алгач, ял итеп утырганда, янәшәдәге берәү:

— Безнең бригадага эләктең, балык эшендә булырсың,— диде.

— Әйбәт, балык яратам мин. Төрмә ризыгыннан тәмам гарык булып беткән идем,— дидем.

— Бик шатланма, бу утрауда озак тотмаслар, тагын да ераграк җибәрерләр әле,— дип куйды әлеге тоткын. Озынча буйлы, пеләш башлы, ябык ай йөзле, бераз эчкә баткан зәңгәр күзле ул тоткынның кем икәнлеген тиз таныттылар. Һава суларга ишегалдына чыгуыма, кемдер:

— Сәяси фраер янында чуалма,— дип пышылдады.

Эндәшмәдем. Әйтүче — яшь тоткын. Күп нәрсәләрне аңламый да торгандыр. Аның кем икәнлеген белергә дә теләмим. Ә менә «сәяси фраер» мине кызыксындырды. Үзе белән якыннан танышасым килде. Нинди гаебе өчен монда килеп эләкте икән? Баракка кергәч, ул минем яныма килеп утырды. Танышып алдык. Иректән яңа китерелгән кеше булганлыктан, аның да минем белән аралашасы килгән икән.

— Федор Папин булам. Яшем илледә. Унынчы елымны тутыра алсам, яңадан бишесе кала әле,— дип башлады «сәяси фраер» үзе турында. Сүзләрен уйлап кына әйтә, минем кем, кайдан икәнлегемне белгәч: «Язмышларыбыз бер икән, 58 нче статья бик тә әшәке. Башта миңа унны

гына чәпәгәннәр иде. Сугыш беткәч, протест хаты язган идем, яңадан бишне өстәделәр. Бусы инде лагерьда булды. Сиңа, Алланың рәхмәте беләндер инде, бишне генә биргәннәр. 1937—38 елларда безгә бирелгән статья бик модада булды. Йә аттылар, йә унны бирделәр.

Папин бераз сөйләгәч, хәлемне аңлады булса кирәк, игътибар белән йөземә карап торды да: — Шактый суырылгансың. Сизеп торам, җелегеңне шәп имгәннәр. Сиңа тизрәк сәламәтлегеңне ныгытырга кирәк. Сыйлыйм әле үзеңне, миндә балык мае җитәрлек. Югыйсә, бу кыяфәтең белән носилка да күтәрә алмассың,—дип, каядыр китеп барды.

Яратам да соң шундый ачык, киң күңелле кешеләрне. Андыйлар минем тормышымда күп очрады.

Федор Папин кышын лагерь мастерскоенда тегүче булып эшләгән. Шундагы танышыннан миңа бер шешә балык мае китереп бирде:

— Чамалап кына эч, күп кулланырга ярамый,— диде.

Бу кичне күп нәрсәләр турында аңлаштык без аның белән. Акыллы, тормыш тәҗрибәсе зур булган кешене тыңлау мине чиксез куандырды. Яшәргә теләү өмете тагын да ныгый барды, көч-куәт бирде. Әмма Папин кебек унар, унбишәр ел азатлык көтеп ятарга сабырлыгым һич тә җитмәс. Картаеп беткәч, нигә кирәк ул миңа тормыш!

... Йокыдан иртәнге сәгать биштә уяттылар. Монда корабтагы кебек кабалану юк. Тирәмдәгеләр ашыкмыча гына киенделәр. Мин дә алар эшләгәнне кабатлыйм. Юынырга барам. Аннары паегымны алып, чәй эчәргә утырам. Кичә яңа килгәннәргә дә эшкә чыгарга дигәннәр иде. Шуны хәтерләп, барагыма кайтуым булды, яныма Федор Папин килеп басты.

— Эшкә чыгасыңмы?

— Кешедән калып булмас инде.

Яңа танышым белән бер-ике сүз алышырга өлгермәдек, баракка зур гәүдәле, кызылсу йөзле, җәенке борынлы кеше килеп керде.

— Лагерь коменданты,— диде миңа Папин.

Керүче эре-эре атлап, озын баракның уртасына җитеп туктады. Башта бер сүз дә әйтмичә, буш ятакларга күз йөртеп алды. Тоткыннар берәмберәм кайтып беттеләр. Аннары ул:

— Бүген яңа килгәннәр дә эшкә бара! Кем чыкмый, үзенә үпкәләсен! — дип боерды да чыгып китте. Лагерь капкасы төбендә тезеп санаганнан соң, капкадан чыгара башладылар.

Көн болытлы. Һава үтә дымлы иде. Якында гына диңгез шаулаганы ишетелә. Корабтагы тормышым исемә төшә. Йөрәгем әрни. Ә монда мескенлеккә төшкәннәр боегып кына кузгалу боерыгын көтә.

Сак начальнигының:

— Адым сулга, адым уңга — качу дип санала! — дигән тавышы яңгырады. Сакчылар, мылтыкларын әзер тотып, үз урыннарына килеп бастылар. Бишәр-бишәр булып тезелгән тоткыннар түбәнгә — диңгез ягына таба атлый башлады.

Диңгездә тәгәрәгән дулкыннарны мин инде аермачык күрәм. Күңелемдә бары бер генә уй — әнә шул шадра дулкыннар кочагына кереп югаласы, барлык газаплардан, борчулардан мәңгегә котыласы килә...

Без ташлы юлдан балык комбинатына барабыз. Күптәннән инде сафта атлаганым юк иде. Атлыйм, ә күңелем әллә кайларда. Янәсе, яшь диңгезчеләр бүген походка чыкканбыз...

Тиз килеп җиттек. Бригадирлар наряд алу өчен якындагы таш йортка кереп киттеләр. Сакчылар да читкәрәк китеп тәмәке көйрәтә башладылар.

Көтәбез. Бригадирлар чыгып, яныбызга килделәр дә эш бирә башладылар.

— Икегезне сейнердан балык ташырга билгелим,— диде Папин белән миңа безнең бригадир.

— Сине үзем белән бергә эшләргә сорадым,— дип куйды Папин миңа.

Аның бу сүзләре мине куандырды. Күңелгә хуш килгән кеше белән эшләү әйбәт булыр. Бригадир күрсәткән җирдән носилка алып, калын такталардан тезеп эшләнгән озын пирска бардык. Анда терәлер-терәлмәс биш сейнер тора. Аларга да трап салынган. Үзебезгә күрсәтелгәненә күтәрелдек. Бездән алдарак киткәннәр озын саплы көрәкләр белән носилкага балык тутырдылар. Арттан башка парлар да килде.

— Әнә, күрәсеңме теге корылманы? Шунда илтәбез. Анда чаннар бар. Бушатабыз да кабат киләбез,— дип Папин носилканың алдына чүкте.

Кояш күренмәсә дә, диңгез буендагы томан инде шактый таралган иде. Сейнерларның барысы да аермачык булып күренә. Алар приска калын сүс арканнар белән тарттырып беркетелгән. Үзенә күрә балык причалы икән бу. Балык сөзүчеләр — иректәге кешеләр, сезонлы эшкә килүчеләр. Без бушатырга билгеләнгән сейнерның капитаны базык гәүдәле, башында чак-чак кына эленеп торган фуражкасы читләреннән тузгып чыгып торган кап-кара чәчле, зур коңгырт күзле, түгәрәк йөзле, күп булса утыз-утыз биш яшьләр чамасындагы кеше иде. Безнең шикелле тоткыннарны күп күргәндер ул. Ашыкмыйча гына эшләгәнебезне карап тора. Бераз шадра йөзендә кырыслык сизелә. Нишләптер бу капитанны крейсерда үземне кулга алган кешегә охшаттым. Энесе түгел микән, дип уйлап куйдым. Өченче тапкыр сейнерга килүебездә кыяр-кыймас кына:

— Сезнең абыегыз хәрби моряк түгелме, дәрәҗәле эштәме?— дип сорадым.

— Тоткыннар белән сөйләшү безгә катгый тыела,—дип ул каютасына кереп китте.

— Аның белән сөйләшкәнеңне сакчы күрсә... Кара аны, сак була күр,— дип Папин миңа иптәшләрчә кисәтү ясады.

Иректәгеләр белән дә сөйләшүдән мәхрүм ителүебезгә йөрәгем әрнеде.

Эшебез башта җиңел тоелса да, чанга бишенче мәртәбә балык белән тулы носилкабызны илткәндә кулларымның бик нык талчыкканын, гәүдәмнең авырайганын тойдым. Папин да моны тиз сизде.

— Морячок, кабаланма. Носилканы менә болайрак, төптәнрәк тот. Ычкындырып җибәрсәң, бригадирдан эләгүе бар,—диде.

Эш кайнап тора монда. Берәүләре балык ташый, икенчеләре аларны сортларга бүлеп, чаннарга тутыра. Күптән эшләүчеләргә кызыгып карыйм. Алар чаннардан селедкаларны сөзгечләр белән чыгарып, агач кисмәкләргә тутыралар. Балык тозлаучылар — иректәгеләр икән. Тозлык ясап, күпмедер вакыт чаннарда тоталар, аннары гына агач кисмәкләргә тезәләр.

Күк болытлардан тәмам ачылды. Җил караңгы болыт өерләрен куып бетерде. Кояш кыздырып җибәрде. Тирләп-пешеп беттем. Шулай да арыганлыгымны тәҗрибәле Папинга сиздермәскә, аңардан калышмаска тырышып эшләдем.

Сейнерларны бушатып та бетердек. Төш җиткәндә бригадирлар сак начальнигыннан учак ягып балык пешерергә рөхсәт алдылар. Озакламый, якын-тирәдән чыбык-чабык җыеп, берничә урында учак кабызып җибәрделәр. Зур гына буш консерв банкаларына балык тутырып, пешерергә дә куйдылар.

— Мин дә пешеримме?— дип сорадым Папиннан.

— Әлбәттә, күп итеп пешер. Кышка кадәр сәламәтлегеңне ныгытып кал. Аннары кая күчерәсе907ләре билгесез. Бер сезоннан артык тотмыйлар монда.

Үзебез ташыган корылмага кереп, чаннан симез эре балыклар сайлап, юып, өч литрлы банкага тутырдым да учакка куйдым.

— Җитез икәнсең үзең,— диде Папин.
— Тамак йөгертә ул,— дидем мин елмаеп.
Диңгезгә карап, яңа танышым белән дөнья хәлләрен сөйләшә-сөйләшә, якындагы ташта утырабыз. Ул һаман миннән иректәге тормышым турында сораштыра. Иректән мәхрүм ителүемә өч айдан артык вакыт үтеп киткән бит инде. Бу дәвер эчендә нинди генә үзгәрешләр булмагандыр. Әмма Папин өчен алары да яңа, чөнки күптәннән тоткынлыкта.
Тоткыннар учак янына җыела башладылар. Папин янында утыра бирәм. Банкада балыкларымның пешкәнен көтәм.
Озакламый балык пешеп тә өлгерде. Ашарга керештем.
Кичкә кадәр эшләдек. Яңадан сейнерлар килде, аларын да бушатып бетердек. Эшләр тәмамлангач, сафка бишәр-бишәр тезеп, сакчылар безне лагерьга алып киттеләр.

* * *

Көннәр моңсу, салмак кына үтә тора. Сөенерлек, тынычланырлык вакыйгалар юк.
Шулай беркөнне эштән кайткач, баракка комендант килеп керде. Кемнедер эзли иде булса кирәк. Һәрбер сәндерә янына килеп, нәрсәдер сораштыра. Федор Папин белән ятагымда утырып гәп кора идек. Менә ул безнең янга да килеп җитте.
— Фамилияң?
— Бадыйкшанов!
— Монда икәнсең. Сине эзлим. Әйдә, «кода» чакыра.
Лагерь оперуполномочыен «кода» дип атыйлар икән. Комендант артыннан иярдем.
Папин:
— Нәрсә булса да синең өчен бер яңалык бар,— дип, ишеккә хәтле озатып калды. Капка янындагы таш йортка кердек.
— Менә, сез сораган тоткын шушы,— диде комендант.
— Барыгыз, ул калсын,— дип, «кода» комендантны чыгарып җибәрде. Нәрсә өчен чакырды икән дип, сабырсызланып көтә башладым.
— Жалоба язган идегезме?
— Әйе. Хөкем карарын кабат тикшерүләрен сорап язган идем.
— Җавап килде. Мәгез, укып чыгыгыз. Аннары кулыгызны куярсыз.
Килгән җавапка болай дип язылган иде:

**«Бадыйкшанов Л. Ә.га**
**Язган шикаятегез буенча баш хәрби прокуратура тарафыннан 1947 елда сезне хөкем итүнең нигезлелеге тикшерелгәнне хәбәр итәм.**
**Тикшерү, 1947 елда Советка каршы агитация алып барганыгыз өчен, сезне хаклы хөкем итүләрен һәм бу эш буенча хөкем карарына ризасызлык белдерүнең нигезсез булуын ачыклады.**
**Төп хәрби җинаятьләр бүлеге хәрби прокуроры, юстиция полковнигы — Ярчевский».**

Кат-кат укыдым. Башта зиһенемне җыя алмый тордым.
— Аңлашылдымы?
— Һич тә юк!
— Имзагызны куегыз!
Уйланып торырга вакыт юк иде. Күтәрелеп карадым да, «кода»ның миңа текәлеп торганын күреп, нәрсә булса да әйтмәкче идем, өлгерә алмый калдым. Ул:
— Монда аңлашылмаган нәрсә юк. Барысы да ачык итеп язылган. Ярый әле әз биргәннәр,— дип әйтеп куйды.

Тешемне кысып булса да эндәшмәдем. Өстәлендә яткан ручкасын сорап та тормастан, тиз генә: «Җавап белән килешмим, мин гаепсез»,— дип яздым да, юстиция полковнигы имзасы янына кулымны куеп, бер сүз дә әйтмәстән бүлмәдән чыгып киттем.

Баракка кайтышлый күзем яшьләнде, тамагыма ачы төер утырды. Тикшергән булсалар, мондый җавап җибәрмәгән булырлар иде. Тикшермәгәннәр аны. Мондый җавапларны бик күп тоткыннар алды инде. Әллә югары партия органнарына үзем барып сөйләп бирим микән? Алар хәлемне аңламый калмаслар.

Шулчак башыма кыю уй килде: качарга кирәк! Кирәкле урынга үзем барып сөйләргә? Шунда гына җанымны тынычландыра алырмын мин. Приморье крайкомында әйбәт кешеләр эшли. Беренче секретарен да күргәнем бар. Ул Үзәк Комитет члены. Мине, әлбәттә, тыңлар...

Партиядән чыгарылмаган килеш кулга алындым бит мин. Бу — законсызлык. Чын дошманнар эшедер...

Федор Папинга ни өчен «кода» янына чакырылуымны әйттем. Аның бер дә исе китмәде.

— Югарыдан игелек көтмә син. Сәяси статья белән, срогыңны тутырмыйча торып, иреккә чыгу турында уйлама да.

Өлкән кешене тыңласам да, күңелемне тынычландыра алмыйм. Тылсымлы әкият сыман ирек мине үзенә тартты...

Һәркөн балык комбинатына эшкә йөрибез. Инде мин беренче килгән көннәрдәге кебек көчсез, ябык тоткын түгел. Көн дә төш вакытында пешереп ашаган балыкларның файдасын сизәм. Папинга иректәге тормышымнан кайбер кызыклы хәлләр сөйлим. Ул рәхәтләнеп тыңлый, кайчакта башын селкетеп:

— Булган егет икәнсең,— дип куя.

— Юк, күрә белмәгәнмен,— кешеләргә ышанып яшәгәнмен. Ә алар миңа тозак корганнар.

— Борчылма. Барысы да үтәр. Срогың әллә ни күп түгел.

— Күп булмаган кая! Әле дүрт елдан артык җәфа чигеп яшисем бар! Ирек — ирек инде ул. Кеше, лачын кебек, үз ихтыярында яшәгәндә генә дөньяның рәхәтен таба. Менә мин яшьлегемнең иң матур елларын тоткынлыкта үткәрәм. Ә ни өчен диярсең?

— Бераз гына беләм инде. Җае белән сөйләп бетерерсең әле...

Папин лагерь тормышының ачысын-төчесен күп татыган. Тегүче һөнәре үзләштергән. Еш кына шул һөнәре аркасында авыр эшләрдән алып калганнар. Комендантларга, наряд бирүчеләргә киемнәр теккән. Шунлыктан үзен бүгенге көнгә хәтле саклап килә алган. Папин минем ни уйлаганымны белми әле. Ә миндә хәзер бер генә уй — качу! Әллә аңа бу хакта әйтмим микән? Хупларлмы? Ярамый диярме? Юк, әйтмим. Үз-үземә ант бирдем. Иң кадерле серләремне башка беркемгә дә әйтмәячәкмен. Нинди генә яхшы кеше булса да! Миңа тоткын булуымны онытырга һич тә ярамый...

Качу уе көннән-көн көчәя бара, җанга тынычлык бирми башлады. Еш кына яр буендагы бүрәнәләр өеменә карыйм да күңелемнән башка тоткыннар кебек бишәр, унар ел үкчә астында изелеп яшәргә көчем дә җитмәс, түзә дә алмам, дип уйлыйм. Мине йөрәгем гафу итмәс. Иң мөһиме — моннан тизрәк ычкыну. Аннары күз күрер...

Федор Папин һаман саен: «Син әле беркатлы, сәясәтне аңламыйсың. Дөньядагы үзгәрешләр шундый тиз бара, еракларак карый белергә вакыт инде сиңа»,— ди.

Анысы шулайдыр да. Әмма нигә һаман коммунистларны сүгә ул? Минем бит бөтен өметем аларда — югары партия органнарында. Качарга теләвемнең сәбәбе дә шул бит. Ә ул...

Бу хакта сүз чыкканда:

— Син өлкән кеше. Партиягә тел тидермә. Ниндидер кара көчләр бар. Безне шулар тинтерәтә. Иртәме, соңмы бу фаш ителәчәк,— дим. Ә ул

минем белән килешми, җүләрлегең кайчан бетәр икән, дип куя. Юк инде, безнең монда эләгүебезгә халыклар атасы Сталинның нинди гаебе булсын? Әгәр ул безнең нахакка утыруыбызны белсәме!..

Папинны гаепсезгә утыртканнар икән — моңа бит партиянең катнашы юк. Мине дә түбән җанлы бәндәләр, өстемнән донос язып, шушы хәлгә төшерделәр. Беркатлы, тиз ышанучан булмасам, бу көнгә калыр идемме?

Көннәр бозылып китте. Көньяктан килгән кара болытлар өч тәүлек буена һавада эленеп торды. Көне-төне җылы яңгыр яуды. Әмма эшкә алып баруларын барыбер туктатмадылар. Чыланып бетсәк тә эшләдек. Тоткыннар сүгенә, көне буена барлык аллаларны яман сүзләр белән каһәрлиләр. Күпләр йөткерә, төчкерә башлады. Сейнерлар пристаньга килеп кенә тора. Бушатып кына өлгер, тамагыбыз тук булсын дип, һаман эшләгән булабыз. Эшкә шуның өчен генә барасың. Таш утрауда тәндә җылы саклау өчен шактый энергия кирәк. Әмма шунысы әйбәт: балыкны күпме пешерсәң дә, сүз әйтүче юк. Төш вакыты җиттеме, үземә балык сайлап алырга чабам. Тик ипи генә юк. Аны иртән баракта гына бирәләр. Теләсәң бер утырып аша яки кичке ашка калдыр...

Өс киемнәребез кипми, һәр иртәне чирканып кына киенәбез. Эх, кайчан булса да юрганга төренеп, җылынып ятар көннәрем булыр микән?

Иләмсез кара болытлар бүген дә күкне томалап тордылар. Яңгыр дигәне кичкә табан тагын да шәбрәк коярга тотынды. Баракка кайткач, кичке ашны чөмереп алдым да ятагыма аудым.

Яныма Папин килде.

— Арыдыңмы?

— Азрак кына булгандыр инде.

— Әле генә тыштан кердем. Дөнья кап-караңгы, күзгә төртсәң дә күрерлек түгел. Ул коя яңгыр! Ишек алдында шарламыклар котырынып ага,— диде ул.

Сөйләшәсе сөйләшенгән, аның тормыштан зарлануыннан туеп беткәнлектән, эндәшмәдем. Өс киемемне салып, йокларга җыендым. Ә ул һаман янымда басып тора. Өлкән кеше бит, куып җибәреп булмый. Нәрсәдер әйтәсе киләме соң инде? Килмәгәе, үлеп йокы басты әле монда.

— Ярый алайса, ял ит. Миңа да вакыт җиткәндер,— дип, ул китеп барды.

Тыңлап ятам. Такта барак стенасы аша тышта яңгырның коеп яуганы аермачык ишетелә. Башымда бер уй — качу.

Нишләргә? Моннан ничек котылырга? Ирек биредән әллә ни ерак түгелдер бәлки?

Тоткыннар инде тирән йокыга талганнар. Аларның гырлап йоклаганнарын ишетәм. Кинәт үзем дә сизмәстән торып утырдым. Өс киемемне киендем дә чыгып киттем. Яңгыр коя гына. Күзгә бернәрсә күренми. Гөрләвекләр акканы ишетелә. Вышка беленер-беленмәс кенә күренә. Сакчы мондый вакытта винтовкасын кочаклап, тыныч кына йокымсырый булыр. Кемнең дә качып китүен, әлбәттә, башына да китермидер. Төн караңгы. Әллә тәвәккәлләргәме? Менә, уйларым, күңелемне тарсынып, гөрләвеккә кушылдылар. Әнә, алар инде, лагерь коймасын үтеп, иреккә чыктылар! Иреккә әйдәгән акылдан шаштырырлык уйларыма буйсынмыйча булдыра алмадым! Тәвәккәлләдем! Берничә адым пычрак ерып атладым да, тулып аккан гөрләвеккә капланып, бака сыман алга үрмәләдем. Су елганы шактый тирән ашаган икән. Сакчы вышкасына җитәрәк ул тагын да киңәйгән. Өскә карап алдым. Тып-тын, бары тик яңгырның коеп яуганы гына ишетелә. Яңадан үрмәләргә тотындым. Зонаның теге ягына чыгып җиткәнлегемне артыма борылып карагач кына сиздем. Якында гына диңгез дулкыннары шавы колагыма килеп бәрелде. Авырлык белән генә торып бастым. Лагерь вышкасы карачкы сыман арттан карап калды. Ә алда — диңгез! Якын ул, кул гына сузасы.

Ярга таба киттем. Теге бүрәнәләр өеменә тизрәк барып җитәсем килә. Беләм, ул җир әллә ни ерак булмаска тиеш. Караңгылык, дөрес, юл алырга комачаулый комачаулавын. Шулай да ярдан түбән төшә башладым. Төшә торгач, нәрсәгәдер килеп бәрелдем. Әһә, менә алар! Әйе, бүрәнәләр өеме. Уйланып торырга вакыт юк, тизрәк эшкә керешергә кирәк. Диңгезгә карап алдым. Әнә ул, кара кучкылланып мине көтә. «Тизрәк, тизрәк, Локман, мин сине коткарам!» — ди сыман. Барлык көчемне җыеп, җилкәм белән өстәге бүрәнәне этә башладым. Башта кузгалырга теләмәде. Шулай да, селкетә торгач, кузгалган кебек булды. Яңгыр ишә генә. Юк, көчем җитми. Бүрәнә селкенми. Нишләргә?! Өем өстенә менеп, җиңелрәк бүрәнә эзләргә керештем. Әһә, менә, кыска гына күсәк кисәге. Бүрәнә каерырга ярый бу. Бүрәнә арасындагы бушлыкка күсәкне китереп тыктым. Хәзер инде каерасы гына. Бөтен көчем белән күсәккә асылындым. Кинәт бүрәнә күтәрелеп, шуып китте. Миңа шул гына кирәк иде. Җилкәм белән аның күтәрелгән ягын аска, диңгез ягына эттем. Бүрәнә урыныннан кузгалып, гөрселдәп түбәнгә тәгәрәде. Мин аның лач итеп диңгезгә килеп төшкәнен генә ишеттем. Сөенечемнән үземә дә рәхәт булды. Беренче җиңүем бит! Йөзеп китмәсен дип, артыннан ук суга сикердем. Ниһаять, бүрәнәмне барып кочакладым. Әйтерсең ул — ирекнең үзе иде. Бүрәнәнең бер башын суга турыларга керештем. Үч иткәндәй, тәгәрәп килгән дулкыннар бүрәнәне һаман комга териләр. Мин усалланып, аның борылган башын кабат диңгезгә турылап куям да, урта бер җиренә атланып, учларым белән тиз-тиз ишәргә керешәм. Газаплана торгач, диңгезгә кереп киттем. Көчем җитми, хәлем юк, әмма ишми чарам юк. Бер дулкынны кисеп үтәргә өлгермим, икенчесе килеп бүрәнәмне ярга бора. Инде тәмам өметемне өзеп, бүрәнәдән төштем. Бәхетем юктыр инде, югыйсә ирек диңгездә елмаеп ята бит. Теләгемә ирешә алмаудан өзгәләнеп, ярга чыктым. Нишләргә? Таң атканчы кайтмасам, иртәгесен лагерьда тревога күтәреләчәк. Яңгыр да туктарга җыенмый. Тагын диңгезгә карыйм. Якында гына мин тәгәрәтеп төшергән бүрәнә тирбәлеп тора... Өметемне җуеп, килгән юлым белән лагерьга таба атладым.

Салкында куырылып йоклап ятканда кемдер төртеп уятты. Барактагылар барысы да аякта иде. Күземне ачуга янымда теге үзем белән тәпәләшкән Иванны күрдем.

— Төнлә чыгып киткәнеңне дә, кайтып кергәнеңне дә күрдем. Кыю егет икәнсең. Курыкма, берәүгә дә әйтмәм, эшкә баргач сөйләшербез әле,— ди бу миңа.

Эндәшмәдем. Игътибарсыз гына карап алдым да торып утырдым. Тәнемдә тельняшкам юеш иде әле. Төнге маҗараларым куркынычлы авыр төш кебек күңелне бимазалый. Барак исе күкрәгемне кыса. Аяк-кулларыма гер такканнар мыни, шундый авырайганмын, аягыма баскач авып китә яздым. Иртәнге чәйгә теләр-теләмәс кенә бардым. Эшкә барасы килми, үлеп йоклыйсым килә. Бернишләр хәл юк, барыбер барырга кирәк...

Көн һаман болытлы, яңгыр гына туктаган. Болыт өзелгән җирләрдә зәңгәр күк күренгәләп ала. Их, зәңгәр күк! Янында сакчылар торгач, биеклегеңнән, чиксез киңлегеңнән миңа ни файда! Әллә соң бу болытлар, Шаулап яуган яңгыр һәм иксез-чиксез күк... үзләре дә кол микән?

Эшчеләр колоннасы тезелеп беткәч, безне вахтаның теге ягына чыгара башладылар. Бүген дә эш кайнап торды. Беркем дә дәшми. Башларны аска иеп, эшләвебезне беләбез. Аякларымны көчкә-көчкә генә сөйрим, ләкин сынатасы килми. Федор Папин төш вакыты җиткәч:

— Утырып тор, балыкны синең өчен дә пешерермен,— диде. Белмәсә дә, минем белән бер-бер хәл булганын сизенгән ул.

Папин янымнан киткәч, күп тә үтмәде, каршыма теге угры Иван килеп басты. Башта як-ягына каранып алды, аннары якын тирәдә кеше фәлән юклыгына ышангач:

— Төнге сәяхәтеңне башыннан ахырынача белеп тордым. Моннан тиз генә ычкынырмын дип уйлама, башта әзерләнергә кирәк, ничек булса да көймә белеш. Шуннан соң гына материк ягына сыптырырга булыр. Мин дә җайлы вакыт көтеп йөрим. Шикләнмә миннән, бергә сызарбыз...

Аның йөзе җитди, күзләре ут булып яна. Папин килгәнче ул миңа лагерьлардан берничә мәртәбә ычкынганын сөйләп алды. Икешәр-өчәр ел ирektә йөргән икән. Барыбер эләктергәннәр үзен. Башта эндәшми тордым, аннары бераз уйлангач, күңелемнән аның белән килешкән кебек булдым. Икәүләп качу җиңелрәк булыр дигән нәтиҗәгә килеп:

— Карап карарбыз,— дидем. Теге вакыттагы үзе белән бәрелешеп алуны искә дә алмады. Шулай да «Кем үткәнне искә төшерә — аның күзе атылып чыксын», дип куйды. Бу аның «үткән-беткән» дигән сүзе иде булса кирәк.

Папин балыклар алып килүгә, угры Иван китеп барды. Учак көйрәтеп өлгергәннәр иде инде. Икебез дә чистартылып тутырылган балыкларыбызны шунда куйдык. Беркадәр читкәрәк китеп ташлар өстенә утырдык.

Эш сәгате беткәнен бик авырлык белән генә көтеп алдым. Кайтканда лагерь алдындагы әлләни ерак булмаган җирдә, диңгез яры өстендәге бүрәнәләр өеменә күз төшердем. Һаман урынында торалар. Бары тик берсе, мине тыңламаганы гына, суда чайкала.

Баракка кайткач, лагерьга берничә врач килүе турында ишеттек. Иртәгә комиссия булачак икән. Көчле, таза кешеләрне каядыр озатчаклар. Моңарчы бер дә күренмәгән хәрби начальникларның лагерь конторасы урнашкан ике катлы таш йорт тирәсендә тыз-быз йөргәләп торуларын күргәч, бу хәбәргә үзебез дә ышандык.

Икенче көнне йөзгә якын кешене эшкә җибәрмәделәр. Алар арасында мин дә, угры Иван да, тегүче Папин да бар. Танышлар булгач, күңелем пошынмады, бераз тынычландым. Ник шунда җәһәннәмгә озатмыйлар! Тик зур җиргә алып кына чыксыннар. Бөтен теләгем шул. Югыйсә, бу шыксыз утраудан тиз генә ычкынырлык түгел. Комиссиядән тиз үттем. Караган врачлар:

— Мондый егетләр күбрәк булсын иде әле,— диделәр.

Ике көн үтүгә, без алтмышлап тоткын, иртә белән вахта капкасы янына тезелдек. Барлап, кабат тентү үткәрелгәннән соң, конвоирлар сагы астында балык комбинатына төшә торган юлдан диңгез буена таба юнәлдек. Күренеп тора — якорьда безне буксир пароходы көтә. Аның янында шактый зур баржа да бар. Диңгез өсте тыныч, яңгырдан соң һава ачылып китте. Көндезләрен җил булса да, кичкә тынлык урнаша. Еракта, беленер-беленмәс кенә, материк ярлары күгелҗемләнеп күренә. Нишләптер бер генә кораб та, җилкәнле көймә дә күренми.

Ярга төшеп җиттек. Буксирдан берничә хәрби кеше төшеп безне китергән конвоирлар белән сүз алыша башладылар. Өлкән чинлысы кулындагы папкасын ачып безне барларга кереште. Исемнәре чыккан һәрберебезне баржага менәргә кушып тордылар.

Кыска вакыт эчендә озын тимер баржаның трюмына төшеп урнашып та беттек. Яктылык бары тик люктан гына төшә. Кая карама, ватык балык кисмәкләре аунап ята. Чистартмаганнар да ичмасам. Бу баржаның балык комбинатыннан материкка тозланган продукцияне җиткерү өчен кулланганлыгын шундук аңладым. Авыр ис аңкып тора, күңелне болгата. Люктан әлләни ерак түгел урынга барып урнаштым. Папин да янәшәмдә генә икән. Ул миңа:

— Менә шулай унынчы елымны сәяхәт итәм инде комфортабельный каюталарда,— диде.

— Минем дә гомер шулай үтәр микәнни?

— Кая китәрсең, башта авыр булыр, күнегерсең...

Баржа корпусына дулкыннар бәрелгәне ишетелә. Кая таба кузгалганбыз? Моны беркем дә белми. Ирекtән мәхрүм ителгән кешенең язмышы

әнә шундый билгесезлеккә юлдаш. Йә ул көннәрдән бер көнне котыла, йә һәлакәткә очрап тормышын чикли. Аның каберенең кайда икәнен туганнары да, гомере буе аралашкан дуслары да һичкайчан белмәс...

Шулай дөньядан ваз кичеп ятканда, янымa Иван килеп:

— Теге әйберләрне булдырдым, менә алар. Мә, үзеңә дигәнен алып яшер, ычкынырга туры килсә, ярап куяр,— диде.

Нинди әйберләр икән дип уйларга өлгермәдем, Иван кулыма озын гына сапсыз пычак тоттырды. Ничек алып керә алган ул мондый пычакларны? Артык сораулар биреп булмый иде, тиз генә ыштан бавына кыстырып куярга туры килде. Угрылар телендә пычак — «перо» икән.

Иван:

— Нык сакла, перо миңа бик авырлык белән эләкте,— дип, янымнан китеп тә барды.

Яшерүен яшердем, ләкин үземә тынычлык таба алмый башладым. Никадәр генә онытырга теләсәм дә, авыр йөк булып йөрәгемне тырнап торды. Юл буе баржада буталып йөрдем. Ахыр чиктә Иванның «бүләген» баржаның караңгы бер җирендәге ватылып-аунап яткан балык кисмәкләре янына яшереп куйдым.

Кая карама, кәрт сугалар. Үзем уенга кысылмасам да, Иванның «иҗатын» кызыксынып күзәтәм. Аның кулындагы ясалма кәртләр шундый тиз йөриләр ки, исем китте хәтта. Ярга килеп җиткәнче, аның алдына фуфайка, бүрек, аяк киемнәре тау булып өелде. Уйнаучыларның һәммәсен отты ул. Баржа комга терәлгәндәй, чайкалып китте. Күпләребез авып, егылып та алды. Әһә, ниһаять, килеп җиткәнбез икән. Бик озак чыгармый тордылар. Селедка белән икмәк ашаганыбызга байтак вакыт үткәнлектән, бик тә су эчәсебез килә. Баржага бәрелгән дулкыннарның тавышы һәммәбезнең дә эчен пошыра. Беләбез — тозлы дулкыннар алар. Барыбер эчәр идек әле.

Караңгы төшә башлагач кына өстән:

— Әзерләнегез! — дигән тавыш яңгырады.

Әзерләнәсе юк, безнең бөтен байлыгыбыз — өстебездәге киемнәр. Иван кәрттә отып алган «байлыкларының» яхшыракларын миңа сузды. Мин баш тарттым. Аннары ошаганракларын үзе киеп алды да, калганнарын хуҗаларына ыргытты.

Чыгып тезелдек. Исемлек белән барлап чыктылар да, бишәр-бишәр тезеп кузгалырга боердылар. Яннарында бозау хәтле этләр.

Диңгез ярына күтәрелеп, уйсулыкка урнашкан ниндидер поселокка табан юл тоттык. Култык дугасыман уелып эчкә кергән. Ярдан күтәрелүгә тайга башланып китә. Уссури тайгасы шушыдыр инде. Барган шәпкә сөйләшкәләп карадык. Берәүнең дә бу тирәләрдә булганы юк икән. Ниндидер борылманы үтүгә, берәр картлы йортлардан торган поселок урамына килеп кердек. Безгә игътибар итүче дә, карап калучы да күренми. Читтәрәк вак куаклыклар күренә. «Менә кая качарга була икән»,— дип уйлап алдым. Качып кына кара, шундук этләр теткәләп ташлаячаклар, аягыңа да баса алмассың... Бара торгач, чәнечкеле тимерчыбыклар белән кат-кат тарттырылган корылмалар күренә башлады.

Менә син нинди икәнсең, яңа йорт! Аның капкасына китереп җиткермәстән туктаттылар да җиргә утырырга боердылар. Капканың бер ягында таш йорт. Үзе әлләни зур түгел. Озакламый аннан хәрби киемдәге кешеләр килеп чыктылар. Аларның берсенә (өлкән чинлысына), безне озатып килгән өлкән сержант «дело»ларыбызны тапшырды. Күп тә үтмәде, шыгырдап капка ачылды. Лагерь эчендә тәбәнәк, озын бараклар күренде. Утлары ялтырый. Ә вахта янындагы озын баганада прожектор яна. Җиргә төшкән энәне дә күрерлек.

Безне утырган җиребездән берәмләп торгызып, тентеп зонага кертә башладылар. Ярый әле, Иван биргән пычагымны баржада калдырдым. Югыйсә кабуым бик тә ихтимал иде. Барак янында лагерь коменданты каршы алып тора. Кайсы баракка барасыңны үзе күрсәтә:

Ниһаять, миңа да чират җитте. Башта капшадылар. Аннары аяк киемемне салдырып селкергә куштылар. Ботинкам ышнурсыз булганлыктан, аларны аягымнан бик тиз шудырдым. Аннары тиз генә киеп, капкага киттем. Комендант миңа да «юл» күрсәтте.

Барак җир идәнле, ике яклап икешәр катлы сәндерәләр тезелгән. Түшәм уртасындагы тимер чыбыктан үреп эшләнгән калпак эчендә тонык кына булып электр лампасы яна. Ишек янындагы сәндерә янына барып үземә урын алырга теләдем. Алгарак үтеп, ятагында утыручы берәүдән белештем: урыннар барысы да буш икән. Килеп туктаган сәндерәм беренче катта булып, аның матрасы, мендәре, иске генә булса да солдат одеялы бар иде. Янәшәсендә тумбочкасы да бар икән. Ятагымның матрас-мендәре кипкән үлән белән тутырылган, капшап карауга, «сөйләшергә» керештеләр.

Янәшәмә Папинга да урын алып калган идем, килеп керүгә ул куанычыннан көлеп җибәрде. Бераздан безне ашханәгә алып киттеләр.

«Тафуин» атлы хезмәт белән төзәтү лагерына килгәнлегебезне белдек. Монда таш чыгаралар. Аксак-туксак һәм авыруларны санамаганда, һәр көнне өчәр йөзгә якын зэк диңгез култыгының аргы ягына таш карьерасына эшкә йөри. Элегрәк монда япон әсирләре яшәгән булган. Баракларны да, вахтаның теге ягындагы таш йортларны да алар салып калдырган. Моннан бер генә ел элек үзләрен каядыр башка җиргә күчергәннәр икән.

Диңгезче, балыкчы, менә хәзер ташчы да булырга туры килә миңа. Тагы кем генә булырмын да,ниләр генә күрермен икән? Күрәселәремне Аллаһе Тәгалә бары тик үзе генә белә булыр.

Йоклар алдыннан яныма Иван килде. Аның авызы ерылган.

— Каптыра яздылар үземне, перомны чак кына сизмәделәр. Күрәм, син дә эләкмәдең. Болай булгач, без озакламабыз, тәвәккәлләрбез...

Иванга пычагымның юклыгын әйтмәдем.

— Көчебез бар чакта ычкыну ягын карыйк. Кешеләрнең йөзләре ничек көл төсенә кергән, җелекләрен суырганга шулай ул,— дип куйдым мин дә үз нәүбәтемдә.

— Ашыкмыйк әле, сабыр иткән морадына җиткән,— диде Иван минем сүзләремә җавап итеп. Тик мин аның белән сөйләшүнең мәгънәсен тапмыйм. Ни әйтсәң дә угры ул. Юлларыбыз аерыла. Яшьли караклыкка күңелен биреп, хәвефсез тормыштан мәхрүм ителгән мескен бәндә белән юлдаш буласым килми минем. Бергә ычкына-нитә калсак, авыр юлларны үткәндә җиңелрәк булыр дип кенә аралаша башлаган идем.

Аның белән хәтсез вакыт юк-бар нәрсә турында гәп корып утырганнан соң (үзе дә туйды булса кирәк), янымнан китеп барды.

— Нигә аның белән вакытыңны әрәм итәсең,— дип янәшә сәндерәдә яткан Папин сүзгә килде. Мин аны йоклый дип уйлаган идем. Ә ул тыңлап яткан икән. Аңлаганмы-юкмы — белмим. Белсә дә беркемгә дә ычкындырмас.

— Бу лагерьда кәнтәйләр өстенлек итәләр икән. Үзләре эш сөймәсәләр дә, мужик өстеннән җитәкчелек итә беләләр алар. Менә күр дә тор, эштә беренче ялкаулар шулар булыр, син алар өчен эшләрсең, эшләмәсәләр дә икмәкне синнән ким алмаслар, син миннән аерылма,— дип куйды.

Серле «Тафуин»нан Уссури тайгасы башланып китте. Икенче көнне үк яңа килгәннәрне бригадаларга бүлеп таш эшенә билгеләделәр. Иртәнге сәгать биштә йокыдан торгызып, ашханәгә алып бардылар. Тамак «котыртып» алганнан соң, конвоирлар сагы безне вахта капкасыннан чыгарып, эшкә алып китте. Һәрбер зэк башына өч кубометр таш чыгарып, аны өеп куярга кирәк икән. Эш кораллары итеп ике кешегә бер лом бирделәр. Лом белән киртләч-киртләч яр ташларын каерабыз, ватабыз, аннары штабельгә өябез. Зуррак ташларны көч-хәл белән тәгәрәтеп китерәбез. Кем күпме таш өя, шуннан чыгып блокнотына бригадир язып куя. Кичен нормасын үтәгәннәргә җидешәр йөз, арттырганнарына сиге-

зәр, тугызар йөз грамм икмәк бирәләр. Дүртәр-бишәр кубометр итеп таш өеп куючылар да бар. Алар эшнең җаен беләләр, күнеккәннәр. Тугызар йөз грамм икмәк алучылар бездән көлгән булалар. Әйдә көлсеннәр, тора-бара, бәлки, без дә нормаларыбызны арттырып үти башларбыз...

* * *

Октябрь бәйрәме килеп җитте. Зур бәйрәм хөрмәтенә бригадабызны поселок мунчасына алып бардылар. Конвойны ике тапкыр арттырдылар. Алар гына җитмәде, каяндыр берничә овчарка алып кайттылар. Лагерьның үзендә овчаркаларның күренгәне юк иде. Күрәсең, якын-тирәдә овчаркалы башка бер лагерь бар. Монда китергәндә дә каршыларга этләр белән килүләре исемә төште.

Баракта күптән эшләмәгән радионы көйләгәннәр. Анда Мәскәүдән бәйрәм алды концерты яңгырый. Тыңлавы күңелле булса да, йөрәк әрни. Озакламый бәйрәм белән котлау сүзләре тапшыра башладылар. Янәшә утырган Папинга:

— Булмас, ахры, амнистия дигәннәре юк сүздер,— дидем.

— Мин дә ышанмыйм,— дип куйды Папин.

Җиденче ноябрь көнне эшкә бармадык. Начальство лагерьдан бер кадәр читтәрәк урнашкан зур таш йортта бәйрәм итте. Анда музыка уйнап торганы безгә дә ишетелә иде.

Дежур офицер, ике солдат ияртеп, вакыт-вакыт лагерьга кереп, баракларны тикшереп йөрде.

Сигезенче ноябрьдә эшкә алып киттеләр. Төнлә аяк асты шактый туңган иде. Шул ук диңгез култыгы буена таш чыгару эшенә бардык. Култыкны урап әйләнеп, аргы яктагы ярга җитеп туктадык. Диңгез өстендә вак шадра дулкыннар тәгәрәп тора. Безнең бригада ярның очлаеп өскә күтәрелгән җиренә туры килде. Икенче бригада алдарак, култык ярының уелып торылган ягында эшкә кереште. Алар безгә күренми дә. Ул якта яр асты тәбәнәк булганлыктан, дүрт сакчының өчесе шунда булуны кулайрак таптылар, күрәсең. Безне саклаганы яр буендагы, кайчандыр өстән тәгәрәп төшкән дәү генә ташка сөялеп, кулындагы автоматын кочаклап, эшләгәнебезне карап тора башлады.

Иван белән бергә эшлибез. Еш кына сакчыга күз төшергәлим. Ул гамьсез генә утыра бирә.

— Әллә сызабызмы?

Иван шаркылдап көлеп җибәрде.

— Җүләр син, як-яктан автоматлар белән саклыйлар, ничек ычкынмакчы буласың?

— Ярдан менәбез дә китәбез!

— Сабырсыз бәндә син, түз, вакыты җиткәч үзем әйтермен.

Хәтсез вакыт тавышсыз-тынсыз гына эшләдек. Сакчыга карап алган саен өметем ныгый барды. Түзмәдем:

— Ваня, сиңа сер итеп кенә әйтәм, мин ычкынам, комачауламавыңны гына үтенеп сорыйм,— дидем. Иван дәшмәде.

Тоткыннар һәммәсе дә үз җайлары белән эшли. Ташка утырган сакчы көн җылылыгыннан йокымсырый. Кайвакыт башы кинәт иелеп-иелеп китә. Үземнең дә постларда торган вакытларым күп булды. Шул чаклар исемә төште. Шундый чак була, тырышсаң да йокыны качыра алмыйсың. Җитмәсә, бу сакчы шактый мәлҗерәгән. Кичәге бәйрәм нәтиҗәсе икәнлеген иртән үк аңлап алган идем. Ә култыкның уелып борылган ягындагы сакчыларның берсе дә безнең якка килеп карамады әле. Бу минем өчен бик шәп.

— Башка уңайлы вакыт тиз генә булмас, тәвәккәлләдем. Ваня, тавыш чыгара күрмә, теләсәң, әйдә минем арттан,— дидем дә, соңгы тапкыр сакчыга карап алып, кулымдагы ломны тоткан килеш, ярдан күтәрелә

башладым. Олы ташны урыныннан әле һаман кузгата алмый азапланган Федор Папин янына җиткәч, яңадан түбәнгә күз салдым. Берәү дә игътибар итми. Миңа шул гына кирәк иде. Бары тик Иван гына кулы белән миңа кире төшәргә ишарә ясый. Ярга менеп җитәргә берничә адым бар. Ул араны үтү һич югында минуттан артык вакытны алачак. Үргә атлау авыр. Уйланырга соң иде инде. Ломымны кадап куйдым да, кызыл балчыклы ерганактан өскә таба үрмәләдем. Йөрәгем атылып чыгардай булып тибә, көчем кимегәннән кими. Маңгаема кайнар тир бәреп чыкты. Сулышым кысыла, күз алларым томанлана, шулай да үрмәлим. Аякларым астыннан вак таш катыш балчыклар аска шыбырдап тәгәри. Ярга күтәрелеп җитәргә дә әлләни күп калмады. Хәлем бетте, күзләрем томаланды. Аякларымны ташлы балчыкка терәп, кул бармакларым белән тырмаша-тырмаша, актык көчемне җыеп, тагын үрмәлим. Ниһаять, кулларым яр өстенең чирәмле кәсенә җитте. Күкрәгем белән шуышып өскә менеп җиткәч тә әле бераз үрмәләдем. Аннары, аягүрә басып, як-ягыма каранып алдым. Тезләрем калтырый, авам, ахрысы. Яр астында диңгезнең шаулавы ишетелә. Каршымда вак куаклар, аңа кул гына сузасы, ә аннан арырак — тайга күренә. Бер тын атлап китә алмый тордым. Үземнең нинди куркыныч хәлдә икәнлегемне исемә төшергәч кенә, чабып киттем. Шул вакытта автоматтан аткан тавыш ишетелгәндәй булды. Йөгерә торгач, куаклыкка да җиттем. Эчкәрәк кергән саен яшь куаклар, мине яшерергә теләгәндәй, куера бардылар. Корыган чыбык-чабыкларга сыдырыла-сыдырыла, алга барам. Көчемнең үзеннән-үзе артканын тоям. Дөньямны онытып, тирләп-пешеп чапканнан соң, туктап, тирә-якка күз салып алдым. Бик еракта карлы таулар тезмәсе зәңгәрләнә. Шунда таба барырга карар бирдем. Куакларны үтеп, биегрәк булып үскән агачлар арасына килеп кердем.

Хәзер инде мин яр ягыннан күренмим. Бераз гына булса да тынычлана төштем. Йөрәгем алай ук ярсып типми. Сирәк агачлы таучыкка күтәрелгәч, түбәнгә күз салам. Нindидер тар гына юл тайгага кереп китә. Юлның уң ягында еракларда килүче елганың диңгез ягына таба акканы күренә. Шул якка таба юнәлеш алдым. Түбән төшү бик читен. Таучык сөзәк икән. Түбәнгә кадәр үлән белән капланган. Егылдым да тәгәри башладым. Әллә нәрсәләргә килеп бәреләм. Авыртуны да тоймыйм. Башымны күтәреп карап алам да, тагын тәгәрәп китәм. Түбәнгә төшеп җитүемне сизми дә калдым. Күзләремне ачсам, ни күрим — бөтен дөнья әйләнгәндәй тоела. Аякларыма басып карасам да, таучык өстендә күргән юнәлешне ала алмыйм. Түмгәкле саз буена төшеп җиткәнмен икән мин. Еракта тау елгасы ялтырый. Башта шунда кузгалырга чамаладым. Аннары бу уемнан кире кайттым. Ничек кенә булмасын, сазлыкны үтеп, каршыдагы таллыклар арасына кереп югалу кирәк. Берничә адым китәргә өлгермәдем, дерелдәвекле, өсләре вак камышлы түмгәкләргә бәреләә башладым. Үзем барам, аякларым сазга шуып төшә. Дүрт аяклап үрмәләргә туры килә. Аргы якка чыгып җитәргә әлләни ерак калмады кебек. Ләкин баруы авыр. Таллыкларга җитәм генә дигәндә, билемә тиклем быкырдавыкка баттым. Ярый әле, янәшәмдә саз түмгәкләре бар. Бөтем көчемне җыеп, шуларга үреләм. Көч-хәл белән генә аякларымны тирән сазлыктан суырып чыгардым. Күзләремне томалап, маңгаемнан эре тир тәгәри. Абына-сөртенә, көч-хәл белән генә, таллыкларга килеп җитеп тотына алдым. Чыбык-чабыкларга сыдырылып, коры җиргә аяк баскач кына хәл алдым. Мине куа чыккан булсалар да, белмим, бу сазлыкка керергә батырчылыклары җитәр микән? Шулай уйлап, тынычлана төшеп, яңадан аякларыма бастым. Кояш әле һаман җылыта. Тоткынлыктан ычкынганлыгыма сөенеп бетә алмыйм. Ерткыч-җанвар урманда ачтан үлми бит. Мин дә үлмәм.

Менә шундый уйлар белән үземне тынычландырып, әрәмәдән атлыйм. Күпме барганмындыр, белмим, су буена килеп чыктым. Нишләптер ул акмый. Җитмәсә, аның өсте юка боз белән капланган. Күрәсең, күл бу.

Киңлеге дә артык зур түгел үзенең. Әйләнеп-буталып вакыт үткәргәнче, әллә тәвәккәлләргәме? Бәлкем, елга да ерак түгелдер. Шулай уйланып, ни булса да булыр дип, күлгә кереп киттем. Бернечә адым атларга өлгермәдем, төпкә төшеп чумдым. Калкып чыгып, йөзәргә керештем. Авырайган киемнәрем мине һаман аска таба тарта. Кулларны, аякларны хәрәкәтләндерү ифрат кыен. Бик авырлык белән генә йөзәм. Өстәвенә, вак боз авызга керә, йөземне сыдыра. Хәлем бетә башлады. Кулларымны күтәрә алмас булдым. Яңадан төпкә киттем. Авызга су тулды. Дөнья белән саубуллашыр вакытым җитте, дигән уй акылымны шашындыра язды. Тагын тыпырчына-тыпырчына өскә таба омтылдым. Тирән төшмәгәнмен, бик тиз калкып чыктым. Башымны селкеп, авызыма тулган суны төкергәләп, соңгы көчемне җыеп йөзә башладым. Бервакыт кулларым ниндидер лайлалы каты бер әйбергә тиеп китте. Тизрәк тотынырга ашыктым. Шунда гына калкып, бераз хәл алырга мөмкинлек туды. Карасам, ни күрим, нибары ун-унбиш метр чамасы гына ара үткәнмен. Тотынган нәрсәмнең юан агач икәнлеген чамаладым. Суга күмелгән булса да, төпкә төшеп китмәгән үзе. Агачның бер башы ярга таба киткән. Кайчандыр тамырлары ашалып суга егылган озын агач булса кирәк ул. Шуның өстендәге лайлаларны сыпыра-сыпыра үрмәлим. Кайвакыт бер якка шуып китәм, аннары, лайлаларны сыпыра-сыпыра, яңадан көч-хәл белән агачны кочаклап алам да, башымны калкытып, ял итәм. Тагын менеп атланып, түшем белән тыпырчына-тыпырчына, үрмәләргә керешәм. Ниһаять, күлдән чыгып җитәргә бер-ике генә адым калды. Ул араны да үттем. Ләкин ярга аякларымны күтәреп менгерә генә алмыйм. Атлыйм да кирегә шуам. Аптырагач, үрмәләргә керештем. Менә бәхет, кулым тамырларга тиде, шуларга тотына-тотына сөйрәлеп, бик авырлык белән генә ярга мендем.

... Хәтсез вакыт бардым. Башларын болытларга кадәр сузган кедр агачлары арасында инде мин хәзер. Кояш та вакыт-вакыт кына күренеп ала монда. Тәбәнәк куаклыкка килеп чыктым. Күрәм, гөлҗимешлек икән бу җир. Шундый өлгереп пешкәннәр, ашыгып барып, авызыма тутырырга керештем. Сыпырам гына. Баллы да, татлы да үзләре. Карыным инде күптән ачыккан иде. Бу табигать ризыгы бик тә ярап куйды. Үзем умырам, шулай да сизгерлегемне югалтмаска тырышам, як-ягыма караштыргалыйм. Менә ерак та түгел куаклар селкенеп китмәсенме! Сагайдым. Куаклар арасына яшеренергә өлгермәдем, биш-алты метр ераклыкта гына каршыма бозаудай бүре килеп чыкты. Бөтен көчемне җыеп, кесәмнән очлы ташымны алып каршы торырга хәзерләндем. Тамагына ташлы кулымны тыгып, кочаклап алып буарга иде исәбем. Ара бик якын булса да, бүре миңа ташланырга ашыкмады. Ул минем күз карашымны күтәрә алмады. Бер-беребезгә карашып торганнан соң, куе куаклар арасына кереп югалды. Ә мин кулыма ташымны кысып тоткан килеш шактый вакыт басып тордым.

Уссури бүресе мине бүтән борчырга теләмәде. Очраклы рәвештә генә килеп чыккан булгандыр ул. Тынычлана төштем, юлымны үзгәртергә туры килде. Бүре киткән якка түгел, гел икенче юнәлешкә борылдым. Башыма берсеннән-берсе куркыныч уйлар килә. Ирекне алдым алуын, хәзер нишләргә? Мин бит Уссури тайгасында адашып йөрергә дип качмадым. Владивостокка, Приморьедагы партия органының беренче секретарена барып җитеп, нахакка, юк-бар уйдырмалар чәпәп төрмәгә утыртуларын әйтер өчен барам бит мин. Ул беренче секретарьны — Николай Михайлович Пеговны үзем күреп беләм. Кеше язмышына кереп белә торган җан ул. Әлбәттә, мине тыңлар, трибуналга әйтәсе сүзен әйтер...

Адымнарымны ешайтып тирләп-пешеп атлый торгач, бер тауфыкны үттем. Әле караңгы төшмәгән, тирә-юньне яхшы күреп була. Кайда кунарга, ничек итеп төн үткәрермен дип баш ватып атлаганда, сирәк

агачлар арасында бер йорт күренде. Ни булса булыр, йортка барып җитәргә кирәк.

Мин карак түгел. Мылтыксыз кеше. Анда кеше-фәлән булса, аңлаша алырбыз әле. Шунда таба атлый торгач, хәтсез якынайдым йортка. Аның аргы ягында тар гына инеш тә күренә. Бара торгач агачлар бик тә сирәгәйде. Куе үләнлек башланды. Каранып алдым. Кичке шәфәкъ сүнеп килә. Караңгы төшкәнче миңа ул йортка барып җитәргә кирәк. Сугыш вакытында разведкада булган чагым исемә төшеп китте. Кичекмәстән күзәтү ясап алырга, аннары күз күрер — кирәргәме, юкмы? Җиргә ятып, үлән арасыннан шунда таба үрмәли башладым. Якынайган саен, җиргә колагымны куеп тыңлыйм. Кабат үрмәлим. Авыл мунчасына охшаган йортның биеклеге дә ике метр чамасы гына булыр. Түбәсе агач каерысы белән ябылып, беләк юанлыгы бастырыклар куелган. Әкиятләрдәге убырлы карчык йортын хәтерләтте ул миңа. Нигезенә кадәр шуышып барып җиткәч, үлән арасыннан башымны калкытып астагы бүрәнәсенә колагымны терәдем. Бернинди тавыш та, хәрәкәт тә ишетелми. Эчтә җан иясе булса, инде күптән үзенең барлыгын сиздерер иде. Үлән арасыннан йортның икенче ягына барып чыктым. Анда да шикләнерлек нәрсә юк. Батыраеп аякларыма бастым.

Ишек ябык иде. Бер тартуда ук ачылып та китте. Бердәнбер кечкенә тәрәзәсеннән тоныкы кына булып яктылык керә. Җир иденнең уртасында тупас кына итеп эшләнгән кечкенә өстәл бар. Бусагада басып торганнан соң:

— Кем дә булса бармы? — дип кычкырдым. Җавап бирүче булмады. Яңадан кабатладым, бу юлы да тынлык хөкем сөрде. Түргә уздым. Уң ягында ташлардан өелеп балчык белән сыланган миче дә бар икән. Тиз генә мичнең артына барып карадым. Анда кипкән үлән өеменнән башка бер нәрсә дә юк. Эзләнергә керештем. Мич өстендә кечкенә генә төенчек таптым. Аны кулыма алып, чиштем. Ул вак тоз булып чыкты. Телемне тидереп карагач, сөендем. Мин хәзер нинди бай! Яңадан никадәр генә актарынсам да тамак ялгап алырлык һичнәрсә табылмады. Тоз белән генә тук булып булмый шул.

Эх, чеметем генә икмәк кисәге дә булсачы! Икмәк искә төшеп киткәч, авызга сулар килде. Әле моңарчы иртәдән бирле ач йөрсәм дә, болай ук ашыйсым килгәне юк иде. Нишлисең, түзәргә туры килә. Бушлатымны салдым да, йорттан чыгып, юан гына таяк табып кереп, ишек тоткасына кертеп бикләп куйдым. Ишектән һичбер җан иясе керә алачак түгел. Тәрәзәне дә өстәл белән капладым. Мич артындагы кипкән үлән өстенә ятып, бушлатымны өстемә ябындым.

Күпме ятканмындыр, белмим, шулай да ярты төн үткәндер кебек тоелды. Башым авыраеп, йоклап киттем инде дигәндә генә, тышта кемнеңдер йөргәнен тойдым. Башта колагыма гына шулай ишетелә торгандыр дип, үземне тынычландырырга тырыштым. Тынымны да чыгармыйча куркып ятам. Кая ул хәзер йокы кайгысы. Менә аяк тавышы йорт кырыена ук килеп җитте. Ишеккә борыла инде дип торганда, йорт түбәсенә кемнедер менә башлавы сизелде. Әллә инде ишекне тартып караганын йокым белән ишетми калганмын. Йоклаганда, лагерь баракларында тычкан кыштырдаганга да уянып китә торган идем. Менә доп-доп басып килгән аяк тавышлары морҗа янына җитеп, яңадан җиргә төште. Аннары тәрәзәгә якынлашты. Ярый әле ул кечкенә. Аңарга нибары кеше башы сыярлык кына. Моны исемә төшергәч, бераз тынычланып киткәндәй булдым.

Көтмәгәндә тәрәзәне каплап куйган өстәл кинәт идәнгә шап итеп килеп төште. Йорт эченә тоныкы кына яктылык көлтәсе сузылды. Ай күренде. Аннары кап-караңгы булып китте. Тәрәзәдән башын сузып кемдер иснәнергә кереште. Бу аю иде. Аю керә алачак түгел. Йөрәгемдә курку бераз басылды. Аю бертын иснәнеп торды да тәрәзәдән китеп

барды. Яңадан ай яктылыгы төште. Мин дә җиңеләеп иркенләп сулыш ала башладым. Кеше барлыгын сизде, күрәсең. Ярый әле аның белән йөзгә-йөз очрашмадык. Торып яңадан тәрәзәне капларга кыймадым. Тирән тынлык урнашты. Борчулы сәгатьләр бик әкрен үтте. Мине йокы баса башлады. Үзем дә сизмәстән, йокыга талдым.

Туңып уянганда, кояш чыккан иде инде. Тайга өстенә сибелгән кояш нурлары йорт идәнендә дә уйный. Торып аягыма бастым. Юлга чыгарга, ашыгырга кирәк...

Тышта салкынча саф һава, аяк асларын туңдырган. Үзәгемне әрнетеп ашыйсым килә башлады. Инеш буена таба атладым. Тар гына су чуер ташлар өстеннән сикергәләп ага. Йөрәгемнең януын басар өчен хәл ала-ала ятып су эчәм. Аның салкынлыгыннан тешләр тешкә тими. Аз гына булса да ашыйсы килүне басар ичмасам. Инешне атлап чыгып, каршыдагы әрәмәлеккә таба юл алдым. Сөйрәлеп кенә атлыйм. Әрәмәлеккә килеп кергәч, балан куаклыгына очрадым. Яфраклары коелып бетә язган, чыбыкларында бөрешкән балан телгәшләре күземә чалынып китте. Кабалана-кабалана баланнарны авызыма тутырырга керештем. Бик ачы икән. Шулай да ашарлык үзе. Күп итеп ашадым да, бушлат кесәләремә шыплап тутыргач, куаклыктан чыгып киттем...

Бу тирәләрнең дулкын-дулкын булып әлләни биек булмаган таучыклардан гыйбарәт икәнлеген кичә үк чамалаган идем. Шунысы әйбәт, бу таучыкларның барысында да урман үсә. Һәркайсының диярлек асларыннан йә кечкенә инеш, яки елга ага. Бара торгач яңадан түбәнгә төшә башладым. Агачлар арасыннан тар гына елга күренде. Шунда таба турылап киттем. Биек агачларны үтүгә тәбәнәк әрәмәлек башланды. Атлый торгач ниндидер сукмакка очрадым. Кеше йөргән сукмак булса, болай ук тар, борылып-борылып әрәмәне урамас иде, дип уйладым. Чү, алда куаклар селкенеп китте. Тизрәк куерак чытырманлык арасына кереп постым. Куаклар арасыннан берничә кабан дуңгызы килеп чыкты. Алар мин килгән тар сукмакка җитеп, шуннан түбәнгә таба киттеләр. Берничәсе бик эре, калганнары, күрәсең аларның балаларыдыр. Елгага киткәннәрен күреп калгач, миңа анда бару ярамый. Кешегә һөҗүм итүләрен ишеткәнем булганга, юлымны читләтеп китәргә булдым. Түбәндә кечкенә елга иде. Кыргый хайваннар әнә шул тар сукмактан елгага су эчәргә йөриләр икән.

Менә кайда ул ит... Нигә берәрсен тотарга тырышып карамаска? Барасы юлым бик ерак. Җыйган кыргый җимешләрем күпкә бармас. Яңадан очрармынмы, юкмы андый хәзинәгә? Ә менә ит ашап карасаң, бөтенләй башка булыр иде. Борынгы кешеләрнең мылтыклары да булмаган, ә үзләренә кирәк чагында мамонт кебек зур хайваннарны да аулый белгәннәр.

Озак та үтмәде, кыргый кабаннарның киткән сукмакларыннан менеп килүләрен күрдем. Чытырманлыкта торам. Үтеп киттеләр болар. Башыма фикер килде. Иртәгесен дә алар шушы сукмактан су эчәргә төшеп китәчәкләр. Кичекмәстән эшкә керешергә кирәк! Җиренең ташлымы, йомшакмы икәнлеген белдем башта. Бармак буе казырга өлгермисең, ташка килеп төртеләсең. Кесәмдәге очлы ташны да эшкә файдаланып карадым. Аның да файдасы тимәгәч, ботинкамны салдым. Аның үкчәсендә айсыман тимер дагасы бар. Шуны таш белән суккалап, кубарып алдым да, таяк башына беркеттем. Тимер кисәге шактый шомарган, нечкәргән иде. Җиргә батырдым, әйбәт керә. Миңа шул гына кирәк иде. Озынлыгы метр ярым, киңлеге ярты беләк чамасы сукмакны кисеп, казыр өчен билгеләдем. Бу эшләр белән мавыгып вакытымны үткәргәндә ай калкып, йолдызлар җемелди иде инде. Бушлатымны салып ташлап чокыр казый башладым. Җирнең өске каты гына авырлык белән киселде. Ә аннары ком катламы, үзеннән-үзе коела. Учым белән читкә сибәм генә. Ярты метр чамасы казыгачтын, ял итеп алыйм дип, чокыр читенә

утырдым. Төн салкынаеп килә. Күпме вакыт үткәнне дә белмим. Бераз тамак ялгап алырга, күкрәк изүеннән бөрешкән кыргый җимешләрне бүрегемә чыгарып салдым да тәмләп ашап алдым. Аннары, инешкә төшеп ятып туйганчы су эчтем. Тәнем суына башлады. Елгачыктан казый башлаган чокырым янына барып бастым. Баштагы дәртем сүрелгән, эшлисе килми. Уйладым-уйладым да, ярты метр казыган чокыр янына корган үлән җыеп китереп салдым. Хәзергә җитәр дип чокырга аудым. Тар булса да өстемә бушлатымны япкач тынычландым. Бик арылган, шулай да йокы керми. Башыма төрле куркыныч уйлар килә. Ерткыч җанвар гына һөҗүм итмәсә ярар иде. Белмәссең, ерткычлар бит алар төннәрен генә ауга чыгалар. Кулыма тимерле таягымны алып кочаклап яттым.

Барыбер йоклый алмадым. Уйланып яттым-яттым да яңадан эшкә тотындым. Яктыра башлаганда чокырның тирәнлеге билдән булды. Тар чокырга берәр кечерәк кабан дуңгызы төшә калса, һич кенә дә сикереп чыгарлык итмәдем.

Тирә-юнь якты иде инде. Нечкә чыбык-чабыклар җыйнап китердем дә, чокыр өстенә тезеп, якын тирәдән бер кочак коелган яфраклар алып килеп өстенә тигезләп сиптем. Тозак әзер! Тырышлыкларым әрәмгә генә китмәсә ярар иде. Биек кедр агачлары арасына кереп китә торган уйсулыкта кue үләнле урын сайлап, шунда ятып ял итә башладым. Иртәнге ак томан күтәрелә башлады. Бераз җылытып җибәрде. Мин үзем дә сизми йоклап киткәнмен...

Уянып китсәм, кояш шактый күтәрелгән, томан таралып беткән. Табигать тып-тын. Төндәгеләрне төшемдә күргән кебек кенә исемә төшереп, «тозагыма» таба атладым. Инде күптән кабаннар су эчәргә киткәннәрдер, тозагымда берәрсе мине көтеп ята булыр.

Сакланып кына шунда барам. Әнә ул, мин чокыр казып төне буе җәфаланган куаклык. Якыная барган саен күңелемне рәхәтлек тойгылары били башлады. Бер-ике чыбыгы селкенеп тора түгелме соң? Чокырның бер читендә чыбык күтәрелгән күтәрелүен, әмма кабан төшмәгән. Чокырда бүрек хәтле бер керпе йөри. Кызгандым ул мескенне. Аны чыгармасам, ул шунда ачтан һәлак булачак бит. Чыбык-чабыкларны сыпырып, аска төштем дә бүрегем белән керпене алып өскә ташладым...

Тау итәгеннән үткән юлга килеп чыктым. Машина, арба эзе юк. Ул таучык буеннан биек кедр агачлары янына китеп югала. Көзге яңгырлар таудан юып төшергән ком катыш вак ташлар каплаган аны. Ерганак эзләренә агач үсентеләре шытып чыккан. Бушлатым төрле җиреннән агачларга сыдырылып умырылган булганлыктан, юлдан баруны кулай күреп иркенләп атлап киттем. Яньчелеп беткән аяк киемем белән җайлырак басарга тырышып калкурак җирләрне чамалап атлыйм. Кая булса да кеше яши торган авылгамы, шәһәргәме алып чыгар әле бу юл...

Ботинкаларымның үкчәсе шулкадәрле нык ашалган, озакламый тәпитәпи атларга туры килер, ахрысы, миңа.

Кояш салынкы ак болытлар арасыннан тайгага саран нурларын сибә. Баруы күңелле булса да, җиле миңа каршы булганлыктан атлыйсым килми. Агачлар арасында ышык иде, ә монда баруы уңайлы, ләкин җил йөзгә бәрелә. Яңадан биек кедрлар арасына кереп китәсем килде. Юлдан чыгыйм дип атларга өлгермәдем, бәйләгән ботинкамның башы яңадан ачылды. Аяк бармакларым күренә. Туктарга мәҗбүр булдым.

Өмет, татлы хыялларга чумып, тайга юлыннан сөйрәлеп, сөзәнрәк юлдан атлый торгач, вак куаклыкка юлым борылды. Ул юл таучыкка күтәрелә башлады. Менеп җитәргә өлгермәдем:

— Тукта, кулларыңны күтәр, югыйсә атам,— дигән тавыш ишетелде. Ботинкамның башы купканлыктан, аска карап атлый идем. Башымны күтәрсәм, ни күрим, дүрт-биш кенә адым булыр, каршымда хәрби киемнән кулына автомат тоткан кешегә тап булдым. Тиз генә куе агачлар

арасына сикерергә уйласам да, уемнан кире кайттым. Соң иде инде. Кулларымны күтәрергә мәҗбүр булдым.

— Кузгаласы булма, автоматтан чират биреп алам,— ди бу. Мине атып үтермәкче була. Үзе атмый, миңа карап тора. Яшь ул. Безнең лагерьныкы түгел. Аларның барысын да күреп беләм.

Баскан урынымда тораташ сыман мин. Шунда солдат автоматыннан бер чират биреп тә алды. Әле һаман аякларымда иконлегемне тойгачтын, бераз гына булса да эчкә җылы керде. Үзе миңа якын килергә кыймый, автоматын миңа төбәп басып тора. Озакламады, агачлар арасыннан яңадан коралны кешеләр килеп чыкты. Шунда гына солдатның автоматыннан атып иптәшләрен чакырганлыгын аңладым.

Тозакка килеп капканмын икән. Күпмедер вакыт алар минем шушы юлдан үтәсемне чамалап көтеп торганнар.

Сакчыларның берсе:

— Әһә, эләктеңме, качкын. Безнең кулдан ычкынучылар юк әле ул,— дип җәһәт-җәһәт яныма килде дә, кесәләремне актарырга керешге. Өчлы ташымны алды, кыргый җимешләрем бераз калган иде, аларны җиргә койды. Шундук якында гына торган бер иптәшеннән бау алып кулларымны артка борып, кыймылдамаслык итеп бәйләп куйды.

— Йә, хәзер ычкынып кара инде, синең аркада өч йөз кеше, ничәмә зэк, дүрт көн буена эшкә чыкмады. Качып безгә нинди зур мәшәкать салуыңны аңлыйсыңмы?!

Эндәшмим. Үземне тыныч тотарга тырышам...

Ярый әле мине тотучылар мәрхәмәтле солдатлар булып чыктылар. Югыйсә, бик сирәк вакытта гына качкыннарны исән килеш тотып кайталар. Күп очракта эшен бетереп, кулларын гына кисеп, лагерь «кодаларына», төрмәдә алынган тоткынның бармак эзләрен чагыштырып карау эшләре генә кала...

Белмим әле, аларның уйларында нәрсә бардыр. Атып егулары бик ихтимал!

Басып тора-тора ардым, тез буыннарым калтырый башлады. Лагерь сакчылары тәмәке көйрәтеп, бер-берсе белән гәп суганлар. Күңелләре күтәренке аларның. Нигә күтәренке булмаска, тагын бер тоткынны эләктерү бәхетенә ирештеләр. Аларның кәефләреннән бер дә ашыкмауларын күреп торам. Кемнәрнедер көтәләр. Сизенүемнең юкка түгел икәнен аңладым. Каршы яктан тагын өч солдат килеп чыктылар. Кулларында автоматлар. Авызларын ерып миңа карый-карый иптәшләре янына килеп бастылар.

— Шушы буламыни инде качып китүче чибәр егет!

— Нәкъ үзе! Күрмисеңмени, сул яңагында кызылланып торган җәрәхәт эзен? Тиз танырлык качкын. «Кода» шулай дигән иде аның турысында...

Таучык юлыннан алга таба барабыз. Аякларымны көчкә-көчкә генә сөйрәп барам. Кулларым артка каерып бәйләгән.

Таучыкны төшеп, тар гына тау елгасына барып җиттек. Сакчылар, озын балтырлы күн итекләрдән булганлыктан, суга кереп тә киттеләр. Ә минем икеләнебрәк торумны берсе бик тиз сизде, артымнан автомат түтәсе белән каты итеп төртте. Шундук абынып суга капландым. Яңадан төрткәләп торгыздылар да алга таба алып киттеләр. Салкын бөтен тәнемә таралды. Ботинкам эчендә су бытырдый, тишекләреннән пычрак атылып чыга.

Көн төшлеккә җитеп килгәндә, тайга юлы тауга күтәрелә башлады. Бөтен тәнем алҗыды, тешләремне кысып булса да сөйрәлеп атлыйм. Алда, камышлы күл күренде. Таучыкны төшкәч, аны әйләнеп үтеп елгага килеп җиттек. Бу тирәләрне үзем үткәнлектән, лагерьга барып җитәргә дә күп калмаганлыгын аңладым. Елга ярыннан барабыз. Вак куаклык

баскан аланлыкта конвоирлар чирәмгә утырып тәмәке көйрәтергә керештеләр. Күрәм, кайберләре кесәләреннән икмәк чыгарып ашый да башладылар.

Хәтсез генә вакыт утырдылар алар. Мин һаман тораташ сыман басып торам. Теге яктан безгә таба килгән көймә күренде. Көймә ярга килеп төртелгәч, барыбыз да шунда, кереп урнаштык. Мин көймә төбендәге суга аякларымны салындырып утырдым.

Конвоирларга килеп кушылганнарның берсе:

— Бүген бу егет тотылмаган булса, кайтырга да боерганнар иде,— дип куйды.

— Ил буена эзләргә боерык бирелгән. Хәзер аны кайлардан гына эзләмиләр...

Елганың теге як ярына да чыгып җиттек. Көймәче безне озатып калды. Юлыбызны дәвам итә башладык.

Башымда бер генә уй да юк. Барысы да чәлпәрәмә килде!

Бервакыт конвоирлар яңадан ялга туктадылар. Шунда берсе:

— Мә, егет, тәмәке көйрәтеп ал, бая да сорамадың,— диде.

Башымны селкеп, тартмый торган кеше икәнлегемне белдердем. Ул елмаеп куйды. Күрәсең, бик тә кешелекле адәм. Бәлки, ул дөреслек эзләр өчен качуымны белгәндер. Ял итеп алганнан соң, кузгалдык. Озак барырга туры килмәде, ниндидер тар гына елга буена урнашкан берничә йорттан гына торган авылга килеп кердек. Анда машина көткән икән. Хәрби егетләр бик тиз генә шуңа сикереп тә менделәр. Мине тартып алып машина идәненә утырттылар.

Тайга юлыннан озак бардык. Таныш җирләр күренде. Качып киткән таш карьеры да артта калды.

Машина яр буе юлыннан борылды. Менә лагерь, аңа кул гына сузасы калды.

Лагерь капкасы янына килеп туктаган машинабызны каршыларга бер төркем хәрбиләр килеп чыкты. Әйтерсең, аю тотып кайтканнар. Барысының да күзләре миндә генә. Качуымның никадәрле кешегә мәшәкать китерүен үз күзләрем белән күрдем. Тоткыннар да мине абайлап алдылар. Кул болгап сәләмлиләр. Янәсе, исән-сау алып кайтканнар, сөен, диләр сыман.

Машинадан ничек төшкәнемне дә белми калдым. Вахтада торучы сакчыларның сөйләшүләре мине кызыксындырмый: юлда атып үтермичә алып кайтуларына күңелемнән куанам. Вахта йортына алып керделәр. Дежур старшина җитди генә итеп:

— Нигә качтың? Мең мәртәбә үзеңә начарлык эшләдең! Срогың да әлләни зур түгел икән, менә көт тә тор, яңадан срок өстәрләр,— дип, җикеренә, кабахәт сүзләр белән сүгәргә тотынды. Аннары вахта йортында икәү генә калгач, усаллыгыннан нишләргә дә белмичә, чыгырыннан чыгып яныма ук килеп басты:

— Качкын!— дип көтелмәгәндә яңагыма сукты. Мәтәлеп китеп, аргы баштагы эскәмияләргә барып төртелеп, идәнгә аудым. Сизәм, ул чыгырыннан чыккан. Күзләре ут булып яна. Мине теткәләп ташлардай булып торганын күрәм. Өстемә яңадан җикеренеп килә генә башлаган иде, түзмәдем:

— Рәхмәт, гражданин старшина, матур эләктердең, кулларың кычытып торган икән, син бит совет старшинасы, ә мин диңгезче, сугышлар үткән кеше, ни хакың бар кул күтәрергә?— дип әйтеп бетерә алмадым, вахта ишеге ачылды да, лагерь начальнигы Комаров килеп керде. Миңа яңадан сугарга хәзерләнгән старшина аның каршысына тиз-тиз басып, устав буенча тәбрикләде.

— Алып кайттылар качкынны, ачтан да үлмәгән, кесәләрендә кыргый җимешләр дә җитәрлек булган әле,— диде.

Лагерь башлыгы Комаров озынча буйлы, юка яңаклы, зәңгәрсу күзле, тиз генә җикеренә торган кешеләрдән түгел иде. Беренче килгән көнем-

нән үк мин аны кешеләргә мәрхәмәтле булганлыгы өчен ошаттым, ялгышмаганмын икән.

— Йә, диңгезче, йөреп кайттым диген? Мин сине качарсың дип башыма да китермәгән идем. Карак яки рецидевист түгел бит син...

Бертын тынып торды. Аннары, мин бер сүз дә әйтмәгәч: «Сине гаепләгән кәгазьләреңне карадым, гаебеңне дә танымагансың, шулай булса да гаепләгәннәр үзеңне, бусы аның суд эше. Шуны әйтәсем килә, качарга кирәкмәс иде. Эшеңне карап, тере килеш тотып кайтырга үзем боерык бирдем»,— диде.

Ул шунда минем яшьлегемне дә искә алды. Совет законнарының каты икәнлеген дә исемә төшерде. Үзенең Ватан сугышында иң авыр хәлләргә калганын искә төшереп алды. Кыскасы, явыз кешеләрдән түгел икәнлеген миңа төшендерергә, аңлатырга тырышты.

Миңа эндәшерлек урын калмаган иде. Ни әйтсәм дә барысы да файдасызга гына булганга күрә, аның кешелекле йөзенә карап басып торам. Лагерь начальнигы миңа утырырга кушты. Аннары старшинага:

— Егет ачтыр, бар кайнар аш, икмәк китер, тамак ялгап алсын,— диде.

Икәү генә калгач:

— Бик тә жәл, бөтен илгә фотокарточкаларыгызны таратып эзләү әмере бирелгәнлектән, лагерьда калдыра алмыйм...

Старшина озакламады, икмәк белән кайнар аш китереп дежур өстәленә куйды.

— Тамагыңны ялгап ал, озакламый Владивостокка китәсең,— дип, лагерь начальнигы өстәл янына килеп утырырга тәкъдим итте.

Күптәннән бирле кайнар аш күрмәгәнгә, беренче кашыкны кабуыма тәнемә җылы кереп китте.

Ярый әле, бәхетемә күрә, мәрхәмәтле лагерь начальнигы дежур йортына килеп керде. Югыйсә, старшина гына булган булса, кая ул кайнар аш, укытасы кул сабакларын бик шәпләп тагын укыткан булыр иде.

Тамак ярыйсы гына ялганды. Хәзер инде кая гына алып китсәләр дә түзәргә булыр.

Ашап алуыма, дежур йортына лагерь «кода»сы белән бер сакчы килеп керде.

Керүчеләр начальник белән бер-ике сүз алыштылар да үзләре белән мине алып чыгып та киттеләр.

Капка төбендә үк машина килеп туктаган икән. Көтеп-нитеп тормастан шунда менеп тә утырдык.

Диңгез портының якынлыгын мин яхшы беләм. Туп-туры шунда таба китеп тә бардык.

Диңгезне күргәч күңелем сыкрап китте. Әнә ул горур, миңа илһам бирүче, яшьлегемнең иң гүзәл вакытлары үткән дәрья! Янадан кол хәлендә калган булсам да, мине диңгездән нәрсәгә булса да утыртып алып китәчәкләр. Ярга төшәбез, анда балыкчы көймәләре, баржалар, буксирлар тора. Тукталып-нитеп тормастан, бер буксир пароходына тупас такталардан киң итеп эшләнгән траптан менеп тә киттек. Палубага аяк басуга, гудок тавышы яңгырады. Аннары, минут та үтмәгәндер, кузгалып та китте. Бик вакытлы килеп җиткәнбез икән. Мине озатып сак астында алып килүчеләр кем беләндер бер-ике сүз алышып алдылар да, машина бүлеге белән янәшә кубрикка төштек. Миңа урын күрсәттеләр. Үзләренә кубрикка төшә торган трап янында урын алдылар.

Ботинкаларым ертык, бармакларым күренә. Аларны салдым да чүпрәккә әверелгән юеш чолгауларымны борт кырыеннан үткән калын кайнар торба өстенә киптерергә куйдым. Берничә җиреннән умырылган бушлатымны да салып шунда куйдым. Үзем дә җылы торбага сөялдем. Башта җылылыкны тиз генә тоймадым. Ачык изүемнән диңгез хезмәтемнең соңгы истәлеге булып калган тельняшкам күренә. Ул да инде бик

тузган, кырыкмаса кырык жиреннән ямалган. Күптән ташлаган булыр идем, тәнемдә череп бетсен дип үз-үземә сүз биргән идем. Шуның өчен генә аны ташламыйм.

Сыбызгы тавышы ишетелде, аннары сузып-сузып кычкырткан гудок тавышы яңгырады.

Берсе артыннан берсе кубрикка берничә матрос төште. Мине моннан башка җиргә күчерерләр дип курыккан идем. Сүз әйтүче булмады. Керүчеләр бик тә сүзчән булып чыктылар. Аларның берсе мине озатып килүче «кода»дан:

— Нинди кеше ул,— дип сорады.

— Качкын, бүген генә тайгадан тотып кайттылар үзен, менә Владивостокка илтәбез. Анда аңа яңадан срок өстәячәкләр...

Матрос миңа җентекләп карап алды. Тельняшкама игътибар итте булса кирәк ул. Аның күз карашыннан үземне кызгануын тойдым.

Әледән-әле бортка бәрелгән су тавышыннан буксирның барганын сизәм. Күңелем бераз гына булса да тынычланды. Барасы җиребезгә җиткәнче, өс-башымны киптерә алсам, миңа шул җиткән. Тайгада йөрүләрем, шундый авырлык белән алган ирегемне югалтуыма әрнеп, алдагы көннәремдә ничек яшәргә, мөмкинлек булу белән барыбер коллыкта яшьлегемне үткәрмәскә сүз биреп, йөрәгемне барлык күрәсе газапларга чыныктырырга уйланып утырам.

Матрослар кубрикка төшә торган траптан бер кадәрле читкәрәк куелган озын өстәл янына тезелешеп утырдылар да домино уйнарга керештеләр. Шактый еракта булсам да, шома сөякләрне дәртләнеп өстәлгә бәрүләрен күреп торам.

Уеннары хәтсез дәвам итте аларның. Берсе урыныннан торып траптан югарыга менеп китте. Шуны гына көткән икән, мине озатып баручы «кода» өстәл янына барып уйнаучыларга кушылды. Лагерьдан килгән солдат та кызыксынып домино сугучыларга карый, вакыт-вакыт миңа да игътибарын юнәлтеп алгалый.

Чыгып киткән матрос өстән трап буенча бераз төште дә:

— Туганкайлар, әйдәгез, кичке ашка! — дип, ничек тиз төшкән булса, шулай ук бик тиз менеп тә китте. Уеннарыннан туктап матрослар да кубриктан чыгып китәргә ашыктылар. Без яңадан өчәү генә калдык.

Бортка бәрелгән дулкыннар тавышын тыңлап оеп китә башладым. Киләчәк көннәремне уйлыйм. Кемнәр кулына барып эләгермен? Хәзер читлектәге кош кебек мин. Мәгънәсез билгесезлек белән акылым чуала.

Траптан төшеп килгән матросларның аяк тавышларыннан куркып китеп, күзләремне ачтым. Төшеп килүчеләрнең берсенең кулында миски, икенчесенекендә шактый зур төргәк бар. Өлкәнрәге булса кирәк, траптан төшеп җиткәч, өстәл янында утырган «кода»дан нәрсәдер сорады. Аннары туп-туры минем яныма атладылар.

— Ашап ал, кеше,— диде, алдан килгән матрос, миңа мискиен сузып. Кисәк-кисәк итләре күренгән карабодай боткасы иде ул мискидә. Өстенә алюмин кашык та куелган. Икенчесе:

— Шәптән үк булмаса да, менә сиңа киемнәр,— дип яныма китереп куйды. Рәхмәтемне әйтеп бетергәнемне дә көтмәстән, алар трап янындагы озын өстәлгә таба китеп тә бардылар. Күрәсең, «кода» үзләренә минем белән сөйләшергә кушмаган.

«Кеше» дип мөрәҗәгать итүләренә йөрәгем әллә нишләп китте. Күзләремнән яшь бәреп чыкты. «Мин — кеше, әйе, кеше бит әле мин». Бу күңелемә якын сүзне йөрәгемә сеңдереп, китерелгән ризыкны ашый башладым.

Майда таралып пешкән итле карабодай боткасы шундый тәмле булды, аны ничек ашап бетерүемне дә сизми калдым.

Таушалган булса да җылы оек, калын табанлы эш ботинкасы, кайбер җирләре мазутка буялган диңгезче бушлатын өстемә киеп алгач, рәхәтләнеп киттем.

Матрослар озын өстәлдә домино уйнауларын дәвам иттеләр. Диңгезче халкы шулай инде ул, үз эшләре өчен үлеп тора.

Дөньяда чын, ихлас күңелле кешене бер карауда аңлый белүчеләр күп. Кабахәт җанлылар гына булган булса, тормышның матурлыгын беркем дә тоймас та, яшәүнең яме дә булмас иде.

Кубриктагы матросларга чын күңелемнән диңгездә исән-имин йөзүләрен теләп, мең рәхмәтләремне укып җылынып утырам. Диңгезчеләрнең тормышлары авыр, четерекле, кайвакыт көтелмәгәндә генә шундый давылларга очрыйсың, әгәр дә үз араларында бердәмлек, оешканлык булмаса, һәлакәткә дучар булуыңны көт тә тор. Шулай, гомер-гомергә тату гаилә булып яшиләр...

Хыялга бирелеп, үземнең тоткын икәнлегемне онытып җибәрә язганмын, су эчәсем килеп утырган җиремнән торып китәргә аякларыма бастым. Мине сакларга билгеләнгән солдат һәм «кода»ны күргәч кенә тоткын икәнлегем исемә төште. Шулай да «кода»га мөрәҗәгать иттем. Ул уеннан туктап:

— Сабыр ит, озакламый барып җитәрбез, шунда кирәк кадәрле эчәрсең,—дип миннән башын борды. Уен белән мавыккан матрослар безнең сүз алышуыбызга игътибар итмәделәр. Яңадан хәтсез вакыт телем белән иреннәремне чылатып утырырга туры килде. Бушлатымны баш астыма куеп җылы тимер идәнгә яттым. Кәеф әйбәтләнсә дә йоклый алмадым. Домино сугучылар кубриктан чыгып киткәч кенә, бераз черем итеп алдым.

Күп еллар элек, үсмер чагымда бер мажаралы кино караган идем. Анда яралы кызыл сугышчы акларның эзәрлекләүләреннән мең бәлалар белән котыла. Нигәдер, менә шул исемә төште. Үземә үзем сорау бирдем: «Мин кемнән качам соң?» Әйе, ясалма рәвештә җинаятьче иteлдем, шул турыда сөйләр өчен үзәк органнарының берәр кешесенә барырга дип юлга чыккан идем. Котылып булмады. Бәлки, акланып котылган булыр идем әле...

Мине озатып баручылар үзләре белән югары палубага алып чыктылар. Йолдызлар белән чигелгән аяз төнгә сокландым. Пароход яр сызыгыннан беркадәр генә читтәрәк бара. Анда-санда маяк утлары җемелди. Күк йөзендә киң генә булып көл төсендәге яктылык күренә. Мин аның диңгез буендагы шәһәр утлары балкышы икәнлеген шундук чамаладым. Йөрәгем леп-леп тибә. Юк, юк, минем юлларым әле киселеп бетмәгән, мин кешеләргә таба, кешеләр йөрәгенә якынаям.

## Алтынчы бүлек

Мине шәһәр читендәге ниндидер төрмәгә китереп тапшырдылар. «Кода» надзирательгә читкәрәк китеп нидер әйтте. Аннары мине озын коридорның иң читендәге камерага кертеп яптылар. Бер тар тәрәзә, ул да стенаның иң югары җиренә уелган. Өлгесенең ике урынында пыялалары яртылаш юк. Түшәмендә тимер чыбыктан үрелгән «оясы» эчендә тонык кына булып электр лампасы яна. Аның яктысы цемент идәнгә төшә. Уң як стена буенда тимер караваты да бар. Камераның озынлыгы дүрт-биш адым чамасы булып, киңлеге дә әлләни озын түгел. Стеналары бәсле. Башта миңа салкынлык әлләни сизелмәде. Ярты төн иде. Ничек тә булса төнне үткәрермен әле дип, тимер караватка барып яттым. Эчемнән өстемә кием биргән матросларга рәхмәт укыйм. Иртәгә мине ни көтә? Бу сорауга акылымнан җавап эзлим, таба гына алмыйм. Нишләтерләр, дүрт көн иректә йөргәнем өчен бәлки әлләни күп

срок та өстәмәсләр. Җавабым әзер! Хәрби трибуналны эт итеп сүгәчәкмен, яңадан «эшемне» ябык суд белән түгел, ачык халык суды караса гына, сорауларына җавап бирәчәкмен.

Йокым качты, торып бастым да, цемент идән буйлап арлы-бирле йөргәләргә керештем. Барыбер салкын үзенекен ала. Өс киемнәремнең әллә кай җирләреннән үтеп тәнемне салкын алганлыктан, түзмәдем, ишекне дөбердәтергә тотындым. Җавап бирүче юк. Күрәсең коридордагы надзиратель йоклый. Нишләргә? Җаен таптым. Тиз генә ботинкамның берсен салдым да, үкчәсе белән көчемнән килгән кадәрле тимер ишеккә бәрә башладым. Аяк тавышлары ишетелде. Ишек уртасындагы үгез күзедәй тишек ачылып китте.

— Нәрсә булды?

— Туңдырып үтермәкче буласызмы әллә?

— Карцерда икәнлегеңне онытма. Качкыннарга бездә хөрмәт булганы юк.

— Мин бит кеше!

Соңгы сүзләремне надзиратель тыңлап та тормады, «үгез күзен» ябып китеп барды.

Яңадан чакрымнарны үтә башладым. Ардым, хәлдән тайдым, йөрүемне туктатмадым.

Тәмам ардым. Бераз тәнем җылынгандай булды үзе. Яңадан караватка менеп аякларымны бөгәрләп, башымны бушлат якасына яшердем. Йокыга китәргә миңгерәүләнә генә башлаган идем, карцер ишеге ачылды.

— Кеше, әйдә, башкасына күч,— диде надзиратель.

Аның артыннан ияреп, дежур өстәле каршысындагы камерага барып җиткәч:

— Ерактан китерүләрен искә төшереп, җаваплылыкны үз өстемә алып булса да, җәлләп кенә кертәм үзеңне, бар, таңыңны аттыр, анда туңмассың,— диде.

Кердем, як-ягыма каранып алдым. Караватта матрас, одеял бар. Стеналарында кар бөртекләре күренми. Тиз генә аяк киемемне салдым да караватка менеп яттым. Йоклап киткәнемне сизмәгәнмен дә...

Ишек ачылды. Каршымда дежур надзиратель белән төрмә киеменнән утыз яшьләр тирәсендәге берәү кереп басты. Миңа бер кружка кайнар су, бер кисәк икмәк биреп:

— Йокының кирәген бирдең, бер очтан тугыз сәгать йокладың,— дип надзиратель эшчене ияртеп чыгып та китте.

Төрмәдә дә төрле кешеләр була.

Тикшерү эшләре башланды. Минем таләпләремнең берсенә дә колак салмадылар. Миңа билгеләнгән тикшерүче Приморье баш прокурорына язган шикаятемә кыска гына итеп: «Сезне хәрби трибунал хөкем иткән, без катнаша алмыйбыз, качуың өчен закон алдында җаваплылыкка тартулары дөрес» дигән язуны күрсәтте һәм кул куярга кушты. Мин баш тарттым. Кыстамыйбыз, үз ихтыярыңда, диде ул.

Бер атна буе мине чакырмый тордылар. Анда мин төрле җинаять эшләре буенча ябылганнар белән яшәдем.

Аз гына булса да борчылуларымны онытып, кешеләрне тыңлыйм. Бигрәк тә Рәхим мулла мине үзенә җәлеп итте. Аны Төньяк Кореядә кулга алып китергәннәр. Рәсәйдә гражданнар сугышы барганда Омск шәһәреннән Колчак армиясе калдыклары белән Кытайга киткән булган. Тумышы белән Татарстанның Чистай ягыннан. Унике яшьлек малай чагыннан ук тырыш, зирәк һәм тапкыр булганлыгы аркасында үз яшьтәшләреннән аерылып торган. Яшьли атасыз калып, анасы белән генә үскән. Башта авылда яшәгәннәр. Шулай бервакыт, анасы белән Рәхим кечкенә арба тартып Чистай ярминкәсенә йорт кирәк-мазарлары өчен күкәй сатарга баралар.

Анасының ерак бер туганы ярминкәдән әлләни ерак тормый икән. Анасы малайны шунда калдырып, күкәй сатарга ярминкәгә китә.

Иртә белән өйдән чыгып киткән ана кайтмый да, кайтмый. Рәхим зарыгып әнисен көтә. Төш вакыты җитә, малайның тамагы ачыга башлый. Нишләргә? Капка төбе саклап тамак туйдырып булмый бит. Өйдә туксан яшьлек карчыктан башка берәү дә юк. Әбидән ярты гына телем булса да ипи сорый ул.

— И-и бәбкәм,— ди әби,— үзебез дә ачлы-туклы гына яшибез, мине киленем ашатканда ашата, ашатмаганда — юк. Аңардан башка ризыкка тотына алмыйм,— дигәч, Рәхим яңадан урамга чыгып, капка төбендә әнисен көтә башлый. Ә ул кайтмый гына. Аптырагач малай әнисенең киткән ягына тәпиләргә мәҗбүр була.

Ярминкәнең иң кызган вакыты икән. Халык кырмыска оясындагы кебек кайнап тора. Кая карама — кибетләр, лареклар.

Ярминкәнең бер җирендә Рәхим лимонад сатканнарын күрә. Халык шундый күп, һәркемнең бер-берен этеп-төртеп, чиратсыз тәмле су эчәсе килә. Бу хикмәтне күреп алган Рәхимнең башына бик тә матур бер фикер килә. Тукта, ди ул, күңеленнән, монда акча җүнәтеп була икән. Халык арасыннан этә-төртә чыгып теге өйгә элдерә бу.

Кайтып җитсә, әнисе һаман юк. Өйдәгеләрнең берсе дә ярминкәдән кайтып җитмәгән. Рәхим яңадан әби янына керә.

— Әбекәй, сезнекеләр кайтып җиткәнче, мин өйгә су ташып куям әле,— дип рөхсәт сорый ул.

— И-и бәбкәм, арып кайтырлар, бик тә әйбәт булыр иде, димәсенме әби. Рәхимгә шул гына кирәк тә. Ул өй алдында торган ике чиләкне ала да хуҗаларның бакчалары артындагы чишмәгә китә. Тар сукмактан шунда барып кәнди белән ике чиләкне дә салкын су белән тутыра. Аннары чиләкләрне арбага берсе артыннан берсен янәшә куеп, ярминкәгә таба китә. Базарның башыннан эчкәрәк бераз кереп туктый да:

— Чишмә суы, рәхим итегез, туйганчы эчегез, күп алмыйм, нибары ярты гына тиен,— дип күңеленә килгән беренче сүзен кычкырып җибәрә. Аны шундук базар халкы сырып ала. Сусаган базарчылар комсызланып чишмә суын эчәргә ябырылалар. Бик тиз арада ике чиләкне бушатып та бетерә Рәхим. Акчаның күпме җыелганын да санап тормый ул, арбасын тартып яңадан чишмәгә элдерә.

Бу эш берничә мәртәбә кабатлана. Соңгы чиләкләрне бушатып бетергәндә базар тарала башлый. Арып-талып үзләре туктаган йорт хуҗаларының бакча капкаларына ике чиләкне дә яңадан чишмә суы белән тутырып кайтып кергәндә, аны әнисе зәһәрләнеп:

— Кая югалдың, юньсез малай,— дип колагыннан борып, бик каты шелтәли башлый. Рәхим эндәшми. Белә ул әнисенең ачуы тиз бетәсен. Ике чиләк чишмә суы да алып кайтылган бит әле. Моны күргән анасының туганы:

— Майбәдәр, улың безнең өчен тырышкан, әрләмә инде аны, күреп торасың, чишмәдән су алып кайткан, без бик тә канәгать синең улыңнан,— дигәч кенә ана йомшап китә. Бу ярминкәнең соңгы көне була. Майбәдәр апа күкәй сатып, сабын, тоз алган. Ул күкәйләрен сатып бетерүгә бик канәгать булып, ярминкәдән соң гына кайткан, малаеның өйдә булмавына бик тә борчыла башлаган булган. Өйдәге туксан яшьлек әбидән сораштырган, ул Рәхимнең ике чиләк асып чишмәгә китүен әйткән әйтүен. Майбәдәр чишмәгә берничә мәртәбәләр барса да, улын анда күрмәгән.

Рәхим әнисенә үзенең акча эшләвен башта әйтергә кыймаган. Ерак туганнары алдында тешен кысып булса да түзеп торган.

Авылларына арба тартып кайтып җиткәч кенә Рәхим аңа бер уч бакыр акчалар биреп:

— Әнием, сине ярминкәдән эзләп-эзләп таба алмагач, мин дә сиңа ярдәм итәргә булып, акча эшләдем,— дип, малай анасына бәйнә-бәйнә үзенең маҗараларын сөйләп бирә.

Ана башта ышанмый тора, аннары улын кочаклап үбә.

Көз җитә, Рәхим авыл мәдрәсәсендә дүртенче елын укый башлый.

Икенче елны да алар Чистай ярминкәсенә баралар. Рәхим су сатуын яңадан бик теләп кабатлый. Бу елны җәй бигрәк тә эссе. Ярминкә беткәндә алар җыелган акчага берничә кадак ак он алып кайталар. Өченче ел да килеп җитә. Кадерләп кыш буе саклаган ак оннан Майбәдәр кызартып вак клиндерләр пешерә. Шул нигъмәтне алып алар яңадан ярминкәгә юл тоталар. Уңышлы гына сатып бетереп барлык җыелган акчага тагын ак он сатып алалар.

Дүртенче елны да шулай эшлиләр. Бу ярминкәдә бер Себердән килгән сәүдәгәр алар янына килә дә:

— Апа, мин сезне инде өченче елымны күзәтәм, малаең бик тә булган икән. Син аны минем белән себергә, Омск шәһәренә җибәрәсеңме, ул миндә сатучы булыр, кышларын укыр, кеше итәрмен үзен, сиңа болай арба тартып, клиндерләр сатып йөрергә туры килмәс, тормышыңны алып барырлык акча җибәреп торырбыз,— ди сәүдәгәр.

Ана белән малай үзара киңәшәләр дә, сәүдәгәрнең тәкъдименә риза булалар.

Рәхимгә инде бу вакытта унбиш яшь тулган, җегәрләре ныгып, бик шәп итеп укый-яза да белүе сәүдәгәргә бик ошап китә.

Рәхим сәүдәгәргә ияреп китеп, Омск шәһәрендә яңа тормыш башлап җибәрә. Сәүдәгәр аның тырышлыгыннан бик тә канәгать була. Тора-бара, сәүдәгәр Рәхимне үзенең иң ышанычлы кешесе итеп аңа барлык сәүдә эшләрен тапшыра. Өч кибете, берничә приказчигы булган сәүдәгәр Рәхимне уналты яшенә чыккан бердәнбер кызына өйләндерү турында уйлана башлый. Бу вакытта Рәхимгә дә унсигез яшь тулган була. Эшне озакка сузмыйлар, туй да ясап җибәрәләр. Бөтенесе дә әйбәт кенә барганда, илдә революция чыга, гражданнар сугышы башлана. Себер адмирал Колчак кулына күчә. Берничә ай үтми, кызыллар Колчак армиясен тар-мар итеп Себергә килеп җитә башлыйлар. Сәүдәгәр бик тә хәйләкәр, ерактан күрә белә торган кеше булганлыктан, байлыгын ычкындырмас өчен, кызыллар килеп җитә башлагач барлык мал-мөлкәтен арзанрак бәһагә сатып бетерә дә, яшь кияүне, үзенең кызын, хатынын алып Харбинга китә. Анда кибет ачып җибәрә.

Ниһаять, 1945 ел да килеп җитә. Совет гаскәрләре японнарны җиңеп Манчжуриягә, Кореяга барып җитәләр. Бу вакытта Рәхим инде олыгайган, берничә шәһәрдә йорт-кибет тоткан, үсеп җиткән кыз-уллары булган, Харбинда яшәүче татарларның бик шәп мәчетләрендә мулла булып тора. Совет гаскәрләре килеп җиткәч, ул тәрҗемәче вазифасын үти. Япон, кытай, корея телләрен ана теле кебек белгәнлектән, аны урыслар бик хөрмәт итәләр.

Җиңү тәэмин ителгәч, Рәхим мулланың кирәге калмый. Ул рөхсәт сорап, пропуск ала да, Төньяк Кореядәге Гензан шәһәренә яшь хатыны янына китә. Анда аның кибете дә була. Барысын да күз-колак булырга дип кайтса, ни күрсен — хатыны өйне бикләп, Кытайга, малае янына киткән. Кибет таланган. Ярый әле йорт исән-сау калган. Хатыны язу калдырган. «Сөекле картым, сугыш якынлаша башлагач, барлык акчаларыбызны, алтын-көмеш әйберләребезне алып китәргә мәҗбүр булдым» дигән язуны укыгач, Рәхим тынычлана.

Бер-ике көн үтми, берәү ишек шакый. Ачса — чибәр генә кызыл офицер басып тора. Килгән кешене куып җибәреп булмый бит. Танышалар болар. Керүченең фамилиясе Хафизов икән. Үзен Татарстанның Чистай районыннан дип тәкъдим итә ул. Якташын Рәхим йортта булган ризыклар белән әйбәтләп сыйлый. Хафизов саубуллашып китәр алдыннан

Рәхим мулладан әҗәткә акча сорый. Икенче көнне үк китереп бирермен, ди. Ә хуҗаның кул астында акчасы бик аз була. Хафизов канәгатьсезләнеп чыгып китә. Ярты төн житкәч, ишекне бик каты дөбердәтәләр. Рәхим төнге халаттан гына ишеккә килә. «Кем бар?» дип сораугa тыштан:

— Совет хәрбиләре,— дип җавап бирәләр. Тәржемәче булып хезмәт тә күрсәткәч, Рәхим, бәлки бик кирәк булганмындыр дип, килүчеләрне өйгә кертә. Алар исәнлек-фәлән сорашып та тормастан, өйнең астын-өскә китереп, тентү башлап җибәрәләр. Күп тә үтми берсе көзге артыннан япон маузерын табып ала. Шундук акт язалар, Рәхимне корал саклауда гаепләп кулга алалар.

Менә хәзер Рәхим мулла Владивосток төрмәсенең бер камерасында суд көтеп ята. Аның язмышы нәрсә белән бетәр, хәзергә билгесез.

— Харбин, Сеул, Гензан банкларында меңәрләгән акчаларым калды. Оныкларыма да җитәрлек,— диде, уфтанып Рәхим мулла миңа.

Судтан соң мине янәдан камерага кайтардылар. Рәхим мулла анда юк иде инде. Мин үз-үземне тынычландырдым, әйдә дим, кылансыннар. Барыбер гомерем буе утырмам әле лагерьларында. Иртәме, соңмы — барыбер котылырмын. Дөньялар үзгәреп тора, мәңгелек бернәрсә дә юк.

Төшке ашны ашап алдык. Күп тә үтмәде, мине янәдан «әйберләрең белән», дип кабат чакырып чыгардылар.

Төрмә ишек алдында йөзәрләгән кеше. Һәммәсе дә юлга җыенганнар. Барыбызны да кая булса да алып китәчәкләр.

Озакламый зур тимер капка ике якка ачылды. Безне бишәрләп тездeләр. Капканы чыгуга, автоматлар белән коралланган этле сакчылар каршылады. Колоннага кисәтелде: «Адым сулга, адым уңга — качу дип исәпләнә». Сакчылар автоматларын тоткыннарга төбәделәр. Менә кузгалырга боерык булды. Туганнарын күреп калырга дип, урамның ике ягыннан кешеләр йөгерешә. Кайсыларының кулларында төенчекләр. Кычкырыш, тавыш:

— Степан, син андамы?

— Федор...

Тагы-тагы әллә кемнәрнең исемнәрен атап дәшәләр. Колонна өстенә ыргытылган төенчекләр кулдан-кулга күчеп хуҗасына барып җитә. Сакчылар каты тавыш белән:

— Ярамый, ярамый,— дип, әледән-әле акыралар, кешеләргә якынрак килергә этләр ирек бирмиләр. Кыскасы, күңелсез тамаша. Барабыз да барабыз. Ике йөзләп чамасы тоткын җәһәт атлап шәһәрдән чыгып киттек. Акрынлап шәһәр кешеләре дә артта калды. Бер сәгать чамасы атлагач, таучык итәгенә урнашкан зур лагерь күренде. Аның берничә җирендә сакчы манаралары калкып тора. Биек койма белән әйләндереп алынган зона эчендә мал фермаларына охшаган озын-озын ак бараклар. Озакламый лагерь капкасы янына килеп туктадык.

Зур озын өстәл чыгарып куйганнар. Озатучылар кочак-кочак итеп безнең формулярларны шунда өеп тә куйдылар.

Исем-фамилияләребезне кычкырып берәмләп чакырып чыгара башладылар. Лагерь сакчылары кабул итеп тора. Һәрберебезне башта тентиләр, аннары гына зонага керәсең. ниһаять, миңа да чират житте.

Лагерь эчендә кабул итеп торучы комендант миңа кайсы баракка урнашырга икәнен әйтеп, кулы белән төртеп күрсәтте. Мин ул күрсәткән баракка киттем.

Әле караңгы төшмәгән иде. Тоткыннар зона эчендә йөреп яңа килүчеләрне каршылыйлар.

Баракка кердем. Буйдан-буйга өчәр катлы сәндерәләр тезелеп киткән. Һәрберсендә дип әйтерлек кайсысы яткан, кайсы утырган тоткыннар. Иң түрдәгесенә барып җиткән идем, исем китте, бергә төрмәдә утырган

танышым Рәхим мулла. Ул да мине күреп алды. Кочаклашып күрештек. Ничә ел бирүләрен сорадым.

— Өч ел,— диде ул.— Ә бит ул наган дигән нәмәстәкәйне теге юньсез Хафизов махсус эшләгәнлеген соңыннан гына аңладым. Банклардагы акчаларымны конфискацияләргә чамалаганнар, ә мин аны балаларым исеменә салган идем, булдыра алмадылар.

Мулла абзыйның сүзләре күңелемә хуш килде. Аның янына урын да алгач, күңел тагын да күтәрелде. Аның чит илдәге милләттәшләребезнең оешып бер-берсенә ярдәм итеп яшәүләре турында бәйнә-бәйнә сөйләве мине канатландырды. Болай да Харбин, Мукден, Чанчунь кебек шактый зур шәһәрләрдә татар җәмгыятьләре гөрләп торуы турында сугышка хәтле үк укытучым Нәкый ага Исәнбәттән ишетеп белә идем.

— Энем, безнең татар халкы барлык илләргә дә таралган, әдәбиятыбызны күбрәк укысаң, барысын да белерсең,— дигәнен һич тә онытачагым юк.

Рәхим абзый шул белгәннәремне тагын да киңәйтте. Югарыда әйтеп киткән шәһәрләрдә, «Милли байрак», «Чаткы», «Милли юл» кебек газета-журналлар чыгып килүен дә санап киткәч, мин таңга калдым.

— Татарның үз мәдәнияте, бай тарихы, дине бар. Гореф-гадәтләребезне ана телебездә балаларыбыз күңелләренә сеңдереп калдыра алсак, тарих безне һичкайчан дә онытмас. Без бит тарихыбызга хуҗа булырлык зур милләт балалары,— диде ул. Аннан үзенә генә хас сөйкемлелек белән елмайды.

— Син, улым, (ул мине төрмәдә үк шулай дип атый башлаган иде) һаман миннән читтәге татар тормышы, әдәбияты турында сөйләвемне телисең. Совет әдипләрен яхшы беләсең булыр. Аларның кызганыч язмышлары хакында сөйләүнең кирәге юк инде хәзер. Шундый зур мөхтәрәм Галимҗан Ибраһимов, Кәрим Тинчурин, Фәтхи Бурнаш кебек язучыларыбызны да совет юк итте. Ярый әле Гаяз әфәнде вакытында Рәсәйдән китеп калды. Ул бит иң мөхтәрәм әдипләрдән санала иде...

Мин шул мизгелдә Гаяз Исхакыйның «Зөләйха»сын исемә төшереп алдым. Ватан сугышына кадәрле аның шул исемдәге пьесалар китабы турында шагыйрь һәм язучы Кәрим Әмири сөйләгәне бар иде. Революциядән соң да әле бу әсәр Татар театрында куелган. Большевиклар пьесаны сәхнәдән бик тиз төшерткәннәр. Халыкка зарарлы дип, әсәргә тамга сугылган. Кәрим абзыйның ачынып-ачынып сөйләгәннәре әле дә күз алдымда. Менә хәзер Гаяз Исхакый турында мин кызыксынып Рәхим мулланы тыңлыйм.

— Илдән китсә дә ул татар халкын онытмады. Күп әсәрләр язды, хәтта Берлинда татар газетасы чыгара башлады. Төркия, гарәп илләре, Кытай, Япониягә кадәрле барып чыкты. Әле дә хәтерлим, Кытайга килгәч, татарлар яшәгән шәһәрләрдә булып, милләттәшләребез белән очрашу мәҗлесләре үткәрде. Мөһаҗир халкыбызның милли мәктәпләрен җанландыру, мирасыбызны туплау хакында кайгыртты. Мин муллалыкны соңгы елларда гына башкара башладым. Исхакый әфәнде Харбинга килгәч, үземдә торды. Сөйләшеп туя алмадык. Син әле миннән күп яшь, бәлки, илдә саф җилләр искәнен дә күрерсең,— дигән сүзләрен күзләрем йомылганчы онытачагым юк.

— Син, Локман улым, исән-сау илгә кайта алсаң, аның гүзәл әсәрләрен укырга тырыш. Большевиклар барсын да яндырып бетерә алмаганнардыр әле. Безнең халык ул хәзинәне саклый белә. Карт-корыларның сандык төпләрендә, чорма башларында, умарта эчләрендә саклана булыр. Минем үземнең Харбинда зур китапханәм бар. Татарстанга кайта алсаң, хат язып җибәр, үзем исән булмасам, улларым, кызларым калыр. Алар да минем кебек кеше яратучан, кешене хөрмәт итүчәннәр,— дип сүзен тәмамлады йоклар алдыннан ул.

Иртә белән артымнан эзләп килделәр. Комендант үзе белән башка баракка иярттe. Режимлы баракка билгеләнгәнмен икән. Лагерь эчендә

шундый барак та бар. Зона эчендә зона. Менә сиңа кирәк булса. Бусы да коймa белән әйләндереп алынган, өстенә чәнечкеле тимер чыбыклар тарттырылган.

Рәхим мулладан аерып алуларына эчем пошып, урын алырга дип түргә уздым. Кая карама — ябык йөзле, лагерь тормышының «түмен» шактый татыган урта яшьләрдәге тоткыннар. Зур баракның ишеккә якынрак бер өч катлы сәндерәсеннән үземә урын алдым. Тирәмдә таныш-фәлән күренми. Янәшәмдәге берәү:

— Монда, браток, асыл егетләрне генә җыялар, эштән баш тарткансыңдыр, йә качып карагансыңдыр, шулаймы? — дип куйды.

Әллә кем икәнлегем маңгаема язылганмы, исем китте.

— Әллә син дә качып карадыңмы?

— Браток, мин ике ел Приморьены буйдан-буйга гиздем, паспорт та алып өлгергән идем, Находка портында бер гад пароходка утырганда танып алып тоттырды....

Имән бүрәнәседәй таза гәүдәле, зур башлы, кысык кара күзле, киң маңгайлы, җәенке борынлы, юан муенлы бу кешене кайдадыр күргән кебек булдым. Никадәрле генә хәтеремне эшләтергә теләсәм дә, очына чыга алмадым. Танышып киттек.

— Николай Иванович, фамилиям Кобзарь була. Ата-бабадан килгән диңгезче...

Исемә төшердем мин бу кешене. Бергә флот экипажында Комсомольск шәһәрендә булганбыз икән аның белән. Әле ул мине таныймый тора.

— Ә син кем буласың, каян килеп эләктең бирегә?

Кем икәнлегемне әйтеп бирдем.

— Тукта, тукта, син шунда булдыңмы? — дип куймасынмы бу.

Яңадан таныштык. Моннан җиде ел элек бергә булган вакытларны искә төшереп алгач, күңелле булып китте. Менә бит ул дөнья ничек, тау белән тау гына очрашмый, ә адәм баласы кайда да булса бер күрешә икән...

— Штраф лагерына эләккәнсең икән — түз, монда озак тотмаслар безне. Сизәм, Колымага булыр. Анда да бит кешеләр яши. Үлмәбез...

— Үлүен үлмәбез дә, яшь гомер уза, сугышлар беткән, рәхәтләнеп тормыш корып җибәрәсе урында ят инде бинахакка, — дидем аңа.

— Бөтен ил җәфа чигә золымнан, мин дә синең кебек ирек хакында уйлап, җилкенеп яшим. Кара диңгездә десант операцияләрендә катнаштым, биш орденым гына бар иде бит, исәпкә дә алмадылар. Хәрби трибунал Украинамны яраткан өчен, милләтчелектә гаепләп, сигез ел ямады. Ну, беренче этаптан ук сыздым, күрми дә калдылар. Төрле җирләрдә кара эшләр эшләп йөрдем. Документларымны урладылар дип, милициягә язып бирдем, тикшерделәр, илдән язу килде, паспорт алдым. Әмма...

Режимлы баракта беренче төнемне үткәрдем. Монда чыгып йөрүләр юк. Ишек янында бәдрәф ролен үтәүче лакан. Аны көненә ике тапкыр чыгарып түгәләр. Әлләни зур булмаган баракта йөздән артык тоткын яши. Монда күпме тотасыларын берәү дә белми. Кайберәүләрнең әйтүләренә караганда, озак тотмаслар кебек...

Иртәнге паекларыбызны алырга ишек янына барып тезелдек. Шулчак урта яшьләрдәге берәү:

— Менә син кайда икәнсең, фраер, — диде.

Аптырап киттем. Кайда булса да күрдем микән, дип хәтерләргә тырышып йөзенә карадым. Юк, хәтерли алмадым. Никадәр генә төсмерләргә тырышсам да, очына чыгып булмады. Юньле адәм түгелдер әле. Башымны аңардан борырга өлгермәдем, ул якын ук килеп, яңагыма салып та җибәрде. Чак-чак кына аягымда басып калдым.

— Сез зобаный Сталин коммунистлары аркасында илне төрмә, лагерьлар белән тутырдылар, җир йөзеннән корытырга кирәк үзегезне, —

дип бәйләнә генә миңа. Янымда бер генә танышым да юк. Тизрәк Кобзарьга кычкырдым. Ул шундук чабып килеп тә житте. Эшнең нәрсәдә икәнен тиз аңлады. Теге янадан кулын күтәрә генә башлаган иде, шундый итеп үзенә чәпәде — идәнгә барып төшеп, ике мәртәбә тәгәрәп тә алды теге адәм актыгы. Аннары аягына басып, кырын-кырын каранып баракның түренә китеп барды. Югыйсә мин ул бәндәгә каршы тора алмаган булыр идем. Тамашаны карарга җыелганнар арасыннан берәү минем белән күрешергә кулын сузды. Иван икән.

— Син качканнан соң лагерьның яртысын дип әйтерлек төрле якларга таратып бетерделәр. Миңа эләккәнен белсәң иде...

Иван бик тә үзгәргән, йөзе суырылган, күзләре эчкә баткан. Күрәм, дөньяның җәфасын хәтсез татыган. Теге миңа кул күтәргән бәндә турында да әйтеп алды. Көнбатыш Украинадан, Тафуин лагерында писарь булып эшләгән.

— Икәү качкан булсак, бүгенге көндә иректә йөргән булыр идек,— ди миңа Иван.

— Үзең икеләндең, синең белән качсам, бәлки, чыннан да, эләкмәгән булыр идек. Ул Кобзарьга күрсәтеп:

— Кем бу? — дип сорады. Күптәнге танышым икәнлеген әйттем.

— Теге бәндә, монда икенче атнасын утыра, көчлелеге белән масаеп, хакимлек итмәкче була. Теге танышың шәп итеп бәрде үзенә. Бүтән якын килмәс...

Паекларыбызны капкалап алганнан соң, Иван бераз үзе турында сөйләде. Качарга омтылып караган, барып чыкмаган. Шунлыктан көчәйтелгән режимлы баракка эләккән. Колымага этап киткәнче тагын омтылыш ясап карыйм әле, ди.

— Ай-һай, булдырырсың микән? Зона эчендә зона, бараклар нык саклана. Синең уйларың бөтенләй акылсыз,— дим. Авыр сүз әйтүем аңа ошамады:

— Менә күрерсең, иртәгә мин монда булмам,— дигән була. Бу сүзләрен ул шундый ышанып әйтте ки, әйтерсең чынлап та чыгып китәчәк тә котылачак.

Кичкә кадәр барак буйлап йөрдек. Бер-ике мәртәбә Кобзарь янына барып килдем. Аңа Иван белән элек бер лагерьда утырганымны әйттем, кул гына селтәде. Карак-угрыларны җене сөйми икән.

Ниһаять, утлар алынып, барак эче яп-якты булды. Озакламый кичке барлау башланды. Санап тикшергәннән соң, лакан чыгаручылар артыннан Иван да иярде. Аларга булышкан иткәндәй кылана. Ишектә бер сакчы, надзиратель һәм комендант аларның чыкканын көтә.

Күп тә үтмәде, чыгучылар әйләнеп тә керде. Карыйм, Иван күренми. Исем китте, шулай ук ычкына алды микәнни? Әкияттәге убырлы карчыкның зинданы түгел бит монда. Койма башыннан үткәрелгән чәнечкеле тимер чыбыкларда — ток. Куырылган гәүдә эленеп кала. Кемдер Иванны надзиратель үзе белән алып чыгып киткәнен, аның вахта будкасында икәнен әйтте. Тәрәзәгә карыйм, зонада кешеләр йөргәли. Шулвакыт көтмәгәндә ут сүнде. Ә Иван һаман юк та юк. Бераздан утлар кабынды. Тынычлык урнашкач, Кобзарь янына, сәндерәмә мендем. Аның белән бик озак узган көннәрне искә төшереп яттык.

Иртәнге тикшерүдә Иван Скорняковны таба алмадылар. Актармаган җирне калдырмадылар. Табылмады. Мин аның иректә икәнлегенә акрынлап ышана башладым. Белмим, күпме йөрер, анысын әйтүе кыен. Әмма, эләгәчәгенә шикләнмим. Бу тирәләр режимлы зона дип атала. Кая карама лагерьлар, хәрби постлар.

Һаман Кобзарь белән сөйләшәбез. Статьяларыбыз бер. Уй-фикерләребез әллә ни аерылмый.

— Украинамны үлеп яратам, бу милләтчелек дип атала,— дип башлап китте сүзен.

— Ачы каһәр йөрәгемә үтте минем. Репрессияләр, гаепсезләрне гаепле итеп җыю — ул бары тик КГБны төзегән партиянең чиктән тыш намуссызлыгы. Мин моны яшьли аңладым. Шуның өчен партиягә кермәдем дә. Һәрчакны дөресен әйттем. Ә дөреслек — зур урыннарда утырган коммунистлар өчен кан дошманы икән.

Кобзарь миннән биш яшькә өлкәнрәк. Аның әйткәннәре минем күзләремне тагын да ача төште. Шулай да Совет дәүләтенең гадел законнары барлыгына өметемне җуеп бетерәсе килми, ниндидер кара көчләр хәрәкәт итә монда, дип уйлыйм...

## Җиденче бүлек

Бер атна үтмәде, безне режимлы барактан чыгарып тизделәр дә ачык машиналарга утыртып, каядыр алып киттеләр. Төнге унберләр тирәсе булганлыктан, кая алып барганнарын да чамаламадык. Тимер юл вокзалына караңгы урамнар аша алып килеп, бик каты сак астында маллар йөртә торган вагоннарга ашыктыра-ашыктыра куып кертеп, бикләп тә куйдылар.

Кобзарь белән янәшә ике катлы сәндерәгә урын алып сөйләшеп ятабыз. Октябрь азаклары булганлыктан, вагон әле ягылмый. Икебезнең дә өс киемнәребез шәптән түгел. Бушлатыбыздан башка җылы нәрсәбез юк. Күлмәк-ыштаннар инде берничә ай юылмаган. Керләнеп каткан. Вагонда без утызлап тоткын. Барысы да дип әйтерлек утыз-кырык яшьтәгеләр. Күбесе сугышларда катнашкан элеккеге солдатлар, офицерлар. Каракугрылар да шактый. Алар, сугышчылар күпчелек булганлыктан, таларга, яхшырак өс киемнәрен салдырырга хәзергә батырчылык итмиләр.

Вокзал артындагы диңгезгә терәлеп үк үткән тимер юлга туктаган вагонда туңып бик озак яттык. Ниһаять, кузгалып киттек. Тәгәрмәчләр тавышын тыңлап бара торгач, йоклап киткәнмен. Түшәмгә терәтелеп ясалган рәшәткәле тәрәзәдән көн яктысы төшкәч кенә уянып киттем. Кобзарь:

— Йокының кирәген бирдең, — диде. Хабаровскига җиткәнбез икән.

Көнбатышка таба юл тотканлыгыбызны белгәч, эчкә җылы кереп китте. Себер тайгаларына гына булмасын. Кешеләрнең сөйләшүләренә караганда, анда җәһәннәм. Ачлы-туклы килеш, тоткыннарны урман кистерәләр, торф, таш эшләренә йөртәләр икән.

Ниндидер станциядә поезд туктагач, өчәр йөз грамм икмәк белән икешәр иваси балыгы бирделәр. Вагон ишегеннән генә булса да дөньяның яктылыгын күрдек. Сакчылар чиратлап су ташып, безне «баба шулпасы» белән сыйладылар. Бу инде — өченче көнгә чыккач икенче мәртәбә сыйлануыбыз. Станция күренми, кайдадыр радиодан музыка тавышы ишетелә. Күрәсең, якында гына вокзал бар. Ләкин поездыбыз аннан шактый ерак тора.

Көтмәгәндә вагоныбызга дүрт НКВД офицеры һәм иңбашларында погоннары ялтыраган хәрбиләр менде. Кулларында формулярлар. Исем-фамилияләребезне тикшереп чыкканнан соң берсе:

— Кысылыбрак урнашырга туры килер, — дип вагонның сәндерәләреннән кешеләргә төшәргә кушты. Күп тә үтмәде, сәләмә киемнәр киенгән, йөзләре суырылган уңлап ябык тоткынны вагонга керттеләр. Менә алмаганнарын кулларыннан тартып мендердек. Аннары вагон ишеген ябып, бикләп тә куйдылар. Каян китерелгәннәрен сорашабыз. Казан ягыннан икән. Ай буе шул яктан маллар вагонында килгәннәр. Күбесен хәрби трибунал хөкем иткән. Үзем кебек тәбәнәк буйлы, утыз яшьләр тирәсендәге татар белән танышты. Ризван Мөхетдин улы Мөхетдинов, 1919 елда Татарстанның Биектау районы Ямаширмә авылында туган, Ватан сугышының беренче көннәрендә үк хәрәкәттәге армиядә булган. Снайпер икән.

Сугышка кадәре дә ул 1940 елны Бессарабияне Румыния алган вакытта хәрәкәттәге армиядә булган. Якташ та булгач, аның башыннан үткәннәрен тыңлыйм. Башта ул сугышның беренче көнен ничек каршылавын сөйләп китте.

— Безнең дивизия Доргавич төбендә туктаган иде. Мин снайперлар командасы урнашкан палаткада дневальный булып торганда, көтмәгәндә әллә нинди хәтәр тавышлар белән һавада самолетлар килеп чыкты да бомбалар ташлый башладылар. Нәрсә икәнлеген дә аңламастан, аптырашта калдык. Күп тә үтмәде, тревога сиренасы яңгырады. Аңарга кушылып шәһәрнең завод-фабрикаларының гудоклары уларга кереште.

Дегтяров дигән лейтенант ротага кереп:

— Германия безгә сугыш башлады. Әйдәгез, тизрәк машиналарга,— дип команда бирде.

Йөгерешеп тышка чыктык та машиналарга утырып Карпат тавының аргы ягына таба юнәлдек. Тигез кыр башланды. Командирларыбыз снайпер командасын алга таба дозорга җибәрде. Озак та бармадык, дошман танклары, аларга ышыкланган немец солдатлары күренде. Безнең белән үзбәк егете Хәмидуллин җитәкчелек итте. Полк артта, ничек кенә булмасын, дошманны җибәрми тору бурычы йөкләнгән иде безгә. Немецларга дәррәү ут ачтык. Полкка җибәрелгән элемтәчебез полкның чигенгәнлеген хәбәр итте. Без аз булганлыктан, Хәмидуллин күпсанлы дошманга каршы тора алмавыбызны аңлап, полк артыннан китәргә карар итте. Полкны Львов шәһәрендә куып җиттек. Күрәсең, чигенергә боерык булган. Икенче көнне полк, төнге караңгылыктан файдаланып, Киевка таба юлга чыкты. Немец төнлә белән һөҗүм итәргә батырчылык итми. Днепрның уң ягындагы Украинка, Трипел авылларында ай буе оборонада тордык. Дошманның көче күп иде. Днепрның сул ягына көймә, баржаларга төялеп чыгарга мәҗбүр булдык.

Каты сугышлардан соң Киев шәһәрен калдырдык. Бу сугышта снаряд кыйпылчыгы сул аягымны яралады. Немец артыбыздан куа гына. Көндез оборона тотабыз, ә төнлә чигенәбез. Бәрелешләрнең берсендә пуля уң кулымны тишеп чыкты. Инде бу вакытта полкны немецлар тәмам тармар итеп бетергән иде. Чигенгән вакытта камалышта калдык. Төнге бәрелештә немецларга әсирлеккә эләктем.

Киевтан читтәрәк, Дарница дигән җирдә, лагерьга җыеп, безне Германиягә төяп җибәрделәр. 1942 елның мартында Гамбург шәһәренә китерделәр. Андагы лагерьда бераз торганнан соң, шахтага эшкә җибәрделәр. Көн дә конвой сагы астында шахтага йөрибез. Эш авыр, ундүртешәр сәгать эшләтәләр.

Көз көне эшләүчеләр арасында татар кешесе мин генә идем. Шулай бер көнне, мине эшкә алып бармадылар. Немец солдаты үзе белән ияртеп якындагы әсирләр лагерына илтеп тапшырды. Икенче көнне поездга утыртып, Польшадагы Стильце шәһәренә урнашкан лагерьга китерделәр. Монда барысы да татарлар гына иде.

Бер-ике көн үтмәде, лагерьга каяндыр немец офицерлары белән ике татар кешесе килде. Аларның берсен күпләр тиз танып алды. Ул татар язучысы Абдулла Алиш икән. Немец хәрби киемендә, чиста итеп кырынган, башында офицер фуражкасы. Коңгырт зур кара күзләре белән безгә карап:

— Туганнар, туган илгә табан бару өчен солдат булырга кирәк. Инде беренче батальон китәргә хәзерләнде. Сез, мондагылар — барыгыз да икенче батальон солдатлары буласыз. Хәзергә сәламәтлегегезне ныгыту ягын карагыз...

Янында басып торган немец офицерының бер сүз дә татарча белмәвеннән файдаланып:

— Илгә таба китү үзебездән тора. Анда күз күрер,— дип әйтеп тә куйгач, без аның тел төбендә нинди фикер ятканын тиз аңлап алдык.

Абдулла Алишның балалар өчен язган әкиятләрен мәктәптә малай чагымда укыганнарым исемә төшеп китте. Килүчеләр баракларга кереп күбебез белән танышып, хәл-әхвәл сорап, мондагы тормышыбыз белән танышып йөрделәр.

Берәр атна лагерьда яшәгәч, беренче батальон егетләре саубуллашып илгә таба киттеләр. Алардан соң безне дә хәрби киемнәргә киендереп фронтка җибәрергә әзерли башладылар. Озак көтмәстән, безнең батальонны да көнчыгышка алып киттеләр. Львов шәһәренә килгәч, немецлар беренче батальонның партизаннар ягына кушылганнарын белеп алалар. Шуннан соң тиз генә безне кире көнбатышка бордылар. Львовтан Станислав шәһәренә җиткәндә, татар командирлары, паровоздан дистәләгән вагоннарны өзеп калдырып, урманга качалар. Немецлар калган вагоннарны Станислав шәһәреннән Франциягә алып киттеләр. Мин дә шунда идем. Инде бу вакытта без барыбыз да коралсызландырылган идек. Ниндидер кечкенә шәһәрчектә вагоннардан төшереп, зур гына алма бакчасына урнаштырдылар. Бер-ике көн үтмәде, яныбызга Шәфи Алмаз дигән кеше килде. Ул безгә булып үткән хәлләр турында кыскача аңлатып:

— Беренче батальонның язмышын Гитлерга әйтмәдек, шулай ук сезнең икенче батальонның да яртысыннан күбесе партизаннарга кушылуын немецлар белми. Күңелегезне төшермәгез, сезгә яңадан корал бирәчәкләр...

Чыннан да, бер-ике атна торгач, безне яңадан коралландырып, Франциянең төньягына алып киттеләр. Анда яр буе оборонасында тордык. Монда озак булмадык, яңадан машиналарга утыртып Бельгиягә китерделәр. Монец шәһәрендә тимер юл сакладык. Берничә ай да үтмәде, Англия, Америка гаскәрләре Франциягә бәреп керделәр.

Америкалыларга әсир төштек. Америкалылар безне эшкә җигә башладылар. Бервакыт вагон төягәндә уң кулым сынды. Госпитальгә салдылар. Озакламый Англиягә озаттылар. Лондоннан алтмыш чакрымнар чамасы кечкенә шәһәрчеккә урнаштык. Кулым бераз рәтләнә башлады.

Шулай беркөнне Лондоннан, Советлар Союзы илчелегеннән Кузнецов җитәкчелегендә кешеләр килде. Без монда җиде йөз кеше. Илгә кайтырга чакыралар безне. Башкалар кебек үк мин дә Ватаныма кайтырга теләгемне белдердем. Кайберәүләр кайтудан ваз кичтеләр. Имеш, кайту белән Сталин төрмәгә, лагерьларга утыртачак. Барлык әсирләрне дә ул, Ватанын саткан, дип тамгалый икән. Ни булса да булыр, дип кайтырга тәвәккәлләдем. Чит җирдә солтан булганчы, үз илеңдә олтан бул, ди татар.

Берничә көннән портка алып бардылар. Анда зур океан пароходына урнашып, туган илгә юл тоттык. Гибралтар бугазы, Төркия ярлары артта калды. Ниһаять, туган илгә якынлаша башладык. Одессага килеп җиткәч, тикшерү үттек. Аннары кем кая, туган якларга кайтып китте...

Ризван башыннан үткәннәрен бик озак итеп сөйләде. Мин аны бүлдермәдем. Абдулла Алишны мин яхшы белә идем. Аны күп кенә татар язучылары кебек һәлак булган дип уйлый идем. Ризваннан Муса Җәлил турында да ишеткәч, аларны исән дип уйлый башладым.

...Поезд туктальшында ике тәүлек тордык. Юлда тәгәрмәчләр «җырын» тыңлап баруга күнегеп беткән идек. Лакан чыгарганда гына һава сулап керәбез. Башка вакытта әшәке исеннән якын да килерлек булмаган лаканны чыгарып түгүче табылмый иде. Хәзер ашкынып, ишек ачыла башлау белән барып күтәрәләр. Һәркем бер-ике генә минут булса да тимер юл буе һавасын сулап калырга ашкына. Икенче тәүлеккә чыккач, без Ризван белән икәү, сакчылар сагы астында лаканны тимер юлдан беркадәр читкәрәк алып киттек. Тирә-якта урман иде. Деподан беркадәр читтәрәк икән безнең эшелон. Каранып торырга ирек бирмәделәр, тизрәк вагонга куып кертеп тә җибәрделәр. Себер — Себер инде ул. Бу тайга иле

хәзер — каторгалар, төрмәләр, тоткыннар иле. Кайчандыр тарих китабында укыган вакыйгалар искә төшә. Әле революциягә кадәр бик күп еллар элек патшаның гаскәр башлыгы Себерне буйсындырганда: «Безнекеләр унсигез кеше, ә җирле халык йөзләп иде, бик нык батырлык күрсәтеп сугыштык. Алла ярдәм итте безгә. Авылларын яндырдык, ирләрен үтереп бетердек. Аларның хатыннарын, балаларын үзебезгә әсир иттек, ә бирелергә теләмәгәннәре биек тау башыннан упкынга ташланып үзүзләрен һәлак иттеләр»,— дип патшага хат җибәргән. Нинди кабахәтлек! Имеш, аңар җирле халыкларны ут һәм кылыч ярдәмендә буйсындырырга «Алла үзе ярдәм иткән!» Менә шуларны искә төшереп утырганда вагон ишеге ачылып китте. Берничә хәрби менде. Исемлек белән барлап чыкканнан соң, өч көн элек керткән зэкларны аерып алып вагоннан төшерә башладылар. Ризван да шунда эләкте. Вагон ябылганчы якташыма кул болгап калдым.

Караңгы төшә башлагач, эшелоныбызга паровоз ялгадылар. Янадан кая барабыз икән инде? Ачлы-туклы булганлыктан йокы да керми. Янымдагылар да йокламый сыман. Аларның да үз кайгылары үзләренә җиткән...

Үземне бишектә тирбәлгән кебек хис итә башладым. Юк, бик кызу тизлек белән моңарчы бер дә күрмәгән нindидер белгесез дөньяга очам төсле. Һәм шул мизгелдә Җир шарының мәңге хәрәкәттә икәнлеген күңелем белән тоям. Ерак бабаларым да, аларның уллары да мәңгелек хәрәкәттә булганнар. Тормыш корып иген иккәннәр, балалар үстергәннәр. Илгә куркыныч килгәндә барысы да бер булып яуга киткәннәр. Исән калганнары кайтып яңадан тормыш корган. Ниһаять, минем әтием дөньяга килгән. Ул өч ир бала үстергән. Гражданнар сугышына киткән. Ватылып, җәрәхәтләнеп кайткан, әнием Шәмсекамәр белән матур гына яшәгәндә, илдә революция чыккан, патшаны төшергәннәр. Шул авыр елларның берсендә дөньяга мин туганмын. Яшәр өчен, тормышны дәвам итәр өчен. Ә болай газаплы сәфәрдә йөрү нигә кирәк? Күзләребез йомылгач та мәңгелек хәрәкәттә йөзәчәкбез ләбаса. Тормышта дөньяның гүзәллеген үз иркендә күреп, ләззәтләнеп яшәүдән дә кадерле халәт булуы мөмкинме соң! Ә бүгенге юлым — җәһәннәмгә сәфәр...

Поезд күпме баргандыр белмим, берничә көннән соң вагоннардан төшереп көчле сак астында каядыр алып киттеләр. Зона эченә кергәч кенә Хабаровск шәһәренең читенә урнашкан күчерелеш лагеренда икәнлегебезне белдек. Лагерьның исеме «Камитетская» дип атала икән. Тимер юл вагонында коры ризык ашап тәмам талчыгып, ябыгып беткән идек. Беренче көннән үк кайнар баланда бирә башлагач, җан бераз тынычланып китте. Күпме тотасыларын бирәү дә белми. Бараклар җитәрлек, һәммәсендә дә тоткыннар шыплап тулган. Монда яңадан танышу, аралашу китте. Мин Кобзарьдан калмадым. Диңгезче булганлыгы өчен генә түгел, бик гайрәтле, мине беркемгә дә кимсетергә юл куймаганы өчен дә күңелемә якын ул.

Иректә чагымда мин бу шәһәрдә чыгып килә торган «Тревога» газетасына язышa идем. Анда минем очеркларым, мәкаләләрем күп басылды. Газетаның редакторы Барый Корбанов, әдәби хезмәткәрләре шагыйрь Мөнир Мазунов белән Әдип Маликов, болардан кала тагын бер-ике журналист бар иде. Мине дә шул газетага эшкә алырга дип, командование исеменә Барый Корбанов язу язып җибәргән булган. Ләкин мине корабта кирәкле һөнәр иясе дип җибәрми калдылар. Редакция эшенә киткән булсам, бәлки бу газапларга дучар да булмас идем...

Көннәр бер эздән күңелсез генә актылар да актылар. Шулай беркөнне «этап» дигән сүз таралды. Тоткыннар умарта кортыдай купты. Хәбәр дөрес икән. Күпләр төшке ашны ашарга да өлгермәде, хәрби кешеләр баракка кереп, исемлек буенча тикшереп алдылар да, «әйберләрегез белән», дигән боерык бирделәр.

Янадан этле сакчылар. Янадан товар вагоннары. Без кереп урнашканда борынга алма исе килеп бәрелде. Күрәсең, ул вагонда алма булган һәм аны кайда булса бушатканнар. Озак көтәргә туры килмәде, кузгалып та киттек.

Ятагым сәндерәнең югары өлешенә туры килгәнлектән, вагонның рәшәткәле тәрәзәсеннән карап барам. Моны Кобзарь тырышлыгы дип беләм. Үзенә дә әйбәт. Пыяласыз тәрәзәдән һава кереп тора. Үткән җирләребезнең матурлыгын, алтын төскә төрелгән урманнарның кышка әзерләнгәнен күрәбез. Вак-вак станцияләр бер-бер артлы артта кала бара. Барысы да агач йортлардан гыйбарәт. Поездның барышын Кобзарь чамалады. Бу Себер түгел, диңгез ягына да бармыйбыз, каядыр Төньякка.

Ай яктысы белән коенган тайгага карап бара торгач, зур елга күренде. Юлдашыма:

— Карап ал әле, нинди елга икән,— дидем. Кобзарь башын калкытып ай яктысында көмеш сыман ялтырап яткан дәрьяга карап алды да:

— Бу Амур булырга тиеш, күрәсеңме нинди киң,— дип куйды. Су өстенә төшкән ай нурларына сокланып ләззәтләнәм. Хыялларым, киләчәккә баглаган өметләрем әле миндә сүнмәгән икән. Вакытлы җәбер, үтәр дә китәр, дип үземне тынычландырырга тырышам...

Ниһаять, тоткыннар эшелоны Ванин портына килеп туктады. Анда безне көчле сак астында вагоннардан төшереп тезделәр дә каядыр алып та киттеләр.

Күчерелеш лагере якын икән.

Фамилиям алфавит буенча икенче булып торганлыктан, миңа беренче партиядә үк зонага керергә туры килде. Галәмәт зур зона. Ул баракларны күрсәң, исең китәрлек! Барысы да калын бүрәнәләрдән салынган. Вахтага якынрак баракка урнаштым. Дүртәр катлы сәндерәләр. Тоткыннар күп аунаганлыктан, такталары шомарып беткән. Аскы катта урын булмагач, миңа дүртенчегә менәргә туры килде. Бригадаларга бүлделәр. Яңа килгәннәрне тезеп паек өләшергә алып бардылар. Өчәр йөз грамм икмәк белән икешәр тозланган балык бирделәр. Кичен баланда булачак икән.

Тамак ялгап алгач, зона белән танышырга чыктым. Җиде зона икән. Һәрберсендә меңәрләгән тоткыннар. Халыкның исәбе-хисабы юк. Бу кадәрле халыкны кайларга җибәреп бетерерләр, дип уйлый башладым. Түбәнсетелү, рәнҗетелүләргә ничек түзеп тора болар?

Бер-ике көн үтмәде, мин урнашкан баракның маңгаена сурик буяу белән эре хәрефләрдә «Яшәсен Трумэн» дип язып куйганнар. Күрәсең бу эшне төнен башкарганнар. Иртәгәсен зонага дистәләгән хәрбиләр кереп, шау-шу куптардылар. Тиз арада баскыч та табылды, язуны юып, кырып бетерделәр. Аннары кем башкарганын эзләсәләр дә таба алмадылар. Тоткыннар начальникларга берсеннән-берсе әшәкерәк итеп кычкыра башладылар.

— Ачтан үтерәсегез киләмени?!

— Авыр сугыш үткәргән халыкның канын эчеп нишләмәкче буласыз?

— Генералыгызны күрәсебез килә!

Тагын әллә нинди сораулар биреп, хәрбиләрнең өсләренә бара башлагач, алар тизрәк чигенү ягын карый башладылар. Күп тә үтмәде, безнең баракка таба вышкадагы пулемет көйләп чират та биреп алды. Гомеремнең урынсызга киселүеннән шүрләп, пулемет тыкылдый башлау белән баракка шылдым. Мин генә түгел, күпләр бер-берсен таптыйтаптый төрле якка сибелделәр. Үлүчеләр, яралanучылар хәтсез булды. Тиз арада каяндыр санитар машиналары килеп үлгәннәрне, яралыларны төяп зонадан алып чыгып киттеләр.

Мәхшәрдән соң озак тотмадылар, зонадан портка алып төштеләр. Анда галәмәт зур океан пароходы «Дальстрой» тора иде. Шунда

тоткыннарны көне буе төркем-төркем китереп кенә тордылар. Пароходның эче берничә катлы сәндерәләр белән җиһазландырылган. Халык килә тора, урнаша тора. Бу инде ерак сәфәргә китү дигән сүз.

## Сигезенче бүлек

Кырыс табигатьле, мәңге туң Колымада беренче кышымны каршылыйм. Пароходтан төшкәч, машиналарга утыртып Колыма елгасына кушыла торган Ясачная тамагына якын гына булган Зырянка дип аталган зур поселоктагы лагерьга китерделәр. Бараклар җитәрлек монда. Зона шактый киң. Һәр ягы биек коймалар белән әйләндереп алынган. Почмаклары саен тоткыннарны саклар өчен вышкалар куелган. Зонаның уртасында ашханә, аңа каршы янәшәдә генә клубы да бар. Берничә урында, гадел хезмәт белән акланып кына иреккә чыгарга мөмкин, дигән мәгънәдәге төрле лозунглар, өндәмәләр язылып баганаларга кадакланып куелган. КВЧ дигән клубында газета-журналлар, китаплар җитәрлек. Стенасына: «Бирегә беренче мәртәбә, 1643 елда Дмитрий Зырян дигән казак Ленадан җәяү килеп нигез салган, шул вакыттан бирле бу поселок Зырянка дип атала» дигән язу язылган.

Тоткыннар күп. Баракларга урнашкач кешеләр белән таныша, аралаша башладым. Магаданда мунча кертеп, өсләребезгә күлмәк-ыштаннар, аяк киемнәренә хәтле биргәннәр иде. Монда киез итекләр дә киерттеләр. Салкынлык егерме градус чамасы. Яңа килүчеләрне дә бригадаларга бүлделәр. Кемнең кайда эшлисе хәзер инде билгеле. Килүемнең беренче көнендә үк Демьянов дигән кеше белән таныштым. Ул да сәяси статьялы тоткын, күптән утыра икән. Элек комсомол эшендә булган. Бер баракта урыннарыбыз да янәшә булгач, сөйләшеп туя алмыйбыз. Материктан килгән яңа кеше булганлыктан, сораулар биреп аптыратып бетерде. Ашханәгә дә бергә барабыз. Кичләрен КВЧ га кереп газеталар белән танышабыз. Ләкин бу рәхәтлек күпкә бармады. Атна үтмәде, иртәнге чәйдән соң безнең бригадага вахта капкасы янына чыгып тезелергә боердылар.

Салкын иртә иде. Капка янына җыела башладык. Утызлап кеше икәнбез. Сакчыларның өсләрендә кыска ак тун, кулларында автомат. Стройда басып торабыз, вахтаның теге ягына алып чыгарга ашыкмыйлар. Кемнедер көтәләр. Бригадир баракка йөгереп кереп китте. Озакламый, аннан җилтерәтеп стройга Демьяновны китереп бастырды. Аның изүләре ачык. Лагерь нарядчигы сүгенә:

— Үткән елда урман командировкасына барудан баш тарттың, быел бу эшең барып чыкмас,— дип җикеренде ул аңа. Демьяновның аягында иске итек, чолгаулары кунычыннан чыгып тора. Рәтләп киенергә дә өлгермәгән. Кызгандым. Йомшак күңелле егет. Яше утызлар тирәсендә. Тормышның ачысын-төчесен күп күргән, шулай да лагерь аның матур уйларын, дөньяга карашын үзгәртә алмаган. Ул кичә генә:

— Унынчы елымны Колымада яшим, этап артыннан этап, туеп беттем инде сәфәрләреннән. Берәр җинаять өчен утырткан булсалар үкенмәс тә идем, гаепсезгә бит, гаепсезгә! — дигән иде.

Минем өчен Колыма — яңа җир. Аның турында күбрәк беләсем, кешеләре белән танышасым, табигатен йөрәгемә сеңдереп каласым килә. Бәлки, кайчан да булса иҗатыма кирәк булыр. Ниләр бар икән? Шулай хыялланып торганда, вахта начальнигы артыма китереп типте:

— Нәрсә, тәпәч кебек каттың, атла давай!

Демьянов минем янга килеп басты.

— Курыкма, үлмәбез әле,— дидем аңа. Ул дәшмәде. Кузгалырга команда булган икән. Капкадан Колыма елгасына кул гына сузасы. Ул инде хәзер шактый калын боз белән капланган. Тәбәнәк ярыннан шунда

төшеп киттек. Боз өстендә юл әйбәт. Шуннан аргы якка таба атладык. Зәһәр җил йөзебезгә бәрелә, колакларны чеметтерә, ирексездән кулларны җиңнәребез эченә тыгарга мәҗбүр булабыз, бөрешә-бөрешә атлыйбыз. Елганы да чыгып киттек. Таллыклар ышыгында бара башлагач җилдән котылдык, атлаулары җиңелрәк була башлады. Юл бетеп, тар сукмак башланды. Колыма үзәненнән атлыйбыз. Демьянов минем арттан бара, аның еш-еш сулыш алганын ишетәм. Яшь булса да бик ватылган. Аның белән сүз алышабыз. Лагерьда башлаган хикәясен дәвам итте. Колыманың бик күп урыннарында булырга туры килгән аңа. Хәтта Боз диңгезе буендагы Амбарчик дигән портта да кышлаган ул. Материктан китерелгән йөкләрне бушатып бетергәч, пароход белән үзәк лагерьга төялеп киткәннәр, ләкин кителмәгәндә Колыма боз белән капланып өлгергән. Аларны шундагы лагерьда кышларга калдырганнар. Болан көтүе көткән бер якут кызы белән таныша. Бик тә ягымлы була кыз. Кышын да аның янына лагерьга берничә мәртәбәләр килеп китә. Ризыклар алып килә.

Демьянов сөйләвеннән тынып калды. Аның сөйләүләреннән соң, мин иксез-чиксез тундра даласын, аның салкын кышын, Боз диңгезе ярларын күз алларымнан үткәрәм. Кабат юлдашка карап алам. Әйтерсең ул тоткын түгел, гүзәл кызга гашыйк бер егет. Хуҗа булып атлый Колыма илендә. Аның күңеле киң, йөрәге дәртле. Тормышка зур мәхәббәт белән яши. Төшенкелеккә бирелми ул.

— Йә, дәвам ит инде, тагын нәрсәләр булды?

— Ул елны Амбарчик портында без иркен яшәдек. Сакчыларыбыз безгә ияләшеп беттеләр. Кая барасың, бер якта Боз диңгезе, икенче якта Колыманың тундра даласы. Анда агачлар да үсми, җәен бөтен тирә-як дала, сазлык...

Берчакны шулай атна буена буран котырды. Ерактагы улыстан йөккә килгән боланнар китә алмый тордылар. Минем таныш кызым да олаучы булып килгән иде. Буран басыла башлагач, кыз мине үзе белән улысларына алып китәргә теләвен әйтте. Мин аның сүзләренә каршы: «Җүләр син, Наталья, мин бит тоткын, тоткынга лагерьдан китәргә һич тә ярамый»,— дим. Ә ул: «Начальнигыгыздан үзем сорыйм, өч көнә көнгә»,— ди. Кыз үзенекен итте бит. Начальник миңа рөхсәт бирде. Законлы булсын өчен начальник бер солдат та беркетте хәтта. Болан җигелгән чаналарга утырып тундра даласыннан сыптыртабыз гына! Болан җигелгән чанада барулары үзе ни тора!

Төньяк табигатенең кырыс көннәре, ничек итеп Натальясы белән болан җигеп кунакка барулары турында шундый матур итеп сөйли ул миңа — әйтерсең, мин дә аның янында бергәләп сәяхәт итәм инде...

— Наталья туган җир Колыма елгасының нindидер тар гына култыгы буена урнашкан. Сиңа гына әйтәм, йортлары гел инде, безнең Украинадагы түбәсез авыл мунчасы. Түбәсе балчык белән сыланган, эче тар. Шунда кыргый ташлардан өелгән миче дә бар. Барып кергәч, анасы кызын бик җылы каршылады.

— Болар кемнәр? — дип сорады. Наталья югалып калмады:

— Минем кунакларым,— диде.

Кыз белән ана тиз арада аш-су хәстәрләргә керештеләр.

Сый бик әйбәт булды. Мине озатып килгән солдат белән кунак булдык. Өстәлдә яшь болан ите, тундра даласы җимешләре тау-тау өелеп торды. Ике тәүлек кунак булдык. Сакчы ашыктырмаган булса, артыграк та торган булыр идек. Үземне өр-яңадан киендерделәр. Бигрәк тә миңа яшь болан тиресеннән тегелгән унталары бик ошады. Үзәк лагерьга кайтканчы мин аны аякларымнан салмадым.

— Ошаттым сине, срогың бетүгә үзебезгә алып кайтам үзеңне,— дип Наталья миңа чат ябышты.

Сөйләвеннән туктап уйга калып торды ул. Борчымаска теләп мин эндәшми тордым.

— Беләсеңме, минем аңардан кызым үсеп килә бит,— дип янадан дәвам итте Демьянов тормышының мәхәббәт хикәясен. Күрәм, аның күзләреннән яшьләр бәреп чыкты. Биш ел күрмәгән икән кызын. Наталья баласын тудыргач, Зырянка поселогындагы тоткыннар лагерена килгән булган. Ләкин лагерь башлыгы күрешергә рөхсәт бирмәгән.

— Нинди таш бәгырьле әдәм актыгы икән ул начальник?

— Без зэклар, ә алар кеше...

— Йомгак нинди генә дәү булмасын, барыбер сүтелеп бетә. Исең китмәсен, Демька, түз, синең әле иректә яшисең бар. Тарихны яхшы беләсең булыр, әнә бит нинди зур Рим империясен дә коллар какшаткан, аннары ул үзеннән-үзе җимерелгән.

— Көтә минем Натальям, көтә. «Гомеремнең соңгы көненә чаклы синеке генә мин» дигән сүзе әле бүген әйтелгәндәй күз алдымда яңгырап тора сыман. Синең белән атлыйм, ә күңелем беләсеңме кайда минем?

— Натальяңда дип уйлыйм.

— Анысын мин сүз арасында гына сөйләдем. Төп уем, иректәге чакларым. Яшь вакытымны исемә төшереп алдым әле...

Аны бүлдермәдем, сораулар биреп борчымадым. Бәлки шулай кирәк булгандыр да. Демьянов дәртләнеп яңадан сөйләп китте.

— Үземне комсомол секретаре итеп сайлап куйганнан соң, яшьләр белән якыннан торып аралаша башладым. Аларның йөрәкләрен нәрсә телгәнен аңларга кирәк иде миңа.

— Аңлый алдыңмы соң?

— Аңладым, аңлавын, ләкин үз башыма аңладым.

— Ничек.

— Коллективлашу буенча ата-аналарыгыз сүзен тыңлагыз, алар тормышны күп күргән, каршы бармагыз,— дигән идем. Шул сүзем өчен райкомга чакырып сүктеләр, аннары шул ук көнне өемнән ике милиционер килеп алып та китте. Башта биш ел бирделәр. Шикаять яздым. Яңадан биш ел өстәп срогымны арттырдылар. Себер лагерьлары, Соловки, Казахстан... Кайларда гына булырга туры килмәгәндер миңа. Сугыш беткәч, срогым тула инде дип торганда, тагын ун ел өстәп, Колымага китерделәр. Бер контр дип печать сукты дармы, син шул каһәрләнгән статьядан котылырмын дип уйлама инде...

Атлый торгач ярыйсы гына юл үткәнбез. Җылынып беттек, җилкәләребездән пар күтәрелә. Күңелен борчып торган уйларын миңа бәйнәбәйнә сөйләп эчен бушаткач, аңа рәхәт булып китте күрәсең, коңгырт күзләре матур елмайдылар. Яшьлеге туган якларыннан бик еракта узган яңа танышымны кызганып алдым.

— Килеп җитәбез инде, абзаң бирегә бишенче тапкыр атлый инде.— Ул миңа текәлеп карап ала. Дәшмәгәч:

— Курыкма, андагы начальник әйбәт кеше, мине бик яхшы белә, авыр эшкә куймас әле.

Килеп җитәбез дип әйтсә дә шактый атларга туры килде.

Көн салкын. Күк йөзе аяз. Еракта түбәләрендә мәңге карлары эреп бетми торган Аргаташ таулары күренә. Аның итәкләреннән башлап тайга җәелгән. Ул Колыма елгасы белән генә урталай киселгән дә без атлаган уйсулыкны үтеп әллә кайларга кадәр киткән. Аның очы да кырые да күренми.

— Биредә аюлар, бүреләр җитәрлек. Шулай бер елны әле без атлаган урман кисә торган җиргә бүре өере килеп, атларга һөҗүм итте. Дисталәгән конвоирлар автоматлары белән аларга каршы чыгып көчкә куып җибәрә алдылар. Шулай да ике атыбызны абзар түбәсен җимереп төшеп, буарга өлгергәннәр. Шул чакны биш бүрене үтергәннәр иде,— дип Демьянов бу турыда хикәя кылып алды.

Урман диләнкәсенә килеп җиткәндә, кояш төшлектән авышкан иде инде. Колыма елгасы ярыннан беркадәр арырак хәтсез генә ике озын барак күренде. Шунда ук тәбәнәк корылма да бар. Вышка-фәлән күзгә чалынмады.

Калын бүрәнәләрдән салынган тәбәнәк йорттан өч кеше килеп чыкты. Аларның берсе хәрби түгел. Мин аны шундук, килгәндә Демьянов әйткән начальник, дип уйлый алдым. Ялгышмаганмын, үзе икән. Ул кыска кара туннан, башына бүре тиресеннән тегелгән бүрек, аякларына тезенә чаклы җиткән кара ката кигән иде.

— Аның белән бергә Угольнаяда биш ел элек бергә булдык, ирекка чыгарсалар да китмәде, монда Колымада калды,— дип Демьянов аның турында миңа белгәне кадәре сөйләп алды.

Монда килеп эләккәнче студент булган икән. Билгеле, актив комсомолец. Болар курслары белән Волга каналына экскурсиягә барганнар. Ул шунда атасының тоткын булган хәлдә социализмның бөек төзелешендә эшләп срогыннан элек котылуын, каналны төзүдә төп авыр эшләрне тоткыннар башкаруы турында әйткән. Шуның өчен әйләнеп кайтуына аны төнлә йокысыннан торгызып төрмәгә алып киткәннәр. Нахакка утыртулары турында камерадан Сталинга хат язган. Анда ул кемнәрнеңдер усал ният белән яла ягуын, НКВД кешеләренең аларга ышанып бер дә гаепсезгә төрмәләргә утыртуларына мисаллар китереп язган. Моны ул зур хата дип, халыклар атасына җиткерергә теләгән. Ләкин теләгенә ирешә алмаган. Советка каршы агитация алып баруда гаепләп, 37 нче елда яңа срок биргәннәр. Угольнаяда күмер шахтасында эшләп, бер көне өч көнгә хисапланганлыктан, менә инде дүртенче елын ирекга икән ул.

Демьянов миңа:

— Күрәсеңме, монда зона-фәлән юк. Качарга теләүчеләр булса, рәхим итсеннәр. Ләкин качып кая барасың, тайга да, Колыма сахралары гына. Кеше яшәгән урыннар меңәр чакрым. Китеп кара инде син, ачтан һәлак булуыңны көт тә тор. Ә кая карама сазлык, йә берәр ерткыч авызына барып эләгәсең, йә сазга батып һәлак буласың...

Хуҗа исемлек белән барлап чыккач, безне баракка кертеп җибәрделәр.

Килеп кергәч тә, күзияләшмәгәнлектән, барак эче кап-караңгы булып күренде. Ике яклап икешәр катлы сәндерәләр тезелгән. Алар барысы да беләк юанлыгы түгәрәк агачлардан булып, бер-берсенә юкә бавы белән беркетелгәннәр. Уртада тимер кисмәктән эшләнгән мич сыман нәмәрсәкәй бар. Шуңа калай торба ялгап куйганнар да түшәмгә сузганнар. Мич эчендә дөрләп ут яна. Күз ияләшә төшкәч, баракның аргы башы да күренә башлады. Бергә килеп керүчеләрнең күпләре мичне сырып алып җылынырга керештеләр.

— Нәрсәгә катып калдың, әйдә урнаш, әллә мендәр китереп бирерләр дип көтәсеңме?— диде миңа Демьянов.

— Юк, туганкай, алай уйламыйм, күз ияләшеп бетми әле...

— Ияләшер, ияләшер.

Идәне дә колгалар тезеп эшләнгән икән. Шуннан атлап Демьянов басып торган сәндерә янына бардым. Мичтән бигүк ерак булмаган сәндерәнең астагысына утырдым. Матрасына, мендәренә кипкән үлән тутырылганга күрә, урыным ярыйсы гына йомшак булып чыкты. Мичтән җылы бәреп тора иде, бушлатымны салырга туры килде.

Озакламады, баракның аргы башындагы бүлемтәнең тәрәзә кебек итеп эшләнгән капкачын ике якка да киң итеп ачып куйдылар. Аннан куе пар бөркелеп чыкты.

— Ашарга,— дип кычкырдылар. Пар бөркеп торган тәрәзә янына җыела башладылар.

— Әйдә,— диде Демьянов,— әрсезрәк бул, югыйсә урман баландасыннан колак кагуың бар,— дип тә өстәп әйткәч, мин дә аның артыннан китеп чиратка бастым.

Баракта сукыр лампа янып тора. Кешеләр һәркайсы үз эшләре белән шөгыльләнә. Ямау ямыйлар, эш киемнәрен рәтләгән булалар. Кемнең нинди эшкә барасын белмибез әле. Янымда бер егет килеп утырды. Буйга әлләни калку түгел. Шулай да эре сөякле. Күз карашларыннан аның

шактый үткен булуы сизелә. Үзәк Зырянка лагерендагы тормыш турында сораштыра башлады ул. Икенче елын урман кисү эшендә икән. Җаен дә монда булган. Атларга печән хәзерләгәннәр. Хәзер бүрәнә чыгару эшендә икән. Безгә дә нинди эшләр йөкләнәсен белә. Әле нарядчикның үзен күрмәсәк тә, егет сүзләреннән кеше түгеллеген аңладык. Безнең брат белән хисаплашып тора торганнардан булмавын белгәч, күңелебез төште. Эшкә чыкмаучыны, нормасын илле процентка да тутыра алмаучыларны җир астында казып ясалган карцерга яптырып, өчәр тәүлек ач килеш тотуларга чаклы җәберләү куллануны алдан белгәч, һәммәбезгә дә шом төште. Аның тозагына эләгүчеләр бүген килүчеләр арасында бар. Ерткычның иң кабахәте, диделәр, исемен ишеткәч. Шулвакыт баракка ике кеше килеп керде.

— Әнә, безнең түрәләр,— диде яңа танышыбыз. Өлкәне комендант булып чыкты. Аның кулында калын гына журнал. Исемлек буенча барыбызны да эшкә билгеләп чыктылар. Мин һөнәр иясе түгел. Кая, кем итеп билгеләсәләр дә разый.

— Атта эшләгәнең бармы? — дип сорады нарядчик миннән.

— Юк, җиккәнем дә, йөргәнем дә булмады,— дидем.

Аннан ул:

— Агач кисүче итеп язып куй үзен,— дип булышчысына әйтте. Миннән соң чират Демьяновка җитте. Аны күргәч, хуҗаларның чырае сытылды.

— Син, асыл кош, яңадан бирегә килеп эләктеңме? Теге елны җәфалавың җелеккә төште. Нинди кош икәнлегеңне яхшы беләбез. Йә, әйт, кем булып эшләргә телисең?

Демьянов, күзен нарядчикка текәп:

— Үзем теләп килмәдем. Кем итеп билгеләсәгез дә, мин риза,— диде.

— Яз, баракка кизү итеп.

Булышчысы шундук язып та куйды.

Билгеләү эшләре беткәч, алар бaрактан чыгып киттеләр. Әле йокларга иртә иде. Тоткыннар җыелышып үзара сөйләшеп утыралар. Башкача эш юк. Көне буе тимер мич ягылып торганлыктан, барак шактый җылы. Ишек янындагы стеналар бәсле булса да, салкын түгел. Ятагымның иске булса да, одеялы бар. Өстенә бушлатымны да каплагач, туңарлык булмады. Хәтсез юл килгәнлектән, шактый арылган булган, бик тиз йокыга киткәнмен.

Чаң суккан тавышка уянсам, тоткыннар ыгы-зыгы килә. Аягыма тимер мич янына куйган киез итегемне алып кидем. Тышка чыгып, саф һава сулап, битемне кар белән сыпыргалап як-якка карандым. Әле каптаранңгы. Таң беленә дә башламаган. Чаң дигәннәре баганага элеп куйган рельс кисәге булып чыкты. Шуны кагып, ике баракка урнашкан тоткыннарны уятканнарын белдем. Вахта янында сакта торган сакчы күземә чалынды. Ул озын толыптан. Кулында — автомат. Йөргәләп тора. Якындагы ат абзарында атларның пошкырганы ишетелгәли...

Тоткыннар бараклардан вахта янына җыела башлады. Билгеләнгән бригадам янына барып бастым.

— Кайда югалдың? Әбиеңә коймак ашарга килдеңме әллә? Мә пычкыңны ал, югалтсаң башың белән җавап бирерсең,— дип, бригадир, җикеренеп, әшәке сүзләр әйтеп, кулыма тоттырды.

Конвоирлар егермеләп, һәрберсенең кулында автомат. Каяндыр командировка начальнигы килеп чыкты.

— Сез барыгыз да эшкә килдегез, нормагызны тутырсагыз, үзегезгә яхшы булыр, бер көнегез икегә исәпләнәчәк. Сез кискән агачлар социализм төзелешенә китәчәк,— дип башлап җибәрде ул сүзен. Аның әйткәннәре бер колагымнан керде, икенчесеннән чыкты. Үз кайгым йөрәгемне чәнчеп тора. Бу мәңге туң Колымадан ычкынуымны башыма да китерә алмыйм...

Сак астында вахта янынннан үтеп, караңгыланып торган урманга юл тоттык.

Менә ул тайга! Мәһабәт наратлар башларын күккә сузганнар. Шулар арасына көрт ерып килеп кердек.

Яктыра башлаганлыктан, тирә-якны күрерлек. Бригадир кайсыларны кисеп аударырга икәнен күрсәтеп йөри башлады. Агачлар ышыгында булгач, җилнең барлыгы да сизелми. Биек наратлар безне кызганган сыман моңсуланып үзләрен кисә башлавыбызны көтәләр. Мин алтмыштан узган яһүд белән эшлим. Калку гәүдәле, киң йөзле, кәкре борынлы, коңгырт күзле кеше. Миңа ышанып бригадирдан үзе сораган булса кирәк. Ни әйтсәң дә яшь бит әле мин. Эшли ала торган чак...

Урман эче пычкы сызган моңнар белән җанланып китте. Сакчылар берничә урында учак ягып җибәрделәр. Шунда чиратлап җылыналар. Нәрсә аларга, тирләп-пешеп пычкы тартасы юк.

Гөрселдәп йөзәр еллык агачлар ава башлагач, зур төзелеш мәйданын хәтерләтте урман. Һәркем үз эшендә. Бригадирлар гына начар эшләүчеләргә җикеренеп тынычлыкны бозып куя. Калын агачны кисеп аударыр алдыннан талчыгып билемне турайтырга дип башымны калкытырга өлгермәдем, сыртыма калын таяк белән китереп тә суктылар. Карасам, бригадирыбыз икән.

— Әбиеңә кунакка килдеңмени?!

— Кулың кычыттымы әллә?

— Әле шулаймы!?

Яңадан таягын күтәрде бу. Урынсызга җәберләвенә шундый ачуым килде, түзмәдем, кинәттән ияге төбенә башым белән бәрдем тегенең. Үз акылына килгәнче аяк чалып аудардым да өстенә менеп атландым.

— Башка миңа кул күтәрсәң, бугазыңны чәйнәп өзәм,— дип җан ачуым белән ябыштым.

— Тукта, тукта, нишләвең бу?— димәсенме.

— Эт токымы, син дә бит тоткын...

Бригадир аягына торып басты. Якын тирәдәгеләр эшләрен ташлап, нәрсә булыр икән дип, күрәсең, карап тора башладылар. Ул әлләни таза кешегә ошамый, ябык кына чандыр адәм. Беренче көннән үземне җәберләтсәм, көн күрсәтмәячәк. Бернәрсә дә югалтасым юк. Башланмаган ундүрт ел срогым бар. Һәрбер кәнтәйдән кыйната башласам, нәрсә була ди ул?!

Бригадир үтерердәй ачуы чыккан караш ташлап, янымнан әле безнең эш бетмәде дигәндәй, китеп барды. Бергә эшләүче яһүд, ул күздән югалгач:

— Моның ахыры үзең өчен бик начар булыр, түзәргә кирәк иде, алар барысы да шулай, менә күр дә тор, нормасын тутырмады, дип язып куяр әле,— диде.

Агачларны аударабыз, алмашлап балта белән ботакларын әрчибез. Сөйләшкәләп алгалыйбыз. Сүз арасында аның кем икәнлеген дә белдем. Арнольд исемле кеше иде ул. Теш врачы булган. Күпне күргән. Ун елын инде утырган. Яңадан дүрт елы калган. Күпләп кулга алуларда, репрессияләрдә Советлар Союзының ныгуын күрә. Ә мин яшьләрнең дөреслек эзләүләрен, шуның аркасында төрмәләргә эләгеп газап чигүләрен аңлатырга тырышам. Сәбәпсез хөкемгә тартылганнарның гаепләре юклыгын әйтәм. Ышанмый. Арнольдның бердәнбер гаебе — «Сталин Германия фашистларын да уздырып җибәрде. Сугышның беренче көннәрендә үк кулына корал алган солдатларны әсирлеккә эләккән өчен кайтуына төрмә, лагерьларга утыртып дөрес эшләми»,— дигән сүзе. Тикшерү вакытында әйтмәдем дигән булса да, җәбер-золым белән гаебен танырга мәҗбүр иткәннәр.

Эшебезнең нәтиҗәсе булып, унар метрлы бүрәнәләр карда аунап калды. Аларны атлар белән Колыма култыгына ташыйлар.

Арып-талып соң гына кайттык. Баракка керүемә мине Демьянов каршылады. Ул бригадир белән булган бәрелешебезне белгән. Мине хупламады.

— Кирәкмәс иде,— дип куйды.

— Сыртыңа таяк белән сыптырсыннар әле, син түзеп торыр идеңме?

— Әлбәттә, юк.

— Шулай булгач...

— Кыюлыгыңны хуплыйм,— дип әйтеп бетерергә дә өлгермәде, мине лагерь башлыгына чакырдылар. Барырга туры килде.

— Кем икәнлегеңне күрәсем килгән иде. Менә син нинди кеше икәнсең,— дип, салмак кына итеп бригадирның үзе тарафыннан куелганлыгы, аның сүзен тыңларга кирәклеге турында әйтеп алганнан соң:

— Бу юлга кичерәм, бүтән бригадирга кул күтәрәсе булма,— дип чыгарып җибәрде.

Баракка кайтып кергәч, Демьянов:

— «Кәнтәйләр» белән сак бул, туры килгәндә кабыргаңа перо төртергә дә куллары калтырамый аларның, ә начальнигыбыз 58 нче статья кешеләрен хөрмәт итә белә,— дип куйды.

Кич йоклар алдыннан яңа танышым Кучма килеп утырды.

Моңарчы тоткыннарның төркемнәргә бүленеп яшәвен ныклап аңлап бетерми идем. Кучма бу турыда ачыклык кертте. Ничек була инде ул: карак һәм кәнтәй? Араларында аерма күк белән җир арасы диярсең. Икесе дә җәмгыятебезнең иң кирәксез паразит микроблары булулары гына җитмәгән, лагерь тормышында, юкка-барга эләгеп, җәбергә дучар ителгән эш кешесенең теңкәсенә тияләр. Ярый ла, фронтларда булганнар күбрәк булып, аларга юл куймасалар? Лагерьда начальнигыннан башлап конвоирларына кадәр гади халыкның котын алып, шулар кулы белән кыерсыталар.

Көн дә урман кисәргә йөрибез. Сакчылар смена буе учак ягып җылынып, безне саклый. Бирелә торган ризык җитми. Эш авыр. Баштарак нормабызны үтәдек. Соңга таба көннән-көн ярыйсы гына ватылдык. Өшегән бәрәңге шулпасы, солы боткасы белән генә авыр эштә эшләү тәмам йомшартты. Ит, май кебек ризыкларны төштә дә күргәнебез юк. Алты йөз грамм икмәкне өчкә бүлеп ашасам да, ул җитми.

Көннәр салкыная башлады. Кырыгар градуска җитсә дә эшкә куалап кына тордылар. Бармыйсың икән, карцерга ябылуыңны көт тә тор. Ә анда тәүлегенә өч йөз грамм икмәк белән бер кружка җылы су.

Икенче аебызга киткән иде инде. Арып-талып эштән кайтуыма Демьянов елмаеп кашларын җыера-җыера мине каршылады.

— Сыйлыйм әле үзеңне бүген,— ди бу.

— Нәрсә белән сыйламакчы буласың?

Демьянов, каяндыр табып алган, яньчелеп беткән, кап-кара чиләкне үзенең сәндерәсе астыннан чыгарып, минем тумбочка өстенә китереп тә куйды. Әле моңарчы аның мондый чиләге барлыгын белми идем. Каян алгандыр ул аны. Мине чиләге түгел, аның эчендә нәрсә барлыгы кызыксындырды. Күз салсам, ни күрим, куерып беткән саргылт нәмәрсәкәй ярты чиләктән дә артык.

— Әйдә кашыгыңны чыгар!

Үзе шундук күкрәк кесәсеннән алюмин кашыгын чыгарып, шунда үрелде. Аның артыннан калып булмас инде дип тумбочкамнан мин дә кашыгымны алдым.

— Әйбәт нәрсә икән?

— Монда икебезгә дә җитәрлек, сыптыруыңны бел.

Куе гына итеп пешерелгән кылчыклы солы боткасы икән. Ашарлык үзе, тозы да таман гына. Мае булмаса да, тәмле. Көн дә бирелә торган бәрәңге шулпаң бер якта торсын. Вакыт-вакыт теш арасына тулган солы кылчыкларын төкергәләп алабыз да яңадан ашарга тотынабыз. «Урман командировкасы»на килгәннән бирле беренче сыйлануым.

— Каян эләктердең бу затлы ризакны? — дидем.
— Туры килде инде, анысы аның сиңа кирәкми..
— Йә, әйт инде?
— Сез эшкә киткәч, конюшняга кердем. Шуннан бер бүрек солы эләктердем. Берәү дә күрмәде...
Кылчыклы ботка ашый-ашый тирләп беттем. Тамагым туйгандай булды.
Демьяновның эше җиңел. Барактагы ике тимер кисмәктән ясалган мичне яга, чүп-чарны себерә, бәкедән су китерә. Артыгы соралмый да аңардан. Сые өчен зур рәхмәтемне әйтеп, әҗәтле калмам, дидем. Белмәссең, миңа да шундый табыш очравы мөмкин.
Түрдәге кухня тәрәзәсеннән баландамны алырга киттем. Кеше дә юк иде инде. Пешеҗче кастрюлемә тутырып салып бирде. Ятагыма кайтып, теләр-теләмәс кенә капкаладым да савытын илтеп куйдым.
«Урман командировкасы»на элек карак-угрыларны җибәреп караганнар. Әмма алардан эш чыкмаган. Җүнләп эшләмәгәннәр. Ә Дальстрой агач сорый. Үзәк лагерь начальниклары андыйларны күмер шахталарына җибәрергә мәҗбүр булалар. 58 нче статьялылар эштән баш тартмыйлар. Минем белән килгәннәр дә күбесе шундыйлар. Демьянов белән бу турыда гәп сугабыз, фикер алышабыз...
Кемнеңдер кулы одеялымны ачуга, кинәт уянып киттем. Карасам, ятагым янында ике кеше басып тора. Аларның берсе комендант, икенчесе вахта начальнигы. Исем-фамилияне сорадылар да:
— Кирәкмисең,— дип, башка сәндерәгә таба күчтеләр. Кемнедер эзлиләр. Алар чыгып киткәч кенә барак кизүе Демьянов кайтып керде. Сукрана-сукрана тимер мич янына килде. Мин торып:
— Нәрсә булды? — дип сорадым.
— Икәү качып киткән. Бәдрәфкә дә кеше артыннан чыкмам инде. Сакчылар йоклаганга мин нишләп гаепле булыйм? Миңа урынсызга бәйләнәләр. Белгәнсең, диләр...
Йокым ачылып беткән иде инде. Ирексездән киенергә мәҗбүр булдым. Яна торган мич янына барып бастым.
— Кемнәр качкан?
— Теге син белгән чегән егете Роман. Кичен бик тә уйланып күңелсез генә утырганын күргән идем. «Авырыйсыңмы әллә?» дип сорап та карадым үзеннән. «Үзәк лагерьга кайтасым килә, анда ашау әйбәтрәк, тамагым туймый, түзәр хәлем калмады»,— диде миңа.
— Артыннан куып житеп тотсалар?..
— «Урман командировкасы»ннан качучыларны терелəй алып кайтмыйлар. Моннан өч ел элек өчәү ычкынганнар иде, чегән кебек яшьләр түгел, җилкәләрендә тормыш тәҗрибәсе булган таза ирләр булсалар да, куып житеп атканнар. Берсенең срогы да өч кенә ел калган булган...
Демьянов сөйли, мин уйланам. Шулай шул, йөрәк түзми, сабырлык бетә. Яшәүдән ваз кичәрдәй буласың. Ничек кенә булмасын, авыр тормыштан котылырга телисең. Колымадан качып кая бара аласың? Игечиге күренмәгән тайга, мүк үскән сазлы иңкүлекләр, хисапсыз күп вак елгалар, алар җәй айларында үтәрлек түгел, бу турыда уйлама да! Ә кыш көне ашарга ризыкны каян табасың? Канатлар кирәк, канатлар! Очып кына котылып булыр бу туң илдән.
Демьяновның сөйләвенә караганда, качучыларны элек тә атканнар, әмма срок бирмәгәннәр. Артыңнан куа китеп тотсалар — беттең. Үзең кайтсаң, үтергәнче кыйнап изоляторга ыргытканнар. Исән калсаң, синең бәхетең...
Чаң кактылар. Торкыннар ятакларыннан тора башладылар. Баракка түрәләрдән берәү килеп керде. Киенүчеләргә карап алды да:
— Бүген эшкә бармыйсыз,— диде.
Сәбәбен аңладым. Барлык конвоирлар аякка бастырылган. Күпләрен качкыннар артыннан җибәргәннәр. Димәк, ЧП дигән сүз.

Яныма Кучма килде. Анын йөзе суырылган.

— Харап итәрләр инде чегән егетен,— дип куйды. Ичмаса кызгана белә ул. Ә бит бу сыйфатлар күпләрдә беткән. Хокукыннан мәхрүм ителгән кеше, бары тик үзе турында гына уйлана башлый. Кучма белемле, ак белән караны аера белә. Колымада совет законнарының гамәлдә булмавын миннән дә шәбрәк аңлый. Кем үтерми, аның үзен үтерәләр, диде ул миңа. Күп еллар утыручылардан ишеткәнем бар. Чыннан да, шулай икән. Әле моннан берничә генә ел элек Колымада тоткыннар восстаниесе булган. Берничә лагерь күтәрелгән. Корал эләктергәннәр. Сакчыларның күбесен үтереп, коралсызландырып иреккә чыгуга ирешкәннәр. Зур бер төркем Беринг бугазына таба, икенче төркем Якутскига киткәннәр. Армия чакыртып кына бастыра алганнар.

Иртәнге икмәкне алып ашарга утырдык. Кичәге сыйланудан соң әлләни ашыйсы да килмәде. Кемдер ишекне зур итеп ачып баракка керде. Салкын һава бәрелде. Керүче туп-туры мич янына туктап:

— Күңелсез хәл, чегән егетен куып җитеп атып үтергәннәр,— диде.

Сүз әйтүче булмады. Качу дигәч тә ул, инде Колымадан китәр өчен качмаган. Бары үзәк лагерьга гына барырга теләгән. Мескеннең гәүдәсен чанага салып үзе эшләгән атта Кучма алып кайтты. Икенче көнгә чаклы вахта янында кар өстендә яткырдылар мәрхүмне. Үзәк лагерьдан комиссия килеп акт язганчы күммәделәр.

Иртәгәсен генә кабер казырга дүрт кешене билгеләп, конвой сагы астында Колыма елгасына якын калкулыкка алып бардылар. Алар арасында мин дә бар. Лом, көрәкләр белән эшкә керешсәк тә, туң җир тиз генә бирешергә теләмәде. Яныбызда басып торучы конвоирларның түземлеге бетә башлады.

— Тизрәк кыймылдагыз, үзегезнең иптәшегез бит,— дип берсе әйтеп салды. Никадәр генә тырышсак та, ярты метрдан арттыра алмадык. Арабыздан кемдер:

— Гражданин начальник, ут ягып җирне җылытыйк, төнгә калабыз,— диде. Болай әйтүче калын гәүдәле, таза тоткын иде. Яше дә кырыклар чамасында булыр. Күрәсең, аның кабер казуы беренче генә түгел. Конвоирлар үзара сөйләшеп алдылар да ут ягарга рөхсәт бирделәр. Шундук ике кешене якындагы агачлар арасына утын җыярга сакчыларның берсе озата да китте. Без эшебезне туктатмадык, казуны дәвам иттек.

Ике кочак кипкән чыбык-чабык күтәреп килделәр. Ут бик тиз дөрләп яна да башлады. Яңадан утынга җибәрделәр. Эш өч-дүрт сәгатькә сузылды. Кисәүләрне кабернең бер башына күчереп, эрегән җирне казырга тотындык. Туң җирне лом, кәйлә алмас булды. Караңгы төшә башлауга безне лагерьга куып кайтардылар.

«Урман командировкасы»нда конвойсыз йөрүче биш тоткын бар иде. Шуларның икесен кабер өстендә ут ягып торырга билгеләделәр.

Төн буе кулым, беләгем сызлады. Рәтләп йоклый да алмадым. Син кабер казып аргансың, бүген эшкә барма, димәделәр, иртәнге аштан соң агач аударырга алып киттеләр.

Эшем бик авыр барды. Теге яһүд карты хәлемне аңлады. Кызуламады. Үз җаем белән генә пычкы тарттым. Ашыкмыйча гына эшләсәк тә, кешеләрдән калышмадык.

Тайгадан кайтышлый юлыбыз Колыма ярыннан үткәнлектән, чегән егете күмелгән каберне карап уздык.

Баракка кайткач та әле, бик озак аның кабере күз алдымнан китмәде. Кичке ашны ашап алгач, тынычлана алмыйча, яһүд карты янына барып утырдым. Бергә эшләгәнлектән, бер-беребезне белә башлаган идек. Ул да миңа хөрмәт белән карый. Аның теш врачы булып та авыр эшләргә җибәрүләрен әле һаман аңлап бетерә алмыйм. Арнольд бик үк ватылмаган, сабыр кеше. Мин янына килеп утыргач башта эндәшми торды. Сүз башлавымны көтте. Нәрсәдән күңелен ачып җибәрим дип торганда:

— Сиңа исем китә, нигә син тынгысыз?— дип, беренче булып сорау бирде миңа.
— Гаделсезлектән йөрәгем яна, кая карама җәбер, золым — болар барысы да кемнендер боерыгы белән үтәлә. Җавап эзлим. Тынгысызлык шуннан килә минем,— дидем.
— Яшь шул әле син, яшь! Минем кебек унар ел төрле лагерьларда йөзсәң, аңларсың, аңламый калмассың,— дип, миңа һәрбер сүзенә басым ясап аңлата башлады.
— Тоткыннарның гына түгел, начальникларны да үзара чәкештерергә сәләтле кешеләр бар. Алар үзләре күренмәскә дә мөмкин. Ә аларның эшләре шундый шәп бара, майлаган кебек. Каршы бер генә сүз әйтеп кара син аларга!
— Бу кадәрле меңәрләгән халыкны шунсыз буйсындырып та булмый торгандыр,— дидем, аның фикерләренә нәтиҗә ясап.
— Менә-менә, дөрес аңлый башладың,— дип куйды Арнольд.
— Минем максатым дөреслекне эзләү. Партия җитәкчеләренең барысы да халыкны гаепсезгә төрмәләргә утыртып, аларның йөрәкләренә шом салып, коммунизмга алып барабыз дип уйламый торганнардыр. Хөррият биреп, яшәтергә теләүчеләр булуына да ышанып яшим мин,— дип сүземне дәвам итәм.
— Бигрәк ахмак икәнсең, теге көнне дә шулай диден. Партия идеологы Ждановка үзеңнең гаепсезгә утыруың хакында шикаят язуыңны да әйттең, әле һаман югарыдан өмет көтәсең, кызганам мин сине, бик тә кызганам, ышанма берсенә дә. Мин дә баштарак үземне гаепсезгә утырттылар дип аңлый идем. Һич тә алай түгел икән ул!
— Ничек соң?
Яһүд бу соравыма җавап биргәнче тирә-юньгә күз йөртеп алды, аннары акрын гына:
— Аз-маз фикер йөрткән бәндәләрне гаепсезгә Себер ягына сөреп, Сталин чикләнмәгән шәһәрткә иреште, авызын ачып хак сүз әйтергә теләгән халыкның иреген чикләде...
Ачуым килде, халыклар атасына шундый каты бәрелүенә чыдый алмадым:
— Кем дип әйтим, гафу ит, бик тә дөрес утыртканнар сине. Партия дөрес юлдан бара. Юлбашчы боларның берсен дә белми, аның күзен томалап кемнәрдер пычрак гамәлләрен кыла. Менә күрерсең, иртәмесоңмы, бу ачыкланыр.
Арнольд миңа карады да усал гына итеп:
— Идеология башыңа бик нык сеңгән, аңларсың, ләкин соң булыр,— дип куйды.
Кем икән бу кеше, нигә йөрәгемә ук булып кадалырлык шундый авыр сүзләр әйтә?..
Бүген Арнольд нигәдер миңа эндәшми, үз җаена гына эшли. Алтмышны узган булса да, миннән калышырга исәбе юк. Пычкыны җае белән генә, басмыйча тота белә. Эшләргә җиңел. Бүген дә икәү туры килдек. Хәрәкәттә булгач, салкын алай ук туңдыра алмый.
Норманың соңгы агачын кисү озакка сузылды. Төбе бигрәк тә юан иде шул. Бригаданы көттермик дип, кызулап, тирләп-пешеп беттек. Ниһаять, кисеп чыгара яздык. Тизрәк пычкыбызны тартып алдык та агач астында калмас өчен читкә йөгердек. Менә ул, башка туганнары белән саубуллашырга теләгәндәй, бәскә сырылган ботаклары белән аларны ялап, гөрселдәп аугач та, әле тирә-юньдә бертын кар бураны уйнап торды. Аннары гына беребез аның ботакларын чапты, икенчебез аларны бер читкә өя торды. Арнольдның арганлыгын сизгәч, кулыннан балтаны алып, мин агачны үзем генә эшкәртергә керештем. Шунда зур ботак төбендәге кул сыярлык куышка күзем төште. Нәрсә икән бу? Бияләемне салдым да, кулымны шунда тыктым.

— Кара әле, Арнольд, кил тизрәк,— дип аннан бер уч кипкән гөмбәләр тартып чыгардым.

— Бу, ди, Арнольд, тиеннең кладовое, үзе юкмы соң анда, эчкәрәк кулыңны тыгың кара,— дигән була. Ә үзе табыштан куанган, елмая.

— Шәп нәрсә бит бу,— дим.

— Кичер безне, тиен, син монда хуҗа, тагын бардыр әле яшергән мөлкәтең,— дип куйды Арнольд, үз өлешен кесәләренә тутырганда. Мин дә изүемне ачып, хәтсез генә кипкән гөмбәләр тутырдым. Табышыбызга куанып, агачны ботакларыннан әрчеп тә бетердек. Бригада да эшләрен тәмамлап җыела башлаган иде.

Баракка кайткач, Демьянов янына ашыктым. Аңа табышым турында әйтәм, ул ышанмый. Изүемне ачып ятагыма бер өем гөмбә аударгач кына авызын ерды. Гөмбәбезне юып салып, яңадан теге иске чиләкне эшкә җиктек.

* * *

Шулай рәнҗетүле, ачлы-туклы авыр урман эшендә көннәребезне үткәрә торгач, яз якынлашуы сизелә башлады. Көннәрнең матурланып китүенә, кояшның тайгага турырак карый башлавына куанабыз. Ярый әле, янымда үзем кебек үк яшьләр бар. Нәрсә булса да сөйләп күңелне күтәреп җибәрәләр. Шуларның берсе — Кучма.

Бер көнне эштән кайтуыма Кучма атын туарып, абзарга тапшырган да яныма кергән. Кичке ашны ашап кына өлгергән идек.

Ул сүзен болай башлады:

— Күптән түгел Якут патшасының каберен тапканнар, өч йөз ел элек күмелгән икән. Җир туң булганлыктан өстендәге киемнәренә чаклы бозылмаган, хәнҗәрен, угын-җәясен үзе белән янәшә күмгәннәр икән. Беләсеңме?— дип дәвам итә башлады хикәясен, минем мавыгып тыңлаганымны күреп.— Элек заманнарда бу тирәләрдә якутлар яшәмәгән. Ә юкагир дигән халык яшәгән булган. Алар белән якутлар гел сугышып торганнар. Ахыргы чиктә, якутлар юкагирларны җиңеп, кысырыклыйкысырыклый, Беринг бугазына чигенергә мәҗбүр иткәннәр. Хәзер бу халык санаулы гына калган. Кызыл кенәгәгә кертелгәннәр. Вак-төяк җинаять өчен аларны гаепләү дә тыелган...

Сүзләре бетсә дә, Кучманың тел төбендә борчылу сизеп алдым.

— Нигә әйтмисең, әйтеп сал, үзеңә җиңелрәк булыр,— дим күзләренә карап.

— Сизә беләсең икән. Әйтми дә булмас инде...

Кучма тәвәккәл карашы белән текәлде дә:

— Конюшняда атымның улакка кысылып бер аягы сынган, нарядчик эт итеп сүкте, дөрес бәйләмәгәнсең,— диде.

— Ат караучыга тапшырган идеңме?

— Эштән кайтуга.

— Синең гаебең юк, курыкма, бер нәрсә дә булмас,— дидем. Егетнең күңеле күтәрелеп китте. Ат турында сүз беткәч, гәпне башкага бордык. Янызбызда берәү дә юк иде. Кучманың тагы нидер әйтәсе, сөйлисе килә. Әле мин аның яхшылап кына кем икәнлеген дә белеп бетермим. Фәкать сәяси тоткын булуы хакында гына ишеткәнем бар. Менә шул нәрсә якынайтты да инде безне. Егет гадиләрдән түгел, фикерле белә, дөньяның агышын яхшы тоя. Бу яклары ошый миңа. Уйланып торды да:

— Берәүгә дә авызыңны ачасы булма. Күптән фикеремне синең белән ачыклыйсым килә иде,— дип куйды ул.

— Йә, инде шикләнмә миннән, тыңларга, үз фикеремне әйтеп бирергә яратканымны беләсең...

— Зырянка үзәк лагерендагы начальникны күргәнең бармы?

— Нигә булмасын, күп тапкырлар!

— Анысы шулай, аны барыбыз да беләбез. Ә соң син минем кем икәнемне беләсеңме?

— Профессор, дип әйтә алмыйм инде. Минем кебек үк сәяси тоткын.

Кучма кинәт уйга калып башын түбән иде. Күреп торам, исенә төшерә бу. Аннары миңа карап:

— Тоткынын тоткын, ә бит мин үзгә тоткын...

— Ничек инде ул үзгә тоткын?

— Сугыш вакытында немецларга әсир төштем, телләрен балачактан белә идем. Немец гаиләсендә үстем мин. Яшьли ата-анасыз калганлыктан, алар мине үз балалары итеп үстерделәр. Армиягә озаттылар. Тик киткәннән бирле аларның язмышларын гына белмим. Әсирлектә шундук мине күреп алдылар. «Мондый егетләр безгә бик кирәк, сине укырга билгелибез»,— дип, әсирләр лагереннан аерып алып, ниндидер хәрби мәктәпкә җибәрделәр. Берлиннан ерак түгел бер шәһәрчектә иде ул мәктәп. Группабызда утыз кеше. Әле дә күз алдымда, озынрак буйлы, аксыл ябык йөзле, сары чәчле егет белән аерылганчы гел бергә булдык.— Кучма тынып калды, нәрсәнедер исенә төшерергә тырыша иде. Күрәм, күзләрен йомып хәтерли. Әйдә уйлансын әле, комачауламыйм. Егет дәртләнеп дәвам итә башлады:

— Диверсантлар әзерләү мәктәбе иде ул. Алты ай өйрәттеләр безне анда. Аннары 43 нең көзендә Волхов шәһәре тирәсенә таң алдыннан парашюттан төшерделәр. Бу кеше дә минем белән иде. Ләкин җиргә төшкәч, кабат аның белән күрешә алмадым. Ә бүгенге көндә ул — лагерь начальнигы!

— Кем?

— Правоторов! Ышансаң ышан, ышанмасаң...

— Зырянкадагымы?

— Әйе, үзем белән бергә укыган бәндә шул инде...

Кучманың сөйләгәненә гаҗәпсенеп, ышанырга да, ышанмаска да белмәдем.

— Ошаган кешеләр күп була, ялгышасың булыр, берүк бу турыда берәүгә дә әйтә күрмә, ышанмаячаклар, харап булырсың.

— Исем-фамилиясе аның ул вакытта башкача иде. Мине таный ул, күргән саен башын читкә бора. Хәзер ул капитан чинында. Аның кемлеген әйтәсем килә. Йөрмәсен әле совет офицеры булып, сволочь!

Көннәр җылына. Пычкыбыз да салкын вакыттагы кебек җәһәт йөрми, авыр ышкыла. Һич тә аңламыйм, әллә яз тәэсире инде, пычкыны Арнольд та сөйләшми генә үз җае белән генә тарта. Мин дә ярыйсы гына сүлпәнләндем.

Кисәсебез күп әле. Нормабызның яртысын гына үтәгәнбез. Кояшның төшлектән узганын, караңгы болытлар түбәнтен генә йөзгәнлектән, чамалап та булмый. Җитмәсә, төнен дә бик начар төшләр күреп куркып уянгаладым.

Җегәрем какшады, эшем рәтләп бармый. Икенче көнебезне инде калдырып эшләтәләр. Шунлыктан бәгырем өзгәләнә. Күпләрне инде алып кайтып та киттеләр. Берничә пар гына калдык. Әле ике агачны кисеп аударасыбыз бар. Ул агачларга карагач, йөрәгем жу-у итеп китте. Берсе бигрәк тә юан аның. Тәнем манма су булды. Арнольд та бик йомшарды. Йөзе агарды, сулышын авыр ала, пычкыны үзенә тартканда күзен йома. Өлкән кеше дип, Арнольдны ашыктырмыйм. Агачны аударгач, балтаны аның кулыннан алып әрчергә керештем. Шунда маңгаема бер ботагы сикереп бәрелде. Күз алларым караңгыланып китте. Моны якында гына учак янында җылынып торган сакчы да күреп алды. Көлемсерәде дә:

— Кыймылдагыз тизрәк! — диде.

Ботакларны агачтан әрчеп бетергәнче тагын шактый вакыт үтте. Арнольдка мин дә булыша башладым. Икәүләп читкә ташыйбыз чыбыкларны. Көрт ерасы юк, сукмак салынган, шуннан сөйрибез генә. Соңгы кочакны вак-төякләренә чаклы җыеп күтәрдем дә илтергә кузгалдым. Сакчы Сапарбаев:

— Әнә тегендә, читкәрәк илт,— дип кычкырды. Тубыктан көрт ерып, ул күрсәткән якка киттем. Аны-моны уйламыйча ботакларны шунда сөйрим.

Караңгы төшәргә дә күп калмаган иде инде. Арнольд минем илткәнемне көтә. Кинәт мылтык атылды. Мин калтырап киттем. Сул колак төбемне нәрсәдер чеметеп алгандай булды. Чыбык-чабыкларым кулымнан көрткә төште. Чигәмнән кайнар кан ага. Башым авыраеп китте. Миңа аттылар дигән уй йөрәгемне калтыратып җибәрде. Уйланып торырга вакыт юк иде инде. Шундук карга капландым. Йөгереп килеп җиткән Сапарбаевның:

— Контр, качмакчы булган идеңме? — дигән тавышын ишеттем. Аннары итекләре белән типкәләгәнен тойдым...

Миңа ничек кенә булмасын түзәргә, хәрәкәтләнмәскә кирәк. Югыйсә бу канга сусаган бәндәнең «үлмәгән икән» дип, яңадан атуы мөмкин. Хәрәкәтсез ятам, ыңгырашмыйм да. Урман кисүчеләрдән без икәү генә калып, бу кеше сурәтендә йөрүче затның бәгыренә тигәнбез икән. Чегән егетен дә куып җитеп, ул атып үтергән дигәннәр иде.

Ышанмыйм, мин тереме, юкмы? Кыймылдап карагач кына үземнең әлегә исән икәнлегемә ышандым. Кулларыма таянып башымны күтәрдем. Йөземә салкын җил бәрде. Бернинди тавыш-фәлән ишетмим. Сакчының Арнольдны лагерьга алып киткәненә шактый вакыт үткән. Күз алдында мине атып үтерүләренә аның коты очкандыр...

Яңадан кар өстенә капландым. Чигәмнән аккан каннардан бозлавык хасил булган. Йөзем белән төртелгәч кенә мин моны тойдым. Бияләемнән кулымны бушатып җәрәхәтле җиремә учымны куйдым. Әле һаман кан сарка икән. Тизрәк торып китәргә дигән уй мине янә аякка бастырды. Башымда бары бер генә теләк: ничек кенә булмасын, вахтага кайтып җитәргә дә, үземнең исәнлегемне белгертергә. Яңадан килеп үтереп китүләре бик мөмкин!

Алпан-тилпән атлап, көч-хәл белән генә вахта янына кайтып җиттем. Сакта торган яшь украин егете:

— Бадыйкшанов, сине Сапарбаев качып китә язды, көрт ярып артыннан җитеп атып үтердем,— дигән иде.

— Атты, мин үлмәдем, менә күрәсез, мин тере.

Вахта йортыннан берничә конвоир килеп чыкты. Икесе мине җитәкләп йорт эченә алып керделәр. Сапарбаев кыска тунының сәдәфен тегеп утыра иде. Мине күргәч, аның күзләре шар булды. Акаеп карап алды да башын читкә борды.

— Мин качмадым, нигә аттың? Җавап бирәсеңне онытма!

Вахта начальнигы да йортта иде. Ул кырыклар тирәсендәге имәндәй нык, киң җилкәле, иңбашларында майор погоны ялтыраган кеше. Яныма якын ук килеп, ярама карап алды да:

— Тизрәк беренче ярдәм күрсәтегез! — дип, кемгәдер дәште.

Шундук бер сакчы килеп мине җитәкләде дә урындыкка китереп утыртты. Өстемне салырга булышты. Аннары каяндыр алып килеп бер тартма ачты. Мамык, марля чыгарды. Ярамны спирт белән сөртеп, әле кибеп бетмәгән каннардан арындырды. Җәрәхәтемә нәрсәдер сылап, башта калын гына итеп мамык куйды. Кулы ятып тора икән үзенең. Бик тиз генә марлясын ияк астымнан төшереп, башымның түбәсеннән әйләндерә-әйләндерә әйбәтләп урады.

Күрәм, Сапарбаев начальнигы алдында шәм кебек басып тора.

— Качарга уйлаган тоткын көне буе эшлиме?

— Тыелган зонаны чыгып китте ул, үзегез безгә кем дә кем читкә тайпыла, кисәтүсез атарга дип әйттегез!

— Дөрес аңларга кирәк, Сапарбаев, юлда кая булса да барганда, качып китә икән, шунда гына корал кулланырга, диелгән безнең уставыбызда...

— Җәрәхәте әлләни куркынычлы түгел, пуля бераз тырнап кына үткән,— диде миңа беренче ярдәмне күрсәткән яшь кеше.

— Сапарбаевны карцерга илтеп ябыгыз,— дип, вахта башлыгы кемгәдер күрсәтмә бирде.

— Бар барагыңа, шапырынма, нәрсә булганын берәүгә дә әйтмә. Яраң төзәлгәнче эшкә йөрмәссең,— дип, начальник миңа кайтырга рөхсәт бирде. Мин ишектән чыкканда, Сапарбаев та киенә башлаган иде инде.

Барагыма кайтып кердем. Демьянов, мине күрүгә, атылып килеп кочаклап алды.

— Ай җаным, исән калгансың икән! Болай булгач, яшисең әле, дип, мине ятагыма китереп утырттты да, савытымны алып, кухняга таба китте. Бик тиз арада өлешемә тигән ашымны китерде, ниндидер тәбәнәк әйберне мич янына куеп, миңа шунда утырып ашарга кушты. Китергән ашы бик тә куе, өреле иде. Күрәсең, кухняда да минем хәлне белгәннәр, теләктәшлек йөзеннән булгандыр инде, ашның да әйбәтен салып биргәннәр...

Бер атна эчендә җәрәхәтем төзәлде. Наряд бирүче моны бик тиз абайлап алды. Мине мунча ягучы итеп билгеләп куйдылар. Эшем әлләни авыр түгел, бакларга су тутырасы, атнасына бер мәртәбә ягыла торган мунчага утын хәстәрлисе бар. Көне буе гел тышта, ачык һавада йөрим. Еш кына Демьянов миңа килеп булыша. Вакытында мунча ягыла, су китерелә. Башка эш кушмыйлар.

Яз житте. Карлар эреде, Колыма бозлары өстенә су төште. Озакламый елгада боз кузгалды. Эшләр бер генә көнгә дә тукталмады. Кыш буе әзерләгән бүрәнәләрне Колыманың якындагы бер култыгына атлар белән сөйрәтеп өяләр, соңыннан тал чыбыкларын кайнар суда пешекләп аркан итеп үрәләр һәм бер-берсенә бәйләп беркетәләр. Шул сал була инде.

Мине дә яңа эшкә, тал чыбыкларын әзерләп торырга билгеләделәр. Кучма белән бергә эшлибез.

Безнең салларыбызны Колыма кузгалгач, Амбарчик портына буксир пароходы белән сөйрәп алып китәчәкләр икән. Ул якларда агач үсми. Певик дип аталган җирдә Кучмага да булырга туры килгән.

Без эшләгән җирдә гөрләвекләр ага. Янәшәбездән ара-тирә кыргый боланнар чабып үтә. Сизәбез, юкка гына өркеп чапмыйлардыр?! Димәк, аларны дошманнары эзәрлекли булыр. Кар астыннан мүк җиләге күренә башлады. Хәтта авыз итеп тә алдык. Ләззәтеннән туеп булмый. Күптән инде авызыма әчкелтем-төчкелтем ризык капканым юк иде. Йөрәгем табигатьнең яшәрүен сизә. Күз алларыма туган ягым, ямьле Зәй буйлары, ап-ак булып чәчәк аткан шомыртлы әрәмәләр, гүзәл болыннар килеп баса. Өметемне җуймыйча яши алсам, бәлки, иртәме-соңмы, туган илгә кайта алырмын. Хәзергә язмышым билгесез әле. Мөртәтләр кулында гомер кичерәм, мөртәтләр сагында яшим...

Бүрәнәләрне сал итеп әзерләп бетергәч, монда озак тормадык без. Йөк тартып йөртүче пароход баржаны сөйрәп килеп тә житте. Менә шунда барыбызны да үзәк лагерьга алып киттеләр. Колыманың җәелгән мәле иде. Суы болганчык, кая карама эреле-ваклы бозлар. Бик еракта Аргаташ таулары күренә. Сөйләүләре буенча, җәен дә кар бетми, эреми икән анда.

Ниһаять, буксир калку ярга килеп туктады. Матрослар такта трап төшерделәр. Конвоирларның берсе безне санап чыгарып, сафка тезеп торды. Аннары үзәк лагерьга таба алып киттеләр.

Капка янына килеп туктагач, берәмләп тентеделәр дә зонага кертә башладылар.

Кучманы аерып алып, режимлы баракка алып киттеләр. Аның әйткән сүзләре исемә төште. Димәк, начальник Проваторов аны яхшы белә

икән. Кучма миңа кул болгап китеп барды. Ә без исә Демьянов белән икәү үзебез яшәгән баракка юнәлдек.

Баракка кергәч:

— Локман, кайтуың белән! — дип бирәү килеп дәште. Күптәнге танышым Федор Папин икән.

— Ярый әле быел кыш алай ук салкын булмады.

— Булмаган кая, зәһәр салкыннар булгалады...

— Тегүче булып эшләдем,— диде Папин, кышкы салкыннарны сизмәвенә акланып.

Башка таныш-белешләр дә килеп күрешергә ашыктылар. Чегән егете белән бергә үзәк лагерьга качкан кеше дә яныма килде. Ул исә:

— Сапарбаевның артыбыздан килгәнен беренче булып күрдем, шундук таллыклар арасына кереп посып өлгердем, югыйсә мин дә бетәчәк идем. Чегән егетенең: «Абый җаным, атма!» — дигән сүзен генә ишетеп калдым. Шуннан соң мин ул егетне күрмәдем, таллыклар арасыннан карга бата-бата, үзәк лагерьга төнен генә кайтып җиттем. Мине бик озак кертми тордылар. Начальникны көттеләр. Аякларым бик тә туңган иде. Лагерьда бик каты авырдым. Санчастька салдылар. Шунда ике аягымның да бармакларын кисәргә мәҗбүр булдылар. Өшеткән булганмын. Хәзер төзәлде инде...

Ул сөйли, бертуктаусыз күз яшьләре тәгәри. Күрәсең, кичергәннәрен күз алдына китерә. Үлем аны уратып узган, әмма Сапарбаев күргән булса, һичшиксез, кызганмаган булыр иде бу кешене.

## Тугызынчы бүлек

Үзәк лагерьда тормыш яхшырак. Ни әйтсәң дә, игътибарны күбрәк бирәләр. Еш кына югарыдан комиссияләр килгәләп, төрле башбаштаклылыкларга тамыр җәяргә юл куймыйлар. Соңгы елларда бигрәк тә күзәтүләр көчәйгән. Колымадагы тоткыннарның икегә бүленеп бер төркеме Бренг бугазы ягына, икенчесе Якутск аша юл тотуларын, баш күтәреп ирек даулауларын онытмыйлар. Рәхимсез рәвештә бастырылган булса да, өстә утырган күпләренең башларын әйнытып җибәргән ул фетнә. Мин бу хәлләрне үз күзләрем белән күрә алмадым. Сугышка кадәрле үк Колымага китерелгән, һәм хәзер дә әле срокларын тутырырга өметләнеп яшәүчеләрдән генә ишеткәлим зур фаҗига булып үткәнен...

Урман командировкасыннан кайтуыбызга ике көн дә үтмәде, яңадан бригадаларга бүлеп, Зырянка эшче поселогына эшкә куа башладылар. Мин елгадан ерак түгел кечкенә таучык янындагы кайчандыр казылган зур базны чистарту эшенә билгеләндем. Унлап кеше һәр көн шунда йөрибез. Чокыр шактый тирән. Аны тагын да киңәйтәбез, китереләчәк яшелчә өчен калын такталардан шүрлекләр ясыйбыз. Җитәкчебез — иректәге урта яшьләрне узган грузин. Күп сөйләшеп тора торганнардан түгел. Килүгә:

— Бүгенгә бу эшләрне эшләсәгез әйбәт булыр,— ди дә китә дә бара. Ә конвоирга нәрсә, чокыр өстендә карачкы сыман басып торудан гайре аның башка эше юк. Алар икәү. Алмашлап ниндидер якындагы алачык сыман итеп эшләнгән тар гына корылмада йоклап вакытларын үткәрәләр. Аз кыймылдасак та, эшебез һаман саен алга бара. Утызлардан узган казакъ кешесе белән эшлим. Ул озын буйлы, киң җилкәле, мәһабәт гәүдәле, һәрбер сүзендә аның хатын-кызлардан зарлану сизелә. Шулай бервакыт түзмәдем:

— Нигә шулкадәрле син аларны яратмыйсың, һаман сүгәсең? — дип сорарга мәҗбүр булдым.

— Күрәм, һәрвакыт мактыйсың, аларсыз тормышның яме юк дигән буласың. Ә бит минем Колымага эләгүем дә хатын-кыз аркасында булды,— диде ул.

— Ничек инде ул алай?

— Үземнән биш-алты яшькә өлкәнрәк Зөһрә исемле бер ирсез хатын белән танышкан идем. Киномеханиклар әзерләү курсларында укыган чагымда булды бу хәл. Зөһрәнең квартирасы бик әйбәт. Тора башладык үзе белән. Ә аның чибәр кызы да бар. Әти дип йөри башлады ул кыз миңе. Яхшы кино булган саен үзен киногa алып барам. Механиклар таныклaмaсы белән һәрвакыт киноларга бушлай йөри идем. Зөһрәнең кызын, сеңлем дип үзем белән алып керәм. Ташкентның чигүгә өйрәнү мәктәбендә укый иде кыз. Стипендия саен аңарга йә конфет, шоколад кебек тәмле-томлы нәрсәләр алып кайткалыйм. Әнисе мине үлеп ярата. «Укып бетерүең белән мин сине Татарстанга алып китәм»,— дигән сүзләре әле хәзер дә хәтеремдә. Киткән дә булган булыр идем, ләкин көтелмәгән хәл килеп чыкты...

— Нинди хәл? — дип соравыма казакъ ике көн минем белән сөйләшмәде. Сорау биргәнне бер дә яратмый торган булып чыкты ул. Бер атна сүз алышмадык. Ә минем ни өчен аның хатын-кызны яратмавын беләсем килә. Амангельдеев иде аның фамилиясе. Эшкә килгән саен балтаны кулына иң беренче булып ул ала. Мин такталар сайлап аның кулына тоттырам. Бервакыт үз җае белән янә теге вакыйга турында сөйләп китте ул.

— Шулай бер көнне Зөһрәнең иптәш кызы безгә килде. Шундый чибәр, бер карауда күземнең аңар төшкәнен сизми дә калдым. Сылу сын, биленнән түбән төшкән озын чәч. Күзләре турында әйтәсе дә юк. Шундый көйдереп карадылар миңа, мин өнсез калдым. Чәйдән соң озатырга икәү чыктык үзен. Бу көнне авызымнан бер генә сүз дә чыкмады. Чибәрлегеннән тәмам сихерләнеп калганлыктан, гел аның турында гына уйланып йөри башладым. Чәй эчкәндә Зөһрә ул кызга бер генә мәртәбә дә исеме белән дәшмәде. Бу мине гаҗәпкә калдырды. Шулай да мин аңа күңелемнән исем табып, Зөлфәдер аның исеме, башкача булмас дигән нәтиҗәгә килеп, кайда булса да очраса, уйлап тапкан шул исем белән дәшергә булдым. Шулай бервакыт укудан кайтып киләм. Каршыма шул кыз килеп чыкмасынмы!

— Зөлфә,— дип беренче булып дәштем, нәфис кулын кысарга ашыгып.

— Теге көнне, сез бер дә сөйләшмәдегез, гел миңа гына карап утырдыгыз, исемемне дә сорамадыгыз, мине озаткач, Зөһрә әйткәндер инде, шулаймы? — Зур кара күзләрен миңа төбәп, сөйкемле карашы белән бүләкләде кыз. Шул көннән башлап еш кына очраша башладык. Зөһрәдән качып кына киноларга йөрибез. Хатын-кызларда сизенү, чамалау бик тә көчле була икән. Алданрак сизенгән булган булсам, яңадан тулай торакка киткән дә булыр идем. Соңга калдым. Зөһрә миңа мәкерле, бик тә астыртын тозак корып та өлгергән булган. Мине кулга алып төрмәгә яптылар. Тиз арада суд та булды. Зөһрәнең кызына кул салырга омтылыш ясауда гаепләп сигез ел чәпеделәр дә куйдылар.

— Ышанмыйм, булмас, әйтеп бетермисең. Гаебең булмаган булса, утыртмаган да булырлар иде,— дип әйттем мин Амангельдеевка.

— Ә үзең соң, гаепсезгә утырмыйсыңмыни?

— Менеке икенче мәсьәлә,— дидем мин аңа кызганып карап.

Көннәр үтә торды. Зур бәйрәм килеп җитте. Лагерьда һаман үзгәреш юк. Эшлибез, яңа этаплар килеп тора, аларны көн-төн башка лагерьларга озаталар. Урман командировкасыннан кайтканнарны кузгатмыйлар әлегә. Бәйрәмне каршыларга безгә дә насыйп булган икән.

Үзәк лагерьда КВЧ (культуралы тәрбияләү бүлеге) бар. Аның инспекторы — офицер. Ә инструктор булып эшләүчесе үзен яхшы тотуы белән сыналган бер тоткын. Килгән көнемнән үк ул кеше белән танышып алган идем. Көн-төн диярлек газета-журналлар белән мавыгам. Бу керүемдә ул:

— Иртәгә, лагерыбызга Магаданнан мәшһүр җырчы Лидия Русланова җитәкләгән концерт бригадасы килә. Ябык концерт булачак. Анда зур начальство, лагерь администрациясе, бушаган сакчылар гына кертелә. Тамаша залын җиһазларга сине дә билгелим. Бу хакта берәүгә дә шапырынма, алдан ук кисәтеп куям,— димәсенме!

Урыс халык җырларын иң оста башкаручы шәп җырчыны да лагерьга япсыннар әле?! Ни гаебе булган икән аның хөкүмәт алдында? Моны белүче, аңлаучы бар микән? Уку бүлмәсеннән кешеләр чыгып киткәнче журнал караштырып утырдым.

— Барагыңа кайт, мин дә бүлмәмне бикләп чыгам,— диде миңа инструктор.

Ашыкмыйча гына өстәлләрне рәткә кертергә булышып, чыгу юлына атладым. Шунда инструкторның кәефе әйбәтлеген күреп:

— Миша абзый, мин Руслanованың җырларына гашыйк кеше, шундый гүзәл җырчыны нигә утырттылар икән?—дип сорадым.

— Дөрестерме, юктырмы, шуны гына әйтә алам, аның кызы Мәскәүдәге чит ил кешесенә тормышка чыккан булган. Шуның өчен булса кирәк, анасын шпионлыкта гаепләгәннәр...

— Аңламассың бу дөньяны,— дигән булдым мин.

Икенче көнне иртәнге чәйдән соң мине берничә егет белән бергә КВЧ клубына эшкә билгеләделәр. Алдан ук белеп торганлыктан, бу миңа яңалык түгел иде инде.

Клуб әйбәт. Тоткын рәссамнар аны кулларыннан килгән кадәре матур итеп бизәгәннәр, хәтта, Мәскәү Кремлен, Ленин мавзолеен күрсәтеп зур полотно эшләп куйганнар. Әйтерсең, без лагерьда түгел, ә ниндидер шәһәрчектә эшкә китерелгәнбез дә, үз иркебездә яшибез...

КВЧ клубының тәрәзәләрен эчтән кара пәрдәләр белән кадаклап, кайберләренә рәсемнәр элдек. Юдык, җыештырдык. Урындыкларны тигез генә итеп тездек. Кыскасы, клуб эче танымаслык булып үзгәрде.

Дядя Миша, эш беткәч, үземә генә:

— Концерт башлангач, арткы ишектән үзеңне кертермен,— дип калды. Аңарга ышанырга була, ул да кайчандыр хәрби диңгезче булган икән. Шуңа күрәдерме, мине якын итә.

Дустым Демьяновны да мәшһүр җырчыны тыңлаудан мәхрүм итәсем килмәде. Вакыты җиткәч, аны да үзем белән иярттем. КВЧ янынnan ике-өч тапкыр әйләнеп үттек, ләкин концерт башланганы ишетелми әле. Дядя Миша янына барсам да ишекне ачмый. Югыйсә, башлануга арт ишекне ачып кертермен дип вәгъдә биргән иде.

Лагерь зонасы яп-якты булып прожекторлар белән көйләнгән. Әнә төшсә дә күренерлек. Килеп стенага колагымны терәп тә карадым. Һаман тынлык хөкем сөрә...

Менә бервакыт дядя Миша зал ягы ишегеннән килеп чыкты да, мин яшәгән баракка таба җәһәт кенә атлап китеп барды. Артыннан куып җитим дип шунда таба кызуладым. Ул баракка кереп тә өлгерде, мине Демьянов туктатып җиңемнән тартты.

— Ашыкма, сине эзләми ул, ни өчендер бригадирыбыз кирәк булган аңар,—диде.

Чыннан да, озакламады, бригадирыбыз белән дядя Миша килеп тә чыктылар. Нәрсәдер сөйләшеп алгач, бригадир кереп китте, ә тегесе каршыдагы баракка таба юнәлде. Дустым белән баракка ашыктык. Керсәк, ни күрик, барысы да гөр килеп ашыга-ашыга киенә башлаганнар.

Тиз арада тоткыннар бaрактан чыгып тезелделәр. Концерт барыбыз өчен дә икән, дип сөендем. Каршыдагы бaрактан да чыгып өлгергәннәр иде инде. Иң беренче булып безнең бригада кузгалды.

Тамаша залына тәртип белән генә кереп урын алырга ашыктык. Алдагы рәтләрдә начальство утыра. Алар артында вахтадан бушаган сакчылар, ирекгәге тәэминият кешеләре. Иң беренче булып сәхнәгә баян-

чы чыгып үзенә билгеләнгән урынга барып утырды. Ул күк костюмнан, изүе ачык ак күлмәктән. Бер дә зэк, дип уйламассың. Менә уңъяк чаршау дулкынланып алды. Аннары озынча буйлы, зәңгәрсу озын күлмәктән хатын-кыз килеп чыкты. Аны шундук көчле алкышларга күмеп тамаша залы каршыларга ашыкты. Бу хатын Русланова иде. Аны гомеремдә беренче генә күрүем булганга, барлык дикъкатемне биреп сәхнәгә текәлдем. Ерак утырганлыктан, йөзен ачык итеп күрә алмавыма үкенеп алдым. Зал тып-тын булды. Лидия Андреевна беренче җырын «Валенки»ны башлап җибәрде. Әй, тавыш та бар икән үзендә! Йөрәгемә үтеп керде, иректә булган вакытларым, зур концертларда тыңлаган җырчыларымны күз алдыма китереп бастырдым. Гөлсем Сөләйманова, Рәшит Ваһапов, Усман Әлмиев, Асия Измайлова, Фәхри Насретдинов, Разия Тимерханова кебек татар халкының мәшһүр җырчыларын флотка киткәнче зур концертларда тыңлаганым булды. Һәм менә Русланова! Аның искиткеч ягымлы тавышына сихерләнеп, барлык кайгыларымнан арынып, дөньямны онытып утырдым. Һәрбер җырын башкарган саен, КВЧ клубы көчле алкышларга күмелде. Концертта башка номерлар да булды. Аларын да бик хупладык...

Ике сәгатькә сузылган концертның ничек үткәнен дә тоймадык. Чаршау ябылгач, әле һаман да кул чабулар тынмаганлыктан, Лидия Русланова, аның белән килгән башка җырчы-биючеләр ике-өч мәртәбә сәхнә артыннан чыгып тамашачыларның зур хөрмәт күрсәтеп тәбрикләүләренә баш иделәр.

Халык таралгач, ишек алды ягыннан КВЧ клубының аргы ягыннан барып, Мишаны эзләп таптым. Аның күңеле бик тә күтәренке, йөзендә канәгатьләнү балкып тора. Мине күрүгә:

— Морячок, ничек? Шәп булдымы концерт? — дип сорады.

— Искиткеч, лагерьда икәнлегемне дә оныттым.

— Бараклардан зэкларны нигә чакырганнарын әле син белмисең булыр?

— Каян белим ди?

Дядя Миша грим бүлмәсенең ишеген ябып, үзенә генә хас йомшак тавышы белән:

— Концертны чак кына өзми калдык. Лидия Русланова клубыгызда мин җырларга теләмим. Күрәсезме, анда офицерлар, конвоирлар гына килгәннәр. Аларның күңелен күрер өчен мине кулга алдылармыни? Юк, инде анысы булмас, әгәр дә үзем кебек тоткыннарны чакырмасагыз, теләсә нишләтегез, җырламыйм, — диде.

— Акыллы хатын икән Русланова!

— Начальниклар, сүз көрәштереп тордылар да, клубны халык белән тутырыр өчен, ике бригаданы чакырып кертергә мәҗбүр булдылар.

Вакыт соң иде инде. Мин дядя Миша белән саубуллашып кайтып киттем. Озак йоклый алмый яттым. Күз алдыма һаман Лидия Руслакованың гүзәл сыны, матур тавышы, йөрәгемне йомшартып, барлык кайгыларымны оныттырган берсеннән-берсе эчтәлекле, сокландыргыч җыр сүзләре кабатланып торды. Хыялга бирелеп, аны океан дулкыннарына баса-баса каршыма елмаеп килгән фәрештәгә тиңләдем. Әйе, менә-менә килеп җитәр дә сөлектәй ак куллары белән кочып алыр сыман...

Көннәрем дәртле уйларда, мавыктыргыч, берсеннән-берсе матур хыяллар диңгезендә үтә башлады. Бары тик коллыкка дучар булган тәнем генә авыр эш белән җәзаланды. Күз алдымнан Лидия Русланова китмәде. Эшкә барганда да, кайтканда да.

Казакъ Амангелдеевның күңеленә хатын-кызга карата яңадан мәхәббәт салырга, авыр көннәрендә дәртләнеп өмет белән яшәр өчен чынбарлыкка туры килерлек вакыйга эзләдем. Әйе, Руслановканы тыңлаганнан соң, башымда туган уемны сөйләп бирәсем килде.

Шулай беркөнне, әбәттән соң, үзебез ясаган баздагы шүрлекнең югары катына менеп утырдык. Һәркемнең ял иткән чагы. Казакъ Амангелдеев калын такталардан җәелгән шүрлекнең базга төшә торган җирендә ямансулап утыра. Янына килеп мин дә урын алдым.

— Синең Зөлфәңне исемә төшердем әле. Чыннан да, ул кыз гүзәлләрнең гүзәле икән,— дип бер легенда сөйли башладым.

...Зәңгәр диңгезнең нәкъ уртасында түп-түгәрәк, бик матур бер атау булган. Ул үзе бик зур да, бик кечкенә дә түгел икән. Ләкин табигатьнең матурлыгы белән бөтен кешене таңга калдыра торган булган.

Диңгез кораблары аның яныннан үткәндә, палуба өсте халык белән тула икән: «Нинди матур атау!»— дип гаҗәпләнгәннәр алар. Атауның уртасында төрле агачлар белән капланган тау булып, итәкләрендә алма, хөрмә, инҗир, зәйтүн агачларына төренгән кечкенә генә өйләр тезелеп киткән булган. Ләлә чәчәкләре арасыннан көмештәй елтырап чишмә сулары чылтыр-чылтыр океанга агып торган. Атау кырыеннан үткән корабларга әкрен генә искән йомшак җилләр төрле чәчәкләрнең хуш исләрен бөркегән. Һәркайда нәфис тавышлы кызларның моңлы җырларын тыңларга диңгезчеләр бик тә яратканнар. «Матурлыгы белән дә, халкының хезмәткә тырышлыгы белән дә бик тә күркәм бу атау»,— дип узган юлчылар.

Кешеләр анда шундый бәхетле яшәгәннәр, аларның бәхетле мул тормышларына диңгез үзе дә сокланып карый, сөенә торган булган. Океан атауны йомшак сулары юган, халкын туендырган, киендергән...

Хатын-кызлар үзләрен иркәләп үстергән океан турында соклангыч матур җырлар чыгарганнар. Тиңсез гүзәл чәчәкләрне, чәчләренә, күкрәкләренә кадап, нәфис ап-ак кулларына хуш исле букетлар тотып биегәннәр. Үзара сөйләшә-сөйләшә, берсен-берсе куышып, атау ярының битен юган дулкыннар аларның искиткеч матур җырларын, оста итеп биюләрен алкышлап торган.

Шуңа күрә дә аны «Бәхет атавы» дип атаганнар да. Шул атауда Зөлфә исемле бик матур, бик гүзәл бер кыз яшәгән. Диңгез дулкыннары белән көрәштә батыр калган чибәр ир-егетләр аны «Бәхет атавы»ның гүзәл чәчәге дип йөрткәннәр. Ауга киткәндә дә, аудан кайтканда да гүзәл кыз Зөлфәгә багышлап җыр җырлаганнар. Кыю, батыр егет Солтан, кызның янып, балкып торган алсу йөзен, сөрмәле күзләрен, озын кап-кара толымнарын мактарга сүз таба алмый икән. Мәхәббәтеннән шашар хәлгә җитеп, моңлы гына көйли икән бу:

Әллә гүзәл таңда миләүшәдән
Көмеш тамчы булып төштеңме?
Әллә умырзая чәчәгенең
Сыннарына охшап үстеңме?

Күрәм, Амангелдеев һаман саен җанлана, күзләрендә ялкынлы нурлар сизелә бара. Авызын ача төшеп, һәрбер әйткән җөмләмне йотып алырдай булып барлык дикъкатен биреп мине тыңлый. Чак кына тукталыбрак торсам:

— Дәвам ит инде, син мине тәмам сихерләдең,— дип куя.

— Җырчы кызлар ауга киткән егетләрне, атаудагы иң биек яр өстенә менеп, һәр көнне җыр белән каршылый торган булганнар,— дип дәвам итә башлыйм. Андый вакытта хәтта океан үзе дә шаулавыннан туктап торган.

Ауга океанга кереп киткәч, һәркем батырлык күрсәтергә тырышкан. Кыю егетләр аудa танылып кына Зөлфәнең җырын ишетергә хыялланганнар. Һәрберсе аңа үзенең батырлыгы турында әйтергә җилкенгән.

Океаннан кайтучыларны Зөлфә берсеннән-берсе көчлерәк яңгыраган яңадан-яңа матур җырлар белән каршы ала икән...

«Бәхет атавы»ның гүзәл чәчәкләрен күкрәкләренә, озын толымнарына кадап, океан ярындагы кыя ташлар өстенә тезелеп баскан кызлар арасында Зөлфәнең нәфис тавышы әллә кайдан аерылып торган. Солтан, йөрәгенә чыдаша алмыйча, эчендәге дәрте ташып:

Безнең атау гөл генә,
Җир йөзендә бер генә;
Шунда үскән бер чибәр бар —
Сөяр ул кемне генә? —

дип җырлап җибәргән. Кызларның йөзләренә ниндидер оялчан шатлык, өметле елмаю нуры балкып чыккан. Араларыннан берсе:

— Солтан җырлады бит, Солтан!.. Бу җырны кемгә төбәп җырлады икән? — дип әйтергә өлгермәгән, Зөлфә алгарак чыгып баскан да җилкәнле көймәгә карап җырлап җибәргән:

Җилең серле җил икән,
Таң җиленә тиң икән;
Әйтче, егет, ул кызый
Безнең илдә кем икән?

Солтан аптырап калмаган, җыр белән җавап биргән:

Кем дигәнең үзе ул!
Солтанның уң күзе ул!
Йөрәгемнең түрендә
Тулган айның йөзе ул.

Көймәдәге егетләр, кинәт сискәнеп, бер-берсенә карашып алганнар. Ә кызлар, башларын аска иеп, сүзсез калганнар. Егетләрнең һәрберсе Зөлфәне үзенә лаеклы дип йөри икән, бу хәлдән соң аларда зәһәр көнчелек уты кабынган.

«Бәхет атау»ына хас булган гүзәл чәчәкләр бәйләмен Зөлфә Солтанга ыргыткан да тыйнак кына, кыюсыз гына түбән караган, аның алсу йөзе ут булып яна икән.

— Рәхмәт, Зөлфә, син миңа чәчәк бәйләме белән бергә «Бәхет атауын», океанны, хәтта бөтен дөньяны бүләк иттең! — дигән Солтан.

— Йә, нинди батырлык күрсәттең син, сөйлә! — дигән кыз бераздан.

Солтан, сөйләргәме, юкмы дип торганда, өлкән аучы, алга чыгып болай дигән:

— Бу егетнең батырлыгы аркасында без исән калдык, югыйсә кит балыгы безнең көймәне койрыгы белән генә селтәп сала иде. Шундый дәү кит балыгын авызлыклаган егет ул.

— Юк, батыр егет, бу әле батырлык түгел, кит балыгын һәркем җиңә ала, син бер кеше дә эшли алмый торган батырлык күрсәт, — дигән кыз, бөтенесен гаҗәпкә калдырып.

Егет каушап калмаган. Ул горур рәвештә:

— Кешеләр җиңә алмый торган бернәрсә дә юк бит, чибәр кыз, — дигән.

Зөлфә егетнең хак сүзләрен ишетеп уйга калган. Бераздан Солтан җавап көткән Зөлфәгә тагын да якынрак килеп:

— Батырлыкның рухы акыл түгелме? — дигән.

Зөлфәнең алсу йөзе тагын да алсуланган. Шуннан соң ул:

— Ярый, Солтан, мин җавабын эзләрмен, — дип, кинәт борылып кызлар янына йөгереп киткән.

Шуннан соң Зөлфәгә бик күп егетләр килгән. Ләкин ул берсенең дә батырлыгын кеше эшли алмаслык дип тапмаган. Диңгез хәшәрәте сигезьаякны җиңеп кайткан егеткә дә Зөлфә күтәрелеп карамаган. Давыл белән көрәшеп, көймәне коткарып калучыга ул елмаймаган да:

— Боларны кем дә эшли ала бит,— дигән.

— Ай-һай, чая кыз булган икән синең Зөлфәң,— дип куйды Амангелдеев, фикеремне туплап торудан файдаланып. Минем хис иң югары ноктага килеп җитә язган иде инде. Түзмәдем:

— Ышан егет, мәхәббәтең көчле булса, таш ярырга да сәләтле буласың. Мин моны үземдә сынадым инде. Башыма төшкән барлык җәберзолымнарга түзәм, ни өчен икәнлеген аңлыйсың булыр, туган илемдә калган сөйгәнем хакына...

Егетнең күзләреннән яшь тәгәрәде.

Хикәямне дәвам итмәкче генә идем, тирә-юнемдәгеләр эшкә тотынганлыктан, утырган урынымнан җиргә сикереп төштем.

Ул көнне дә үз вакытында лагерьга кайттык. Үзгәреш юк, шул ук кешеләр боегып йөриләр. Дядя Миша Увольная дигән күмер шахтасына этапка китүчеләрнең исемлеге барлыгын әйтте миңа. Китү иртәгә булачак икән. Исемлектә мин дә бар.

— Анда әләксәң, эше авыр-авырын, әмма шунысы бар, бер көнең өчкә санала. Тизрәк котыласың,— дип куйды.

Бу яңалык мине канатландырып җибәрде. Димәк, иң күп булса, дүртбиш елдан иректә булачакмын...

## Унынчы бүлек

Иртәгәсен барагыбызга өч түрә килеп керде. Алар Угольнаяга китүчеләрнең исемлеген укып чыктылар. Урман командировкасыннан кайтучыларның күбесенең фамилияләрен ишеттем. Димәк, китәбез!

Керүче түрәләр исемлектә укылганнарга җыенырга кушып чыгып киттеләр. Озакламады, вахта капкасы янына барып басарга боерык булды. Йөзгә якын кеше җыелдык. Күпләрнең китәселәре килә икән. Күңелләре күтәренке, бер көнең өч көнгә саналсын әле! Бу бит, Колымадан срогыннан алда ычкыну дигән сүз. Янымда Амангелдеев, Демьянов, Папин, тагы бик күп таныш белешләр. Демьяновның гына үзәк лагерьдан китәсе килми икән.

— Булдым инде мин анда, шахтаның нәрсә икәнлеген яхшы беләм. Әле дә хәтерлим, шулай бер чакны Угольнаяда икенче шахта шартлады. Анда утыздан артык зэк җир астында күмелеп калды. Берничә кешене генә казып ала алдылар. Метан дигән газ җыелган булган. Кемдер тәмәке көйрәткән, күрәсең, таң алдыннан шартлады ул шахта.

Фаҗига турында тыңларга һич тә яратмыйм. Үз уйларыма бирелеп, ул турыда уйламаска булдым. Язмыштан узмыш юк. Тәкъдиреңә нәрсә язылса, шулай булачак. Ходай саклаганны саклармын дигән дииоен.

Вахта капкасы янында хәтсез генә басып тордык. Менә бервакыт озата барырга дип этләр җитәкләгән күп кенә конвоирлар килеп җитте. Янә санап капкадан чыгардылар да Зырянка поселогы аша Көнбатышка таба юл алдык.

— Угольная ерак түгел, ни булса алтмыш километр гына,— дигән була Демьянов.

Сәгатьтән артык яхшы юлдан бардык. Аннары сазлык башланды. Аякларга су үтте. Урман юлыннан барабыз, кая карама — түгелгән ташкүмер. Күрәсең кышын машиналар белән күмер ташыганнар...

Майның актык көннәре булуга карамастан көн алай ук бик җылы түгел. Ашыкмыйча гына атлыйбыз.

Амангелдеев минем янымнан бара. Сизәм, аның теге чакны башлаган Зөлфә турындагы хикәямне тыңлап бетерәсе килә. Ә мин башлап җибә-

рергә ашыкмыйм. Лидия Руслановага охшаган гүзәл кыз Зөлфә әле һаман үз күңелемдә тора. Мавыктыргыч вакыйгалар аша үзенә тарта. Егеткә сөйләми торуымны теле кебек...

Этап шактый сузылды. Барабыз. Тынычлыкны бозып, овчаркалар өргәләп алгалый.

— Йә, Зөлфә турында сөйләп бетер инде, тәмам мин дә гашыйк булдым ул кызга,— дип Амангелдеев дәвам итүемне сорады.

— Тыңлыйсың килсә, башлап җибәрәм,— дим.

...Көннәрдән бер көнне атауның өстен еракларлан килеп кара болытлар каплаган. Бөтен тирә-як караңгылыкка төренгән. Үзләрен җылыткан, иркәләгән кояш күренмәгәч, кешеләр аптырашта калганнар, куркышканнар...

— Кояш тотылган көн булгандыр ул,— дип, тыңлаучы казакъ егетем миңа ачыклык кертмәкче булды.

— Юк, мин әйтәм, алай булмаган. Болытлар үтеп китүен кешеләр көткәннәр, ләкин алар һаман куерганнан-куерганнар, һаман куркыныч төскә керә барганнар.

Аның өстенә, үч иткәндәй, океан ягыннан көчле давыл килеп, түбәнтен генә йөзгән болытларны үзе белән аралаштырып, тагын да көчлерәк булып су баганаларын һавага очырган. Океан үкергән, улаган... Атау ярларына һөҗүм иткән. Күп тә үтмәгән, көчле дулкыннар, ярсып-ярсып ярлардан ташыган да сикереп-сикереп, атауга тәгәрәгән. Дулкыннар атауны күмеп китәргә омтылганнар...

Җырчы кызлар, Зөлфә белән бергә биек тауга менеп, көндәгечә, җырласалар да, шашынган дулкыннар тынмаган.

— Кем дә кем, атауга килгән өермәне туктатып, су басуга чик куя, без аны туган илнең батыр ир-егете дип танырбыз, дип җырлаганнар кызлар. Бу җыр Солтанны бик тә җилкендергән.

— Кешеләр җиңә алмаган бернәрсә дә юк! — дигән ул.

Солтан океанның атауга бәреп керүен кичекмәстән туктатырга дигән теләк белән янган. Тиз генә иптәшләре янына чапкан, аларны җыеп килгән дә зур-зур ташларны яр буена өяргә керешкәннәр. Атаудагы барлык халык егетләргә булышырга ашыккан. Күп тә үтмәгән, океаннан килгән дулкыннарга каршы куелган таш кыя барлыкка килгән.

Океан өстендә тагын да дәһшәтлерәк өермә күтәрелгән, тау кадәрле дулкыннар мәрхәмәтсезләнеп үкерә-үкерә, ярларга бәрә башлаганнар. Ләкин атау халкы аларның таш кыяларга бәрелеп кире чигенгәнен күргән.

— Әйе, океанны да кешеләр җиңде! — дип шатланганнар алар.

Зөлфә, иптәш кызларын җыеп, яңадан биек тау башына менгән. Ул йөрәген биләп алган ялкынлы җырын тыя алмаган. Аның кемгә атап җырлаганын барысы да сизеп торганнар:

Ир бул дисәм, ир булдың,
Ил тоткасы син булдың;
Яуга чыктың — ул яуда
Юлбарыска тиң булдың.

Гөлләр үссен юлыңа,
Былбыл кунсын кулыңа.
Йөрәгемне тапшырам
Илнең батыр улына!

Океан бәрсә илемә,
Сине күргәч чигенә;
Кыя булып син генә
Басалдың яр читенә.

Йөрәгеннең типкәнен,
Мине якын иткәнен,
Белдем, егет, күргәчтен
Океанның чигенеп
Үз иленә киткәнен...

Атау халкы гына түгел, бөтен табигать тынып калган. Әйтерсең лә, бу җырның моңына буйсынган. Күктә йөзгән кара болытлар таралган, атауны балкытып кояш чыккан.

Гүзәл Зөлфә, әле моңа кадәр бер дә җырламаган яңа җырларын җырлый-җырлый, Солтанны каршыларга океан ярына төшкән.

— Батыр егет, мең яшә, сүзең дөрес, чыннан да, кеше җиңә алмый торган дөньяда бер нәрсә дә юк икән.— Солтан, Зөлфә сүзләрендәге яшеренгән мәхәббәтне тиз генә аңлап алган да:

— Менә ул, син икәнсең гүзәл чәчәгем минем,— дип Зөлфәне кочагына алган.

Шул көннән соң күп тә үтмәгән, алар бәхетле матур тормыш корып җибәргәннәр. «Бәхет атавы»нда әле дә булса, һаман яшиләр, ди...

— Сөйләп бетердең дә мени? — дип куйды Амангелдеев.

— Ике яшь йөрәкнең ничек яшәүләре турында, калганын үзең күз алдыңа китер инде,— дигән булдым үз нәүбәтемдә.

Караңгы төшә башлагач, ял итәргә туктаттылар. Ниндидер шактый киң елга буе иде бу.

Артыбыздан арбага җигелгән ике ат та килеп җитте. Анда безгә ашап алырга ризык китергәннәр икән. Берәр селедка белән өч йөз грамм икмәк өләштеләр. Тамак ялгап алып, хәтсез генә ял итеп, юлыбызны дәвам иттердек. Угольнаяга күп калмады. Каршыбызда тиз агышлы елга бар икән. Шуның янына килеп җитәрәк, минем белән янәшә барган Демьянов:

— Күрәсеңме, әнә без ябыласы лагерь, елгадан ерак түгел ул. Урман итәгендә, тау битенә урнашкан. Эшкә йөрисе шахталар да ерак түгел. Бер авызың пешсә, өреп кабасың, дигәндәй, теләсә нишләтсеннәр, бу юлы да шахтага төшмәячәкмен,— диде.

— Моннан иртәрәк котыласың килми мени синең? — дигән соравыма:

— Сәламәтлегем төкәнде, көем калмады, җир астына төшүдән миңа мәгънә юк,— диде ул.

Лагерь тормышының ачысын-төчесен татыган кеше шулай дигәч, баштагы өметләрем какшады. Мин бит срогымны алданрак бетерергә исәп тоткан идем. Шахтада шартлаулар да булгалагач, шөбһәгә калдым. Бик күп еллар җәфа чиккән шул Демьянов. Аңа еллар гына үтсен. Зур үзгәрешләр көтә ул. Белмим, кайчан, ничек булыр үзгәреш? Совет дәүләте нык. Илгә коммунистлар хуҗа. Ничәмә еллар инде, коммунизмга барабыз, дип лаф оралар. Коммунизм булырына кешеләрнең иманы нык.

— Менә шушы инде Зырянка елгасы, күр, ничек шәп ага. Мондагы ташкүмерне баржага төяп түбәнгә төшерергә дә чамалап караганнар иде, барып чыкмады. Бер генә буксир пароходы да баржаны сөйри алмады...

Ике йөз метр чамасы киңлектәге елганы чыгар өчен як-ягына юан корыч трослар тарттырып, аларның өстенә калын такталар тезгәннәр. Шунда килеп җиткәч, безне берәмләп елганың аръягына чыгара башладылар. Без, аналарына ияргән үрдәк бәбкәләре сыман алдан чыгып киткән конвоирларга карап трослардан җәелгән асылмалы күпердән каршы ярга атладык. Күпер бишектәй тирбәлә. Елгага күз салсаң, баш әйләнә. Бигрәк биеккә күтәреп тарттырганнар корыч тросларны. Мондый асылмалы күперне кайчандыр Америка фильмында күргәнем исемә төште. Менә хәзер мин дә шундый күпер аша җәфалы тормышымны үткәрер өчен үзем яшәячәк коллар лагерына барам.

Күперне бер сәгать чамасы чыктык. Алдан киткән конвоирлар безне көткәннәр. Ярга чыгып тезелә тордык. Арттагылар әле һаман елганың теге ягында. Тирәсенә кагылган калын казыклар белән уратылып алынган лагерьга кул гына сузасы. Лагерьның почмакларына вышкалар куелган. Ярдан хәтта аларның сакчылары да күренә. Лагерь эчендәге зур мәйданда озын-озын тәбәнәк бараклар, әйтерсең, җыйнак кына бер авыл инде. Зэклар зонада йөргәли. Көн кояшлы булганлыктан, барысы да аермачык булып күзгә ташланды.

Иптәшләребез күперне чыгып беттеләр. Бишәр-бишәр булып тезелештек һәм безне лагерьга алып киттеләр.

Вахта йорты юан бүрәнәләрдән салынган. Янәшәсендә зур капка бар. Капка алдына барып җиткәч туктадык. Озакламады, вахта йортыннан

берничә хәрби чыкты. Араларында берсе өлкән лейтенант, берсе майор. Безне озата килгән өлкән конвоир кулында «дело»ларыбыз. Майор белән берничә сүз алышкач, исемлекне укый да башлады. Берәмләп киң ачылган капкадан зона эченә фамилияләре аталган тоткыннар керә торды. Анда аларны лагерь коменданты каршылады. Мин иң түрдәге биек казыклар белән әйләндереп алынган зонаның аргы башындагы баракка туры килдем. Буш урыннар хәтсез иде. Ишеккә якын тәрәзә янындагы сәндерәнең астагы ятагында үземә урын сайладым. Артымнан Демьянов та килеп җитеп, минем яныма урнашты. Безгә бергә күңеллерәк булыр...

Яныма киң җилкәле, коңгырт чәчле, балавыздай шома йөзле, сөйкемле генә бер кеше килде. Күрәм, танышырга тели.

— Татар малае икәнсең, әллә каян күренә. Без якташлар бугай. Исемем минем Зөфәр,— диде ул. Бик тиз сөйләшеп киттек. Чистай тирәсеннән икән. Чистай — Әлмәткә якын. Йөз километрдан чак кына артык. Кулларына күзем төште. Бер баш бармагы төптән диярлек юк.

— Шахтада электрик мин. Бармагымны шунда өздердем. Һәр эш көнем өчкә исәпләнә, срогым да бетеп килә. Монда эш кешесен яраталар. Юлдан арып, ачыгып килгәнсең, беркая да китмә, миндә ризык бар, хәзер алып киләм. Ашап алырсың,— дип, Зөфәр эре-эре атлап бараклан чыгып китте. Һәм тиз генә әйләнеп тә керде. Кулында корымланып беткән зур консерв банкасы. Ике литрлы булыр. Солы боткасы китергән бу.

Алюмин кашыгыбыз кесәдә безнең. Ботканы Демьянов белән тиз арада ашап та бетердек. Зөфәр карап торды. Ахырдан күзләрен кыса төшеп: «Тукайны беләсеңме?» — дип сорады һәм өзек укып алды.

«Нәкъ Казан артында бардыр
Бер авыл — Кырлай диләр...»

Бөек шагыйребезне ерак Колымада якташым авызыннан ишетү күңелле иде. Димәк, Зөфәр чын татар, укымышлы кеше. Яше утыз бишләр тирәсе булыр. Иркенләп сөйләшер өчен зонага чыктык. Зөфәр сөйли, мин тыңлыйм. Ул армиядә өлкән лейтенант, контрразведчик булып, сугышны башыннан актыгына кадәр алгы сызыкта үткәргән. Аны хәрби трибунал, бер мадьяр хатынын алтын алка-йөзекләрен салдырып үтерүдә гаепләп, ун елга хөкем иткән. Әмма җинаятьне ул эшләмәгән, башка офицерлар ачу итеп гаепне аңа аударганнар икән. Аклана гына алмаган. Мәрзия исемле сөйгән кызы да бар икән. Кулга алганнан бирле элемтәләре өзелгән. Бу хакта ул йөрәге әрнеп сөйләде. Һәркемнең үз язмышы, түземлелек кирәк шул, түземлелек!

— Ябык, кансыз икәнсең, ашау ягыннан булдыра алган кадәрле булышырмын. Поселокта Миндияров фамилияле танышым бар. Ул да электрик. Аның участогында да булгалыйм. Эшенә булышам. Ашау әйберләре белән миңа ул гел ярдәм итә. Хәзер конвойсыз йөрим. Озакламый нарат җиләге өлгерә. Витаминга бик бай ул. Синең срогың әлләни күп түгел икән. Әйбәт эшләсәң, дүрт елга да сузылмас, ирекккә чыгарсың...

Үзем тыңлыйм, башымда төрле уйлар... Срокның аның бер елы да бик озын гомер. Сабыр канатларым гына сынмасын...

Кичке аш вакыты җитте. Ашханә лагерьның сул ягында икән. Шунда киттек. Чират торып аш алдык. Үзәк лагерьдагыңа караганда монда аш әйбәтрәк, болан итеннән пешерелгән. Икмәкне өч йөз грамм бирделәр. Яңа килгәннәрнең кәефләрен җибәрмик, дип уйлаганнар, күрәсең. Болай ашатсалар, җанны саклап булыр...

Зөфәрнең акчасы да бар икән. Кичен ларектен шикәр, май, ак икмәк алып, үзе яшәгән барагына дәшеп мине тагын сыйлады. Күптән юньле ризыкларны күрмәгәнгә, миңа бу чын бәйрәм булды!

— Ай саен унар сум акча бирәләр, калганы җыела бара. Срогыңны тутырып чыга калсаң, кулыңа аласың. Чыгучыларны үзем күргәнем бар. Уч тутырып акча алалар да Зырянкадан материкка самолетта очып китәләр...

Зөфәр сөйләгән бәхет көне миңа килеп җитәрме, юкмы, анысын әлегә күз алдына да китерә алмыйм. Ә якташым бу лагерьда өченче елын бетереп килә. Бер көне өчкә саналганлыктан аның срогы шактый күп кыскарган. Тизрәк котылсын гына, илгә кайтып сөйгән Мәрзиясын табарга насыйп булсын аңа.

Йоклар вакыт җиткәнче Зөфәрдән аерылмадым. Дөресрәге, ул мине яныннан җибәрмәде. Материктан килүемә нибары елдан артык кына бит әле. Хәтерем әйбәт. Кораб, диңгез тормышы кызыксындырды аны. Мин аңа башымнан үткән нәрсәләрне сөйләдем.

Татар язучыларының әсәрләрен яхшы белүе белән мине ул үзенә бик якынайтты. Белмәгән язучысы юк икән. Хәтта безнең заманда тыелган Гаяз Исхакый әсәрләрен дә укыган булып чыкты. Якташы бит. Минем кулыма да кермәгән «Зөләйха» дигән пьесалар китабының эчтәлеген дә сөйләде.

Яңа килгәннәрне бригадаларга бүлгәннәр. Иртәгә эшкә шахтага барасы. Демьянов, Амангельдеев, Папин белән бер бригадада булып чыктык. Танышларым белән бергә булгач, күңелем тынычланды. Зөфәрнең «тырышып кешеләрдән калышмый эшләсәң, срогың кимер», дигән сүзләре уйларымны биләде. Ул юкка әйтмәс, тырышырга булыр, дигән уй белән ятагыма аудым. Озын юл үтеп нык арылганлыктан, шундук күзләрем йомылды.

Икенче көнне иртәнге аштан соң баракка булачак бригадирыбыз керде. Үзе белән таныштырды. Аннары вахта капкасы янына барып тезелдек. Исемлек белән барлап капкадан чыгара башладылар. Анда безне коралланган конвоирлар каршылады.

Тиз агышлы елга ярыннан бераз читтәрәк сузылган, күп токтыннар таптап шомарган юлдан шахтага юнәлдек. Шахта ерак түгел икән, озак та үтмәде, күмер тавына юлыктык. Аның өстенә рельс сузылган. Бераз баргач ничектер сәер бер корылма да күренде. Янәшәмдә атлаган Демьянов.

— Менә шушы инде шахтага төшә торган корама,— диде, алачыкка ошаган йортка ымлап. Килеп җиткәч бригадир артыннан шунда кереп киттек. Эче шактый зур, озын өстәле, эскәмиясе, тимер мичкәдән эшләнгән миче дә бар. Ул янып тора. Смена киткән генә, күрәсең. Безне эре гәүдәле, зур башлы, чиста сырма кигән өлкән яшьтәге кеше каршылады. Аның белән янәшә колгадай озын ярым хәрби киемдәге адәм дә бар иде. Өлкәне — смена мастеры, ярым хәрбие — техника буенча башлык икән.

— Хәзер алар безгә ничек эшләргә икәнне, куркынычсызлык кагыйдәләре турында сөйли башларлар,— дип, Демьянов миңа шыпырт кына әйтеп куйды.

Тартучыларга тәмәкеләрен, шырпыларын стенаның бер башыннан алып икенче башына кадәр сузылган бүлем-бүлем итеп эшләнгән шкафларга куярга, шундагы шахтер фонарьларын алып билгә бәйләргә, ә шнурга беркетелгән фонарьларны бүрегебезгә маңгаебыз турысына тагарга куштылар. Нотык күпкә сузылмады. Һәрберебез җитәкчеләрнең әйткәнен җиренә җиткереп күмер базына төшәргә җыендык.

Демьяновны смена мастеры таныды. Аңар карап елмайды да:

— Син, күгәрченкәем, яңадан миңа җәфа булырга килдеңмени инде? Өстә калдырам үзеңне, чыккан күмерләрдән токымнарны (порода) җыеп торырсың. Калдырсаң, үзеңә үпкәлә,— дип, аны алып калды.

Алачыкның аргы башында такта ишек бар икән. Бригадирыбыз шунда атлады. Без дә аның артыннан иярдек. Текә ярдан төшә торган баскыч сыман ителеп эшләнгән тар коега иңәбез. Сирәк-сирәк утыннарда тоныкына булып электр лампалары яна. Ярый әле башларыбызда түгәрәк фонарь. Алдымнан атлаган кеше артыннан калышмыйм. Аска хәтсез вакыт төштек. Штрек дип атала икән озын шахта юлы. Шуның уртасыннан тар гына тимер юл үткәргәннәр. Аның бер башы каядыр түргә

караңгылыкка китеп югала. Ә икенчесе күмерне өскә күтәртә торган якка сузылган. Рельс өстендә анда-санда әлләни зур булмаган тимер вагоннар күренә. Шулар ярдәмендә күмерне югарыга күтәртәләр, күрәсең, дип уйлыйм. Бик сирәк җирдә генә штрек өстендә электролампалар янганы күренә. Иң кирәк яктылык — үзебезнең бүрегебезгә беркетелгән яктылык. Бригадир әйткәнне көтәбез. Барыбыз да төшеп беткәч, кемгә нәрсә эшләргә кирәклеген әйтеп төрлебезне төрле якка җибәрде ул. Миңа вагонетка тәгәрәтергә насыйп булды. Якындагы буш вагонеткага барыпябыштым да алдан кузгалган Амангелдеев артыннан куып җиттем. Хәтсез генә түргә барып, алдагы вагонеткаларның берсенә ялгаш кебек киң калайдан күмер коелганын күрдем. Кай арада яныбызга бригадирыбыз килеп тә җиткән. Аны күрми дә торам.

— Лавада күмер җитәрлек, аяк астына коелганын көтмәгез, берегез артыннан берегез өлгерергә тырышыгыз,— димәгән булса, аның янымда басып торганын күрмәгән дә булыр идем. Күмер аккан төшне «лава» дип әйтелгәнен аңардан ишеттем. Вагоным тиз тулды. Алдан выжлап тәгәрәгән Амангелдеев вагонеткасы артыннан йөгемне этеп киттем. «Арбама» тонна чамасы вак ташкүмер төялүенә карамастан, рельстан шәп тәгәри. Күп көч куясы да юк. Вакыт-вакыт йөгерергә дә туры килә. Җир өстенә сөзәк кенә булып күтәрелгән урынга килеп җиттек. Аннан өстән аз гына көн яктылыгы төшкән. Каршылаучы берәм-берәм китерелгән арбаларны калын троска беркетелгән ыргакка эләктерә дә, үзе янындагы калын баганага беркетелгән щиттагы үгез күзедәй кара төймәгә баса. Шундук арба өскә менеп тә китә...

Арбаларыбызны соңгы тапкыр китерүебез булган. Бригадирыбыз, җыелып бетүебезне генә көткән икән.

— Шабаш, егетләр, смена нормасын үтәдек, иртәгә дә бүгенгедәй эшләсәгез, рәхмәттән башка бер сүз дә әйтмәсләр,— дип куйды ул.

Чыгу юлына атладык. Менә-менә арып беттем. Җир астына шактый тирән төшкәнбез. Дүрт йөзгә якын баскыч санадым. Чыккач, бер-беребезне танымадык. Күзләр генә ялтырый. Каралып беткәнбез. Зыян юк, юынгач агарырбыз әле...

Вахта капкасыннан кергәч, каяндыр Зөфәр килеп чыкты.

— Ничек, ошадымы шахта? — Аның беренче сүзе шул иде. Нәрсә дип әйтергә дә белмәдем.

— Эшләгән булдык инде, күрәсең ич, алып бардылар да кайтарып та куйдылар...

— Негрга ошагансың, бар юын, үзеңне рәткә керт, соңрак яныңа кереп чыгармын әле,— дип китеп тә барды.

* * *

Килгәнебезгә бер ай үтмәде, Федор Папин шахтадан авырып кайтты. Гел терәү тотып, өскә карап эшләгәнлектән, авызы ачылып калган, нишләптер ябылмас булган. Зөфәргә баргач күрдем аны. Кулы белән ишарәләп янына чакырды. Гел авызын ачып эшләгән, күрәсең. Нәтиҗәсе, сеңерләре аскы ияген тотмый башлаган, авызы гел ачылып тора. Лагерь врачы ялда, каядыр киткән. Ә санитар, дәвалый алмый. Иң мөһиме, ризыкны чәйнәүдән мәхрүм ул. Су, шулпа эчеп кенә яшәп булмый бит инде.

Өч көн баракта ятканнан соң, Папинны санитар пунктына салдылар. Анда биш-алты кешелек бүлмә бар. Нык авырып киткәннәрне генә урнаштыралар. Терелерлек булмаса, Зырянкага үзәк лагерьга ат белән илтәләр. Бу турыда санитар сөйләде. Ә кышын ташкүмергә килгән йөк машинасында озаталар икән.

Эштән кайтуга, Папин янына ашыгам. Сизелерлек ябыга башлады бу. Санитар берниндиярдәм итә алмый. Ә врач һаман кайтмый.

Эшем эш булмады, уйланам, күптәнге танышым Папинны кызганам. Санитар аннан туеп беткән, ашатырга да иренә. Килгән саен Папин миңа кулы белән ашыйсы килгәнлеген аңлатырга тырыша. Сәгатьләр буе яныннан китмим, шулпаны авызына кашык белән салам. Картның, мине күрде исә, күзеннән яшь тәгәри башлый. Кызганам бичараны. Шулай бервакыт Зөфәр:

— Кемең ул синең, шулкадәрле, нигә өзгәләнәсең аның өчен? — диде.

— Лагерь тормышында тәүге яшь башлаган көннәремдә, синең кебек, миңа ризык белән кул сузган кеше ул,— дидем.

— Аңладым, бик әйбәт, авыр вакытта ярдәмчел булуыңа рәхмәттән башка сүз әйтә алмыйм,— дип куйды Зөфәр.

Ярдәмчел булу бер хәл, ә менә картны аякка бастыруның берәр әмәлен табып булмасмы? Эштән кайтканда бернәрсә уйлап кайткан идем. Әгәр дә авыру риза булса, тормышка ашырып карарга исәплим...

Флотка китәр алдыннан, еш кына циркка йөрдем. Бигрәк тә боксерларның аренада күннән эшләнгән йомыры калын бияләй белән бәргәләшкәннәренә сокланып бетә алмый идем. Шулай берчакны берәүнең ияген төшерделәр. Авызын яба гына алмый бит теге. Арбитрлары авызы ябылмаганны күрәш мәйданыннан тартып чыгарды да, читкә алып китеп, тамашачылар күзе алдында кулындагы сөлгесе белән ике куллап башта тегенең ияген капшап карады, сынмаган икәнлегенә тәмам ышангач, учларын киң итеп ачып, сөлге аша бармаклары белән асылынып төшкән боксерның ияген күтәртте дә урынына элеп тә куйды. Аннары шул ук сөлге белән ияк астыннан башына чолгап аренадан чыгарып та җибәрде. Папинның да шундый хәл түгел микән дигән фикер башыма килеп төшмәсенме!

Кыюланып санитарный бүлек урнашкан йортка бардым. Башта хәләхвәл сораштым. Аннары санитар белән сөйләшеп алдым. Папинга теләгемне аңлаттым. Сөйләшә белмәсә дә, миңа ризалыгын белдерде. Башта ияген капшап карадым, яньчелгән-ниткән җире күренми. Күп вакыт үткән шул. Урынына утырыр микән дип шикләнеп тә куйдым. Шулай да омтылып карарга кирәк булыр дигән нәтиҗәгә килеп, санитарга су кайнарлатырга куштым. Суны тиз өлгертеп өстәлгә китереп куйгач, урын җиреннән җәймәсен алып, аны җебеттем. Бик үк кайнар булмасын дип җилләтеп, картның яңакларын берничә тапкыр угалап йомшарттым. Иң мөһиме генә калды. Бусы ике учым белән бармакларымны батырып ияген күтәреп үз урнына эләсе. Тәвәккәләдем! Башта картның ияген аска таба бастым, аннары күтәртеп үз урынына авырлык белән генә элеп тә куйдым. Папинның маңгаеннан, йөзеннән тир бәреп чыкты. Мине аягы белән тибәргә чамалады. Ләкин бөтен авырлыгы белән өстенә ава төшеп, аңарга хәрәкәтләнергә урын калдырмадым. Эш бетте.

Яңадан төшмәсен дип шул ук простыня белән башын урадым.

Ул кичне озак кына санитар пунктында утырырга туры килде. Берничә мәртәбәләр карт санитар яныбызга кереп күренде. Соңгысында:

— Лагерь йоклый инде, иртәгә эшкә барасың бардыр, кайт,— дип чыгарга кушты.

— Иртәгә кадәр авызыңны ачасы булма!

Папин, тыңлармын дигәнне белгертеп, башын селекте. Барагыма кайтып киттем...

Икенче көнне эшкә китәр алдыннан хәлен белергә Федор Папин янына кердем. Кулына кашык тотып ашап утыра. Күрүенә мине басып каршылады. Кочаклап үпте. Өлкән кешенең сабыйларча шатлануына чиксез дулкынландым. Әгәр дә алданрак башыма килгән булса, карт күптән аягына баскан булыр иде.

Эшемнән кайттым. Яныма Зөфәр килеп:

— Доктор да була беләсең икән, әйдә миңа, сыйламый да булмас инде үзеңне,— дип, яшәгән барагына алып китте.

Чәй кайнаткан, ак май белән конфет куйган. Бергәләп булган ризыкларны сыпырдык...

* * *

Жәй башланды. Эссе, бөркү көн иде. Демьяновны ни өчендер безнең белән җир астына күмер эшенә билгеләгәннәр. Ул наряд будкасында аска төшүдән баш тартты. Югарыда токым сайлаучы итеп куйгансыз икән, шунда гына эшлим,— дип кырт кисте.

Смена бетеп, югарыга күтәрелгәч, Демьяновны шәрә хәлдә күреп чәчләрем үрә торды. Бик тә кызгандым мин аны. Шахтага төшмәгәне өчен конвоирлар аны тышка алып чыгып чишендергәннәр. Без күтәрелгәнче шәрә килеш черкиләрдән талатканнар. Бөтен тәне чөгендер кебек кып-кызыл булган. Ничек түзгәндер, мескенем...

Күңелем бик озак төшенке йөрде. Эшкә барганда, кайтканда башымда гел караңгы уйлар булды. Мәрхәмәтсез кешеләргә каһәр укыйм. Ачу катыш усалланып эшләдем. Йөрәгемнең ярсуын басар өчен иң авыр күмер кисәкләрен лавадан ялгашка үзем төшерәм. Төшмәгәннәрен кәйлә белән чәрдәклим. Көчем җитмәгәннәренә авыр ломны эшкә җигәм. Күз алдымда һаман шәрә килеш Демьянов басып торгандай була. Теге көннән бирле ул эшкә чыгудан бөтенләй баш тартты. Башта нарядчик яхшылап сөйләшеп тә караган. Аннан лагерь начальнигына җиткергән. Аның эше нәрсә белән беткәндер, белми калдым, үземә дә болыт куерып килә башлаган икән.

...Смена бетәргә күп калмаган иде. Соңгы мәртәбә вагоннарыбызны күмер белән тутырасы да, шуның белән вәссаләм! Сак астында кайтып китәсе генә калды.

Вагоннарны китерделәр, ә күмер бетте. Эш башлаганда бораулаучы, лавада күмер җитәрлек, дигән иде. Әмма ялгаштан акмый гына бит күмер. Берәүнең дә параллель юлга менәргә батырчылыгы җитми, кыймыйлар. Нишләргә? Күмер агарга җайланган шома ялгаш янында минем кебек биш-алты егет чуала. Йөзләре кап-кара, күзләре генә ялтырап күренә. Өскә менәргә батырчылык итүче булмагач, үзем тәвәккәлләргә булдым. Ялгашка зур гына күмер кисәге аркылы яткан икән, урыныннан кузгатуым булды, аска таба вак күмер шаулап ага да башлады. Бер-бер артлы вагоннар тулып та өлгерделәр.

— Күп кирәкми инде, синең вагон гына калды,— дип кычкырдылар астан.

Тирәмдә күмер бетте, ә югарыдарак зур кисәкләр вак күмерне тоткарлап тора. Барып кузгатасы үзләрен. Бераз күтәрелеп шулар янына барасым килде. Берничә адым атларга өлгермәдем, лава түбәсеннән вак-вак күмерләр ташкыны ага башлады. Маңгаема беркетелгән фонарь белән яктыртып алырга да өлгермәдем, боз чатнагандагыдай тавышлар ишетелде. Чигенергә соңга калдым, өстән гөрселдәп күмер ишелеп тә төште. Вак күмер мине үз астына күмеп, ялгашка таба өстемнән агып та китте. Шул ара да булмады, лава ишелергә тотынды. Мин күмер астында калдым. Селкенер хәлем дә юк. Җаным атылып чыгардай булды. Берниндн дә тавыш-фәлән ишетелми. Менә тирә-юнь тып-тын булып калды...

Гәүдәмне кыймылдата да алмыйм. Казып чыгармасалар, үземнең күмер астыннан котыла алырлык көчем калмады. Тавыш бирергә дә мөмкинлегем бетте. Башымнан утлы уйлар уза.

...Ике йөз метр җир астында, мәңгелек тыңлыкта! Йөрәгем өши, зиһенемне җыя алмыйм, акылдан шашарга җиттем, ахрысы. Кем мине моннан коткарып чыгара алыр икән? Яшьли флотка китеп, ничәмә еллар ватанга тугры хезмәт иттем, энә очы тикле дә хыянәтем булмады, мөртәтләр, динен, иманын, халкын саткан кабахәт җаннар мине шушы

хәлгә калдырдылар... Нигә тудым соң әле мин бу дөньяга? Җәфа чигәр өченме! Уйларга вакытым күп иде минем салкын җир куенында, кайда калуымны беркем дә белмәячәк. Барлык кылган эшләрем тузандай юкка чыгачак. Хәзер мин кемгә кирәк?! Колыма җиренәме? Ни өчен, нинди гаебем өчен? Мәхәббәт чишмәсеннән дә авыз итмичә, очраклы үлем белән корбан китүемә әрним. Барысы да акрынлап күз алдыма килеп баса башлады. Әнием, әтием, әбием, бабам, туганнарым — һәммәсе дә бер-бер артлы исемә төште. Акрынлап күңелем таш булып катты. Тәнемнән җаным чыкмаганлыгын гына уйлый алам. Димәк, тере икәнмен. Тәнне һаман саен күмер кыса бара. Менә бервакыт җаным тәнемнән чыгып киткәндәй булды. Читтән үземне күрәм. Каядыр бик еракта нindидер якты ут күренә. Мин шунда җансыз тәнемне озата барам. Бернинди дә авырту, кысу, җәбер-золым да сизмим, ә шундый зур тизлек белән каядыр акканлыгымны тоям...

Берзаман кеше тавышлары колагыма ишетелде. Аннары, дөп-дөп басып, кемдер яныма якынайды:

— Монда ул, фонарь яктылыгын күрәм,— дип кычкырды. Боларны ишеттем, аннары...

Ашыгып-ашыгып мине казып чыгаралар, ахрысы. Үземне сөйриләр, ә нишләптер чыгара алмыйлар. Күрәсең бик тирән күмелеп калган булганмын.

Җылы һава йөземә бәрелде. Күзләремне ачсам, ни күрим — мин җирдә. Шахтадан казып чыгарып җир өстенә күтәргәннәр үземне.

Яңадан кояш күрүемә сөенеп бетә алмыйм. Менә ул ак дөнья, нинди киң, матур, саф һавалы! Янымда кешеләр сөйләшә, тик сүзләрен генә аңлый алмыйм. Лагерь санчастенда акылыма килдем. Барысы да аңлашылды. Мине 18 сәгатьтән соң, ягъни икенче көнне генә исән-сау казып алып кайтканнар. Моннан да зур сөенечнең булуы мөмкинме? Мин исән! Яныма танышларым килгәли. Хәзер инде ашау да, су да тамагымнан үтә. Акрынлап үз хәлемә кайтам. Торып йөргәлим, һавага чыгам. Димәк, мин теге дөньядан кайттым. Алла мине онытмаган, яшәргә хаклыгымны мәртәтләргә исбатлап күрсәтү өчен тере килеш алып кайткан!

Зөфәр Әхмәдиев килде. Ул поселоктан үзенең иректәге дустыннан булса кирәк, шеколадлы конфетлар, кипкән өрек, нindидер как сыман нәрсә белән ак күмәч китергән. Менә бит ул олы җанлы, мәрхәмәтле кеше. Исән калуыма сөенеп бетә алмый.

— Болай булгач, яшисең әле, бер дә борчылма. Тукай ничек дип әйткән әле, тукта хәзер исемә төшерәм:

...Кисмәк өстендә кара кош —
Иттифакый кунган ул.

— Барысы да артта калыр. Исән булсак, синең белән без әле туган якларыбызда күрешербез...

Аның сүзләре минем күңелемне күтәрде. Тәнемнең сызлавы басылгандай булды. Әйе, болай булгач, яшим икән әле. Колыма дөньясы ничек кенә кырыс булмасын, анда тереклек бар. Без бар! Кешеләр теш-тырнаклары белән җиргә ябышып гомер итә. Яшь кешегә, егет кешегә нинди генә авырлыклар башына төшсә дә түзәр.

Зөфәр хәтсез утырды янымда. Аның тормыш турындагы фәлсәфи әңгәмәсенә таң калдым. Моңарчы мин яшәүнең төп чыганагы материя дип уйлый идем. Ә аныңча, җан икән. Җанның үлемсезлеген шундый матур итеп сөйли, исем китте. Аныңча, тәнебез яши-яши картая, искерә, үлә. Җиргә күмелә. Ә җан мәңгегә яшәвен дәвам итә. Ул йә яңа туган бер кешегә, йә бер үсемлеккә, йә хайванга гомер бирә...

Зөфәрне тыңлыйм, үзем тирән хыялга биреләм. «Кара әле, бу чыннан да синеңчә бит»,— дип куям.

— Синеңчә ничек?

— Минемчә... Ә нигә алай булгач, Сталин, Гитлер кебек явызларга да җан бирә ул Ходай?

Тормыш мәшәкатьләренә чумып яшәгәнлектән, җан турында фикер йөрткәнем юк иде. Моның сәбәпчесе, әлбәттә, Зөфәр якташ. Ул сөйли, мин тыңлыйм.

— Берзаман сары төлке, авылга тавык урларга ауга киткән икән. Хуҗа бу юлы аны сагалап торып мылтыктан аткан. Бәхетедер, ядрә тимәгән. Куркуыннан төлке абзар, бакча артыннан алдын-артын карамыйча урманга сызган. Яңадан ядрә тимәсен дип турыдан элдергәндә сазлыкка сикергән. Аның көч-хәл белән үткән дә, урманына барып җиткән. Бу юлы тиресе саз лайласына буялып кап-кара булган. Чираты буенча төлкенең урмандагы барлык җанварларга патшалык иткән чагы икән. Урманга керүенә, аны башта танымаганнар.

— Нинди ерткыч икән бу? — дигән гаҗәпсенеп бүре. Хәтта, аю да:

— Мондый ерткычны безнең беркайчан да күргәнебез юк, — дип куйган.

— Мин сезнең Аллагыз, яныгызга бергәләп яшәргә килгән Аллагыз, — дигән төлке.

Аның бу ягымлы сүзләренә ышанып, ерткычлар яңадан аңа буйсынып яши башлаганнар. Төн җиткән. Ерткычлар кем ничек шулай, үз тавышлары белән хәбәрләшеп һәркайсысы ауга китәргә җыенган. Төлкегә дә чират җиткән. Аның шундук кем икәнлегенә тавышыннан бик тиз төшенгәннәр. Алла түгел, гап-гади бер төлке генә икән ул. Аның ялганын тотып, шундук кулга алганнар...

— Әкиятенең мәгънәсен аңлап бетермәдем әле, — дип куйдым.

— Бер дә исең китмәсен, безнең заманда бер генә намуслы кеше дә дәүләт башында утыра алмый. Менә шуның өчен дә инде, миллионлаган кешеләрне җәбер-золымга дучар иткән кабахәт җаннар өстебездән хакимлек итәләр дә...

Тормыш үз тәртибе белән ага бирә. Бер ай дигәндә терелеп, мине санитар бүлмәсеннән чыгардылар. Иртәгә эшкә чыгасымны белгәч, нарядчикка барып, бүтән шахтага төшмәячәгемне әйттем. Ул дәшмәде. Лагерь начальнигы белән сөйләшермен, дип куйды...

Минем өчен хәвефле көннәр башланды. Эшкә куалар, ә мин киреләнәм.

— Нинди генә эшкә куйсагыз да ризамын, шахтага гына төшәргә булмасын, — дим.

Бер кичне баракка нарядчик килеп керде.

— Тиз бул, сине начальник сагынган, — диде ул.

Минем әле лагерь түрәсенең хакимлек иткән йортына аяк атлаганым юк иде. Җәберләү өчен чакырадыр әле дигән шикләнү белән нарядчик артыннан иярдем. Үземне генә чакырганлыктан, күңелемдә шөбһәле уйлар тынгылык бирми генә бит. Бүлмәсенә кергәч, күрәм — анда безнең лагерьның докторы, тагын моңарчы бер дә күрмәгән тәбәнәк, ак йөзле, күзлекле ярым хәрби киемнән кеше дә бар.

Нарядчикны чыгарып җибәрделәр. Бүлмәдә дүртәү генә калдык.

— Синең формулярың белән таныштык, корабльдә чакта артиллеристлар бүлекчәсендә өлкән санитар булып та бераз эшләгәнсең икән.

— Туры килде.

— Сугыш вакытында беренче ярдәмне күрсәттеңме?

— Шуның өчен укыттылар.

— Латинча укый беләсеңме? — Бу сорауны лагерь врачы бирде.

— Яхшы беләм.

Шунда таныш булмаган ярым хәрби кеше, нәрсәдер язып миңа сузды. Шундук укып та бирдем. Рецепт иде бу. Миннән медицина буенча имтихан ала башладылар. Жгут куюмы, кан басымын үлчәүме, укол салумы — берсе дә калмады. Йә лагерь врачы, йә ярым хәрби бер-бер артлы сораулар яудырып кына тора. Эшнең кая таба барганлыгын тиз аңлап алганлыктан, кыю рәвештә уйлап кына, дөрес җавап бирергә тырышам.

Башка сорау бирмәделәр, чыгарып җибәрделәр. Барагыма кайтып, кешеләр белән сүз алышырга өлгермәдем, нарядчикның тавышын ишеттем.

— Бадыйкшанов, сине лагерь врачының ярдәмчесе — өлкән санитар итеп билгеләделәр, бар, каптеркадан менә бу язу белән яңа киемнәр ал,— дип кулыма кәгазь сузды.

Шул көнне мин лагерьның өлкән санитары булып алдым. Карт санитарны минем ярдәмчем итеп калдырдылар. Аның иреккә чыгарга срогы күп калмаганлыктан, врач эштән чыгарырга кыймады.

Хәзер минем вазыйфам зур, врач югында аның урынына авырулар кабул итәм, лагерь ашханәсендә баракларда чисталык тикшерәм. Зонадан шактый читтә урнашкан поселок больницасыннан үзебезгә кирәкле дарулар алып кайтам. Моның өчен озатып йөрергә махсус конвой бирәләр. Сәяси тоткын булганга, сакчылар миннән шикләнми.

Торган җирем санчастьның кечкенә бүлмәсендә. Карт санитар да шунда яши. Танышларыма еш кереп йөрмәскә куштым. Бу алар өчен дә, минем өчен дә бик кирәк. Лагерь җитәкчелегенә төрле имеш-мимешләр ишетелмәве хәерле.

Хәзер миңа доктор дип кенә эндәшә башладылар. Баштарак эшем авыр булды. Бигрәк тә врач килмәгән көннәрдә. Кайбер тоткыннар, юк сәбәп табып (янәсе, яңа кешене алдап булыр), интәшә башлады. Алар эшкә чыкмас өчен нинди генә хәйләләр уйлап тапмыйлар. Хәтта иң тәҗрибәле врач та белә алмас хәйләләрен. Ә мин яхшылап сөйләшәм, чиратка куям, син иртәгә эшкә чыкмассың, бүгенгә алып кала алмыйм, кирәгеннән артык күп калдырдың инде, дигән булам. Ризалашалар иде тагын.

Озак та тормыйча, бик тә күңелсез бер хәл булып алды. Беркөнне минем белән олы җирдән бер вакытта килгән ике карак яныма килделәр:

— Доктор, зинһар безне коткара күр, үләбез,— ди болар.

Башта ышанмый тордым. Аллалары белән ант итәләр.

— Нәрсә булды соң сезгә? — дим.

— Менә инде өченче көнебез, нәрсә генә ашасак та, кан булып агып чыга. Тукта та гына күр,— диләр.

Врачның каядыр киткән чагы иде. Мин бик тә борчылдым. Икесен дә авырулар өчен җиһазландырган махсус бүлмәгә урнаштырдым. Анализларын алдым. Чыннан да, дөрес икән. Канлы дизентерия. Моны бары врач кына хәл итә ала. Нишләргә? Ул кайтканчы үлеп китсәләр? Башым бетәчәк... Боларга кемдер поселоктан бозылган балык консервасы китергән. Нәтиҗәсе — нинди дә булса ашыгыч чара күрелмәсә, икесе дә үләчәк. Лагерь начальнигына барып хәлне аңлатып бирдем. Кичекмәстән үзәк лагерьга, Зырянкага озатырга кирәклеген әйттем. Җавабы кыска булды:

— Исең китмәсен, бездә андый хәлләр җитәрлек, үлсәләр күмәрләр, лагерь артында урын җитәрлек, аларны алтмыш километрга илтергә транспортыбыз юк, юл сазлыклы, җәяү генә барып була. Аларны озатырга конвой да кирәк, лагерьны сакларга да кеше җитми...

Аптырап калдым. Башымны иеп, күңелсез генә санчастька кайттым. Төрлечә уйлап карадым, бары бер генә сорау борчыды, ул да булса — нишләргә?

Кан агуны туктата торган бернинди дә дару юк, барлык шкафның шүрлекләрендәге порошокларны, микстураларны җентекләп укып чыктым. Аңламаганнарын медицина сүзлегеннән ачыкладым. Җавап таба алмадым.

Санчастьның бәдрәфе белән янәшәдә тәрәзәсе-ишеге рәшәткәле кечкенә генә бер тар бүлмә бар. Анда үлгән яки акылдан язганнарны гына керткәннәрен кемнәндер ишетеп калган идем. Болар, минәйтәм, ашарга сорарлар, мин ашханәдән китерттермәсәм, иптәшләре китерәчәк. Ә аларга ашарларына бирергә һич тә ярамый. Башыма килгән фикеремне

әйтергә дип вахта начальнигына бардым. Нәрсә булганлыгын аңлатып бирдем. Яшь лейтенант мине тыңлаганнан соң:

— Бер дә курыкма, үзеңчә эшлә, бер конвой бирермен, бүлмәңне саклар,— диде. Аның яныннан тынычланып туп-туры ашханәгә киттем. Өлкән пешекче Тунядән дүрт селедка сорап алдым. Санчастька кайтып теге ике егетне изоляторга кертеп утырттым. Бер дә карышмадылар, керделәр.

— Егетләр, мине тыңласагыз, исән каласыз, әгәр дә каршы килсәгез, бетәсез. Икесенең берсен сайлагыз?

Йөзләре суырылган, күзләрендә яшәү нуры сүнгән егетләр беравыздан:

— Сиңа ышанабыз,— диделәр.

Күгәрчен дә очып чыга алмаслык бүлмәнең түрендә мыштым гына утыралар болар.

Төрмәдәгедәй кечкенә ишегенең уртасындагы тәрәзәчектән икесенә дә башта берәр селедка бирдем. Аны бик тиз ашап бетерделәр дә су сорадылар.

— Хәзер, мин әйтәм, кайнаган суга повар янына китәм, мәгез тагын берәр селедка ашый торыгыз...

Алып ашый да башладылар. Ишекне япкан булып үз бүлмәмә чыгып утырдым. Биш-ун минут үтмәде, болар ишекне дөмбәсли дә башладылар. Эндәшмим. Тагын да ныграк кагалар болар, әй кагалар...

Лейтенант сүзендә торды. Кичкә таба санчастька сакчы җибәрде. Мин бүлмәмнән чыкмадым. Тегеләрнең су сорап тавышлары карлыгып бетте. Сакчы кечкенә тәрәзәчекне ачып:

— Сезгә ни кирәк, тавышланмагыз,— дип бер-ике тапкыр әйтеп тә карады. Кая ул, ерткыч җанварларча карлыккан тавышлары белән:

— Сусыз интектереп үтермәкче буласызмыни?— диләр.

Сакчы ике мәртәбә алышынды. Минем йокым йокы булмады. Карт санитар:

— Зур бәла алдың башыңа, моның ахыры үзең өчен дә начар булып бетүе мөмкин,— ди.

— Түзсеннәр, читтән кергән тәмле калҗа ашый белгәннәр,— бер-ике көндә генә үлмәсләр әле,— дим. Яхшы беләм — тозлы балык эчне киптерәчәк, ашказаннарындагы микробларны яндырып бетерәчәк...

Биктәгеләр икенче тәүлеккә чыкканда эндәшмәс булдылар. Иптәшләре хәлләрен белергә теләсәләр дә, сакчы аларны изоляторга якын да җибәрмәде.

Өченче тәүлеккә чыкканда гына шкафтагы кипкән гөлҗимешне жебетеп пешекләдем дә икесенә дә берәр стакан төнәтмә бирдем, комсызланып бер генә йоттылар. Тагын сорадылар, бирми тордым.

— Ничек, хәлегез әйбәтләндеме?

— Эчебез авыртмый инде, кан да килми башлады.

— Тереләсез, хәзер ашарыгызга да китертәм,— дип карт санитарны ашханәгә майсыз гына ботка, куе чәй алып килергә җибәрәм.

Карт санитар тиз әйләнеп килде. Изолятордагылар бик яратып китергән ашамлыкларны тиз арада сыптырып та бетерделәр. Аннары үзләренә чәй бирдек. Анысын да эчтеләр.

Өч көн дигәндә авыруларым аякка басты. Изолятордан чыгарып, зуррак бүлмәдәге ятакларга кереп урнашырга рөхсәт бирдем үзләренә. Егетләр миңа башта бик ачулы булсалар да, сусау басылгач, терелеп тә киткәч, рәхмәт укудан башка чаралары калмады.

Аларны санчастьтан чыгарып җибәргәч, күп тә тормады врач кайтты. Хәлне сөйләп биргәч, эче катып бер рәхәтләнеп көлде.

— Булдыргансың,— киләчәктә синнән шәп врач чыгачак,— дип мактады. Аннары:

— Срогың күбрәк шул, иреккә чыгуга, врачлыкка укырга керергә дә булыр иде. Белемең дә бар,— дигән булды.

Тагын бер хәл турында язып үтим. Лагерь ашханәсенә зонаның теге ягындагы ашамлык складыннан наряд буенча бер капчык он китергән булганнар. Капчыктан болан башы килеп чыккан. Шуның казанга салырга яраклымы-түгелме икәнлеген тикшерергә мине чакырдылар. Мин бик аптыраштa калдым. Кем белә, бәлки, ул баш бациллалыдыр. Тоткыннарга аннан аш пешерсәләр, кырылулары мөмкин. Шундый нәтиҗәгә килеп, уйлап-уйлап тордым да, вахтадан дежур лейтенантны чакырттым. Башны элек зонадан алып чыктык. Складка барып ризыклар җибәрүчедән сораштырып, башка капчыкларны капшап карадык. Болан башының бер генә капчыктан чыкканлыгы беленгәч, шөбһәгә төштем. Капчыклар язда ук китерелгәнгә, башның яраксызлыгына шигем калмады.

— Чокыр казып башны шунда яндырып күмәргә кирәк,— дидем.

Барысы да аптырап калдылар.

— Бозылмаган ул, сөрсемәгән дә, әрәм итмик,— ди повар. Дежур лейтенант минем яклы.

— Ярый, шулай эшләрбез,— диде склад башлыгы. Ул иректәге кеше иде. Кайчандыр шушы лагерьда утырып чыккан булган. Эшләргә калган. Минем китүемне көтә болар. Ә мин ашыкмыйм.

— Әйдәгез, эшне тизрәк бетерик,— дим.

— Нишләп бозылган булсын, менә врач кайтыр, үзе тикшерер. Аңарчы складта торып торсын,— ди кухня эшчесе.

Үземнекен иттем. Башны җиргә күмдереп санитар пунктына кайттым.

Өлкән повар оештырган булып чыкты моны. Болан башын миннән ярамаслык иттереп таптырып, дус-ишләрен сыйлар өчен шул авырлыктагы онны алып яшергән булганнар.

Врач кайткач, аңа барысын да сөйләп бирдем. Ул рәхәтләнеп көлде. Эшемне хуплады.

## Унберенче бүлек

1953 елның бишенче марты барлык нечкәлекләре белән күңелемә сеңеп калды. Иртә белән санчастька берәү дә килмәде. Карт санитар белән икәү генә утырабыз. Ул тәрәзәдән карады да:

— Кара әле, кешеләр, КВЧ янына ашыгалар. Бу кадәрле күпләп ашыкмаслар иде, әллә тагын берәрсен суйдылар микән? — ди бу.

— Әйдә, картлач, китик әле шунда,— дидем.

Тиз генә шунда юнәлдек. Юлда ук берәү очрап:

— Сталин үлгән, Сталин! — димәсенме!

Йөрәгем әллә нишләп китте. Әмма җыелган тоткыннарның йөзләренә карап, көрсенү, борчылу яки шатлану сизмәдем. КВЧ инспекторы юлбашчының үлеме турында кыскача хәбәр иткәннән соң, күпләр башларын иеп кенә тора башладылар. Анда-санда һавага баш киемнәрен чөючеләр дә булды. Ләкин андый-мондый начар сүз ычкындыручы булмады.

Лагерь режимы сизелерлек булып үзгәрде. Күпме кирәк, шулай хат яза аласың, конвоирларның тоткыннарга мөгамәләсе яхшыланып китте. Үзебезне иркенрәк тоя башладык. Зур үзгәрешләр көтәбез, ә ул һаман юк та юк әле...

Күпмедер вакытлар үткәч, Бериянең кулга алынып, тиз арада хөкем булуын ишеттек. Бусына инде тоткыннар сөенеп бетә алмадылар. Аның КВЧда эленеп торган зур рәсемен йолкып төшереп, залдан сөйрәп чыгардылар да лагерьның уртасына вахта капкасы турысына ташлап, баштa өстенә менеп биеп алдылар, аннары ут төртеп көлешә-көлешә яндырдылар.

Бик күп җәфа чиккән танышым Демьянов кич белән яныма килеп:

— «Мыек койрыгын төшерде», аннары аның иблисен дөмектерделәр. Көт тә тор, Локман, озакламас, илдә хөррияткә юл ачылыр,— дип чиксез куануын әйтте...

— Яхшы якка үзгәрешләр була гына күрсен,— дип, озак кына сөйләштек Демьянов белән. Аның күңеле күтәренке, кәефе әйбәт. Балаларча сөенеп яши башлады ул.

Илдә зур үзгәрешләр көтелсә дә, Колымага юл ерак, монда хәлләр һаман элеккеге килеш кала бирде.

Апрельдә Зөфәр Әхмәдиев срогыннан алда шахтада эшләгәнлектән, иленә кайтып китте. Киткәндә саубуллашты, поселок кибетеннән миңа күчтәнәчләр китерде.

— Син дә котылырсың, зур амнистия булыр, дип өметләнәләр. Күңеленне төшермә,— диде ул соңгы күрешүебездә.

Аның лагерьдан конвойсыз чыгып китүен карап калдым. Ямансу булып китте. Санчастька кайтып, врачның килгәнен көтә башладым. Ләкин ул билгеләнгән вакытына өлгермәде. Ашханәдән иртәнге ризыкның сыйфатын тикшереп журналга кул куярга дип пешекче үзе килде. Аның янында ак сөлге белән ябылган поднос тоткан кухня эшчесе дә бар. Башта пешекче сөлгенең бер башын ачып алюмин савыттагы иртәнге ашны кабып карарга кушты. Ризык әйбәт, тозы да ярыйсы, арпа ярмасы да әйбәт пешкән, шулпасында өреләре дә бар.

— Кулыңны куй,— ди бу, үзе янәшәсендә басып торган булышчысына карап күзен кысып алды. Тегесе шундук подноска ябылган сөлгене ачып җибәрде. Ни күрим, икенче алюмин савытта кызарып пешкән ярты үрдәк куелган.

— Бусыннан да рәхим итеп авыз итеп кара, доктор Бадыйкшан,— дип куйды повар.

Лагерьда тоткыннарга кош итләре ашатыр вакытлар да җитте микәнни, дип уйласам да, үземә-үзем ышанмыйм.

— Бик шаян син, Сергей, болан итеннән үрдәкнекен бер караудa аера беләм. Шунысы гаҗәпләндерә, каян эләктердегез?

— Анысы аның икенче мәсьәлә. Вакыты җиткәч каян алганлыгымны күрерсез!

Кабып карыйм, искиткеч тәмле. Исем китте, алдымда ерак төньякта майда кыздырылган үрдәк ите тора, җитмәсә, урталай ярып пешерелгән алмадай кызарып торган бәрәңгеләр дә бар. Авызыма сулар килде. Комсызланмадым, бер-ике генә каптым да карт санитарга:

— Син дә сыйлан,— дидем.

— Бригадир эшкә киткәч, кухняга килерсең, шунда үрдәкнең каян килгәнен үз күзең белән күрерсең,— дип, пешекче Сергей булышчысын ияртеп ашханәгә чыгып китте.

Күп тә үтмәде, иртәнге кабул итү башланды.

Бригадаларны эшкә озаткач, көндәгечә, комендант, нарядчик, вахтадан дежур сержант белән берлектә чисталык тикшерер өчен баракларга юнәлдек.

Бәйләнерлек, начар җыештырылган баракларга тап булмадык. Кизүләр тырышканнар. Без килгәнче әйбәтләп юып чистартып чыгарганнар. Идәннәр ялт иткән, урын-җирләре дә тәртиптә.

Тикшереп йөрү тәмам булгач, ашханәгә киттем.

Апрель быел җылы башланган иде. Лагерьга якын гына тау елгасына су төшкән булса да, соңгы ике-өч көндә һава кинәт салкынаеп киткәнлектән, яңадан боз белән капланды. Җитмәсә, кар явып үтте. Су кошларына чын мәгънәсендә ризык табу кытлыгы туды. Үрдәкләр, акчарлаклар кая барырга белмичә, якындагы урманга, лагерь артындагы чүплеккә таба очалар, өз гына кардан арынган җир күрүгә шунда йөзәрләп очып төшәләр, ачтан үлмәс өчен үзләренә җим эзлиләр. Инде моннан бер-ике көн элек лагерь өстеннән очып үткән кошларга игътибар иткән идем. Кояшлы җылы көн башланганлыктан, ашыкмыйча гына ашханәгә барам.

Пешекче мин килгәнне көтеп ашханәнең киң баскычында, үзенең яраткан мәчесен иркәләп басып тора иде.

— Әйдә, иптәш доктор Бадыйкшан, минем мәчемнең ничек итеп үрдәк эләктергәнен күзлибез,— дип кулына Пушогын тоткан килеш яныма баскычтан йөгереп тә төште.

Киттек лагерьның аргы башына. Андагы бараклардан урманга кул гына сузасы. Сакчы баскан күзәтче вышкасы да шактый ерак. Пешекче, барып җиткәч, мәчесен кулыннан төшерде дә, иелеп аны үзенчә сөеп, иркәләде:

— Бар, әнә тегендә,— диде, һәм зона киртәләренә таба күрсәтте. Пушок шуны гына көткән икән, без бер-беребезгә карашып алырга да өлгермәдек, теге якка чыгып та китте. Пешекче:

— Әйдә, барак түбәсенә менәбез,— дигәч, артыннан иярдем. Түбәгә менгәч кенә, пешекченең хәйләсен аңлап алдым. Зонаның теге ягындагы, кардан шактый арынган зур чүплек янына барып яткан мәчене күргән үрдәкләр башта дәррәү кубып һавага күтәрелделәр. Аннары аның хәрәкәтсез ятканын күреп, яңадан чүплеккә очып төшә башладылар. Мәчегә шул гына кирәк булган икән, яшен тизлеге белән атылып, бер үрдәкне эләктереп тә өлгерде.

Барак түбәсеннән тиз генә төшеп, мәче янына ашыгабыз. Мәче пешекче янына үзе үк килеп җитте. Тегесе аның авызыннан үрдәкне алып шундук изүенә яшергән пычагы белән башын кисеп «аучысы»на сузды. Мәче канәгать булды, күрәсең, биргәнне эләктереп ашханәгә таба элдерде.

— Күрдеңме инде, минем аучымны?— диде пешекче, мактанып. Пешекче Балтыйк буе республикаларының берсеннән икән. 1940 елда Сталин белән Гитлер үзара килешеп безгә басып керделәр, мөстәкыйльлегебезне бетерделәр, халкым Германия җиңелгәч тә әле русларга каршы сугышны туктатмады. Диңгез буе урманнарында партизан сугышы алып барды, ди.

— Әллә син дә советка каршы сугышып йөрдеңме?

Туня башта әйтергәме-юкмы дип торды, күрәсең, аннары яшермәде:

— Кешеләрдән калмадым инде, ике ел партизанлыкта йөрдем.

— Ничек эләктерделәр соң?

— Урманда, бункерга граната ташлап миңгерәүләттеләр, өчебез һәлак булды, мине, тагы икебезне, җәрәхәтле килеш әсир иттеләр. Хәрби трибуналга бирделәр.

— Ничә ел?

— Егерме биш кенә ел...

Үземнең язмыш та аныкыннан ким булмаганлыктан, көрсенеп кенә алдым.

* * *

Август ае килеп җитте. Лагерь халкы өмет белән яши. Тауга күмер һаман саен күбрәк күтәрелә. Һәркем үзе өчен тырыша. Бригадирлар тәҗрибәле шахтерлар булганлыктан, кемнең ничек эшләгәнлеген күреп торалар. Санчастька юк-бар сылтаулар белән килүчеләр сирәгәйде. Кулын яки бармаган сыдырып, күзенә чүп кергән кебек вактөяк сырхауларны исәпкә алмаганда, искитәрлек, мине шөбһәгә салырлык куркынычлы авырулар күренми. Барыбыз да амнистия көтәбез. Ялгышмаганбыз икән, ниһаять, беренче сменада эшләп кайтучылар:

— Иректәгеләрдән илдә зур амнистия булачагы хакында хәбәр бар,— дип әйттеләр. Зэк халкы сөенде. Күпләрнең статьялары амнистиягә эләгә. Алар арасында мин дә бар. Көткән өметемнең тормышка ашачагына ифрат дәрәҗәдә сөендем. Кулыма ireккә чыгару кәгазе көтәм.

Унынчы августта мине лагерь башлыгы чакырып алды.

— Иреккә чыгасың, эшләреңне Бондаренко дигән егеткә тапшыр. Ярты срогын киметкәннән соң да әле аның биш елы кала,— диде.

Икенче көнне иртә белән санчастька нарядчик керде.

— Бадыйкшанов, башта бухгалтериядән расчет ал, сиңа шахтада эшләгән айларың өчен күпмедер акча булырга тиеш,— дип миңа бәхетле юл теләп чыгып китте.

Лагерь белән исәп-хисапны өзеп, әйткән җиргә бардым. Ике сакчы озатуы астында лагерьга акча алып кайтырга бухгалтер Зырянкага барырга җыенган икән. Мин дә аларга иярдем. Юл начар булса да, шатлыгым зур булгач, атлавымны тоймыйм. Зырянка елгасы аша корыч чыбыклар белән тарттырылып салынган асылмалы күперне ничек үтүемне дә сизмәдем. Угольная поселогы артта калгач кына, соңгы мәртәбә артыма борылып карадым. Әнә ул зэклар лагеры. Аның шахтасында эшләп чак кына мәңгегә җир астында ятып калмадым. Шулай да дөньяга карашым тагын да киңрәк ачылды анда, бигрәк тә Зөфәр Әхмәдиев якташымның ярдәм кулын сузуын һич тә онытачагым юк. Федор Папин, Демьянов белән дә саубуллашып киткән идем. Аларның да сроклары, амнистиягә эләккәнлектән, бик аз калган. Күп булса ике ел гына. Бәлки тора-бара чыгарып та җибәрерләр әле үзләрен...

Кесәмдә кечкенә генә язу. Анда: «Локман Әхмәт улы Бадыйкшанов амнистия нигезендә азат ителә»,— дип язылган. Ул язу белән Зырянкадагы лагерьлар кәнсәләреннән амнистиягә эләгү кәгазен аласым бар. Аннары паспорт мәсьәләсе кала. Аның артыннан күпме йөрергә туры килер, анысын әле тәгаен әйтүе кыен.

Акча бик аз. Зур җиргә очарга билетка да җитәрлек түгел. Зырянкага җиткәч, эшләп алырга кирәк булыр. Колымада пароходлар йөреп тора. Шуларның берәрсенә матрос яки кочегар булып урнашырга исәплим...

Икенче көнне иртә белән кояш шактый күтәрелгәндә генә Зырянка поселогына килеп җиттек. Бергә килүчеләр үз юллары белән китеп бардылар. Мин алар белән саубуллашып ИТЛ канцеляриясенә юнәлдем. Үзем уйлар тоткынлыгында. Лагерьда калган Демьяновның «Украинамны яратам, миңа Россия кирәкми!» — дигән канатлы сүзләре исемә төшә. Кем генә үзенең туган илен, җирен яратмый икән? Шул ярату өчен статьялар чәпәп кешеләрне тинтерәтәләр. Милләтче дигән ярлык тагып җәһәннәмгә озаталар...

Алты ел гомер узып та киткән. Мин менә икенче көнемне үз иркемдә, берниндн сакчысыз Зырянка урамыннан атлап барам. Киемнәрем начар булса да, миңа игътибар итүче юк. Кичтән бирле авызыма бер нәрсә дә капмаган әле мин. Ашыйсым килми. Бөтен өметем канцеляриядә. Аннан котылу таныкламасын алу. Аннары күз күрер...

Мине яшь кенә якут кызы каршылады. Тәрәзәдән:

— Син әле амнистия белән чыгучы өченче генә кеше,— диде ул, матур гына елмаеп. Кәтәм, кыз формулярдан тикшерә, кабат карый, ачыклый. Туган елымны, аемны, кайда хезмәт итүемне, кайларда булуымны сораштыра. Беләм, болары аңар һич кирәкми. Шулай да кызыксына.

— Санитар булып эшләгәнлектән, акчаң да юктыр инде, безнең Зырянкада калып эшләп ал,— дигән була. Үз нәүбәтемдә:

— Башта паспорт алыйм әле, аннары күз күрер,— дигән булам. Якутлар төрки халык, шуңа да күп кенә сүзләре миңа аңлашыла. Ләкин диннәре христиан. Күпләрнең исем-фамилияләре дә урысныкы. Ниһаять, кулыма амнистия белән ирекkә чыгу кәгазе эләктереп, атылып урамга чыгам. Бөтен тәнем, әгъзам белән сөенәм. Канатлы һәм һәр җан иясенә илһам бирә торган ирек дигән сүз язылган кәгазьне яңадан кесәмнән капшап карадым да, күз караган якка атладым. Кая ашыкканымны үзем дә белмим...

«Ашап алырга кирәк»,— дигән фикер башыма килде. Якында гына поселокның уртасында бик матур итеп салынган ашханә бар икән.

Ничәмә-ничә еллардан соң, үзем теләгән токмачлы аш, итле карабодай, куе, хуш исле чәй сорап алып акча түләдем. Бик озак, ашыкмыйча

гына тәмләп ашадым. Авылдагыча бала чагымны искә төшереп, икмәгемнән коелган валчыкларны учым белән сыпырып авызыма каптым. Мине күзәтеп торучы булган икән. Каршыдагы өстәл янында утырган диңгезче киемендәге кеше:

— Яшь кеше, туктагыз әле, күрәм, яңа котылгансыз гына бугай. Эшкә керергә уйламыйсызмы? — диде.

— Әйе, документ кына алдым әле. Эш кирәк булачак,— дидем.

— Мин пароход капитаны Вахитов булам, Казаннан чыгышым. Кочегар бик кирәк миңа, акчасы да мул,— ди бу. Шундук күкрәк кесәсендәге блокнотын чыгарып, кадрлар бүлегенә язу да язып кулыма тоттырды. Аннары:

— Иртәгә Амбарчик портына китәбез, бүген үк эшеңне бетер,— дип китеп тә барды капитан.

Шахтада аз эшләгәнлектән, миңа акчаны уч тутырып алырга насыйп булмады. Нибары биш йөз чамасы гына. Аның белән Магаданга гына очарлык. Ә ары китәргә, илгә юллык өчен калмаячак. Шуның төбен уйлап, кичекмәстән капитан кулыма тоттырган язу белән елга портына атладым. Уйламаган җирдән каршыма дядя Миша килеп чыкты. Мине күрүгә:

— Морячок, котылуың белән тәбриклим! Уйлаган идем аны, аз сроклыларны лагерьда тотмаслар, дип, ялгышмаганмын. Өлкән диңгезче ике кулымны да тотып алып, озак кына җибәрми торды. Үзенең күптән срогы бетеп, Зырянкада эшкә калуын, бераз акча җунәтүен, кайтырга җыенуын әйтеп алды. Кая баруымны да сорамастан:

— Әйдә минем белән,— дип, үзе белән алып та китте. Күптәнге таныш булганлыктан, бүген аңарда кунармын инде дигән уйлар белән аңа иярдем. Юл буе гел ул сөйләп барды. Лагерь начальнигы Проваторовны, безнең этап Угольнаяга китеп озак та тормастан, Магаданнан ниндидер зур хәрби кешеләр килеп, кабинетында ук кулларына богау салып үзләре белән алып китүләрен әйтте. Кучманың аның турында урман командировкасында миңа куркып-куркып кына сөйләвен исемә төшереп алдым. Бик үк ышанып бетмәгән идем, менә хәзер барысы да аңлашылды.

Озак бармадык, поселокның уң як капкасына «Зырян аэропорты»,— дип язылган йорт янына килеп туктадык. Дядя Миша:

— Хәзер әйләнеп чыгам, көтеп тор,— дип дежурда торучы солдатка пропускасын күрсәтеп кереп тә китте.

Кайдадыр түрдә, еракта, самолет тавышы ишетелде. Һавага карыйм, күренми. Мавыгып торганда дядя Миша ишектән килеп тә чыкты. Йөзе тагын да ачылып, күңеле күтәрелеп киткән аның.

— Әйдә, сиңа да пропуска яздырып алып чыктым, миңа керәбез.— Ишек алдының уң ягында күк төскә буялган озын гына бер йортка табан атладык.

— Бу очучыларның кунакханәсе була, мин анда үзенә күрә хуҗа. Бүлмәмне күрерсең, синең барыбер кунар урының юк. Ошаса, миндә калырсың...

Баскычтан күтәрелүгә беренче ишек аның бүлмәсе. Яп-якты, киң, тәрәзәсе дә биек. Ак чаршау эленгән, стенасында зиннәтле рамда зур көзгесе дә бар. Аның каршысында артлы йомшак урындык. Әйтерсең чәч кыручының бүлмәсе. Җитмәсә, көзге каршысында тарак, одеколон, берничә кырыну пәкесе кебек нәрсәләр дә куелган. Боларны күргәч исем китеп:

— Бөтен кирәк-яракларың бар икән, минем чәчләрне ирektәге әдәмнекедәй итеп, эшкәртеп алчы, зэк дип уйламасыннар. Мин бит икенче көн ирektәге кеше...

Дядя Миша башта матур итеп елмайды, аннары:

— Анысы гына булыр аның, әйтәсе мөһим сүзем бар әле сиңа! — диде.

— Тыңлыйм, синнән бары тик яхшы сүз ишетүемә шикләнмим дә.

— Бер атнадан материкка очам, урыныма кеше кирәк. Аэропорт начальнигы белән сөйләштем, сине тәкъдим иттем. Аның сәяси статьялы кешеләргә игътибары зур...

Артыгын аңлатып та тормастан, дядя Миша көзге каршысына утыртып, чәчләремне чын парикмахерлардай рәтләргә дә кереште. Инде ничәмә ел пөхтә иттереп башымны болай рәткә кертkәннәре юк иде. Карт дингезче мине чибәр кеше итте дә куйды! Килешен китереп хушбуй да сиптереп алган булды. Тиз арада кайдандыр вак шакмаклы күлмәк, искерәк булса да, пинжәк чыгарып, өс киемнәремне алыштырырга кушты. Өлкән дингезченең сүзен тыңламый да булмас, дип, үземнекеләрен салып ташладым да, киенеп алып, көзге каршысына килеп бастым.

— Менә ичмасам, егет булдың, әйдә, хәзер аэропорт начальнигына барабыз...

Каршыдагы ак кирпечтән салынган дәү генә ике катлы йортка атладык. Алдында чәчәкләр үсеп утырган аллея. Уртадан вак чуер таш түшәлгән юл салынган. Менә ике якка да ачылган зур ишек. Бусага кергәч тә икенче катка күтәрелдек. Анда берничә күк төстә буялган ишекләр. Иң түрдәгесенә җитеп туктадык. Дядя Миша башта үзе генә кереп чыкты. Аннары мине чакырды. Кабул итү бүлмәсе алдындагы секретарь утырган өстәл янында икебез дә туктадык. Зур зәңгәр күзләре белән мине баштанаяк сөзеп чыкты да секретарь кыз начальнигына керде. Бик тиз чыгып икебезгә дә:

— Барыгыз, начальник сезне көтә,— диде. Дядя Миша артыннан кыюланып мин дә атладым.

Шактый зур, киң кабинет, ике тәрәзәсе түшәмгә кадәрле итеп ак ефәк шторлар эленгән. Тәрәзә төпләренә гөл чүлмәкләре куелган, алар һәммәсе дә чәчәктә. Яшел постау ябылган киң өстәл артында кырык яшьләрдәге, шәп кус кара чәчле, озынча йөзле, очучылар костюмына киенгән кеше утыра иде.

— Утырышыгыз,— дип ул шундук урын тәкъдим итте.

Алдан сөйләшеп куелган булганлыктан, начальник артык сораулар биреп тормады. Котылу кәгаземә күз салып алу белән:

— Гаризаңны яз, паспорт алгач, миңа күрсәтерсең, карт морякның кайтасы бар, тоткарламыйм инде аны. Ничек эшләргә кирәклеген сиңа өйрәтер,— диде.

Сүз кыска булды, кабинеттан чыгып, секретарь кыздан кәгазь алдым да гаризамны язып, дядя Миша белән чыгып та киттек.

— Күрдеңме Константиновның нинди әйбәт кеше икәнлеген,— дип дядя Миша әйтеп куйгач, мин сөенеп, бер сүз дә дәшмәстән, карт дингезче артыннан иярдем.

Бүгеннән башлап, мин очучылар кунакханәсенең хуҗасы...

Дядя Миша мине бер атна буена яңа эшемнең барлык серләренә өйрәтте, үз күзе алдында мине сынап карады. Кунакханә җитәкчесе булу белән бергә, мин җыештыручы да, очучылар кунып киткәннән соң урынҗир әйберләрен җыеп, аларны кайнатып киптерүче дә. Әле алай гына түгел, чәч, сакал-мыек кыручы да булып киттем. Бу эшләрем өчен акча майлы калҗа булып кереп кенә тора. Эш хакымны әйтәсе дә юк, анысы да әйбәт. Аена ике тапкыр алам да барысын бергә кушып саклык кассасына сала барам. Карт дингезче үзенең парикмахер өчен кирәк булган эш коралларын юнь бәягә генә миңа сатып калдырды, алар миңа бик тә ярап куйды. Атна буе сакал-мыек кыру, чәч эшкәртүләрне шундый оста башкарам, очучылар «әллә күптән эшлисеңме», дип әйтеп тә куялар. Сер бирмим, малай чактан ук өйрәнеп үстем, дигән булам...

Дядя Мишаны озатканнан соң атна-ун көн үтмәде, аэропорт начальнигы Константинов секретаре аша үз янына чакырып алдырды да:

— Сиңа җаваплы зур бурыч тапшырам, бүген материктан поселокка гаиләсе белән яңа милиция җитәкчесе очып төшә. Каршылап квартирасына илтергә булыш, конюхтан иң яхшы атны җиктереп ал да әзерләнеп тор,— диде.

— Була ул,— дип тизрәк конюшняга ашыктым. Самолет аэропортка килеп төшәргә күп калмаган иде. Җигелгән атны куалап шунда элдердем.

Көн болытлы, вак яңгыр сибәләп тора. Өстемдә плащ кебек нәрсә булмаганлыктан, кунакханәгә тукталып, бер бүлмәдә яткан хәтсез генә киң брезентны арбага чыгарып салдым да, бер чите белән каплап, атымны аэропортка кудым. Вакытында барып җиттем, кешеләр әле чыга гына башладылар. Бер дә күрмәгән, белмәгән начальник милициясен ничек танырмын икән? Хәер, ул формадан булырга тиеш. Менә бервакыт иң соңгы булып өч үсмер кыз бала, хатыны белән милиция майорын күреп алдым.

— Гафу итегез, Сез безнең Зырянкага килүче яңа милиция начальнигы түгелме?— дидем каршысына килеп.

— Әйе, мин булам!

— Сезне квартирагызга илтеп куярга мине билгеләделәр. Рәхим итегез, транспорт көтә,— дидем. Майорның йөзе ачылып китте. Гаиләсе белән артымнан иярде. Ул елларда җиңел машиналар поселокта юк иде әле (Ат шәп, арба да ярыйсы гына). Хатынын, балаларын арбага менгереп утыртып, өсләренә брезент яптым. Аннары майор белән багаж бүлегенә барып ике-өч мәртәбә чемоданнарын ташыдык. Эшләр беткәч, үзебез дә арбага менеп утырып, поселокка таба юл алдык. Бирелгән адрес минем кесәмдә иде. Барасы урамны яхшы белгәнгә күрә, турырак юлдан шунда таба атны юырттырдым.

Кирәкле квартираны табып майор гаиләсен күчерештем, әйберләрен ташыдым. Эшләр беткәч китә генә башлаган идем:

— Хезмәтегез өчен мәгез сезгә,— дип майор миңа егермебишлекне сузды.

— Гафу итегез, кирәкми, әле сез килдегез генә, бу минем вазыйфам, эш хакым миңа килеп тора,— дип акчасын алмадым.

— Йомышыгыз төшсә, туп-туры үземә килегез,— диде майор. Ул мине елмаеп озатып калды. Атымны юыртып китеп бардым.

Җилкәмнән зур эш төшкәндәй булды. Кайтып аэропорт начальнигына майорны каршылавымны, гаиләсен бирелгән адреска илтеп куюымны әйттем. Ул канәгать булды.

Якутскидан килгән самолет очучылары кунакханәдә урнашып ял иттеләр. Икенче көнне бортмеханик мине чакырып алды да:

— Энекәш, күрәм, син яңа кеше икәнсең. Дядя Миша кайтып киттемени?— дип сорады.

— Әйе, аның урынына калдым, бераз гына акча эшләп алам да, мин дә китәм,— дидем.

Ягымлы сөйләшүе ошады аның. Тагын нәрсә әйтер икән дип уйларга өлгермәдем:

— Яңа киемнәр алдык, киелгән булса да, менә болары да әйбәт әле. Сиңа бүләк итеп бирәм,— дип миңа китель, чалбар, фуражка бирде ул. Акча чыгардым, алмады.

— Бушка аласым килми,— дигән идем, тавышын күтәрә төшеп:

— Бирәләр икән ал, акчаң кирәк булыр әле, тоткынлыкта җәфа чиккәнгә ошыйсың. Дядя Миша да гаепсезгә ун ел утырган кеше иде.

Маңгаема язылганмыни, кем булуымны бер күрүдә чамалады очучы. Яшермәдем, кыскача сөйләп бирдем. Теләктәшлек белдереп, игътибар белән генә тыңлады.

Көн явымлы булганлыктан, очучылар бүген дә кунакханәдә кундылар. Аларга чәй кайнаттым, поселок магазиныннан азык-төлек алып кайтып тапшырдым. Юл уңаеннан милициягә барып секретарь кыздан инде

күптән тапшырылган документыма нигезләп тутырылган паспорт алдым. Аны аэропорт начальнигына күрсәттем. Ул:

— Паспортың шәптән түгел, моның белән ерак китә алмассың,— диде. Аптырап киттем. Аңламаганымны күреп:

— Тамгалы паспорт биргәннәр,— дип күрсәнде.

Кунакханәгә кайткач та әле тынычланып бетә алмадым. «Ерак китә алмассың»,— дигән Константиновның сүзләре яңа гына әйтелгәндәй колагым төбендә яңгырап торды...

Очучылар киткәнгә инде өченче көн була. Яңадан килүчеләр әлегә күренми. Зырянка тирәсендә һава әйбәт. Күрәсең, башка якларда бездән үтеп киткән яңгырлар самолетларга күтәрелергә мөмкинлек бирми булыр...

Көндәлек эшләремне карап, кунакханәне баштанаяк чистартып, ялт иттереп куйдым. Очучы бүләк итеп биргән киемнәремне карап чыгып, үземә килешеп торырлык итеп бераз кыскарттым. Кием-салым Зырянка магазинында бар барын, ләкин кыйммәт. Кайтырга дип җыйган акчамны киметәсем килми. Әйе, эшләрем әйбәт кенә бара иде... Шулай бер төнне йоклап ятканда бүлмәм кинәт яктырып китүгә күзләремне ачып җибәрдем. Кем яндырды икән дип башымны калкытмакчы булган идем, иягемә ниндидер очлы нәрсә килеп төртелде. Шундук караватым янында үтә ябык, яңаклары суырылган җирән чәчле берәүне күреп алдым.

— Мужик, шәп баеп киткән булырга ошыйсың, тор, акчаларыңның барысын да чыгарып сал, югыйсә менә бу нәмәрсәкәй белән...— Каршымда кем басып торганын шундук аңлап алдым. Бүлмәмдә тагын берәү бар. Анысы актарына, нәрсәдер эзли. Ишегем дә эчтән бикләнгән югыйсә, каян кергәннәр дип уйларга өлгермәдем, тәрәзәмә күзем төште — зур бер өлгесен алып кергәннәр.

Торып утырырга мөмкинлек бирделәр. Шунда сүз әйтергә өлгерә алмадым, зур көзге астындагы шкафымны актарганы:

— Доктор Бадыйкшанда кунакта икәнбез, перонны яшер, дускай, сораганыбызны үзе бирер ул,— диде.

Әһә, таныдым мин аны. Лагерьда үзен үлемнән коткарып калган карак икән.

— Акчаларым янымда юк, өч көннән соң гына эш хакымны алачакмын. Булганы әнә шкафтагы китель кесәсендә.

— Үзең алып бир,— диде янымдагысы. Тиз генә барып, кителем кесәсеннән барлык булган унбиш сум акчамны чыгарып өстәлгә куйдым. Бер-берсенә карашып алдылар да берсе:

— Ярый, тиеннәреңне алмыйбыз, одеколоның булса, чыгарып куй, капкалап алырга нәрсәң бар?

— Кухняга барып килим,— дидем.

— Чыгып йөрмә.

Бер дә башланмаган өч флакон одеколонымны шкафтан өстәлгә китереп куйдым. Тәрәзә төбеннән стаканны үзләре алдылар. Бик тиз арада бер флаконны эчеп бетерделәр дә икесен кесәләренә салып:

— Без киттек, монда булуыбыз турында берәү дә белмәсен, акча алган көнеңдә тәрәзәгә килеп чиертербез,— диде мине белгән карак.

Ничек кергән булсалар, шулай тиз генә тәрәзәдән чыгып та сыздылар.

Әле таң атмаган иде. Минем башка йокы кермәде. Уйландым, ничек Зырянка поселогыннан исән-сау килеш чыгып китү юлы турында башымны эшләтергә тырыштым...

«Бу паспортың белән ерак китә алмассың»,— дип әйткән аэропорт начальнигының сүзләре кылт итеп исемә төште. Яңадан борчылу...

Димәк, миңа сәяси статья белән тоткын булганлыгым өчен зур шәһәрләрдә яшәргә ярамый торган тамгалы паспорт биргәннәр. Кичекмәстән милиция майорына барып хәлемне аңлатып бирергә кирәк булыр. Аның: «Эшең төшсә, үземә кил»,— дигәнен хәтерләдем.

Эш сәгате башлануын ничек көтеп алырга да белмәдем. Яктырылса да бик озакка сузылгандай булды бу иртә. Аэропорт капкасындагы кечкенә йортта дежурда торган сержантка кунакханәнең ачкычын калдырып, майорның эшенә киттем.

Мин килгәндә, майор инде күптән үзенең бүлмәсендә утыра иде. Бик җылы каршылады ул мине. Килүемнең сәбәбен ачып салып аңлатып бирдем. Бер сүз дә әйтмәстән:

— Паспортыңны калдыр, кич эш сәгате беткәндә янәсын килеп алырсың,— дип мине сөендереп кайтарып җибәрде.

Дөнья явызлар белән генә тулмаган, яхшы фигыльле, мәрхәмәтле кешеләр дә күп икән әле.

Кайтуга, аэропорт начальнигы Константинов янына кердем. Төнге «кунаклар» турында сөйләп бирдем. Монда башка кала алмавымны, кичекмәстән мөмкин булса, бүген яки иртәгә самолетка утыртып йә Магаданга, һич югында Якутскига җибәрүен үтендем.

— Урыныңа кеше тап, калганын үзем эшләрмен,— диде начальник. Кемне тәкъдим итәргә? Зырянка поселогында бер генә таныш-белешем дә юк. Эшли башлавыма өч ай гомер узган. Акчам да бар. Ярый әле атна саен саклык кассасына салып бардым. Алдан күрә-сизенә алуым өчен шатланып бетә алмадым. Барлык җыйган акчаларымнан колак каккан булыр идем.

Әмма, алмашка каян кеше табарга, кемгә мөрәҗәгать итәргә? Елгачылар кадрлар бүлегенә барып, кунакханәгә кеше кирәклеген әйткән генә идем:

— Артыңнан ук җибәрәм, эш сораучылар җитәрлек, бер дигәнен аэропортка җибәрермен,— диде кадрлар бүлеге мөдире.

Кайтып ашап-эчеп алырга өлгермәдем, аэропорт начальнигы мине чакыртып алды. Кабинетында урта яшьләрдә булып, мөлаем йөзле, матур гына киенгән хатын-кыз утырганын күреп алдым.

— Кеше табылды. Бу ханым белән таныш, әзерләнә башла, бухгалтер җибәрермен, бергәләп эшеңне тапшырырсың.

Кунакханәгә кайтып җыена башларга өлгермәдем, аэропорт бухгалтериясеннән яшь кенә бер кыз һәм теге мин күргән ханым килеп тә җиттеләр. Эшемне, барлык булган кунакханә мөлкәтен ничек кабул иткән булсам, шулай тапшырдым. Барысы тәртиптә иде. Актка кул куйганнан соң, бухгалтер кыз:

— Расчет алуга аэропорт начальнигына кер, аның сиңа нәрсәдер әйтәсе сүзе бар,— диде.

— Яхшы эшләвең өчен билетны сиңа бушлай бирергә булдык. Кассирга әйтелгән, төшеп ал, кичке сигездә самолет була, шуның белән Магаданга китәрсең,— дип аэропорт начальнигы мине сөендереп куйды. Аңар зур рәхмәтемне әйтеп, паспорт алырга милиция майорына йөгердем.

Самолетка утырганда, мине бернинди тоткарлыксыз баскычтан кертеп тә җибәрделәр.

Унсигез кешелек самолетка бик тиз урнашып беттек. Күңелемнән яхшы кешеләргә мең рәхмәтләр укып, алдагы көннәремә ышанып, туган якларыма, ирек дөньясында яшәргә өметемне баглап, һавага күтәрелдем. Сау бул, минем тоткынлыкта җәфа чиктергән Колыманың Зырянка яклары! Сау бул, бәхетсез яшьлегем башкаласы! Сау бул, каргышлы күз яшьләре белән сугарылган төбәк!

## Уникенче бүлек

Мин җир улы, канатсыз булсам да, һавада очам. Бу бәхеткә ирешүемә куанып бетә алмыйм. Кайчандыр үсмер чагымда микән, төш күргәнем исемә төште. Имеш, авылыбыз урамы өстеннән түбәнтен генә кулларымны җилпеп кош сыман акрын, бик акрын очып барам. Малайлар миңа караганнар да:

— Әнә Локман ничек оча белә, аның анасы фәрештәдер, шулай булмаган булса, ул ничек оча алган булыр иде,— диләр. Моңа кадәрле беркайчан да самолетка утырганым да, очканым да юк иде. Иллюминатордан аска күз салам, әнә ул тоткыннар каһәрләгән Колыма! Башларында мәңге эреп бетми торган карлы Аргаташ таулары. Юк, күктән яумагандыр. Алар кеше күз яшедер. Шуңа эремидер аның карлары! Тау итәгендәге урманнар, вак-вак елгалар...

Менә бервакыт кайдадыр бик еракта аста, утлар җемелдәве күренә башлады. Димәк, кешеләр яши торган җирләргә якынлашабыз. Түбәнгә таба очканыбызны сизәм. Стюардесса очучылар яныннан чыгып:

— Безнең самолет Семчан аэропортына төшә,— диде. Турыдан-туры Магаданга очмыйбыз икән әле. Тукталыш көтә безне. Озакламады, көпчәкләрнең җиргә тиеп китә-китә, ниһаять, тигез юлдан чапканын тойдым.

Аэропорт поселокның читендә генә. Безгә монда куначагыбызны әйттеләр. Башкалардан калышмаска тырышып аэропорт йортларына таба атладым. Ике катлы таш йорт. Тәрәзәләре зур һәм биек. Кергәч тә кем кайда, буш урындыкларга урнашырга ашыктык. Киемнәрем яңа булмаса да, очучыныкы, бүләк итеп бирелгән. Бераз утырып торганнан соң, янәшәмдәгеләр белән уртак тел таба алмагач, торып китәргә мәҗбүр булдым. Кая барырга? Ничек төн үткәрергә! Уйланып һавага чыктым. Якында гына кочегарка бар. Шунда күзем төште. Килеп керүемә мине шактый өлкән яшьтәге берәү каршылады. Бик тиз танышып киттек. Күптән түгел генә иреккә чыккан, 58 нче статья белән утыртканнар. Кочегар булып урнашкан, юлына акча җыя. Кавказ кешесе. Башта мин аны грузин дип белдем, түгел икән. Әзербайҗанлы. 36 нчы елда Колымага китерелгән. Башта алтын чыгарган, аннары Магаданның үзендә ташчы һөнәрен үзләштереп йортлар салган. Срогын тутыруга, яңадан ун ел өстәгәннәр. Беренче мәртәбә Бакуда үзе эшләгән оешмада, ниндидер зур җыелыштан соң, залны җыештырган вакытында трибуна янындагы Сталинның мәрмәр бюстын төшереп ваткан икән. Кеше күрмәгән арада аны чиләккә тутырып, ишек алдындагы чүп бункирына чыгарып ташлаган. Өч көн эзләгәннән соң, гаепләне тапканнар. Куркуыннан туган шәһәре Чәкегә качкан булуына карамастан, артыннан килеп җитеп, Баку төрмәсенә алып китеп япканнар...

— Син бәхетле, яшьрәк чагында котылгансың, болай булгач, туган ягыңа кайтып тормыш корып та өлгерәсең әле,— диде ул миңа, күңелемне күтәреп.

Кемнәр белән генә очрашмыйм, кешеләр язмышы. Һәммәсе өмет белән яши.

Кочегар белән саубуллашып, баягы йортка юнәлдем. Йортның күп кенә бүлмәләрендә утлар сүндерелгән иде. Узып барганда каршыма ару гына киенгән ике хатын-кыз очрады.

— Якын-тирәдә кунакханә бармы?— дип сорадым аңардан.

Берсе:

— Шуннан киләсез түгелме?— диде, гаҗәпләнеп.

— Юк, әнә тегендәге кочегаркадан.

— Очучы була торып юри сорыйсыздыр әле,— дип куйды берсе.

— Һич тә алай түгел, моннан ике сәгать элек кенә Зырянкадан очып төштем, төн үткәрергә урын эзлим!

— Барыгыз, үтеп киткән теге йорт очучылар кунакханәсе була, анда сезгә, әлбәттә, урын табылыр...

Рәхмәт әйтеп, кирегә атладым. Чыннан да, кунакханә икән. Ягымлы гына кабул иттеләр анда мине. Түләү хакы да арзан.

Паспортымны гына озаклап караганнан соң, администратор:

— Кайда торуыгыз күрсәтелмәгән, үзегез очучы, нишләп болай ул?— дип сорады.

— Югалткан идем, Магаданга кайтып барам, шунда яшим,— дип ялганнарга мәҗбүр булдым. Башка сорау биреп тормадылар, икенче каттан бүлмә бирделәр.

Шундый әйбәт җыештырылган бүлмә, исең китәрлек. Телефонына чаклы бар. Ләкин минем беркемгә дә шалтыратасым да, хәбәрләшәсем дә юк. Самолетыбыз иртәнге сигездә генә очасы булганлыктан, миңа ашыгасы түгел. Чишенеп йомшак урын-җиргә яттым. Ирек дөньясы шул, синең белән кешечә сөйләшәләр, кулларыннан килгәнчә ярдәм итәргә торалар. Яңа паспорт биргән милиция начальнигына, Зырянка аэропорты хуҗасына күңелемнән мең рәхмәтләр кабатлап ята торгач, кайчан йокыга киткәнемне дә сизмәдем.

Кешегә күңел тынычлыгында, үз иркендә яшәүдән дә рәхәтрәк башка нәрсә бар микән бу дөньяда! Мин бүтәнчә күз алдыма китерә алмыйм. Озын сәфәргә чыктым, исән-сау туганнарым янына, җәбер-золымнар нәтиҗәсендә тукталган әдәби иҗатымны дәвам итәргә кайтып кына житә алсам иде. Моннан да олы бәхет юк миңа!

Урындагы радио Магадан вакытын әйтеп, иртәнге тапшыруларын башлап җибәрүгә, хәрбиләрчә сикереп тордым. Бәрәкалла, ванна бүлмәсенә чаклы бар. Кичтән искәрмәвемә ачуым килде. Соң түгел, хәзер дә юынып алырга була.

Буфеты да икенче катта гына. Очучылар бүлмәләреннән чыгып шунда атлаганнарын чамалап алардан калышмадым. Нинди генә татлы ризыклар юк биредә. Карабодай ярмасы белән күпереп торган кайнар вак колбасалар, какао, лимонлы чәй дисеңме, һәммәсе дә күз алдында. Инде күп еллар төшемә дә кермәгән карабодай боткасы белән телеңне йотарлык кайнар вак колбасалар алып рәхәтләнеп сыйландым ул буфетта. Лимонлы чәй дә эчеп алгач, үземне оҗмахның түрендә яшәгән фәрештәдән ким сизмәдем. Кемне генә очратмыйм — хөрмәт, игътибар. Үткән икән гомерем михнәтле газап мәгарәсендә...

Яңадан очабыз. Кояшлы ноябрь иртәсе. Күңелем тизрәк Магаданга житеп, җиргә төшүне тели. Иллюминаторга күз салам, кая карама, башларын күккә сузган таулар тезмәсе. Самолетыбыз шулар өстеннән оча. Шундый тизлек белән һаваны кисүенә карамастан, миңа ул бик акрын оча сыман. Инде уйларым, ерак Татарстанымда, ямьле Зәй буйларында! Теләкләремне генә Аллаһы Тәгалә кабул итеп, бәхетле яшәргә насыйп итсә генә ярар иде. Түбәнгә төшә башладык. Әнә ул Магадан шәһәре! Урамнарын, биек йортларын, мәйданнарын аермачык күрәм. Охот диңгезе буендагы иң зур порт буена салынган. Минутлар үтмәс, самолетыбыз җиргә төшәчәк. Аннары — Владивостокка...

Магадан аэропортына төшүгә, автобуска утырып шәһәргә юл тоттым. Урамнарын бер әйләним, йортларын күрим, дигән уйлар белән үзәккә житкәч, автобустан төшеп калдым. Күңелгә Сеймчан аэропортының кочегаркасында эшләгән азәрбайҗанлы кочегар исемә төште. Менә кемнәр бармаклары сөякләрен әрнетеп салган бу йортларны дип уйладым. Ике дистә ел эшләсә дә, кайтарына акчасы да юк үзенең.

Шәһәр белән танышып, бераз йөргәннән соң, яңадан автобуска утырып, аэропортка киттем.

Билетлар сатыла торган залга керсәм, ни күрим — халык шыгырым тулы. Китә алмыйча, атналар буе чират торалар икән. Башта ук чиратка басмавыма үкенеп куйдым. Болай озаклап көтәсемне башыма да китермәгән идем.

Яңа кешеләр, һәммәсе дә китү өчен борчылып, көтә-көтә талчыгып беткәннәр. Чиратлап ял итеп алгалыйлар. Тәртипне нык саклыйлар.

Биш тәүлек билетка чират көттем. Утырып, басып йоклар-йокламас торганлыктан, тәмам алҗыдым. Вокзал үзе бер дөнья! Монда кемнәр генә юк. Профессор, геолог, инженер, зур чинлы хәрбиләр дисеңме — барысын да күрергә туры килде. Кайберләре белән ныклап таныштым.

Адреслар алыштык. Ләкин берсенә дә алты елдан артык лагерьларда тормыш университетын үткәнемне әйтмәдем. Күбрәк үзләрен тыңладым. Мине алар аэропорт хезмәткәре итеп кабул иттеләр. Отпускага яки командировкага китүче мосафир дип белделәр.

Ниһаять, миңа да билет алырга чиратым җитте. Документ белән акчамны кассага сузуым булды, көтмәстән кемдер арт яклап җилкә якамнан сөйрәп тартты да, фил аягыдай тупас кулына тоткан акчалары белән паспортын минекеннән алданырак эчкә шудырды:

— Владивостокка бер билет,— диде көр үтә яңгыравыклы тавышы белән. Башымны борып карасам, әзмәвердәй таза, калын гәүдәле озын кеше килеп баскан. Кешеләрнең кайберләре:

— Чиратсыз билет алырга ни хакың бар?— дип әйтсәләр дә, ул аларга игътибар итмәде. Әйтерсең, аның акчасы белән паспортын гына көтеп торган, кассир хатын билет та биреп өлгерде. Башка вакытларда тәртип күзәтеп торучы милициянең бүген берсе дә юк. Соңгы билет булган икән. Миңа насыйп булмады. Яңадан бер тәүлек көтәргә калдым. Теге әзмәвер бәндә мыскыллы елмаеп китеп барды.

Күп тә үтмәде, диктор вокзалга күңелсез хәбәр игълан итте. Теге мин очып китәсе самолет кайдадыр Магаданнан әлләни ерак та түгел һавада шартлап, экипажы-ние белән егылып төшкән, барысы да һәлак булганнар. Бу шом мине сискәндереп җибәрде. Кайберәүләр чиратларын ташлап, көтү залыннан чыга башладылар...

Мин дә күңелсез уйларга бирелдем. Нигә миңа ашыгырга соң әле? Әллә кибеп-саргаеп сөйгән ярым көтәме? Юк. Әнием, әтием сугышка кадәрле вафат, ике абыем да Ватан сугышында һәлак булдылар. Мәкерле пәрәвез җәтмәсеннән исән-сау котылып чыктым. Кайчандыр диңгезче идем, нигә пароходта кайтмаска! Акылым йөрәгемә бу уемны сеңдерергә теләде.

Яңа танышым — яшь геологка:

— Әллә диңгез портына таба тәвәккәлибезме?— дим.

— Мин дә ашыкмыйм, киттек, әйдә.— Башта көлешеп алдык. Аннары залдан автобус тукталышына чыгып киттек. Танышым тыгыз тәнле, кара тутлы, кара күзле ачык чырайлы, сүзчән, игътибарлы кеше. Миннән күбрәк сөйләтергә тели, ә минем киресенчә: аннан зур җирдәге элекке тормыш хакында тыңлыйсым килә. Яшь ул, институт тәмамлап, Колымага килгән. Тамбов ягыннан, ялга кайтып барышы. Бу якларда эшләгәннәргә, ялны берничә ай итеп, акчаны да мул бирәләр икән.

Портта дәү-дәү океан пароходлары, танкерлар, ярында рельста йөрүче краннар бик күп. Һәммәсенә дә күз салып, китү ягын кайгыртып белешмәләр бүлегенә кердек. Бәхетебез барлыгына шундук куандык. Бер сәгатьтән Находка портына пассажир пароходы кузгалачак. Кассага барып тиз генә билет алырга өлгердек.

Ике кешелек каюта самолетка караганда ун тапкырга җүн. Бу миңа ярап куйды. Сәфәрем озын, акчамны чамалап тотканда гына туган якларыма кайтып җитәчәкмен. Пароходта буфет, уку, китапханә, кино залына чаклы бар. Танышымның шахматта уйнарга яратуы мине куандырды. Күптәннән уйнамаганга, башта күп оттырдым. Аннары геологның ничек итеп йөрүләрен белеп алганнан соң, өстенлекне мин ала башладым.

Икенче тәүлеккә чыкканда Сахалин утравына якынлаша башладык. Өмет — ярты гомер ул. Куанмаслык та түгел, бәлагә юлыккан адәм баласына иректән дә кадерле нәрсәнең булуын күз алдыма да китерә алмыйм...

Көн чалт аяз. Ноябрь кояшы үзенең салкын нурлары белән диңгезне иркәли. Тире-якта иксез-чиксез су дәрьясы. Пароходыбыз өстендә акчарлаклар бөтерелә. Димәк җир якын. Йөземә җир, туфрак исе бәрелгәндәй була. Ихтимал, кайтып җитүебез шушыдыр инде.

...Геолог егет белән Находка портыннан кичке поездга мәшәкатьсез генә утырып, Владивостокка таба юлыбызны дәвам итәбез. Өметебез тизрәк барып житү. Алты елдан артып киткән Алтын Мөгез буендагы ул шәһәрдән аерылганыма. Максатым зур, теләкләремнең чиге юк сыман. Беренче нәүбәттә, нахак уйдырмалар нигезендә гаепләп, хәрби хезмәтем беткәндә генә крейсердан кулга алынып, үземне тинтерәткән КГБга бару. Аның миңа «яхшы лагерь» вәгъдә иткән генералыннан тентү вакытында алынган әдәби кульязмаларымны кайтарып бирүләрен таләп итү. Исән микән ул алтын укалы генерал? Анда минем машинкада бастырып куелган, диңгез темасына багышланып язылган унҗиде хикәям, ике зур күләмле повестым, җиде калын көндәлек дәфтәрләрем, туганнарым һәм дус-ишләремнең йөзәрләгән фоторәсемнәре калды. Шуларны кайтарып ала алсам, мин нинди бәхетле булыр идем. Диңгездә үткән яшьлек елларымның вакытым булган саен теркәп барган иң кадерле язмалар тупланган аларда!

Икенче көнне төштән соң гына Владивостокка килеп җиттек. Вокзалда геолог белән саубуллашып аерылыштык. Ул ашыга, ә минем барасы җирем бик тә мөһим! Эш сәгате тәмамланганчы кирәкле оешмага барырга кирәк. Кая барасын, нинди урамда икәнлеген яхшы беләм. Йөрәгем күкрәгемнән чыгам-чыгам дип ашкынып тибә. Уйларым алга куйган максатым миңа дәртле ашкыну көче биреп тора.

Кирәкле җиремне бик тиз барып таптым. Мәрмәр баскычлардан (бу юлы инде мин сак астында түгел, үз иркем белән) күтәреләм. Мине хәрби сакчы туктатты. Пропуска алырга кирәк икән. Документларымны чыгарып, ул күрсәткән кечкенә тәрәзчеккә барып, максатымны әйттем. Хәтсез вакыт пропуск бирми тордылар. Телефоннан шалтыратып алдылар. Аннары гына кулыма паспортым белән кирәкле рөхсәт язуын кечкенә тәрәзәчектән суздылар.

Таныш мәрмәр баскычлардан югары катка күтәрелеп, күрсәтелгән бүлмәгә җиткәч, ишек шакып кердем. Мине уртачадан калку, иңбашларында полковник погоннары ялтыраган кеше каршылады. Өстәле янына якын килеп гозеремне әйттем. Ул мине дикъкать белән тыңлады, аннары:

— Бездә андый кәгазьләр өч ел саклана. Срогы үткәч, әһәмияте булмаганлыктан юк ителә,— диде.

Коелып төштем, дөнья караңгыланып киткәндәй булды. Бер сүз дә әйтә алмастан, кинәт нәфрәт белән тулган йөрәгемнең әрнүен басарга тырышып:

— Язганнарың сакланыр дигән иде тикшерүче капитан Шумихин,— дигәнемне сизми дә калдым. Ә алынган җаваптан күңелемне шөбһә биләп алды:

— Исән-сау кайтып җитүегезгә сөенегез, без коткара да, гаепли дә беләбез!

Төшенке күңел белән бу йорттан чыгып киттем.

Бердәгә бердәнбер танышларым — Җамал апа Заһидуллиналарга кереп чыгарга уйладым. Бәлки, онытмаганнардыр әле?

Ишекне Җамал апа үзе ачты:

— Әстәгъфирулла! Локман түгелме соң син?

— Әйе, мин...

Күрештек. Ачык йөз белән өйгә керергә чакырды.

— Синең кулга алынып, зур срок биргәннәрен, үзең белән безгә килгәләгән Хөсәенов килеп әйтте,— диде ул, бераз тынычлана төшкәч.

Чәй янында озак кына сөйләшеп утырдык һәм берзаман Җамал апа тиз генә торып басты да, урындыгын алып, шифоньер янына китереп куйды. Урындыкка менеп, кабалана-кабалана кулларын сузып эзләнә, актарына башлады. Күп тә үтмәде, кулына бер конверт тотып идәнгә сикереп тә төште.

— Хәтерлисеңме, Локман, сугыш елында син безгә җибәргән хәрби врач Шиловыгызны? Менә бу хатны ул китерде безгә. Сине тиздән кайтачак, тапшырырсыз үзенә, диде.

Шактый калын конверт иде ул. Кулыма алуга, кем кулы белән язылганын шундук таныдым. Йөрәгем әллә нишләп китте. Ниндидер кайнар тойгы бөтен тәнемә йөгерде.

— Күптәнге булса да хат минем өчен кадерле, зур рәхмәт, шул гомер буе, саклавыгызга,— дип, кәнәфигә барып утырдым да ачып укырга керештем. Үткән яшьлек елларым исемә төшеп, беренче мәхәббәтем белән кабат очраштым хатны укыганда.

Аның сихри образы бүген дә бик еш күз алдыма килә. Хатындагы сүзләрне дога укыгандай кабатлыйм. «Диңгезчем минем, нәрсә дип уйларга да белмим. Кайда югалдың? Өзгәләнеп, бик тә борчылам хәбәрең булмаганга. «Янар таулар җимерелеп, алар астында калсам да, барыбер кайтыр юллар табармын. Ышан, көт мине, бергә булырбыз». Бу бит синең сүзләрең. Яу кырыннан күпләр кайтып беттеләр инде, ә син һаман кайтмыйсың. Моны ничек аңларга? Бик борчылам. Күпме егетләр арасыннан бары сине генә сайладым. Барыбер көтәм үзеңне. Әгәр дә көрешә алмый калсак, мин үлеп китсәм, бердәнбер гозерем бар сиңа: кайтып, минем каберемә, бер бәйләм роза чәчәкләрен баш очыма, кояшка каратып куярсың. Миңа шундый рәхәт булып китәр, гүремдә елмаеп алырмын. Бу синең белән соңгы күрешү гамәле булыр. Сау бул, хәбәрсез югалган минем беренче мәхәббәтем...»

Берникадәр баргач, Юлбарс тавы дип аталган, шәһәрнең иң биек җиренә күтәрелгәнемне белдем. Моннан бөтен Владивосток, каршыдагы җәелеп яткан Алтын Мөгез култыгы, еракта, офык артында кайчандыр монда килгән елларымда сокландырган Рус утравы күренә. Әнә бөек Петр бугазы. Анда ике крейсер рейдта тора. Алларның берсе һичшиксез мин сигез ел яшь гомеремне сагышларда, сугышларда үткәргәне булырга тиеш. Ә аннан соң гомерем коллыкта узды... Күңелемдә — диңгез давылы котыра, җанымда — диңгез үкереп елый, канымда — туган халкым үкси... Соңгы сулышымда кипкән иреннәремә су тидерергә килгәндәй, җанымны шигырь эзләп таба. Гомерем озын булыр әле минем. Җанымны бернигә дә сатмадым, беркемгә дә бирмәдем һәм бирмәм дә! Шигырь сүзләре ирнемә куна. Җыр җырлагандай Дәрдмәндны укыйм:

Шаулый диңгез...
Җил өрәдер...
　　　Җилкәнен киргән кораб!
Төн вә көндез
Ул йөзәдер:
　　　Юл бара ят ил карап...
Чыкты җилләр,
Купты дулкын —
　　　Ил корабын җил сөрә!..
Кайсы юллар,
Нинди упкын
　　　　　Тарта безне җан сорап?!

# Игътибар: Сез көткән романның дәвамы!

«Иртеш таңнары» романының беренче китабы сиксәненче елларда «Казан утлары» журналында басылып, 1988 елда аерым китап рәвешендә дөнья күргән иде. Укучылар әсәрне яратып, аңлап үз итеп укыдылар. Автор — Тубыл ягы Ялан авылы укытучысы Якуб ага Зәнкиев күп санлы хатлар алды, укучылардан хат-хәбәрләр әле дә өзелми. Себер татарлары тормышына, көнкүрешенә, гореф-гадәтләренә багышланган, сирәк очрый торган китапның алдагы язмышы, ниһаять, хәл ителде, автор романның икенче китабын язып тәмамлады.

Дөнья үзгәрә, дөнья белән бергә кешеләрнең язмышлары да һич көтелмәгән якларга кереп китә. Беренче китап Ватан сугышы башлану белән бетә иде. Сугыш кадәрле сугыш, дөньякүләм вакыйгаларны бер йодрыкка төйнәгән олы вакыйга роман геройларын төрле якка чәчә, тарата. Мөхәммәт Уразаевның сөекле хатыны Сания табибә, сугыш юлларын үткәндә фашистларга әсир төшеп, Бухенвальдта үзенең ачы язмышына юлыга. Мөхәммәт Уразаев үзе дә сугыш уртасына барып эләгә, каты яраланып, Ялан авылына кайтып төшә. Аны колхоз рәисе итеп билгелиләр. Кырык биш йортлы, таланган, өшәнгән, ир-аты калмаган Ялан авылына кышкы зәмһәрир суыклар башланган бер мәлдә калмыкларны «куып» китерәләр. Һәр йортта карт-коры, бала-чага, ачлар, ялангачлар. Халкыбызның гүзәл сыйфатлары — бер-береңә ярдәмләшү, татулык, сабырлык, кече күңелллелек татарлар арасына сөрелгән калмыкларга да яшәп китәргә, исән калырга ярдәм итә.

Себернең карурманнарында Миша Сорокин «отрядына» тупланган качкыннар әле дә яшәп ята, аларга кайчандыр Урта Азия якларына чыгып югалган Канталыев ярдәм итә. Бу банданы сагалау, тоту эпизодлары автор тарафыннан аерым бер осталык белән язылган.

Романда шактый гына яңа кешеләр дә бар. Аларның берсе, иң сөеклесе, кайчандыр Чиләбе ягыннан сөрелгән укымышлы мәзиннең нәбәрәсе укытучы Миңнурый... Күләме ягыннан әлләни зур булмаган романда автор шактый кызыклы язмышларны очраштырып, мавыктыргыч сюжет кора алган.

Татарстаннан читтә яшәгән милләттәшләребез тормышын төптән үк ачып бирә алган әдәби казанышларыбыз күп түгел! Себер татарлары арасыннан чыккан, дөньяның дүрт ягын да иңләгән, тынгысыз җанлы, җылы күңелле Якуб аганың үз халкына булган мәхәббәте эзсез үтмәгән, ул китаплар дөньясында лаек урын алырлык гүзәл әсәрен тәмамлаган! Афәрин, мөхтәрәм Якуб ага! Себер татарларының, милләтебезнең асыл бер улы икәнсез.

Романның икенче кисәге кайчан басылачагын сорап, редакциябезгә дә байтак хатлар килгән иде. Без Татарстан Республикасы төбәкләренә генә түгел, Себер һәм Урал регионында яшәп ятучы милләттәшләребезгә дә мөрәҗәгать итәбез: әгәр журналга язылмый калган булсагыз, ашыгыгыз, гафил булып калмагыз, озакламый Якуб ага Зәнкиевнең гүзәл романы журнал битләре аша сезнең күңелләргә барып ирешәчәк! ■

# ШИГЪРИЯТ



## Рифкать Закиров

«АККОШ КҮЛЕ» ДӘФТӘРЕННӘН

### Түз, йөрәгем

Төшмәс борын бишектән мин
Мәхрүмдермен сабыйлыктан:
Хәтерләмим һич сөт тәмен,
Бар белгәнем әче бер тәм —
Тел очымда шуны йөртәм.

Кайсы ачы, кайсы әче:
Кайгы ачы, каргыш ачы...
Керән әче, әрем әче...
Ачы-әче яшь койганчы,
Түз, йөрәгем, әрнемәче?!

Түз һәм оныт ачуларны,
Син йот эчкә ачыларны!..
Аз татыдым төчеләрне,
Күп таныдым кешеләрне,
Дус-дошманым ишеләрне...

Соң төшенү — яман, беләм,
Белгән саен һаман беләм;
Эчем пошып янам-үләм:
Күп кешенең тулган икән
Эче-тышы ялган белән?!

Чын булса да җисемнәре,
Ялгыш-ялган исемнәре:
Гадел — гадел түгел әле,

---

Рифкать ЗАКИРОВ (1938) — *шагыйрь, берничә китап авторы. Казанда яши.*

Камил — камил түгел әле —
Рухи гарип күңелләре...

Түз, йөрәгем! Түзик, әйдә!
Мин чыдармын син түзгәндә.
Балда-майда йөзмәсәм дә,
Ни кылсам да, ни күрсәм дә:
Телем ачы, күңелем садә!..

## Көзге чык тамчылары

*Айдар Хәлимгә*

Алсу тамчы саркый миләшләрдән,
Чал кояшлы көзге көн балкый.
Беркемем юк янда сердәшләрдән,
Бәгыремне сагыш-моң талкый,
Хәтер тәрәзәсен кем шакый?..

Кызгылт чыклар тама баланнардан,
Чаганнардан сары коела.
Ялгыз узган чакта аланнардан
Ялгызлыктан җаным кыела,
Салкынлыктан каным куера.

Пакь тамчылар — кыяк, күрәннәрдә,
Яшькелт чыклар — яшел курпыда;
Еллар авыр, айлар сүрән мәлдә,
Мин ни эзлим такыр-буш кырда?
Ул дөньяда, бәлкем, юктыр да?!

Әнкәм яше төсле тере тамчы
Сүс-кылганда тора шәйләнеп;
Күңелләрем тулып түгелгәнче,
Күз тутырып карыйм әйләнеп:
Әллә кабат күрәм, әллә юк?..

## Үкенеч

Юлдаш-терәгем булсын дип,
Таянып таягыма,
Буш күңелләрем тулсын дип,
Чыксам да кай ягына:
Калынгамы кары-бозы,
Аккош күле битараф...
Салкынгамы, каен кызы
Тора оеп, тик карап.

Үсмер чактагы кызларның
Юксынып чыр-чуларын,
Кергән идем тын урманның
Кочыйм дип чыршыларын.

Сердәш икән бит алар да
Бары тик җилгә генә:
Яшим икән дөньяларда
Сарылып кемгә генә?

Атлаулары җайсызланды
Аягым, тоягыма.
Тәннән битәр җан сызланды,—
Олагыйм кая гына?

Ник кайттым монда Уралдан,
Калдырып чыршыларын?
Ничекләр итеп, бер Аллам,
Калтырап кыш чыгармын?!

## Эт елында

Урман юллары тар икән,
Баздай тирән кар икән;
Киләчәгем болай булса,
Күрәчәгем бар икән...

Кай ягыңа син карама:
Карагай да карама.
Күзгә кунып кар бөртеге,
Кадый йөрәк ярама...

Нәрсәм калган бу буранда,
Кышкы урман юлында?
Кеше түгел, кар кешесе
Тыкмый монда борын да.

Юк, чыкмадым мин юлларга
Бүрек, толып урларга,
Чыктым бары Эт елында
Бүре булып уларга!

Мин уласам да яхшырак,
Җавап бирми каршы як:
Үз тавышым тик үземә
Кайта кире яңгырап.

Беркемнең миндә эше юк,—
Хәл белүче кеше юк;
Исләре китмәс үлсәң дә;
Хәтта туңып-күшегеп.

Уйласа да кеше гәрчә,
Яшим дип кешеләрчә:
Тешләшә дә, этләшә дә,—
Яши эт-песиләрчә?!

Аяк астымда баз микән,
Кар астында саз микән?

Кыш артында кышлар микән,
Әллә җылы яз микән?...

Бирмәде, бирмәс һич җылы
Маймыл, Әтәч, Эт елы...
Булырмы бирәр һич югы
Сөенеч, Бәхет елы?

Төнәм шунда уңга-сулга
Урман, кар уртасында;
Әллә чын да мин яшимме
Хайваннар дөньясында?!

## Козгын белән сөйләшү

Улы сугышка киткәч...
Соңгы сулышы җиткәч,
Козгын кычкырып үткәч,
Пышылдады карт бабай:
«Әгәр, козгын, алдамай
Изге хәбәр китерсәң,
Авызыңа бал да май!»

Әтисен бик сагынгач,
Көтә-көтә зар булгач,
Күктә козгын кагынгач,
Сөрән салды бер малай:
«Әгәр, козгын, алдамай
Изге хәбәр китерсәң
Авызыңа бал да май!»

Яуга озаткач ирен,
Каркылдагач ач козгын,
Дәште кат-кат яшь килен,
Көч-ышаныч тапкандай:
«Әгәр, козгын, алдамай
Изге хәбәр китерсәң,
Авызыңа бал да май!..»

... Хәлләр ничек соң бүген,
Әллә белмисең үзең,
Хәбәр бирмисең, козгын?
Болытлы нигә көзем?
Гел дымлы керфек-күзем...
Гомер кыска, төн озын!..
Ник эч поша көнозын?!

Инде күпне югалткач,
Әмма үземне тапкач —
Үз асылыма кайткач,
Мин дә әйтәм: «Син алай,
Козгын, бик еш алдамай
Бер чын хәбәр китерсәң,
Авызыңа бал да май!..»

## Пәри кызына

Иблисләр каршы килсә,
Сине мин яратканга,
Фәрештәләр каршы төшә,
Мине син яратканга.

Шуңамы: «Төн кулай»,— дисең,
Син мине яратканда...
Көн ни, төн ни,— ходай белсен,
Мин сине яратканда!

Син һәр төнне күз дә йоммый
Сөеп, таң аттырсаң да,
Мин төн буе күреп туймый,
Көн буе аһ орсам да,—
Мине — синнән, көнне — төннән
Аера кич-иртәләр;
Аера кичләр, иртәләр;
Арада чик-киртәләр.

Чикне атлап чыгалмыйбыз,
Чиксез яратышсак та!..
Шуңа кушыла алмыйбыз,
Сагынсак-саргайсак та.

Һәм без кавыша алмабыз
Яңадан яралсак та...
Безне иш итми Аллабыз,
Сүзне ишетми Аллабыз,
Ялынсак-ялварсак та?!

## Калгандыр миңа күпме түзәргә...

Адашкан сыман кырларга чыгам,
Карап ымсынам үрләр түренә.
Саташкан сыман кулымны сузам:
Күземә таныш күзләр күренә...

Яшь таммасын дип, күземне йомам,
Җан якмасын дип, кире борылам;
Талгын җилләргә йөземне куям:
Тансык йөзләргә килеп орынам.

Тик сизеп торам: янда юк кем дә...
Мин соң тилмерәм алданып кемгә?!
Ялгыз уза ич бүгенге көн дә,—
Бармы ышаныч алдагы көнгә?

Кемдер үз итә... Кемдер чит итә —
Һәр икесе дә бердәй үксетә...
Бер үкендерә һәм бер җирсетә:
Моңсу-ямансу миңа ничек тә.

Дәшеп күгелҗем үрләр артына,
Акылдан мине кемнәр шаштыра?..
Ахры, авыр юл: тагын чак кына
Түз, сабыр бул, дип ары чакыра...

Карап туйганчы серле күзләргә,
Кабат куйганчы йөзне-йөзләргә,
Бәйләп үргәнче хисне-хисләргә,
Әйләндергәнче төшне өннәргә,

Калмасын миңа күпме түзәргә,—
Язмасын гына өмет өзәргә!..

## Көнчелек

«Күрше хакы — алла хакы»,—
Дип, күршеләр серләшә;
Кем изге дә, кем гөнаһлы:
Икесе дә көнләшә!

Башка кешеләр хакында
Юк сөйләп торасы да:
Көнләшә ир дә, хатын да,
Кодача, кодасы да.

Көнчелгә бар да аз кебек,
Тик күзе туймаганга:
Күрше тавыгын каз диеп,
Тик үзе суймаганга!..

Сыната үзен һәр бәндә,
«Бәхетсез мин» дигәндә:
Көнләшүчеләр бар хәтта
Бәхетсезлегемнән дә!

## Соңгы чиктә

Йөрәккенәм купкан урыныннан
Бакый-гомерлеккә...
Йөреп тирән упкын кырыеннан
Фани гомер үтә?!

Олгайсам да һич утырып җитми
Акыл-фигыльләрем;
Беркайчан да булмас, ахры, җитди
Сабый күңелләрем!..

Урын тапмый җир-күк арасында
Тырмашадыр җаным.
Ургып акмый, йөрәк ярасында
Укмашадыр каным...

Тыштан караганда, бөтен кеше
Гүя оҗмах кошы!
Тик һаман да күбрәк хөсетлесе,
Бик аз иманлысы...

Тапса шулай һаман кешелек ямь,
Үч һәм көнчелектән,
Тора-бара чыкмас микән адәм
Тәмам кешелектән?!

Нишләсәм дә, соңгы чиккә җитеп,
Берни кыла алмам,—
Ачы яшьләремне эчкә йотып
Елый гына алам...

Ишетелә дисәм былбылларның
Җыры колагыма:
Түгә икән җилгә үз моң-зарын
Коры кура гына.

## Тау битләре киртләч-киртләч...

Тау битләре киртләч-киртләч,
Таш ишелде җил искәч;
Җан кыелды, күңел тулды,
Баш иелде син киткәч.

Тау битләре киртләч-киртләч,
Алсулана кич җиткәч.
Ачуланма, аңлашырга
Соң шул инде... кичеккәч...

Тау битләре киртләч-киртләч:
Ташка ташлар береккәч.
Бергә чаклар беркайчан да
Кире кайтмас, бер үткәч.

Тау битләре киртләч-киртләч,—
Кем төшмәс тә, кем менмәс?
Тау ауса да, таш яуса да,
Синең эзләр күмелмәс.

Тау битләре киртләч-киртләч,
Тау боз түгел — эремәс;
Күктә кояш сүнгәндә дә
Мәхәббәтем сүрелмәс!

Тау битләре киртләч-киртләч,
Тау — таяныч, таш — сердәш:
Тетрәнде дә елады таш,
Күзләремдә яшь күргәч!.

Тау битләре киртләч-киртләч,
Кителсә дә кимемәс;
Тау битендә бер җыерчык,
Бер сыр артыр мин үлгәч...

## Илсөяр Иксанова



### Яшәү серен ачтым

* * *

Җиргә нигә килгәнемне белдем —
Күзләреңә бары бер бактым.
Сөю — эзләп килгән,
Сине эзләп,—
Яшәү серен ачтым,—
Яраттым.

Бер дә юкка яшәү түгел җирдә,—
Мең газабын кичим —
үкенмәм,
Җирне җылытырлык сөю калыр
Күзләреңә баккан ул көннән.

### Чиллә

Бу — чиллә.
Бу — хисләр чилләсе.
Аннан җәй авышыр көзләргә.
Күрмәссең җанымның яктысын,—
Пәрәвез сарылыр күзләргә.

Бу — чиллә.
Бу җәйнең уртасы.
Җиләкләр кызарган ут янып.
Миннәнме,
уттанмы куркасың? —
Торасың сокланып,
уйланып.

Бу — чиллә.
Бу — сөю чилләсе.

---

Илсөяр ИКСАНОВА — *шагыйрә, «Ышанасы килә» исемле китап авторы. Казанда яши.*

Җәйләрнең уртасы,—
гомернең...
Мөгаен, мин янып бетәрмен,—
Һәм калмас каралып күмерем.

## Ир

Таяныр иң,
Башың салыр күкрәк.
Баш очында
Күкләр торса күкрәп,
Ышыкланыр кыя,—
Көчле, гайрәтле.

Давыл сирәк,
Көннәр гадәти...—

Һәм ул —
Һәр адымда
Хатын ярдәменә мохтаҗ нарасый...

## Могҗиза

Ялварып сорадым күкләрдән:
Табыштыр,
таныштыр,
кавыштыр!
Күкләрдә адашкан илерү
Ул минем,
тик минем тавыштыр.

Ә күкләр шәфкатьле, шәф-кать-ле!
Без бүген өчебез — бербөтен.
Син берсен үпкәндә иелеп,
Мин үбәм кызымның бер битен.

Мин кабат күкләргә ялварам:
Күп күрмә бәхетемне,
йа раббым!
Гомергә тигезлек, сөю бир,
Каерма җилләрдә канатым.

Бүгенге күкләрем болытсыз.
Кояш күк кадерле бу бала —
Тормышны түгәрәк итүче
Иң олы могҗиза дөньяда.

## Синең җырың

Синең җырың мине саклап килде
Ялгышлардан, хата, каргышлардан.

Нәкъ шул җырың кебек саф идем мин,
Һәм сагышлы идем, сагышланган.

Илаһи моң белән тулы иде
Дөньяларга сыймас төсле күңел.
Мин мөкиббән идем синең җырга
Һәм, әлбәттә, җырга гына түгел...

Гайбәтләрдән мең кат өстен идем,
Гөнаһлардан ерак иде хисем.
Сөю идеме бу,
табынумы? —
Ул халәткә табылмаган исем.

Һәм сагышлы идем,
Саф сагышлы,—
Синең якты җырың шикелле.
Рәхмәт җырга!
Шул саф килеш мине
Үз ярыма илтеп җиткерде.

## Төссез төшләр

Төсле төшләр инде сирәк керә.
Кара да ак һаман,
ак та кара.
Төш түгел бу, тик саташу, диеп
Күңелеңне ышандырып кара!

Аннан җиде яктан хәбәр килә:
Кайда үлем-китем,
кайда нәрсә...
Бу кайгылар булмас иде төсле,
Сиңа саташулы төш кермәсә.

Төш түгел бу,
тик саташу гына...
Онытырга, онытырга тизрәк!
Ак та кара,
кара да ак төшләр
Нигә керә миңа...
нигә кирәк?

Нигә кирәк алдан белеп тору.
Үз-үзеңне санап гаеплегә,
Бәргәләнү аннан төш күргәнгә...

Төшләр керә һаман,
Төссез төшләр керә...

■ ■ ■

**Туфан Миңнуллин**



# ШУНДЫЙ ХӘЛЛӘР

**Ел саен кышын мин «Крутушка» дип аталган санаторийда ял итәм. Ияләшеңгән. Каеннарына хәтле күңелгә якын.**

**Тагын бер ягы кадерле — анда үзебезнең агай-энеләр ял итә. Алардан мин күп нәрсә ишетәм. Мәзәк хәлләрне дә, гыйбрәтле хәлләрне дә сөйлиләр миңа агай-энеләр. Миңа алар, Тукай әйтмешли, язарыма азык бирәләр.**

## Мәчет

Санаторийның өченче корпусы төбендә бер төркем татар картлары гәп куерталар. Сүзләре тәмле. Дөнья турында. Киләсе җәй турында... Сәясәткә күчтеләр. Горбачевка да эләкте, Ельцинга да өлеш чыкты. Әмма тәнкыйтьләре усал түгел. Сүгенмиләр. Күбрәк уйланалар. (Малай чак искә төште. Безнең авылның ирләре шулай кичләрен бүрәнә өстендә дөнья турында ирләрчә сөйләшә иде).

Дингә күчтеләр. Авылларда мәчетләр салына башлавын хупладылар. Азыныл-тузынып беткәнче иманыбызга кайтсак ярар иде диештеләр. Мәчетләрне бетерүчеләргә дә бик эләкте. Кемдер урысны гаепләмәкче иде дә, урысның үз чиркәвен дә яптылар бит дигәч, агай, шулай инде анысы, диде. Тикшерә торгач, мәчет яптыручылар власть башында утыручы түрәләр дигән уртак фикергә килделәр. Шунда бер абзый:

— Үзебез дә гаепле инде,— дип куйды да сүзен дәвам итте,— үзебездә дә гаеп бар. Куркаклар без чөнки. Моннан бер ун еллар элек без, биш-алты кеше җыелып, район башлыгы янына бардык. Мәчет салырга иде бит дип әйтергә исәбебез. Язу да язып бардык. Кереп утырдык моның кабинеты янындагы бүлмәгә тезелешеп. Сикритар кызый кереп китте начальнигы янына. «Берәм-берәм генә керегез», диде. Киңәштек тә, арадан иң өлкәнебезне кертеп җибәрдек. Шактый озак утырып чыкты бу. Чыгуына торып бастык та: «Йә, ничек?» — дип сорадык. Кул гына селтәде дә бу бер сүз әйтмичә чыгып китте. Ул арада икенчебезне чакырып алдылар. Анысы озак тормады. Ул да бер сүз әйтмичә кайтып китте.

Чират миңа житте. Кердем. Айрадрум хәтле кабинетның аргы башында утыра рәис. Янына барып җиткәнче тез буыннары калтырап, аяк тотмый башлады. Көчкә барып җиттем. «Рәхим итегез, абый, утырыгыз», ди бу татарчалап. «Рәхмәт», дидем дә утырдым. Рәис миңа төбәлеп карап тора башлады. Бер сүз дәшми — тик карап тора. Мин нишләргә белмим. Соңыннан аңлатып бирделәр. Ул гел шулай эшли икән. Аның сере дә бар икән. Шулай карап торып ул йомыш белән килүчеләрнең өнен ала икән. Йомыш белән килгән кеше йомышын да рәтле-җүнле әйтә алмыйча ык-мык итә дә тизрәк чыгып качарга чамалый икән.

Мин дә шулай гаепле кеше шикелле шактый озак утырдым. Юк, сез көлмәгез. Шүтке түгел ул. Сталин да шулай эшли торган булган.

Карап торды да рәис: «Йә, абый, ни йомыш?» — дип сорады. Белә бит инде, эттән туган нәрсә, нинди йомыш белән килгәнне. «Мәчет кирәк иде», дип көчкә телемне әйләндереп әйтә алдым. «Мәчетме? — дип сорады бу кабат, — нәрсәгә кирәк инде ул мәчет?»

«Нәрсәгә дип, менә картаелды, бүтәннәр дә сорый, киңәштек-табыштык та, мин әйтәм, рөхсәт булса...»

Рәис тагын текәлеп карап тора башлады. Мин бу юлы шыр җибәрдем. Торып йөгереп чыгып китәсе килә, селкенеп тә булмый. Ярый әле елмаеп куйды бу. «Була ул, абый, мәчет, ди, була ул. Кирәк икән салыгыз. Рәхәтләнеп укыгыз догаларыгызны». Эчкә җылы керде. Бүтәннәр кабинетка кереп мәчетсез чыктылар, мин кердем дә мәчет алып чыгам, дип уйлап куйдым эчемнән. «Мин сез язганнарны да укыдым, сезгә кадәр кергәннәр белән дә сөйләштем, рөхсәт язуы алырсыз», дип тә өстәгәч, рәхмәт укырга тотындым моңа. Елмаеп кына тыңлап торды бу минем рәхмәтләремне. Аннары капылт кына: «Сезнең балаларыгыз бармы?» — дип сорады. «Бар», мин әйтәм. «Кайда эшлиләр?» ди бу. Әйтеп бирдем, берсе врач булып эшли, берсе укытучы, икесе инжинир, икесе авылда, үз янымда», дидем. «Ал-а-ай, ди бу сузып, алар ни ди соң?». «Нәрсәгә ни ди?» дип сорыйм мин дә. «Менә сезнең мәчет даулап йөрүегезне алар хуплыймы соң?» ди. «Хуплыймы дип, сөйләшкән юк. Хупламый нишләсеннәр. Без бит инде картлар», дим. «Юк, абый, сез башта алар белән ныклап сөйләшегез, — ди председател, — эш менә болай тора, — дип өстәде аннары, — без сезгә мәчет салырга рөхсәт бирербез. Ә менә балаларыгыз... Коммунистлармы алар?» «Берсеннән башкалары коммунист», дидем. «Алайса шулай, — диде бу сүзен бетергән сыман иттереп. — Сезгә мәчет салырга рөхсәт бирәбез дә балаларыгызны партиядән чыгарабыз. Партиядән чыгарылгач эшләреннән дә азат итәргә туры килер». «Ни өчен?» дим аңламыйча. «Ни өченме, ди бу, шуның өчен. Алар коммунистлар, ә этиләре мәчет сорап йөри. Нәрсә бу? Нәрсә алар коммунистлар партиясенең дини хорафатларга каршы икәнлеген белмиләрме? Партиягә мәчет салдырыр өчен кергәннәрме?»

Тезде дә тезде генә бит район башлыгы. Ул яңа сүз әйткән саен миңа куркынычрак була бара. Эштән куылсалар балаларым нишләрләр? Рәис юри куркыта дип уйлар идең, коммунистларның бөтен әйткәннәрен дә чынлап эшләгәннәрен күреп белгән кеше бит мин. Колхозын да беләм, утыз җиденчесен дә, аннан соңгыларын да беләм. Шуңа күрә, шиңдем дә төштем. Исән чакта ничек котылырга дип уйлый башладым.

Минем балаларга ниләр буласын әйтеп биргәч, район башлыгы сүзен: «Ничек, абый, мәчет кирәкме?» — дип сүзен бетерде. Әйтәсе сүземне әйтә алмыйча тордым да: «Сау булыгыз», дип чыгып киттем. Ишек төбендә кабинетка керергә торучылар минем каршыга килделәр. «Йә ничек, булдымы?» диделәр. Кул гына селтәдем дә кайтып киттем.

Шуннан соң мәчет дигән сүзне әйтү түгел, әйткән кешеләр янында да тормый башладым. Инде менә бу заман килгәч кенә бераз батырайдым. Ну барыбер ышанып бетмим. Мәчет салдырулар да юкка гына түгел микән дип уйлыйм. Килер берәү властька да җимерергә дип әйтер. Нишли аласың? Үзең салганны үз кулың белән җимерәсең инде. Теге рәис әле дә исән. Яшь әле ул. Сайлауда төшеп калды калуын да. Әмма да исән, көтеп тора яңадан үз чираты җиткәнен. Безнең кебек куркаклар барында теләсә кемнең чираты җитә. Мәчетеңне дә сүтеп ташлыйлар, өеңнән дә куып чыгаралар.

Төркемдәгеләрнең берәрсе абзыйга каршы килер микән дип кызыксынып тыңлап тордым. Берсе дә каршы килмәде, алай булмас димәде. «Шулай шул», диештеләр.

Мин дә эчемнән генә «шулай шул», дип куйдым. Алай булмас, дип кисәтеп әйтү өчен демократик шартларда һичьюгында ун-унбиш ел яшәп карарга кирәк. Хәер, ун-унбиш кенә ел микән?

## Нәсел орлыгы

Туфан абый, бер кызыклы әйбер сөйлим әле, рөхсәт итсәгез. Берәүгә дә сөйләгәнем юк иде. Хәер, берәүгә сөйләгән идем дә, кычкырып көлде, шуннан сөйләгәнем булмады.

Минем үземә дә көлке тоелган иде ул башта, олыгайгач искә төшеп уйлап куям да, ниндидер мин аңлап бетермәгән олы мәгънә ята сыман анда. Сез аны аңларсыз дип беләм, берәр әйбер язганда кирәк булып чыгуы да ихтимал.

Алтынчы класста укый идем. Бервакыт җәй көне иртән иртүк өстемдә нәрсәдер кыбырдаганга уянып китсәм, янымда дәү бабай утыра. Әти ягыннан бабамның әтисе. Ул чакта аңа туксан биш яшьләр булгандыр. Сезнең Әлмәндәрдән дә картрак.

Менә шул дәү бабай бармаклары белән минем тәнемне капшый. Уянсам да, нишли икән бу, дип күзләрне ачмыйча, йоклаган булып ятам.

Кулларны капшап чыкты. Мускулларны кысып-кысып карый, буыннарны тикшерә. Аннан шулай ук аякны тикшереп чыкты. Күкрәк капкачын бик озаклап тикшерде, сөямләп үлчәп тә чыкты хәтта.

Әллә акылдан ычкынганмы дип курка ук башладым. Шулай да түзәм. Муен тамырларын, җилкә чокырларын капшап чыкты. Аннары, сөйләргә дә оят инде, теге җиргә төште. Бот төбенең мускулларына басып-басып карады. Кытык килә, шулай да түзәм. Куркудан түзәм. Берәр сүз әйтсәм, әллә нәрсә булыр кебек. Чит кеше булса, тибеп очырыр идем, бу бит дәү бабай. Бәләкәй чагымда ук мине үзеннән калдырмыйча үстергән бабай. Әни хәтта көнләшкән дә булса кирәк, чөнки әни кулына да бирми иде бугай ул мине. Үз янында яткыра иде. Мин үзем дә аңа ияләшкән идем, аның исен иснәп ятмасам, йокыга китә алмый идем. Исе тәмле иде дәү бабайның. Төтен катыш бал исе килә иде аңардан. Гомере буена умарта караган кеше. Әтинең әтисе бабай да исән иде, тик мин аның барлыгын да белмәдем. Аның үзенең дә миңа бик исе китми иде шикелле. Пустуй кеше чыгар ахры бу бизбашкадан, дия иде. Дәү бабай аны ачулана, әйтмә сабыйга андый сүз, дия иде. Мин берәр «әтлек» эшләсәм, миңа аның өчен эләгергә тиеш булса, дәү бабайның култык астына гына кереп оялыйм, аннан мине беркем дә суырып ала алмый, берәүнең дә тияргә хакы юк.

Ун яшьләрдән узгач дәү бабай мине үз янына яткырмый башлады. Аерым карават куйдырды. Бер бүлмәдә йокласак та ул үзенә, мин үземә. Мине иртән уята, кич йокларга үзе яткыра.

Бер тапкыр да болай иткәне юк иде, бу юлы әллә ниләр кыландырды. Аннары укый торган, яттан белгән бердәнбер догасы «Әлхәм»не укып башымны сыпырды да үз урынына барып ятты.

Мин ни уйларга да белми, кымшанырга да куркып озак яттым. Тәмам яктырып беткәч кенә, алгы бүлмәгә әниләр янына чыктым. Бу юлы дәү бабай уятмады, ятып калды. Үз гомеремдә беренче тапкыр мин торганда ул ятып калды.

— Ни булды сиңа, нигә агарындың? — диде әни мине күргәч. Бер сүз дә дәшмәдем. Дәшәрлек хәлдә дә түгел идем, ахры. Ниләр булганы төштә күргән кебек кенә бүген дә. Хәтеремдә, әни ишегалдыннан әтине чакырып керде. Нәрсәдер сөйләштеләр. Кычкырып сөйләшсәләр дә берни ишетмәдем, берни аңламадым. Бабайның гына исе китмәде, чуртым да булмас, шайтан таягына ни булсын, дигәне генә хәтердә калган.

Минем белән булашып дәү бабайны оныткannар, ахры. Бөтенесеннән дә иртә торучы дәү бабайның урынында ятуына берсе дә игътибар итмәгән.

Мине урыныма кертеп яткырганда гына әти, бабайга ни булган, дип, аның караваты янына барды шикелле. Шуннан бернәрсә дә хәтерләмим. Аңыма килгәндә өйдәгеләр тыз-быз чабалар иде. Ак халат кигән фельдшер апа да шунда иде.

Мин торып утыргач ул ят, ят, дип мине яткырырга тырышты. Мин ятмадым. Янымa әни килеп җитте.

— Хәлең ничек, улым? — ди.

Әйбәт, дим. Чыннан да әйбәт иде, бер җирем дә авыртмый, көндәге кебек.

Дәү бабай караватына карасам, ул һаман ята.

— Дәү бабаң бик каты авырый бит, улым, — диде әни. — Сине әллә ничә сорады. Нигә минем янга килми, ди. Саташа, ахрысы.

Торып дәү бабай янына бардым. Мине күргәч ул елмайды. Бармагы белән ишарәләп иелергә кушты. Иелдем. Ул колагыма гына пышылдап:

— Үзеңне сакла, олан, син нәселебезнең орлыгы, — диде. Аннан әти белән әнине чакырды: — Оланны карагыз, — диде дә күзен йомды.

Менә шул, Туфан абый. Искитмәле бернәрсәсе дә юк кебек болай. Төптәнрәк уйласаң... Үләр алдыннан, үләсен сизеп бит... Ул да урыныннан тормады. Мин дә һушсыз яттым. Ул үлде, мин калдым. Ничаклы сер ята монда.

## Кемнәр алар пинзяклар?

— Син Казан татарымы, Миңнуллин? Мин — пинзяк. Беләсеңме кем ул пинзяк? Пенза областенда алты татар авылы бар — шулар инде пинзяклар. Телем дә минем пинзяк, синең белән генә Казан телендә сөйләшәм. Бер өемә чакырам әле сине, шунда пинзякча сөйләшермен, язып алырсың.

Пинзяклар алар татар булсалар да башка халык. Без Кавказдан күчеп килгән. Менә миңа кара — Кавказ бит инде. Күр бу борынны. Минем бабайның борынын күрсәң иде син. Артист Мкртчянның борыны аның янында чыпчык борыны кебек кенә.

Характер да кызу безнең. Безнекеләр янында чеченнар сарык бәрәне генә. Шул характер аркасында сыешмаган инде безнең бабайлар Кавказга. Пензада да бездән дер калтырап торалар. Ләкин без юкка-барга тавыш чыгармыйбыз. Үзебезгә бәйләнсәләр генә чәйнәп ташлыйбыз.

Хәйлә дә житәрлек бездә. Хәйләгә килгәндә жәбриләр дә безнең белән алыша алмыйлар. Татар булган жирдә жәбригә урын юк, дип кемнәр турында әйткәннәр дисеңме? Без ул — пинзяклар. Шуңа күрә, сату-алу тирәсендә безнекеләр.

Жырга да оста без. Безнең янда синең Шәләпиннәрең ярык барабан гына. Безнекеләр жырлый башласа, сандугач та сайравыннан туктап тыңлап тора.

Безнең кызларның чибәрлеген күргәнең бармы синең? Күрсәң, шунда ук үләрсең. Теге гүзәлләр конкурсындагы чибәрләр безнең кызлар янында мунча пәриләре генә.

Безнең яктан чыккан прафиссырлар да бик күп. Башлы халык без пинзяклар. Безнең янда теге кем әле, Ламанусовмы, шыр надан...

Телгә да оста без. Безнең янда син үзең дә... Кил әле син безгә. Син килешкә Казандагы пинзякларны жыеп куярмын. Үзең дә күрерсең.

## Здравствуй, агай-эне

— Сезгә иярүдән килеп чыкты бу хәл, Туфан әфәнде. Әфәнде дигәнгә ачуланмагыз, үзегез уйлап чыгарган сүз бит. Үзе болай миңа ошый ул сүз. Мин агай-эне дип дәшәм кешеләргә дәшүен. Сезнең ише укыган халыкка агай-эне дип дәшеп булмый ич инде. Әфәнде дигәч олылау кебегрәк килеп чыга. Сезгә ияру дигәч тә сез үзегезгә генә алмагыз. Сезнең сыман язучылар дип әйтүем.

Тел, татар теле, туган тел дип күп сөйли башладыгыз ич. Элек Тукай гына әйткән. Хәзер сез барыгыз да. Күп әйткәч колакка керә икән ул агай-эне. Аңарга чаклы исем дә китми иде, әллә бар тел, әллә юк. Өйдә дә бала-чага маталый шунда үз телендә. Урыс телендә диюем инде. Ис тә китми. Ярамаганмы шунда. Дәресләрен генә белсеннәр. Мәктәпкә чакырып алып кына сукмәсеннәр. Телевизор караганда ачу килеп куйгалый иде куйгалавын. Иртән торсаң урысча, кич ятсаң — урысча. Татарча жыр тыңлыйсы килә бит. Ни әйтсәң дә авылда туып үскән, шунда жыр тыңларга өйрәнгән.

Сез тел, тел дия торгач уйландыра башлады бит, Туфан агай-эне, әфәнде. Туктале, мин әйтәм, карчык, хатынга әйтәм инде, бу безнең малайлар, алар өчәү безнең, үскәч синең белән минем телне белми инде. Шуннан нишлиләр инде? Маржага өйләнәләр инде. Алардан кем туа инде? Аларга синең белән мин кирәкме инде, дим. Алар бит синең белән мине бар дип тә белмәячәкләр бит инде, дим. Без кемнәрне үстерәбез булып чыга?! дим.

Хатын башта аптырап калды. Миннән шундый сүз ишеткәне юк ич аның. Минем хатын радионы күбрәк тыңлый. «Азат хатын»ны укып бара. Миннән ниерәк инде... грамытныйрак.

Киңәштек тә өйдә татарча гына сөйләшергә булдык. Малайлар кәжәләнеп карадылар каравын. Бездән көлгәндәй дә иттеләр. Ләкин алар беләләр — минем талкан коры. Минем димакратиям үзем белән. Үткән кышта тотынган идек, быел менә үзегез барып тикшерә аласыз, муллалар да алай итеп оста сөйләшә алмый татарча. Ышанмасагыз, өйгә килеп карагыз. Жәй көне авылга стажировкага да алып кайттым, мәктәпләренә барып та тавыш чыгардым. Менә шулай ул, Туфан агай-эне. Сезгә ничә яшь? Аһа-һай... Гафу итегез, мин бит сезне минем тирәләр дип... Туфан абый инде алайса, ачуланмагыз.

Стажировка дигәннән, авылга кайттым дидем бит жәй көне? Шунда бергә уйнап үскән малайны очраттым. Ижевскида торалар алар. Ул да хатыны, малае

белән кайткан. Малае зур инде, егет кеше. Мин соңга калып өйләндем, утыз биш яшьтә генә. Малае моның бер авыз татарча сүз белми. Аталы-уллы сиптерәләр генә болар урысча.

Беренче очрашканда без инде дус белән рәхәтләндек сөйләшеп. Кибеткә кырык сумлык канияк кайткан булган. Берне шуны алып сөйләшеп утырдык бездә.

Икенче көнне бу мине чакырырга килгән өйгә. Әни исән әле минем, энекәш белән тора. Шуннан нишләде дип беләсез мине? Шалт мин моның татарча исәнләшүенә урысчалап. Ул, исәнлектәме, нихәлләр? ди. Мин — здраствуй, агай-эне. Ул татарча ни генә әйтсә дә, мин урысчалап. Болай ярыйсы гына сукалыйм мин урысчаны, утыз бишкә хәтле зимагурлыкта йөргән кеше ич. Баштарак дусның исе дә китмәде. Бара-тора мин бер сүз дә татарча әйтмәгәч, нишлисең син, ә? ди. Ничава, мин әйтәм, нормально. Нормально с тобой разговариваю, дим. Кыланма инде, ди. Что за слово «кыланма», я это слово не понимаю, дим. Көлә бу. Мин көлмим. Бара-бара ачуы ук чыкты моның. Мин һаман урысча. Чево, мин әйтәм, сердишься? Какое имеешь право на меня сердиться? Ты же не сердишься на своего сына. С ним по-русски же разговариваешь. И я с тобой только по-русски разговаривать буду, дим. Тузынып чыгып китте бу. Үземнең малайлар, энекәшнең малайлары көлә. Әни ачулана.

Бераздан дусның хатыны килеп керде. Ул да үзебезнең авылныкы. Нәрсә булды сезнең арада, ди. «Ничава ни случилось», дим. Анысы да минем чынлап та урысча гына сөйләшүемне күреп пырлап кайтып китте.

Шаярып кына тотынган идем, Туфан абый, чынга китте бит. Авылда төрле сүзләр сөйләргә тотындылар. Күбрәк көлеп сөйлиләр инде. Кайбер агай-энеләр дә дус белән урысчалап кына сыптыралар икән. Мин барып гафу үтенергә дә уйлаган идем, шунда килелек килде бит. Туктале дим, нәрсәле мин дим, үпкәләмәгәе, дим. Аның белән алып-сатасым бармы, дим. Белсен нәрсә белән бетәсен, дим. Безнең татар бит ул үз башына төшмичә аңламый. Татарны изгәннәр дип сез дөрес сөйләмисез только. Измәгәннәр әле аны. Изелгән кеше уйлый белә ул. Без уйлый белмибез, без уйнап кына яшибез. Ярамаганмы тагын шунда дибез дә...

Бүгенге очрашуга керәм мин. Сез анда татарларга шул турыда да әйтегез. Берсенең колагына кермәсә, берсенекенә керә ул. Менә бит минем колакка керде. Хәзер инде мине берәү дә селкетә алмый. Башта минем телне бел минем малай булгач, аннан үзеңә кара, пожалыста, дөнья тулы тел. Менә бит мин, үземнекен дә беләм, урысныкын да беләм. Мирзачүлдә ике ел яшәгән идем, үзбәкчә гәперәм, Туфан әкә.

# Өч кыйсса

**Әле менә быелтыр бер төркем колхоз председательләре белән ял иткән идем. Кызып китеп алар миңа үзләренең кылган этлекләрен дә яшермичә сөйләделәр. Ишеткәннәремне блокнотка теркәп куйган идем. Искитәрлек нәрсә булмасалар да, мәзәк өчен язып калдырыйм. Ни дисәң дә шушы заман хикмәтләре бит.**

## Беренче кыйсса

— Бер апай белән кичтән барысын да җайлап, көйләп, сөйләшеп куйдык. Иртән урманга китәбез дә көн озынына шайтан да күрмәслек бер аланда икәү генә рәхәтләнеп кәеф-сафа корабыз янәсе.

Иртән нәкъ сөйләшкәнчә булды. Идарә артындагы чиялеккә сиздермичә генә чумуын күрүгә мотоцикл белән шунда килеп туктадым. Апагыз чиялектән чыгып йөлт кенә мотоцикл бишегенә чумды. Мин йөлт кенә өстенә брезентны каплап куйдым да урман ягына таба элдерттем.

Олы юлны кисеп чыкканда йөлт каршыга — райком секретаренең машинасы килеп тә туктады. Беренче үзе!

— Кая чабасың болай? — ди.

— Кырларны карап кайтырга дип чыккан идем,— дим.

— Бик яхшы, әйдә бергәләп карарбыз,— ди.

Ни дип әйтәсең инде. Киттек. Серкә очырып килгән арыш басуын гына күрсәтермен дә таярмын дип уйлыйм үзем. Андый чакта баш эшләүдән туктый бит ул. Мотоциклны калдырып, аның машинасына гына күчеп утырасы да бит, юк, мотоцикл белән машина алдыннан барам. Бернинди дә гөнаһым юк, янәсе.

Арыш басуын да карадык, бодай басуына да сугылдык, кукуруз кырына да бардык. Йөри-йөри, ышанасызмы-юкмы, апагыз турында бөтенләй оныттым бит әй. Ичмасам, үзе дә берәр тавыш чыгармый. Шул инде — күрәчәк күз йомдыра, акылыңны томалый.

Өч-дүрт сәгать йөртте секретарь. Көтүлектән саубуллашып киткәндә кояш бик ныклап кыздыра башлаган иде инде.

Секретарьны озатуга көтүлек янындагы буага төштем дә, чумып алыйм дип чишенә башлаган идем, мышкылдаган тавыш ишетелде.

Исемә төште дә егылып китә яздым. Брезентны ачып җибәрсәм... Мескенкәем!... Шабыр тиргә баткан, ул тир өстенә тузан кунып убырлы карчык кыяфәтенә кергән апагыз бөгәрләнеп ята. Нишләргә? Тартып чыгарыр идем, су буенда сыер савучылар бутала.

Тиз генә киендем дә мотоциклны кабызып әйдәме урман ягына. Агачлар арасына бераз керүгә үк туктаттым мотоциклны. Сөйрәп алып булмый бит апагызны. Бөрешеп каткан теге. Алай итеп, болай итеп көчкә сөйрәп чыгардым бишектән. Апагыз ни үле, ни тере. Көчкә-көчкә адәм рәтенә китердем. Кая инде ул кәеф-сафа кору. Әйтмәгәнен калдырмады. Мин дә кызып китеп әллә ниләр әйттем.

Талаштык, талаштык та... апагыз авылга җәяүләп кайтып китте. Мин кәеф-сафа корырга дип алган коньякны стаканга ике тапкыр салып тарттым да, үземне, апагызны, райком секретарен, язмышны эт итеп сүгеп урман эченәрәк кердем дә, бер алан табып, шунда ятып йокладым.

## Икенче кыйсса

— Йокларга яткан идек. Төнге уннар булгандыр, тәрәзә шакыдылар. Хатын торып тәрәзә янына барды.

— Шоферың килгән,— ди.

— Ни булган? — дим.

— Райком секретаре килгән диме. Чакырта диме шунда.

— Бу вакытта райком секретаре нишләп йөрсен!

— Каян белим, бар, үзең сөйләш,— ди хатын. Бардым тәрәзә янына.

— Райком секретаре килде,— ди шофер,— үтеп барышлый туктадым, ди. Сруны килеп җитсен, ди.

— Кайда соң ул?

— Ындыр табагында.

— Бар әйт, өйдә юк ул, диген.

Шофер китте. Мин урынга барып яттым да сүгенергә тотындым.

— Ял итеп алырга да тынычлык юк. Көне-төне чабасың, исләренә төшә дә йокыңнан уятып торгызалар. Ә син көнләшкән буласың, кая йөрисең өйгә кайтмыйча дисең. Кайтып кара болар белән.

— Йә, йә булды. Нәрсә дип әйттең соң? — ди хатын.

— Өйдә юк дип әйтергә куштым. Әлләни йомышы юктыр әле. Үтеп барышлый гына, ди. Берәр йөз грамм саласы киләдер әле. Җитмәгәндер. Өйгә үзе килсә ни була. Обязательно чакырып алырга кирәк. Азындылар!

Тынычланып, йокыга китеп кенә маташканда тагын шакыдылар тәрәзәне. Тагын хатын барып сөйләште. Тыңлап ятам.

— Тиз килеп җитәргә куша. Мин аның өйдә икәнен беләм дип әйтә,— ди. Хатын минем янга килде.

— Чакыра ди бит.

— Бармыйм, теләсә нишләтсен. Әйтсен, килә алмый, чирләп тора ул дисен.

— Берәр сүз булмасын тагын,— ди хатын.

— Булмагае,— дим,— алып ыргытсыннар председательлектән. Гарык булдым, туйдым. Ике аягымның берсен дә атламыйм. Малай-шалаймы соң мин чакырган саен чыгып чабарга. Әйт, килалмый диген.

— Нәрсә, кәҗәләнәсең,— ди хатын,— бүтән чакта эте-бете килсә дә чыгып чабасың. Кыланма. Бер чакырыр, ике чакырыр да... Борылып та карамас.

— Карамаса тагын, туйдым.

— Бик тиз туйдың,— дип хатын кызып китте,— нишләрсең, алып ыргытсалар. Кеше күзенә ничек күренермен. Нәрсә уен ясап ятасың? Бар! Берәр нәрсә әзерләп куйыйммы, өйгә кайтасызмы?

— Кайтырлык булса, чакырып тормас иде. Барыбер бармыйм.

— Җүләрләнмә диләр сиңа. Тор! Киен!..

Ул арада тәрәзә янына барып шоферга әйтеп килде.

— Җыена, хәзер чыга, диде.

— Син нәрсә? — дидем хатынга.— Син председательме, минме?

— Колхозыңда син, өйдә — мин, җыен,— диде дә хатын закускалар әзерләргә тотынды. Дипломатка бер яртыны да тыкты.

Мин сүгенә-сүгенә чыгып киттем.

— Кайда алар? — дидем.

— Посадкада,— диде шофер.

Киттек. Барып җиткәндә шашлык өлгергән иде инде. Бераз гына төшереп тә алганнар. Хатын-кызларның кәефе дә күтәренке, чырык-чырык көлешәләр. Минем сөяркә дә шунда. Килеп муенга асылынды:

— Ник соңга калдың? — ди.

— Көчкә ычкындым,— дидем дә кулга китереп тоттырган стаканны каплап куйдым.

Таң аткач кына кайтылган. Ну аның каравы савис чиста. Хатын үзе чыгарып җибәрде ич...

## Өченче кыйсса

— Заманында мин дә колхозда председатель идем. Андый хикмәтләрне эшләдек инде без дә. Шуңамыдыр, хатын бәйләнде бит, китәбез авылдан, ди, Казанга күчәбез, ди. Күчтек. Таныш-белешләр шактый иде, фатирны да юнәттек. Эшкә дә шәп кенә урнаштым. Барысы да тәртип. Машина бар иде, гараж сатып алдым.

Таптык, мәткәсен дә таптык. Уйнар өчен урын ягы җайсыз иде. Өендә үсеп килә торган малае бар. Аннан соң, элеккедән калган гадәт — өй тирәсендә күренеп йөрергә яратмыйм.

Тегеләй-болай уйладык та гаражда күрешә башладык.

Беркөнне шулай бик матур гына утырабыз гараж эчендә бикләнеп, мелдер-мелдер генә сөйләшеп, су эчәсе килеп китте бит тегенең. Алырга онытканмын, яшниге белән тора иде югыйсә... Беткән. Эчәсем килә ди, вәссәләм.

— Ярый, мин әйтәм, утырып тор. Менә монда якында гына кибет бар. Алып киләм.

Аны калдырып гараждан чыктым да, гадәт буенча, гараж ишегенә йозак элеп бикләдем. Киттем тиз-тиз генә кибет ягына.

Урамны ашыгып чыкканда күрми калганмын, шалт арт яктан бер мотоцикл китереп тә бәрде. Күздән утлар чәчрәде. Кеше җыелды. Торырга тырышам, урыннан селкенеп тә булмый. Милиция дә килеп житте. Скорыйны да чакырдылар, төяп алып та киттеләр.

Аяк шартлап сынган. Авыртуына чыдар хәл юк. Хәбәр иткәннәр, хатын чабып килеп житте. Аягы аяк, хатыны хатын — гаражда теге бикләнеп ята бит әле. Анысы ачуны китерә. Уйлый торгач очына чыккандай булдым. Бергә эшләктә йөри торган дустым бар. Аңа гаражның ачкычын ничектер җай табып бирергә кирәк. Ләкин аның телефоны юк. Яңа гына фатир алыштырган чагы.

Хатынга әйтеп җибәрдем. Тиз килеп житсен, дидем. Хатын ул дусны өнәп бетерми. Өйгә килеп йөрүен дә яратмый иде.

— Нәрсә, монда да аңсыз тора алмыйсың мәллә? — ди.— Шуның белән очрашкан саен эчәсез. Шул аракы аркасында ятасың да инде,— ди.

— Йә инде, мин әйтәм, тавышланма, монда аның гаебе юк, дим. Бу больниста шундый гадәт икән, операция ясаучы врачны сыйлыйлар икән, килеп күңелен күреп китсен әле шуның,— дим.

Әрепләшә хатын. Көчкә күндердем үзен.

Икенче көнне хатын килде.

— Өйдә юк ахирең,— ди,— ике көннән соң гына кайта, ди.

— Хатынына әйттеңме соң?

— Әйттем инде, әйттем. Килер.

Ике көннән соң чынлап та килде дус. Ачкычны бирдем дә гаражга чаптырдым үзен.

Калганын инде үзегез чамалыйсыздыр.

— Җылый, җылый шешенеп беткән,— ди дус әйтә,— кыяфәтенә карарлык түгел, ди. Өенә илтеп куйдым, шунда гына өненә килде. Сиңа сәлам әйтергә кушты, ди.

Соңыннан очрашкач җылый-җылый сөйләде теге:

— Ишек шакырга да курыктым, ди. Нишләргә дә белмәдем, ди.— Кипкән ипи катыларына хәтле кимереп бетергән мескенем.

## Ташкин якларына карыйм

— Беда әле, Туфан брат, карчык белән. Нормальный гына яшәп ята идек, ычкынды. Прямо нишләргә белгән юк. Беда есть беда. Иртән тора и утыра телевизорга карап. Ну чего утырасың мин әйтәм, ничего там нет. Ә ул утыра и әйтә: «Ташкинны күрсәтми калмаслар, Марс улым белән Рәхилә кызым да бәлкем күренеп китәрләр, ди. Эшкә барган чаклары булыр, кибеткә чыккан чаклары булыр. Күренмичә калмаслар», ди. Толкуй не толкуй. Һаман үзенекен сөйли. Больницага алып барырга да куркам. Алып барсаң, обязательно алып калалар. Ябып куялар сумашедший домга и все. Бер ябып куйсалар, попробовый, алып кара аннан.

Нормально гына иде башта. Как только Ташкентта катавасия башланды, тотынды бит бу. Безнекеләрне харап итеп ташларлар инде, ди. Үзбәкстән дигән сүзне ишетүгә бөтен эшен ташлый и телевизор, радио янына чабып килә.

Мин аны ачуланам. Кому нужны синең балаларың, дим. Йөр спокойно гына, дим. Юк. Һаман свое толкует. Кайтартыйк, ди. Чакырып телеграмм сук, ди.

Ну хат яздым малайга да, кызга да. Кайтып та киттеләр. «Не беспокойтесь, диләр, пока ничего не угрожает», диләр.

Хат та язып торалар. Все бесполезно. Иртән торып утыра и утыра телевизорга карап. Беда, Туфан брат. Вот и үстер балаларны. Кому все это нужно? Менә шулай акылдан шаштырыргамы? Разве это тормыш?..

## Коттеж

— Туфан абый, син Казан янында коттеж саласыңмы?.. Һәй, коттеж салыр өчен акча кирәкмени. Әллә коттеж салучыларның акчасы бар дип беләсеңме. Акча кирәкми, Туфан абый, блат кирәк, блат. Шул салдыра йортны. Синең блат җитәрлектер әле Казанда, депутат та булып тордың. Бөтенесе коттеж салдырганда син авылда ятасың. Җүләр булма, салдырып калдыр, үзең тормасаң, сатарсың.

Хәер, син хәйләкәр кеше. Нишләргә беләсең син. Коттеж салдырмыйча дөрес эшлисең. Хәйләкәр кеше син, беләсең дөньяның борыласын. Дөнья куласа икәнен беләсең син.

Салсыннар әле коттежларны, салсыннар. Салып бетереп типтереп яши башлагач кына без аларны тартабыз да алабыз. Ничек итепме? Ничек итеп алганнар соң элек! Шулай итеп алабыз. Байлар, ярлылар булмаска тиеш, бөтен кеше дә тигез булырга тиеш дибез дә тартабыз да алабыз. Коттеж салучылар чүтеки безгә караганда азрак. Без күбәү.

Бүгенге коттеж салучыларны Себергә бараклар салырга җибәрәбез дә, үзебез алар салган коттежларга кереп утырабыз. Шуннан барысы да тигезләнә.

Себергә куылганнарның малайлары үсеп җитә дә безгә бәйләнә башлыйлар. Влас башына менеп утыралар. Алар да коттеж салырга тотыналар. Минем малайлар тагын аларны куып чыгарып, коттежларына кереп утыра. Дөнья шулай әйләнә ул. Берәү сала, берәү тартып ала, берәү сала, берәү тартып ала.

Син хәйләкәр, син тартып алырлык әйбер калдырмыйсың. Синеке кебек өй минем үземдә дә бар, нигә синекенә кызыгыйм. Тракторыңа күз төшеп йөри йөрүен. Аның белән букланып тормыйм да, рәхәтләнеп утырып йөре.

Син башлы кеше шул, Туфан абый. Беләсең син. Безнең илдә баерга ярамый. Эшләп баерга да ярамый, урлап баерга да ярамый. Барыбер тартып алалар. Ник дисәң, талап яшәргә генә өйрәнгән безнең илдә халык. Без бөтенебез дә бандит. Өстәгеләр дә, астагылар да. Әле бер бандит өскә чыга, әле икенче бандит өскә калка. Әле берсе талый, әле икенчесе талый.

Ю-ук, мин курыкмыйм. Теләсәң кая барып әйт. «Чапаев» дигән кинада дөрес әйтә ул. Әле кызыллар килеп талый, ди, әле аклар килеп талый, ди. Таладылар кызыллар. Сарыкка сөт налугы салып талаганнар бит, заемга кыйнап яздырып талаганнар. Әни сөйләде. Менә аклар килде, хәзер алары талый. Сыер саткан акчаны сбиркассыга салганыем, дурак. Таладылар да алдылар. Үз акчамны сорап барганыем, акча юк дип бирмәделәр. Хәзер бирәләр, пажалысты ал гына. Нишлим мин аның белән хәзер. Ул чактагы биш мең хәзер биш тиен. Бандитлар шулай эшләде.

Таласыннар. Мин дә талаячакмын. Салма, Туфан абый, коттеж, барыбер тартып алабыз. Менә мин әйтте диярсең. Язып куй мин әйткән көннең сәгатен-минутын. Син мине салган баштан сөйли дип уйлама. Аек чакта да уйлап йөрим мин аны. Баш бик каты эшли минем. Телевизордан бөтенесен карап ятам.

Нигә бер жирдә дә эшләмисең, диләр. Эшләмим. Мин бүтәннәр эшләгәнне карап ятам. Эшләп бетерсеннәр, салып бетерсеннәр әле коттежларын, аннары карарбыз. Күрсәтербез әле без ул буржуйларга күрмәгәннәрен. Авылдагы кулакларга да урын табылыр.

Курыкма, Туфан абый, сиңа тимибез. Бер ярты бирсәң хәзер, ике-өч елдан менә дигән йортка күчерәбез үзеңне. Житте, безнең канны күп эчтең, дип күршеңне өеннән куып чыгарабыз да сине кертеп утыртабыз. Нигә алай эшлисең дисәләр, Туфан Миңнуллин халык өчен тырышты, дип авызларын тиз томаларбыз.

Чынлап та, нигә Казан янында коттеж салмыйсың син, Туфан абый? Беләсең син, сабака. Хәйләкәр кеше син. Бир инде бер ярты. Бар бит инде синдә. Ничек инде синдә ярты булмасын. Нәрсә, коттеж салырга жыясыңмыни акчаңны? Жүләрләнмә, Туфан абый. Сине яратканга әйтәм, жүләрләнмә!

... Моннан бер айлап элек ишеткән бу монологны язып куйгач, бакчасында казынучы Әзһәр Шакиров янына чыктым. Сөйләшеп киттек. Коттеж салырга блоклар алып кайткан. Малайларына торыр урын юк икән, коттежны аның өчен салырга жыеналар. Әзһәр әйтә: «Шул тирәдә коттеж салучыларга ялланып эшләүче эшчеләр, үзебез өчен төзибез бу йортларны, вакыты житкәч тартып алачакбыз дип сөйлиләр,— ди.

Димәк, миңа монолог сөйләүче салган баштан гына мәзәк итеп сөйләмәгән икән, ләбаса. Я хода, бу илдә бездән калганнар да рәтле-юньле яшәмәсләр микәнни...

## Эш харап...

**Марсель Сәлимжанов сөйләгәннән.**

— Утыз жиденче елларда минем әни апасының ирено куркынычянаганын белеп өлгергән дә шул хакта әтигә әйткән. Киңәшә торгач «эз югалтырга» булганнар. Ул чакта, беләсең инде, әгәр вакытында сизенеп бөрәр жиргә күчеп китсәң, аллә ни эзләп маташмаганнар. Апаларны танышлары аша әти Кама Тамагы районының бер авылына укытучы итеп урнаштырган. Сугыштан соңгы елларда мин анда барып йөри идем әле. Шул апа белән булган хәлне сөйлим үзенә.

Бервакыт апалар батареялар белән эшли торган радиоалгыч сатып алалар. Ул вакытта бик дефицит нәрсә. Алган көнне кич белән апа радиоалгычны кабызып төрле дулкыннарда ниләр сөйләгәннәрен тыңлап караган. Шунда кинәт «Кремлевские толстолобые коммунисты во главе тирана и убийцы Сталина...» дигән сүзләрне ишетеп алган да тиз генә радиоалгычны туктаткан һәм колхоз председателе янына йөгергән. Колхоз председателе булып карт коммунист эшли икән.

— Берәр нәрсә ишетмәдегезме?— дип сораган апа.

— Юк,— дигән председатель.

Шунда апа радиодан ишеткәнен әйткән. Председатель агарынып, телсез калган.

— Кремльдә берәр нәрсә булган булырга тиеш. Юлбашчыбыз Сталинны төшереп, капиталистлар менеп утырган мәллә?

— Әкрен!— дип пышылдаган председатель.— Син ни сөйләгәнеңне беләсеңме?— дигән. Тучны дөрес ишеттеңме, шулай дип әйттеләрме?— дигән. Апа ант иткән.

Шуннан соң Кремльне капиталистлар алуына тәмам ышанганнар болар. Нишләргә кирәклеге турында планнар корганнар.

Подпольега күчәргә кирәк, дигән карарга килгәннәр дә, председатель ат җигеп, райкомга чапкан.

Төнлә генә әйләнеп кайткан ул аннан. Аңа ияреп тагын бер кеше килгән. Апаларга кергәннәр. Теге кеше бөтенесен җентекләп сорашкан. Апаны тыңлагыч, радионы теләсә ничек боргаламаска кушкан. Мәскәү белән Казанны гына тыңларга боерган. Америка империалистларының безнең илгә каршы коткы тарату йөзеннән русча да сөйләгәннәрен әйткән. Апа ишеткәннәрен бүтән берәүгә дә сөйләмәскә ант иткән. Шул көннән апа радиоалгычка якын килергә дә куркып йөргән.

Ә теге сүзләр «Голос Америки» радиостанциясенең безнең ил өчен рус телендә әзерләнгән тапшыруыннан бер өзек булган.

## Кая гына барсаң да...

Моннан ун еллар элек Анатолий Софронов исемле рус драматургы РСФСР Язучылар Союзында драматургия советын җитәкләүеннән файдаланып, егермеләп язучыны үзенең туган якларына — Дон буендагы Ростовка алып китте. Мине дә иярттеләр. Без Мәскәү театр училищесында заманында бергә укыган Александр Мишарин дигән драматург белән бергәрәк йөрдек.

Милләте белән ул кемдер, белмим. Әмма урыс түгел дә түгел. Миңа ул бераз өстәнрәк карый — чөнки Мәскәү драматургы бит, мин Казаннан гына. Ләкин мин сер бирергә җыенмыйм, исем дә китми, тик карап йөрим.

Фамилиямнең татар икәнлеген күреп-ишетептер, очрашулар вакытында залдан кем дә булса берәү миңа сорау бирә. Татармы? дип сорыйлар гадәттә һәм үзләренең дә татар икәнлеген әйтәләр. Очрашулар беткәч тә, бер-ике татар көтеп алып минем белән сөйләшә. Мишарин моны күреп миңа төрттерә. «Ну и яраталар сине татарлар, кая барсаң да сиңа ияреп йөриләр», ди. «Ияреп йөрмиләр, мин әйтәм. Кая барсаң да шунда татар яши, дим. Син үзең дә татар бит дим, фамилияң — Мишарин, димәк, татар каны бар», дим.

Бер зур гына станицага бардык. Ростовтан еракта — далада. «Менә монда инде татар юк», ди Мишарин. «Ашыкма», дим. Һәм шунда ук, кодрәт юк диген инде, яныбызга бер хәрби килеп басты:

— Гафу итегез, Туфан абый, фамилиягезне белдерүдән укыгач көтеп тордым. Мин моннан ерак түгел генә хезмәт итәм. Үзем Саба егете,— ди. Мишаринның күзе дүрт булды.

Станица совхозның үзәге иде. Аннан безне машиналарга утыртып совхозның бүлекчәсенә алып киттеләр. Бәләкәй генә авыл. Мишарин миннән сорый: «Монда татар бармы, юкмы?» ди. «Ничек инде булмасын», дим. «Әйдә бәхәсләшәбез», ди. Бер шешә коньяктан бәхәсләштек. Йөрибез карап кырларны, фермага да кердек. Саша көлә. «Коньяк сатып алырга онытма», ди. Шуннан бу бүлекчә управляющиенә безнең бәхәсебез турыда мәзәк итеп сөйли. Хуҗа кеше шунда: «бар бездә татарка», дип әйтеп куймасынмы. «Ышанмыйм, ди Саша, күрсәтегез», ди. Управляющий кемгәдер нәрсәдер әйтте дә, озакламый бер хатынны алып килделәр. Түм-түгәрәк битле чибәр генә хатын. Управляющий ни өчен чакырганын әйткәч, кызарды. «Сез чыннан да татармы?» — ди Мишарин. «Әйе», ди тегесе. Мин татарча дәшәм хатынга, ул элеккечә үк кызарып, «Мин татарча онытгым, начар беләм», ди.

Мишаринның коньягын Ростовка кайткач эчтек...

Таганрогка баргач шулай бер мәктәпнең бер классына кердек. «Әйдә, Саша, бәхәсләшәбез, бу класста да берәр татар малае булачак»,— дим. «Юк инде, ди Саша, житте, ди. Бушлай эчеп йөрергә чамалый, хәйләкәр татар», ди.

Бәхәсләшми дөрес эшләде. Очрашу узгач, класс җитәкчесе интернационализм турында бер-ике сүз әйткәч, класста татар малаеның да булуын белдерде.

Шуннан соң Мишарин да: «Сез теләсәгез ни әйтегез, мин бүгенге көннән татар булдым», дип шаяртып йөрде. Шаяртуын шаяртты, әмма миңа карата мөнәсәбәте дә үзгәрде сыман, кешегә санабрак сөйләшә башлады. Юк-бар халыкның вәкиле түгеллегемне төшенде, ахрысы.

*1991—1993 еллар*

■ ■ ■

# ШИГЪРИЯТ

## Рәшит Шиһап



### Рәхмәт, кәккүк!

Моңлы кәккүк!
Синнән сораганда
Күпме калды, диеп гомерем,
Өчне кычкырдың син, белдергәндәй
Артык та һәм ким дә түгелен.
Өч ел гомер күптән узып китте
Өермәле газап эчендә,
Ә мин әле һаман гел көрәштә
Башкалар һәм үзем өчен дә.
Син бит миңа гомер санамаган,
Санагансың даулы елларны,
Тапталган хис, денем, телем өчен
Узарсың дип авыр елларны.
Рәхмәт, кәккүк!
Саташтырган өчен
Гомерем белән көрәш кырларын,
Ул кырларда халкым бәйсезлеген
Мин алда да мактап җырлармын.

### Дөньясына нота

Ник кыерсыта дөньясы
Мин аңа килгән көннән,
Мин аңа килгән көннән лә,

---

Рәшит ШИҺАП — *1938 елда туган, ике китап («Хисләр давылы», «Җырларымнан мине эзләгез». 1992—93, Лениногорск шәһәре) авторы. Журналыбызда беренче тапкыр басыла.*

Язмышым иңгән көннән.
Җәберенә киендергән
Туган мизгелдән башлап,
Китеп барган, авызыма
Имезлекләрен ташлап.
Үрелгәнмен ач әнинең
Сөт кипкән күкрәгенә,
Кычкырганмын, елаганмын
Зарланып күпләренә.
Буй җиткәч тә Дөнья мине
Башымнан сыйпамады,
Изге булырга теләдем,—
Ул аңа ошамады.
Яхшылыклар кыла килсәм —
Китердем ачуларын,
Ташлады утлы давылга
Үкертеп ярсуларын.
Юаш, ятим дөреслеккә
Кыюлыклар салганда,
Кыйнады, туры килми дип,
Бу эш синең заманга.
Гаделсезлекләргә каршы
Кылычлар уйнатканда,
Якамнан тотып селкеде
Этлеген чуалтканга.
Калмас кара сакал кебек
Иярле золымнары,
Яшәрде генә, яшәрде
Хәсрәтем болыннары...
...Дөньясын якадан алып,
Туздырам золымнарын,
Гаделлек белән берлектә
Коямын корымнарын.
Җиһанның пычрак мохитен
Кысып алып учыма,
Кырам, чистартам, пакьлыймын,
Чыга барып очына.

## Кайгылар

Тәңребезнең кайсы фәрештәсе
Җиргә сипте сезне, кайгылар,
Яшәргә дә әле өлгермичә
Сезнең кулда үлә сабыйлар.

Бу тормышның матур мизгелендә
Гомер сөргән чакта юанып,
Кеше азмы көчен сарыф итә
Газиз башы сездән чуалып.

Көтмәгәндә, яшен угы кебек,
Кадаласыз йөрәк түренә,
Күтәралмас йөккә әверелеп,
Илтеп тапшырасы Күгенә.

Бу җиһанның ямьлелеген бик еш
Каплап ала сезнең болытлар.
Болытында — тәмуг кайнарлыгы,
Йә зәмһәрир салкын котып бар.

Кайгыларга чумган җанлы затлар
Һәрвакытта сынау астында.
Бары кеше сезгә түзә ала,
Бары кеше җиңә барсын да.

Кеше — олуг! Гомере кыскарса да,
Сезнең белән көн дә көрәшеп,
Ул үзеннән калган буыннарга
Шатлыкларын китә өләшеп.

Ул өләшә барлык җиңүләрен,
Бәхетләрен, көчен өләшә,
Туар чорда яшәүчеләр өчен
Бүген дошман белән сөйләшә.

Кайгылар, сез күпме килсәгез дә
Күңелләргә безнең убрылып,
Җир баласы үзен горур тота,
Сезгә каршы бара томрылып.

Кайгылардан миләр кайнаса да,
Йөрәк янса утсыз-күмерсез,
Тик шулай да
Гел рәхәттә яшәү туйдыра ул,
Кайгыларсыз була күңелсез.

Бушлык урый бөтен җисемеңне,
Ә кайгылар бирә хәрәкәт,
Бер буш гәүдә булып сөйрәлүең
Кайгылардан болай һәлакәт...

Әй, кайгылар, безне телемнәргә
Турый-турый җанны кыймагыз.
Әнә күпме бушбугазлар йөри,
Сез шуларны күбрәк кыйнагыз!

## Тавышыңны кадерлим

Еллар аша тагы килде тавышың,
Тынып калган хисне уятып,
Тынып калган хисне уятып ла,
Нечкә күңелемне елатып.
Кайтавазы булып яшьлегемнең,
Яннарымнан көлеп үттең дә,
Барлык тынычлыгым җилгә сибеп,
Сихереңә күмеп киттең дә.
Елаулардан инде туйган идем,
Сабырлыгым җәйде канатын,
Нигә инде сабыр канатларын

Сындырырга иде, Канатым.
Менә кабат айный алмый йөрим,
Тавышың калды, әмма үзең юк.
Гомер яртысында табар идем,
Юллар күрсәтергә сүзең юк.
Күпме вакыт җаннарымны кыеп,
Аваз гына булып яшәрсең,
Аваз гына булып яшәрсең дә,
Аваз гына булып дәшәрсең.
Нинди генә гөнаһларым өчен,
Күкләр мине шулай җәберли.
Үзең булмаганга, арган йөрәк
Тавышыңны гына кадерли.

## Әйләнеп кайт тәүге сөюеңә

Бөдрә каеннарга җилләр кунган,
Серләшәләр уйнак яфраклар.
Уйларымда сине иркәлимен,
Искә төшкән саен яшь чаклар.

Кайтавазы булып яшьлегемнең,
Юлларымда тагын күрендең.
Сагынуымны толымыңа урап,
Кайнар кулларыңа үрелдем.

Күзләреңдә күрдем моңсулыклар,
Хыялыңда мине йөрткәнсең,
Бәхетләргә төреп сөймәгәнне,
Тормышыңа мине көткәнсең.

Каеннарны иеп җил ялгыша,
Ялгышларсыз гомер агалмый.
Әйләнеп кайт тәүге сөюеңә,
Ул хыянәт булып саналмый.

## Мин күкләрдән сине сорап алдым

*(М-гә)*

Җаным елаганга тезләндем дә,
Мин күкләрдән сине сорадым.
Күк йөзеннән якты йолдыз очты,
Син киләсең диеп юрадым.

Юрауларым бушка китмәделәр,
Йолдыз төсле килдең яктырып,
Сөю газапларын, сагышын юып,
Сөенечләремне арттырып.

Ярсулардан шашкан хисне тыеп,
Йомшак нурлар сиптең яныма,
Шифа булып кердең күңелемә,
Дәва булып тамдың җаныма.

Мин күкләрдән сине сорап алдым,
Яратырмын йөрәк талганчы,
Бары сиңа гына табынырмын
Күкләр безне үзенә алганчы.



# Рифә Рахман

## Торна җиле

Әле безгә көз тимәде дип мактанган
Үләннәрне торна җиле иеп үтте.
Көзге чәчәк кебек торган иренемә
Канатлары йомшак кына тиеп китте.

Тынычланып калдым бераз. Моңсулыктан
Инде кача алмасам да алай бик тиз.
Җир өстеннән үлән иеп очкан чакта
Миңа көзге яфрак җыеп китерегез!

Җир өстеннән болыт булып күчкән чакта
Җаннарыгыз китмәсен лә ыңгырашып.
Үләннәрне торна җиле иеп үтте —
Эзләп тапты, дип торалар, пышылдашып.

## Курку

Күзләреңә кунган бу серле төн
Керфекләрең кебек чем-кара...
Шәүлегәннең авазлары кереп,
Алачыкка безнең шом сала.

Сыпырам да, күрми, йөзләреңнән,
Артка чигәм кинәт калтырап:
Ачыла ишек, беркем кермәсә дә...
Ачыла ишек нидән сак кына?

Кем соң тапкан безнең алачыкны?
Кем соң тапкан аның сукмаган?
Күзләреңә кунган бу серле төн
Көтеп тора аның сукканын.

---

Рифә РАХМАН — *яшь галимә, шагыйрә; шигырьләре көндәлек матбугатта даими басылып килә. Казанда яши.*

Артка чигәм куркып үзеңнән дә.
Артка чигә миннән бусага.
Ябыла ишек, беркем кермәсә дә.
Ачылыр ишек, биге булса да...

## Синең яшәү

Яшәвең дә —
Көнгә
Гөнаһ өстәү генә.
Шул гөнаһың яше
Коела
Өстәлеңә.

Кулларыңа
Тоткан
Чәең түгелгән күк.
Тамагыңнан калып,
Хәлең җуелган күк.

Почмагыннан
Тама
Кыйшык өстәлеңнең —
Әллә чәең, әллә
Яше
Бу җәеннең.

## Авылда чагында

Гел мине уйлама, бик авыр булса да.
Ялгызлы печәннәр авырдыр тагын да.
Таңгача эшләсәң, төнеңне кызганып,
Минем яшь шикелле, төшәр чык чалгыңа.

Минем яшь шикелле, төшәр чык, туктасаң,
Бөркү таң килгәнгә, хәлсезлек чорнаса.
Киселгән үләннәр өстендә елар кош,
Чәчәкләр таҗында булыр шул оясы.

Елар кош, ятагым чирәмгә төште дип,
Чалгылар үземнең бәгырьне кисте дип.
Егылган печәннәр яңадан тураймас,
Ул кошның оясын күтәреп куялмас.

Җил исеп очырмас оясы өстеннән,
Күзеңнән тамар яшь таң чыгы урнына.
Юатыр сүзләрне табалмый торсаң да,
Ул — минем шикелле, коч аны куйныңа.

## Кыңгырау-кошка

Кошым, сайрап, ишегемә чакырасың:
«Күз»ен ачып, тышны карый алырмынмы?
Хуҗам юкта йортка ир-ат килә калса,
Бусагадан атлатырга ярыйдырмы?

Син сайрыйсың, тамакларың чишелгән күк,
Ишелер күк ишекләрем сайравыңнан.
Сайрап, кунак дәшмә инде ирсез йортка,
Коткар мине бүген көн җавабыннан.

И тутый кош, авыр хәлгә куя-куя,
Кемең өчен шулай бик тә тырышасың?
Икеләнсәм, тавышларың матурлана,
Ачмый торсам, нигә мине орышасың?

## Нәзберек яңгыр

Күзләремә генә ява яңгыр.
Тамчысы да кунмый чәчләремә.
Яңгыр эчеп туйган кара күзем
Салкыннарын җиргә чәчә генә.

Керфекләре рәшә уйната, дип,
Күзем белән генә үчләшә көз.
Алма коеп, сине уята, дип,
Күңелләрен бераз юатыгыз.

Алма коеп, көнне уйнатмый ла,
Алма коеп, көзне уята шул...
Әллә инде каралыгын көнләп,
Килә аның һаман елатасы.

Рәшә түгел, яңгыр атына бит
Сыенышып торган керфекләрдә,—
Салкыннардан туңган алмалары
Җиргә кадәр сыгылып төшкән әнә.

## Ялгышасың

Нинди тыныч, дисең, яшәүләрең—
Борчылмасам, шигырь язаммыни?
Синең белән гәп куерткан чакта
Борчымаган яра ярамыни?

Нинди матур, дисең, торган җирең,
Матур булса, рәсем эләммени?
Синең белән чәйләп утырганда
Рәхәт булса, ярсып көләммени?

Нинди сабыр, дисең, холыкларың,
Сабыр булса, дерелдәрме кулым?
Мине һаман мактап торганыңда
Мең кат тудың, мең кат җаннан җуйдым.

## Соңару

Өметләр, ут капкан җил кебек,
Янды да югалды күземнән.
Йөрәгем киталмый калды шул
Торналар чылбыры эзеннән.

Очалмый калды шул — җылы бар
Якларга, еракка каядыр...
Салкынга түзалмас җанымны
Өшетеп яңгырлар ява гел.

Ява гел күзләрне батырып.
Камашкан миләш күк үзем дә.
Йөрәгем киталмый калды шул
Бу яктан бер генә көзне дә.

* * *

Син дә — газап, бу өй,— газап минем өчен.
Нидер булыр төсле һаман. Гел өркетә.
Ачык калган тәрәзәмнән төннең кулы
Һәр килгәндә кара чәчәк ташлап китә.

Ярый әле таңга кадәр юкка чыга,
Шешәсенә салган суы кипмәсә дә.
Өстәлемә таҗларыннан тамган тамчы,
Көннән куркып, төн катына китмәсә дә.

Төн дип әйтми, торып, сулар салам — нигә?
Нигә кичтән тәрәзәмне бикли алмыйм?
Ни дә — газап, син дә, төн дә — минем өчен.
Шешәгә су! Кара чәчәк булып яныйм!

# САГЫНЫП КИЛДЕЛӘР.

# ЯРАТЫП КИТТЕЛӘР.

Элегрәк елларда язучыларның шау-гөр килеп әдәбият көннәре уздыру еш була торган иде. Без ул хакта газета-журналлардан укып, радио-телевидениедән күреп-ишетеп кенә белә идек һәм кайчан безнең төбәктә дә шундый олы бәйрәм узар икән, дип кызыксынып уйлана идек.



*Балык Бистәсе районының хакимият башлыгы Хатыйп Фатыйх улы Газизов.*

Чынлап та, язучы-әдипләр өчен «ак яклар», кунакчыл төбәкләр республикабызның көнчыгыш районнарында гына шикелле тоелгандыр. Ә безнең Балык Бистәсе, ханнар табынына затлы балыклар куя алган, ямьле Кама буена урнашкан районыбыз башкалардан киммени?! Саный китсәң, халкыбызның горурлыгы саналырлык күпме әдипләр, күпме сәнгать әһелләре безнең җирдән чыккан лабаса! Районыбыз кешеләре эшчәнлек ягыннан да, кунакчыллык ягыннан да башкалардан кимхур түгел сыман...

Хикмәт нәрсәдә? Мәшһүр Казанга якын булып та нишләп әле без гел генә күләгәдә кала килдек. Безне үги итеп, гел читләтеп үтә тордылар. Моңа этәргән күп сәбәпләрнең берсе — безнең район белән һәрчак читтән китерелгән кешеләр җитәкчелек итте. Андый җитәкченең, гадәттә, авызы район байлыгына, ә күзе еракка карый, монда эш күрсәткән булып, тизрәк олырак урынга күчүне кайгырта иде. Бу хакимнәр «өлкән туган» вәкиле буларак, җирле халыкның милли культурасына, мәнфәгатенә битараф иде. Без хәтта милли бәйрәмебезне — Сабан туен да район үзәгендә элегрәк уздыра алмыйча яшәдек.

Ниһаять, соңгы елларда хәл үзгәрде. Безгә Казанның мәдәни нуры төшә башлады, әкренләп үз асылыбызга кайтырга ышаныч артты. Тарихта аерым бер шәхеснең роле хакында төрле фәлсәфи фикерләр, бәхәс-уйланулар бар. Әйе, халыкны уятырга, аны яңа эшләргә ымсындырырга, рухын күтәрергә бер шәхеснең үз вакытында очкын сала белүе җитә икән шул. Районыбызның хакимият башлыгы итеп Хатыйп Фатыйх улы Газизовны сайлап куйганнан соң без моңа тагын бер кат инандык. Туган җир язмышын үз бәгыре итеп тойган, белемле, егәрле бу шәхес артыннан утка да, суга да керергә була! Иң мөһиме: җитәкче буларак, ул — халыкның эш-гамәлен генә түгел, күңел дөньясын да бердәй биеклеккә күтәрүне максат итеп куя. Без моңа көннән-көн инана барабыз.

* * *

Язның матур бер кояшлы көне. Районыбызда — бәйрәм рухы. Ниһаять, безгә дә олы кунаклар — җөмһүриятебезнең күз-кашында торган язучылар киләчәк. Күңел ышанып та бетми әлегә. Тарихта күрелмәгән хәл бит бу! Туган төбәгеңә шушындый да матур көндә иҗади «десант» — утыз язучы килеп төшсен әле!

Менә районыбыз чигендә, рәшә уйнап торган кырда, Казаннан килеп төшкән автобуслар колоннасы тукталды. Чигүле күлмәкләр кигән, кулларына икмәк-тоз тоткан чибәр кызлар уртасында, районның хакимият башлыгы Хатыйп Газизов кунакларны сәламли:

— Балык Бистәсе районы җиренә аяк басуыгыз белән, туганнар!



*Х. Ф. Газизов Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ринат Мөхәммәдиевкә истәлек бүләген тапшыра.*

Үзара сәламләшүгә җыр яңгырады, кочаклашу көрешүләр, «тояк уйнатып» биеп алулар... Мондый да эчкерсез тантанада өлкән язучылар да яшәреп, чын егетләргә әйләнделәр. Көтелгән олы бәйрәм, әнә шулай итеп, Хәсән ага Туфан әйтмешли, «башлана башлады»...

Әдәбият көннәренең эшлекле өлешен республикабызның халык депутаты, Хатыйп Фатыйх улы Газизов бәйрәм өстәле янында дәвам итте.

— Озак еллар буена милләтебезне, динебезне югалту кыйбласын тоттык,— дип башлады ул сүзен.— Мисалга ерак китмик. Шәхсән минем үземә бер дәрес тә татар теле укырга насыйп булмады. Университетны инде әйткән дә юк. Кызганыч, хәзер дә әле җыелышларны урыс телендә алып барабыз. Ләкин шунысы куанычлы: күпчелек татар халкын тәшкил иткән Балык Бистәсенең бүгенге җитәкчеләренең күбесе — татарлар. Үткән елларга борылып карасаң, бәгырьләр өзелә. Бай Чулман, олы КамАЗ юлына урнашкан районга бер дә игътибар булмаган. Җирләребезне кисеп әле Мамадышка, әле Питрәчкә кушканнар. Аннары, аласын алып, җелеген суыргач, мөстәкыйль эшләгез дип, үзен генә калдырганнар. Шуның нәтиҗәсендә, башка районнар белән чагыштырганда без бик калоритлы күренмибездер. Бер генә мисал: күрше Мамадышта 50 урта мәктәп булса, бездә — 24 кенә. Ялгышларыбызны төзәтә барабыз: авыллар ныгый, төпле җитәкчеләребез (нигездә, үз җиребез кешеләре) бар. Мәдәният йортлары белән бергә, һәр авылда диярлек мәчетләр төзибез. Без бүгенге көндә район хуҗалыкларын ваклау юлы белән ныгыту курсын алдык. Зурмы-кечкенәме — һәр авылның төпле хуҗасы булырга тиеш. Андыйларны читтән эзләмәдек, хөрмәткә ия булган шул авыл кешесен сайлап куйдык. Олы эшләргә тотынып алдыннан авыл картлары — аксакаллар белән киңәшләшәбез, дини бәйрәмнәрдә катнаша-

быз. Мин моны иманыбызга кайту дип бәялим. Татар мәктәпләре күбәя бара, музыка, спорт мәктәпләре ачабыз. Районыбызда табигать хозуры — гаҗәп матур урыннар күп. Бездәге кебек тәмле сулы чишмәләр җир йөзендә тагын кайда бар икән! — әнә шулай тәэсирләнеп, үз җиренең улы, патриоты булып сөйләде район хуҗасы!



***Районның Мәдәният йортында үткән очрашудан бер күренеш. Алгы рәттә (сулдан—уңга): Мидхәт Миншин, Әхәт Гаффар, Харис Әшрәфҗанов, Роберт Әхмәтҗанов, Равил Фәйзуллин.***

Татарстан Язучылар берлеге рәисе, язучы Ринат Мөхәммәдиев әдәбияттагы яңалыклар, әдипләрнең бүгенге шартлардагы хәле турында таныштырып китте.

— Сүз дә юк, без хәзер асылыбызга кайту юлларын эзли башладык. Мондый үзгәреш, күтәрелеш Балык Бистәсе районында да нык сизелә. Бу чорны әдәби әсәрләрдә чагылдыру — язучыларның төп бурычы. Әлбәттә, моңа рухи азыкны халык белән турыдан-туры очрашканда, аралашканда гына алырга мөмкин. Без менә шундый элемтәне Балык Бистәсе районыннан башлап җибәрдек. Бу юкка түгел, чөнки бу төбәк республикага күп язучылар биргән бәрәкәтле як. Шунысы куанычлы, әлкән, зур язучыларның берсе дә Балык Бистәсенә бармыйм, димәде, барысы да бик теләп ризалык бирде. Ике арадагы элемтәләрнең нык булуын һәм озак дәвам итүен телим.

Танышу-әңгәмә вакытында язучылар беренче тәэсирләрен уртаклаштылар, үзләрен кызыксындырган сорауларга эчкерсез җавап алдылар.

Аннары... Кунакларны ун төркемгә бүлеп, ун авылга озаттылар.

Татарстанның халык язучысы Гариф Ахунов, Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеев, Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, прозаик Ринат Мөхәммәдиев, шагыйрьләр Шәмсия Җиһангирова һәм Хәйдәр Котлы Бөкәштә булып, халык белән очрашулар үткәрделәр.

Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреатлары, шагыйрьләр Равил Фәйзуллин һәм Мөдәррис Әгъләмов, прозаик Мәдинә Маликовалар Ямаш авылы хезмәтчәннәре белән очраштылар. Равил Фәйзуллинның туган авылы Балтач (Юлсубино) мәктәбендәге кыска вакытлы әңгәмә дә укучылар күңелендә онытылмас тәэсир калдырды.

Татарстанның халык язучысы Мөхәммәт Мәһдиев, филология фәннәре докторы, язучы Тәлгать Галиуллин, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Мансур Шиһапов, «Ватаным Татарстан» газетасының бүлек мөдире Асия Юнысова Балыклы Чүкәй авылы белән таныштылар.

Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗев, шагыйрьләр Нияз Акмалов һәм Газинур Морат Олы Елга авылындагы очрашулардан зур тәэсирләр белән кайттылар.

М. Җәлил һәм Халыкара Андерсен бүләге лауреаты, шагыйрь Роберт Миңнуллин һәм шагыйрә Эльмира Шәрифуллинада Биектау авылы мәктәбендә

очрашу, анда «Базар мунчасы» — күңел ачу бәйрәмен үткәрү онытылмас хатирә калдыргандыр.

Г. Исхакый бүләге лауреаты Рабит Батулла, шагыйрь Роберт Әхмәтҗановлар Күгәрчен авылында кызыклы кичә үткәрделәр.

Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, шагыйрь Шәүкәт Галиев, балалар язучысы Җәүдәт Дәрзаман, Татарстан китап нәшрияты директоры Харис Әшрәфҗанов Югары Тегермәнлектә, прозаик Вакыйф Нуруллин, шагыйрьләр Зиннур Мансуров, Лена Шагыйрьҗан Күки авылында булдылар.

Прозаиклар Әхәт Гаффар һәм Әхәт Мушинский Олы Әшнәк авылы кешеләре белән әңгәмәләр үткәрделәр.

Рус авылы да читтә калмады. Танылган прозаиклар Михаил Скороходов белән Михаил Корчагинны Олы Көл авылы кабул итте.

Шулай итеп, язучыларыбыз мәктәпләрдә, клубларда, эш урыннарында дистәләрчә чыгыш ясадылар, сәясәттән туеп, жылы, жанга ятышлы сүзгә сусаган халык белән әңгәмәләр үткәрделәр. Авылларның яңа төзелеш мәйданнарын, истәлекле урыннарын, музейларны карадылар.

Икенче көнне район үзәгендә мәдәният сарае халык белән шыгрым тулы иде. Бу онытылмас тантанада җыр-музыка, хикмәтле сүз тынып тормады. Сәхнәгә бер-бер артлы язучылар күтәрелә торды.

**Равил Фәйзуллин:**

— Бу безнең өчен тарихи көн. Ун-унбиш ел элек мондый очрашуны күз алдына китерү дә мөмкин түгел иде. Кайчандыр олы су — Идел, Чулман буйларыннан куылган безнең халык. Менә хәзер янәдән ерак офыклары булган киңлекләргә җыелабыз. Кайтабыз. Иманыбызга кайтабыз.

**Тәлгать Галиуллин:**

— Мондый яңача очрашулар бик кирәк. Ул халыкның нинди уйлар белән яшәвен белергә ярдәм итә...

**Илдар Юзеев:**

### Җырлап китәм Котлы Бөкәштән

Кайберәүләр, бәлки, уйлый булыр,
Бөкрәйгән бу карт, бетәшкән...
Мин тураеп, матураеп китәм,
Җырлап китәм Котлы Бөкәштән.
Син дә картайгансың, бөкрәйгәнсең...
Хөрмәт булмагандыр бик яшьтән.
Тураерсың әле, зураерсың —
Шуны көтәм Котлы Бөкәштән.



*Язучылар укучылар арасында. Алгы рәттә (сулдан — уңга): Газинур Морат, Батулла, Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Гариф Ахунов.*

Мин дә бераз ярдәм итәр идем,
Таныш булмаганмын ник яшьтән...
Яңа Тукай, Яңа Сәйдәш тусын...
Күпне күтәм Котлы Бөкәштән.
Чал Чулманың сыман борынгы да,
Киләчәгең белән бик яшь тә...
Сагынып сөйләр көнем, төнем кала...
Җырым кала Котлы Бөкәштә...

**Аяз Гыйләҗев:**

— Без сезнең якларга күңелләрегезгә җылылык өстәү теләге белән килдек. Мине шунысы куандыра: Балык Бистәсе — татар халкының җылы бер почмагы булып киткән. Мин гомерем буе үз халкым өчен куанып яшәдем. Якты өметләр сезне ташламасын. Күңел нурыгыз беркайчан да сүнмәсен.

**Мәдинә Маликова:**

— Ямаш авылында мәктәп китапханәсендә булдык. Китапларым искергән. Димәк, укыйлар. Мин моңа шат.

**Лена Шагыйрьҗан:**

— Күки авылында гомеремдә беренче тапкыр мәчет манарасына мендем.

**Җәүдәт Дәрзаман:**

— Тегермәнлек авылында хуҗалык, мәктәп, авыл Советы җитәкчеләре бер йодрык булып эшли. Алар авылны таркатырга ирек бирмәс...

Район үзәгендәге тантана берничә сәгать буена дәвам итте. Язучылар берлеге рәисе Ринат Мөхәммәдиев район мәктәпләренә ике томлык татар поэзиясе антологияләрен бүләк итте, истәлекле картина тапшырды.
Бу онытылмас очрашуны безнең төбәк халкы әле тора-тора аңлар, рухи иҗат чишмәләренең уянуына этәргеч биргән истәлекле көннәр хатирәсе күңелләрдә кабат-кабат яңарыр.

**Шәүкәт Галиев:**

## Сау бул, Балык Бистәсе!

Килер еллар-дәверләр
Куәт-кодрәт өстәсен,
Яшә, Балык Бистәсе!
Базарлы бу заманда
Бул син Барлык бистәсе,
Шигърияткә, иманга
Бул син Байлык бистәсе,
Хезмәт дигән Чулманда
шәп йөз һәрбер тармакта —
Капма, Балык Бистәсе,
Нужа дигән кармакка!
Бул базарлы,
Булма зарлы,
Бул илнең гөл бистәсе.
Сине котлап, йөрдә хуплап
Өч дистә тел бистәсе —
Сау бул, Балык Бистәсе!

Репортажда районның журналистлары
И. ИЛЬЯСОВ, Г. ХАНОВ, И. АМЕТОВ язмалары файдаланылды.

## ДӨНЬЯ ӘДӘБИЯТЫ ҮРНӘКЛӘРЕННӘН

**Төрек әдибәсе Сәвинч Чокум Истанбул шәһәрендә туган. Башлангыч белемне Бишекташ мәктәбендә, урта белемне Кызлар лисәсендә алган. Аннан соң ул Истанбул университетына укырга керә. Төрек теле һәм әдәбияты факультетында укый, әдәбият укытучысы булып эшли. Хәзерендә Сәвинч ханым киң танылган «Төркия» гәзитәсенең махсус хәбәрчесе булып эшли, иҗат итә.**

**1991 елда Сәвинч Чокум ире Рифат бәй Чокум белән беренче тапкыр Казанга килде. Татар җиренә аяк баскач та аның әйткән сүзе будыр ки:**

**— Мәрҗани белән Тукай каберләренә зиярәт кыласым килә!**

**Һәм сонра ул «Төркия» гәзитәсендә фоторәсемнәр белән Татарстан турында, Тукай, Мәрҗани һәм бүгенге сәяси мохит турында күп кенә мәкаләләр бастырды.**

**Сәвинч Чокум — күп кенә китаплар, романнар авторы. Шулар арасында Кырым татарларының ачы язмышы турындагы тарихи әсәр — «Һилял гөрүнәнчә» (Ай күренгәнчә) романы.**

**Сәвинч Чокумның хикәяләр китабы 1993 елда Төркиядә үткәрелгән әдәби ярышта беренче урынны алды. Сезгә тәкъдим ителгән бу хикәя — шул җыентыктан.**

●

**Сәвинч Чокум**

# РОЗАЛИЯ АНА

ХИКӘЯ

Мартның әче җиле битләрне камчылый, хатыннар юеш тартмалар өстенә тезем-тезем итеп салынган суган, редиска учмалары, сарымсак, пион һәм лалә чәчәкләре бәйләмнәре янында күшегеп басып торалар. Күк йөзе караңгылана башлады, автобусларга, трамвайларга төялеп кешеләр эштән кайта. Яшелчәле тартмалар яныннан узып киткән саен трамвай-автобуслар уты хәрәкәтсез басып торучы әлеге хатыннарның ап-ак йөзләрен әледән-әле яктыртып ала. Яңгыр килә дә ява. Ашыгып узган кешеләрнең нәфрәтлеме, битарафмы — аңлаешсыз, мәгънәсез карашлары чагылып китә. Кибетләрнең бушап калган витриналарына тонык, керле яктылык белән бергә әллә нинди шом кунган. Витрина каплавычларын төшерүгә әнә шул тонык яктылык, керле пыяла вә шом юкка чыгар кебек. Юеш урамнар бушап калганчыга кадәр бу халык ташкыны шулай дәвам итәр.

Салкыннан бөрешеп килгән хатыннар күшегеп беткән кулларын кая куярга белмиләр, кызарып туңган кулларын җылытыр өчен калын-тупас йоннан тегелгән бишмәтләре, кулдан бәйләнгән камзулларының кесәләренә тыкканнары да бар, бичараларның куллары һаман җылы табалмый интегә, алар ирексездән бөтен гәүдәләре белән калтырый. Кайсылары ике кулын күкрәге турысында кушырган, бәгъзеләре бармакларын тыны белән өреп җылытмакчы була.

«Болар беркайчан да хатын булмадымы икәнни соң, Тәнрем? Болар хушбуй исләрен, иннек-кершәннең ни икәнен белмиләр микәнни, йомшак-җылы ястыкларда изрәүнең, нәфислекнең, сөю-сөелүнең, мәхәббәт кайнарлыгының ни икәнен

күргәннәре юкмыни?» — дип сорыйсы, кычкырасы килә. Әмма бу хатыннарны аш пешергәндә, җылы учак янында, бала-чагалары арасында күрергә кирәк. Тавышлары диварлар арасына сыймас, ташып чыгар, бердәнбер байлыклары — алтын тешләре елтырый, колак очларындагы ясалма ташлы алкалары елык-елык килә... Кыскасы, үз гаиләләре янында аларның куллары, йөзләре, бар кыланышлары хатыннарныкына охшый башлый...

Сата торган товарларыннан ук күренеп тора: болар бай түгел... Чәчәк сабаклары өчәр-дүртәр булып бергә бәйләнгән һәм юлдан узганнардан кайберләре кызыл редискалар арасыннан ул чәчәкләрне күрмичә дә китә. Шапкалы, йон башлыклар кигән кешеләр агыла да агыла, аларның йөзләрен хәтерләп калырлык түгел... Яшелчә һәм чәчәкләр тезеп куяр өчен корылган кечкенә агач өстәлләрдәге сатасы нәрсәләр кими башлагач кына аларның эченә җылы инәр, җан керер һәм алар бер-берләре белән сөйләшә башларлар.

— Розалия түти, синең кыздан хәбәр бармы?

— Күптән түгел генә бер хат алдым... Әйбәт дип яза...

— Һай, җанкисәгем, бу кышны ничек чыгарсыз икән?

— Аһ, бер кибетчек ачарга иде шушында... Ашханә кеби бер урын...

Фәридә күрсәткән урам почмагындагы мал эч-башлары, эчәге-карын исе аңкытып торучы, тонык фонарьлар яктылыгына уранган кибетнең пыяла ишекләреннән канлы алъяпкыч бәйләгән адәмнәрнең кереп-чыгып йөргәннәре күренә иде. Әнә шул кибет урынында кечкенә генә чип-чиста бер чәбүрәк кибете калкыр, ул чәбүрәкханәнең тәрәзәләре яктылык балкытып торыр, аннан җылы пар бөркелер, тәрәзәләре боз зәңгәрлеге белән үзенә чакырып торыр берзаман.

— Бераз көт, җанкисәгем Фәридә... Өйләребез корылып бетсен инде... Менә тагын бер ел узды Кырымга кайтканыбызга. Кибет ачарга рөхсәт бирерләр, дип уйлыйсыңмы, җаным?

Розалия Ана өен исенә төшерде. Ярым-йорты житкезелгән диварлары белән тәрәзәсез, ишексез кечкенә бер өйчек шунда... Зәңгәр, кызгылт дачалар кебек булмас инде ул өй, әлбәттә. Аның өе туфрак өстендә үскән яз чәчкәләре кебек матур булачак.

— Кызыма бер йон башлык бәйли башладым әле кичләрен... Китәсе көненә житештеремен, Аллаһ боерса... Мин анда да бездәге кебек кытлыктыр, дип уйлыйм. «Энженар кызым, юлыңа берәр нәрсә төреп тыгыйммы, юкса ач калырсың анда», — дидем. Ул елмайды да әйтте: «Анда һәр нәрсә бик мул, син минем турыда борчылма», — диде. Дөрес микән? Ни эзләсәң, шуны табып була анда, ди... Хәер, дөрестер шул. Энженарым ялган сөйләмәс...

— Шулай, Розалия, шулай диләр...

Фәридәнең сүзләрен алагаем олы, пычрак каплаган трамвай тавышы каплап китте. Шул җен арбасы узганда Фәридәнең итәгенә пычрак чәчрәде.

Розалия чал учмалар катнашкан чәченнән шуышып төшкән йон шәлен рәтләп куйды да:

— Җәйгә Энженарым кайтачак, — диде. — Ул кайтуга, бәлки, мин тәрәзәләрне дә куеп өлгерермен. Бакчамның бер почмагына җиләк утыртырмын. Җиләк үстерәсем килә. Беркөнне кызым: «Әни, җиләк ашыйсым килә», — ди. Ана кеше моңар битараф калырмы? Киттем базарга... Баксам, җиләкнең килосы йөз сум... Монда кешенең бер айлык хезмәт хакы өч йөз сум... Җиләк сатучының кәрҗине янында уйга калдым шулай. Бер килосы йөз сум... Алыргамы, юкмы? Юкса, өемнең диварларын ни белән житкерермен? Өй төзү материаллары алтын бәясе тора... Аккош кебек чибәр кызыма ул җиләкне алачакмын, дим. Әмма Үзбәгестанда мул иде базарда җиләк. Чүлмәге-чүлмәге белән ала идек, ашый идек. Хәзер шундый кысан көннәр килде. Үзбәгестанга безне сөргәннәр иде. Монда безнең ватан. Ватаныбызда ач булсак та түзәрбез, дим.

— Димәк, Энженар Истанбулга укырга китте? Синең кызың булдырыр, Розалия Ана, — диде Сәкинә.

— Имтиханнарын яхшы тапшырды... Минем кызым, Аллага шөкер, әйбәт. Ике ел укыганнан соң нәрсә диярләр тагын? Тагын бер баскычка өскә күчәчәк...

— Алайса синең кыз профессор булырга ниятли...

— Шулай, — диде Розалия. — Шулай, әмма безнең бу хәсрәтләребез бетмәячәк. Кая барсак та, ул безгә ияреп йөриячәк, Сәкинә...

— Их заманалар дигән, Розалия, күз ачып йомганчы вакыт узып китәчәк. Әнә, җәйгә кайтачак дисең ич...

— Кайтыр, иншаллаһ... Хода насыйп итсә...

Заманасы Розалия өчен бигрәк тә рәхимсез булды шул. Замана артыннан куып житеп булмый инде... Яшьлеге тегендә калды. Бер поездлан кул болгый иде,

тыгыз итеп бәйләнгән яулыгы, тулы йөзе, моңсу күзләре, сагыш белән кысылган иреннәре... Поезд дыңгыр-дыңгыр итеп мамык тарлаулары буйлап бара да бара... Һәм соргылт туфраклы җирләрдә бер кара нокта гына булып кала. Кайчан гына исенә төшерсә дә, аның яшьлеге шушында югалды...

Биредә ул туфрак-балчыктан ясалган чатыр-өйләрдә яшәүче кешеләр белән, күршеләренең юеш танаулы балалары белән бергә яши. Хәзерендә хатыннарга караганда ирләр азрак монда. Чөнки күбесе Үзбәгестанга бераз акча эшләргә китеп бетте, алачык кебек өйләрен сакларга, күз-колак булып торырга хатыннарга калдырып киттеләр. Табигый ки, иң күп мәшәкать Розалия Ана җилкәсендә дигәндәй... «Апа, без Сәмәркандка китәбез. Хатыннарыбызны, балаларыбызны сиңа тапшырып калдырабыз. Каралты-курага күз-колак булып торырсың инде. Без китеп, кайбер нәрсәләребезне сатып, бераз мая тупларбыз. Өйләрнең түбәләрен ябар өчен акча кирәк. Алла сакласын, тагын милицияләр килеп өйләребезне җимермәсеннәр»,— дип гозерләде алар.

Киттеләр. Йон башлыклы, балчыкка буялган тупас итекләр кигән, кояш ашаган кызыл чырайлы бу ирләр киткәннән соң, хуҗасыз-иясез, ташландык шәһәрләр кебек бер тынлык иңде уртага... Розалия Ана өчен бер нәрсә дә үзгәрмәде кебек. Ире Мостафа монда күченеп китәр алдыннан гына вафат булды... Саргылт диварлы, житкерелеп бетмәгән өен күрә алмады, мәрхүм... Шунысы кызыклы, Розалия Ана өенең төзелеп беткәнлеген үзе күрә алачакмы, юкмы? Төннәрен йокламыйча, тигез басу өстенә тезелеп урнашкан һәм караңгылыкка күмелгән өйләр ямансы бер тынлыкта утырган вакытта алар, Сәкинә белән, бер-берсенә эчке кайгыларын сөйлиләр... Күченү, сөрелү, куылу... Үзен-үзе белә башлаганнан бирле Розалия өчен кырлар, күкләр, сулар шушы күченү белән, сөрелү белән бәйле булды. Шуңа күрә ул һәрчак тирә-ягына ятимлек, житешмәүчәнлек тойгылары белән карый иде... Бала чакта да, хәзер дә... Әмма Энҗенар, шатлык өчен яратылган кызчык, бу әче хәсрәтләрне белеп бетерми... Белсә, бөтен кеше белгән кебек үк мохтаҗлыкны татыган булыр иде. Розалия Ана кызына шул мохтаҗлыкны күрсәтергә тиеш идемени соң? Юк. Беркөнне Ана кызчыгы өчен йөз сумлык җиләк алырга акча кызганды, алмады. Бу әле һаман хәтереннән китми, эчен тырнап тора...

— Димәк, җиләк үстерәчәксең бакчаңда? Яхшы гына акча эшләрсең, бәлки, Розалия Ана? Синең эшләрең уңса, без дә җиләк утыртырбыз...

Әче җил хатыннарның соңгы сүзләрен алып китте... Сатылмый калган чәчәк бәйләмнәрен киндер капчыкларга салып, тонык яктылыгы белән юлны яктыртып килүче ярымватык иске автобусны көтеп алдылар. Рәхәтләнеп бер җылынырга өмет итеп, ашыга-агыша автобуска кереп утырдылар. Һич сөйләшмәстән, боз булып каткан сөякләрен әкрен генә үтеп керә башлаган җылы иркенә куеп, рәхәтләнеп утыралар. Бераз соңра Розалия Ана кырыс һәм катгыян тавыш белән, урысча:

— Олы юл буендагы чатырлар янында төшереп калдыр! — диде.

Розалия Ана баштагы вакытларында бу сүзләрне шоферларга ничек тарсынып кына әйткәнлеген исенә төшереп, шарфы астыннан гына көлемсерәде. Инсәләре төшенке, сары чәчле шофер көзгесенә карап, кайсы хатын миңа шулай боера, дигәндәй эзләнә башлады. Сәләмә киенгән, кыяфәтләре белән ирләргә охшаш һәм сүзсез хатыннар арасыннан шофер кем шулай каты тавыш белән боерганын аңламады.

Автобустан төшкәч тә аларны бердәнбер сыек яктылыклы фонарь каршы алды. Томан каплаган ай яктылыгында алар, сазга бата-бата, алачык кебек кечкенә өйләренә таба юнәлделәр. Тирә-якны этләр өргән тавышлар каплап китте. Розалия Ана Батыр Җан аккордеонының тавышы белән һәр ахшамны каршылый. Кич життеме, аккордеон тавышы ишетелә башлый. Вә кышкы айсыз, йолдызсыз ямансу төннәрне шушы тавыш бераз җылыта-яктырта. Ай белән йолдызлар калыккач, әлбәттә, шатлык арта. Батыр Җан машинасын капка төбенә туктатып өенә керә, очлы фитыр эшләпәсе, нечкә озын гәүдәсе аннан-моннан төшкән яктылыкта чалына. Ул кайтканда урам бала-чага тавышыннан шаулап тора, ул кайтканда караңгылык яктырып киткәндәй була. Батыр Җан күп вакыт Розалия Ана яккан учак янында җылынырга килә... Әйтерсең лә ул Розалия Ана янына килеп җылынуны үзенең бурычы саный.

— Атаңнан берәр хәбәр бармы, Батыр улым?

— Бу ай ахырында килер, дип уйлыйм инде, Розалия Ана. Бераз кирәк-ярак алып киләчәк, Сәмәркандтан, Аллаһ боерса. Өйгә тагын бер тәрәзәле бүлмә белән тагын веранда корачакбыз...

— Бик яхшы булыр иде дә... Килен белән кайтып төшсә, кайда яшәтмәкче буласыз?

Розалия Ана өйләнү хакында сүз кузгатса, Батыр урыныннан торып китә торган иде.

Розалия Ана монда учак ягуны бер йолага әйләндереп җибәрде. Әйтерсең лә бу учак азатлык ялкыны иде... Таш ташучы, өй җиткезүче адәмнәр, эш арасында аягөсте генә булса да Розалия Ана белән сөйләшәп-киңәшеп китәргә килгәннәр шушы учакта учларын җылытып, җаннарына да җылылык алып китәләр. Розалия Ана шул тирәдә азапланучы кирза итекле, йоннан бәйләнгән башлыклы ирләргә карап, минеке дә исән булса, шулай тырышыр иде, читән-киртә корган булыр иде шушы тәшкә, дип уйлый.

Ялкыны бетеп, күмере төшкәч, ул кайнар көлгә бәрәңге, сугып күмә, күрше-тирә балалары үз өлешләрен күтәп, аның янына җыела, түземсезләнеп көтәләр. Берсенең борыны юешләнгән, икенчесе ыштанына җиффәргән, кайсысы юеш балагына ябышкан балчыкны учак җылысына куйган, шулай итеп, алар көлдә пешә торган бәрәңгене көтә.

Үз ватаннарында чит-ят кешеләр икәнен һәрвакыт аңында белеп, күңелендә тоеп яши Розалия Ана, шулай да ул бала-чаганы үз янына туплап, аларны Салгыр елгасы буендагы бакчага алып китә. Андый чакларда ул һәркөн кия торган тупас тегелгән киемнәрен салып, яхшылыкка саклаган киемнәрен кия һәм кызыллыгы уңган, әнисеннән калган, рәешкә генә тота торган башлыгын киеп чыга. Сәеккән Салгыр елгасының салкын-рәхәт суы белән кулларын, битләрен юар өчен алар белән яр буена килә. Кайчандыр ярлары тулып гөлдер-гөлдер аккан бу елга, кемгәдер үпкәләгән кебек, тыныч кына сызып ята...

Батырның атасы Тимерҗан сөйләгән иде: без киткәннән соң бу җирләр әллә нишләгән... Үсемлеге, бәрәкәте калмаган бу туфракның...

Боларны искә төшергәндә аның карашы Батырларның тәрәзәсендә иде. Тәрәзәдә хәрәкәт күренми, өйдән һичбер тавыш ишетелми. Бары тик җегетнең узган ел утыртып куйган казыклары, җилдә шаулаган камыш кебек, курай тавышлары чыгара иде, әйтерсең лә алар сызланганнан шулай ыңгыраша.

— Балам Гөлшаһ! Батыр Җан кайда икән?

Фәриденең кызы:

— Белмим бит, Розалия Ана,— диде.— Берәр эше чыккандыр...

Розалия Ана аңа да күз-колак булырга тиеш түгел идеме? Әллә берәрсенә очрап, аракы эчәргә киттеме? Әнә теге зур кунакханәгә әхтәри сугарга киттеме, юкса?

— Ни булса да... Кайтыр ул, Гөлшаһ балам...

— Розалия Ана, әнә шул олы йортыгыз турында сөйлә әле, ә?

Әлеге зур кунакханә, элек Розалиянең атасы үзе корган йорт иде, исенә төшкән саен аның бәгырен талый ул хатирәләр...

— Мин биш яшемдә идем, әмма бик яхшы хәтерлим өебезне... Олы сугыш вакытында безне моннан кудылар. Менә кайттык, ләкин эченә кереп карый алганым юк әле... Хәзер анда урыслар яши... Чыбык-чабык ягып, учагы янында җылына торган идек. Хәзер абзардан аермасы юк... Безне ул кара вагонларга тыгып сөргән чакта мин биш яшемдә идем. Бер ай бардык юлда. Юлларда үлем өстенә үлем булды, Гөлшаһ балам. Үлгәннәрне, хайван үләксәсен аткан кебек, юл кырына ыргытып бардылар. Саклап калган җаныбызның кыйммәте-бәһасе шундадыр, кызым. Соңра Сәмәркандка життек. Әтине-әнине мамык басуларына эшкә кудылар. Сыенган урыныбыз кабердән артык түгел иде. Җир астына казып кергән куышларда яшәгәндә үпкәләребез, тирелэребез ябышып катты, бик күп халык кырылды бу шартларда. Тере мәетләр кебек яшәдек без җир астында. Бик озак яшәдек без шулай, бик озак вакытлардан соң гына чыктык без җир астыннан җир йөзенә, балам. Җир астында яши-яши без шулкадәр нык үзгәрдек ки, тора-бара җир йөзеннән биздек кеби, холкыбыз, рәвешебез үзгәрде-алышынды сыман. Артык җыламыйча, артык зарланмыйча яшьлегебез үтте китте. Яшь идек, чибәр идек... күнектек, хирысландык... Адәм баласы шулай инде ул менә. Аласын барыбер ала, җир йөзе нигъмәтләрен, дим... Менә шулай идек... Сөргенлек әчесен, сөрген сызлануларын бәгырьләребезнең төбенә яшереп саклыдык, кайчакларда ул әрнүләр тышка бәреп чыга торган иде, шул чакларда сыгылып егълый идек.

Фәридә, бөеренә таянган килеш, алкаларын атындыра-атындыра якынрак килде...

— Без дә көлә идек, Розалия Ана. Нигә көлмәскә-уйнамаска? Үзбәгыстан ул — гөлестан, җаным... Көлә идек без дә. Сөйдек тә, сөелдек тә.

Фәриденең берничә алтын теше кичке шәфәкъ шәүләсендә ялтырап китте, күзне чагылдырды. Розалия исә:

— Аһ, ул яшьлек,— диде.— Көлә идек, уйный идек. Һәм мамык җыя торган хатыннарга әвереллек, Фәридәкәем. Әмма көлүебез сөргән көлүе, уеныбыз сөргән кешеләренең уены иде, Фәридә җаным.Боларны сөйләгәндә Розалия Ана кулдан эшләнгән камзул, тез астыннан бөрелгән чалбар һәм тәңкәләр таккан калфагын киеп, бармакларын шартлатып, үзбәк кызлары биегәндәй итеп, бөтерелеп алды да сандыктан чыгарып, тагын көмеш путасын, матур башмакларын күрсәтте. Гөлшаһ:

— Розалия Ана, ул гүзәл башмакларыңны кайчан киярсең икән, әй,— дип сорады.

— Өем төзелеп беткәч тә, балам,— диде Розалия.— Батыр Җан аккордеонда уйнар, җырларыбызны җырлар, өзелеп-өздереп җырлар... Без «Кайтарма» биюебезне рәхәтләнеп биербез, Аллаһ боерса.

Ләкин җәйгә бетәчәкме ул өй төзелеп, әллә киләсе елгамы? Кайчан булыр ул бәйрәм... Өенең кыегына тамгалы зәңгәр байракны элеп куйса, узган гомере кире кайткандай булыр. Батыр Җан: «Үзем алып килеп ул байракны тагып куячакмын, Розалия Ана»,— дигән иде. Һай, шәп булыр иде дә... Искән җилдә җилфердәп, данлы узган тарихыбызның байрагы кешеләрнең игътибарын тартып торыр иде... Шул вакытта Розалия Ана, әйдә, уйнагыз, балаларым-җанкисәккәйләрем, мин биим, диячәк... Һәм яшьлек көннәрен искә төшерер, әлбәттә. Хәзерендә җылы күрмәгән кулларын учак ягып ялкынында җылытарак, коры тамырларындагы кан җылынып, тулып-ташып ага башласа, сирәк һәм дымлы керфекләре арасыннан ялкынга карап, кичергән әче көннәрнең хатирәләренә чумар...

— Розалия, Розалия... Сиңа кем кушкан бу исемне? — Беркөнне Батыр Җан кинәттән шулай сорады.

— Анам Разия исемен кушарга теләгән. Әбиемнең исеме Разия булган, имеш. Ләкин документ тутыручы урыс Розалия дип язып куйган. Янәсе, Разиягә караганда Розалия матуррак исем... Атам-анамның колакларына да хуш килмеш, ахрысы, мин Розалия булып киткәнмен.

Батыр Җан:

— Сиңа «Гөлчәчәк» дисәк булмасмы, Розалия Ана? — дип сорады.

Розалиянең озынча ак йөзе тал бөресе кебек алсуланып китте:

— Була, әлбәттә, Батыр Җан,— диде. — Була... Ләкин мин үземне белә белгәннән бирле Розалия булдым... Һәм Гөлчәчәк исеме миңа нигә инде?

Батыр Җанның машинасы балчыклы пычрак юлда бер сикереп, бер бәрелеп кайтып килә, машина йөртүенә караганда, ул ниндидер бер хәвефле хәбәр алып кайта булыр кебек. «Батыр нигә болай ашыга?» — дип аптырады кешеләр... Машина туктар-туктамастан, ишектән Батыр Җан атылып чыкты. Чыкты да:

— Розалия Ана, милицияләр безнең авылны җимерергә килә! — дип кычкырды.

Розалия Ана ишексез, түбәсез, дүрт диварлы өйчеге янына атылып килде... Аның йөрәге кысылды, аркасы тирләп чыкты. Чатыр өйләрнең өстендәге тыныч кичәнең ачык зәңгәр күгенә бакты... Тигез басуга урнашкан авылчыкның каралты-кураларына карап торды... Ярсыган ана бүре кебек еш-еш сулап, ул үз өен әйләнеп чыкты... Батыр Җанның болай да ябык гәүдәсенең җаны юк кебек күренә, аның тере иңкәнлеген бары тик суырганда уты күренгән тәмәкесеннән генә белеп була иде.

— Ярый, Батыр Җан, Ходай ярдәмчебез булсын. Килсеннәр әйдә... Килсеннәр, җаным, күрәселәрен күрсеннәр. Хәзер әнә теге бензин бакларын монда китер...

Батырның күзләре ялкынланды. Розалия Ана аның каршысында төп-төз чыршы кебек басып тора иде.

— Розалия Ана,— диде Батыр Җан, аның тавышы усак яфрагыдай калтырый иде...— Әллә син үз-үзеңне яндырмак... яндырмак буласыңмы?

— Алда гомере булган бу адәмнең шашкынлыгына карагыз әле сез! Яшь шул әле син. Розалия атлы хатын яшәгәне хәтле тагын яшәмәячәк ки... Шушы кадерле өйләребез, йортыбыз Кырым өчен бераүсенең үзен фида иткәне яхшы булырмы, әллә начар булырмы? Ә? Шырпыңны бир, Батыр Җан... Яңа туган бозау шикелле бакма миңа... Шырпыңны бир, дидем. Җә!

Яшь егет камзул кесәсеннән шырпы кабын алды, ул шырпы кабы әйтерсең лә бер граната кебек иде, бу шырпы кабы аның уч төбен яндыра иде.

— Тизрәк бир шырпыңны, Батыр Җан!

Батыр бу катгый тавышка каршы килә алмады, шырпы кабын Розалия Анага сузды да:

— Розалия Ана янсак, бергә яначакбыз,— диде.— Көлебез шушында булыр, янган көлебезне җил, орлыкларны чәчкән кеби, шушы җиргә тарихи ватаныбыз туфрагына сипсен. Шул көлләр өстенә туганнарыбыз яңадан өй корыр...

Бу сүзләр Розалия Ананың бәгырендәге әче хәсрәтне кузгатты. Чөнки Розалия Анадан үрнәк алып, барысы да үзләрен яндырырга карар кылганнары күренеп тора иде.

— Фәридә, Сәкинә, Гали, сез ни әйтерсез? Бензин канистраларын монда ташып куегыз... Тиз булыгыз! Өсләренә Аюдаг аусын, Иләһем... Килсеннәр... Курыкмагыз, карагыз аны, коелып төшмәгез... Килсеннәр... Җанкисәкләрем. Розалия Ананы алар кол итә алыр микән?

Барысы да караңгы юллар өстенә карап, ни булачагын белмичә, шомлы рәвештә көтә башладылар. Бераздан даланың караңгы тынлыгы калтырана башлады, шомлы тынлыкны мотор тавышлары ярды... Машиналарның бер яныл, бер сүнеп килүче фаралары, сирена улаган тавышлар якынайганнан-якыная иде, кочаман олы мамонтлар кеби бульдозерлар кечкенә генә алачык өйләргә таба ыргылдылар. Бөтен караңгы дала бу куркыныч яудан куркып калтырый, тетрәнә башлады...

Иң алда килә торган машинадан милиционерлар сикерешеп төштеләр дә урысча:

— Өегездән аласы әйберләрегезне алыгыз! — дип кычкырдылар.

Татарлар таш дивар кеби өйләре алдына баскан. Розалия бер адым алга чыкты:

— Сез иң башта кырык дүртенче елда бездән талап алган яхшы йортларыбызны кире кайтарыгыз яки хәзер үк моннан китеп олагыгыз! — дип кычкырды Розалия Ана. — Юкса, менә шушы канистрдагы бензинны өстемә сибеп, үзем яндырачакмын...

Анын артыннан Батырның, Фәридәнең, Сәкинәнең тавышлары яңгырады:

— Әйе, без дә үзебезгә бензин сибеп ут төртәчәкбез... Өйләребезгә якын килеп карагыз, күрерсез...

Йорт җимерергә килгәннәр бу сүзләрнең шаярып кына әйтелмәгәнлеген аңлап алды булса кирәк... Алар тагын боерыкларын кычкырды... Розалия Ана учындагы шырпыларны кыштырдап сөйләшкәннәрен ишетте кебек. Алар, сыз безне, як безне, яндыр үзеңне, тиз бул, диләр кебек иде.

Сызгырган тавыш чыгарып искән әче җил туфрак астындагы хан бабаларыбызның, аталарыбызның, аналарыбызның, вафат булган иренең сөякләре чыгарган авазларын алып килә кебек. Әйтерсең лә тау-ташларың аңа дәшәләр иде: курыкма... без сине ишетеп-күреп торабыз, синең бабаң, атаң, ИРЕҢ анаң... синең ташларың бу, синең туфрагың бу, синең агачларың монда, җир-су — барысы да синеке, курыкма...

Шушы мизгел бер гасыр кебек тоелды, карар мизгеле. Бераздан дала өстен моторлар гөрелтесе каплады. Шул ук мизгелдә йөрәкләр сөенеч белән тулды кебек. Китәләр... Киттеләр... Аларны караңгылык йотты... Күк йөзендә бер йолдыз калыкты.

Кешеләр дә таралышты, ләкин Батыр Җан гына урыныннан кузгалмады, ул ни әйтергә, нишләргә белмәгәндәй басып тора иде.

— Әйдә, Батыр Җан, ашыңны аша... Алар кабат килмәсләрдер... Бу төн мин йокламыйча сакта торачакмын, бар, син кит инде...

Батыр, Розалия Анага якынрак килеп, сүзсез генә аңа карап, ананың жегетлегенә -батырлыгына сокланып торды да, чак ишетелерлек итеп:

— Рәхмәт... — диде.

Ул иелә төшеп Розалия Ананың кул аркасын үпте. Күктәге йолдызның шәүләсеме анық битенә төште, бераз читтәрәк елык-елык янып яткан учакның ялкынынданмы алды ул кызыллыкны, Батырның чырае да кызгылт иде. Батыр Розалия Анага элеккесенә караганда да олырак соклану вә мәхәббәт илә бакты. Әйтерсең лә яшь-тәҗрибәсез Батыр Җан юкка чыкты, анық урынында эченә борчу төшкән, дөнья күргән ир басып тора иде.

Розалия Ана:

— Улым, җаным, — дип әйтмәкче иде, ни гаҗәп, әйтә алмады... Батыр да аңа, Розалия Ана, димәде. Соңра Батыр әкрен генә үз өенә таба атлады. Тиздән Батыр өенең кечкенә тәрәзәсендә тонык яктылык күренде... Байтак вакыттан соң тәрәзәдәге ут сүнде... Төне буе ул тәрәзәдән аккордеон тавышы ишетелеп торды. Розалия Ананың күңелен ачар өченме, аңа көч-куәт бирер өченме, Батыр Җан моңлы-хәсрәтле көйләр уйнады, гүя ки ул Розалия Анага нидер аңлатырга тырыша кебек иде... Розалия Ана, озын-озак юллар йөреп алҗыган ана бүре кебек, өйләр арасында арлы-бирле йөренде һәм байтак вакыт узгач кына Сәкинә өенә керде. Төне буе кар эчендә йөреп арыгангамы, әллә тилертер дәрәҗәдәге хуш исле чәчәкләрме аңа йокы бирми, йокыга киттем дигәндә генә уянып ята

торгач, ул Батырның үзенә сокланып карап торган күзләрен күрде һәм талгын гына йокыга китте.

Иртәгесе көн иртүк торып, редис белән суган сатарга, шәһәргә китәр алдыннан Сәкинәнең диварга асылган ватык көзгесенә бакты һәм көзгедә чибәрләнеп киткән яшь бер чырай күреп аптырап калды. Көзгедән аның Сәмәркандта калган яшьлеге карап тора иде. Хыялындагы яшьлек идеме бу? Соңра ул үзендәге бу үзгәрешнең сәбәбен ачыкларга тырышты. Ни булды бу? Ни булды миңа? Хыял куәтенең чагылышымы бу? Нәрсә бу? — дип ул таулардан сорады. Миңа ни булды? — дип агачлардан сорады ул. Ләкин ул ни булганын аңламады... Даланың баткак юлында иртән иртүк чыгып киткән Батыр машинасының тәгәрмәч эзләреннән башка һич нәрсә юк кебек...

Ә Батыр Җанга ни булды соң? Шул көннән соң Батыр үзе утырткан бagana-лар-терәкләре белән дә кызыксынмый башлады, Розалия Ана яккан учак янына җылынырга да килми торган булып китте, йөзеннән элеккеге елмаю да качты кебек, ул инде хәзер кешеләр күзенә бик сирәк күренә... Хыял куәтенең көзгедәге чагылышымы бу, ә?... Әлбәттә, әлбәттә, Батыр Җан элеккеге шаталак Батыр Җан түгел инде, ул хәзер шашкын бер тәҗрибәсез җегет иде.Хыялларга уранган яшь Розалия ястыгында йоклый алмыйча яткан җиреннән кинәт кенә янәдән Розалия Анага әверелде. Сәмәркандта калган яшьлегенең исерткеч җилләре исүдән туктады, хыял гөлләренең чәчәкләре коелды да бетте... Хыял көзгесендәге зур күзле назик хыял юкка чыкты. Аның урынына кирза итекләр, сырган куфайка кигән Розалия Ана торып калды.

Беркөнне Сәмәркандтан Батырның атасы Тимер белән анасы Шәфика кайтып төштеләр. Алар юлда йөреп арган, әмма йөзләре мөлаем елмая. Розалия Ана алар шәрәфенә катыклы күмәч-чүрәк пешерде, балалар сөенечләреннән дала буйлап чаба-чаба чүрәк пешкәнне көтте.

Тимерҗан:

— Без бераз гына төзү кирәк-яраклары алып кайттык... Өйнең теге бүлмәсен җиткезеп бетерәсе иде бит,— диде.— Җә, сөйләгегз әле, без киткәннән соң монданиләр булды, ә? Милицияләр килгән икән, шулаймы, Розалия? Син аларга каршы чыккансың икән... Үзенне үзең яндырмакчы булгансың икән, диләр...

— Шулай кирәк иде...— диде Розалия Ана.

Ул кичне Батырлар гаиләсе Сәкинә йортында кунак булды... Батыр да шунда иде. Аның култык астында ниндидер бер букча бар иде... Соңра ул букчаны Розалиягә сузды. Ул элеккеге Батыр иде. Анасы, атасы янында ул кыюланып, Розалия белән гадәттәге кебек сөйләшеп утырды. Букчаны биргәч, әйтеп куйды:

— Сүз биргән идем, менә алып килдем,— диде.

Розалия ике-өч мизгел эчендә букчаны ачты. Анда тамгалы зәңгәр байрак иде... Розалиянең йөрәгә тоткан кебек булды, күңелендәге мәңге эремәс кебек тоелган бозлары эри башлады сыман.

— Һай, йөз яшә, Батыр Җан... Моны өемә кадап куячакмын... Шунда җилфердәп торсын!

— Шулай булсын! — диде Батыр.

Иртәгесен Батыр, корык-колга тоткан бер төркем сабыйлар ияртеп, Розалия өе янына килде... Балалар алып килгән колгага байракны бәйләп, өйнең бер янына беркетеп куйды. Байрак күк йөзенең зәңгәрләге белән кочаклашкандай булды. Даланы сарган бала-чага арасында, чыр-чу килгән сабыйлар тирәсендә Батыр, мөстәкыйльлек игълан иткәнлегенә мәгъруp кыяфәттә, арлы-бирле йөренә иде... Соңра шушы байрак янында чатыр өйдә яшәүчеләрнең фоторәсемгә төшүләре бер матур йолага әйләнеп китте.

Бераз вакыт узганнан соң Батырның атасы Тимерҗан Розалия янына килде, Розалия базарга китәр өчен кәрҗиннәрен рәтләп маташа иде.

— Хәерле иртәләр, Розалия...

— Хәерле булсын, Тимерҗан...

— Ай-һай-һай, кәрҗин-кәрҗин редислар, лаләләр, суганнар — күз явыңны алыр, валлаһи...

Тимерҗан нидер әйтергә теләсә дә, тортелеп калды шикелле.

— Миңа бер-бер әйтер сүзең бармы, Тимерҗан?

— Ие шул, Розалия... сөйләшәсе сүзем бар иде...

Ул күлмәк кесәсеннән тәмәке алып кабызды...

— Безнең Батыр турында сөйләшмәкче булам, Розалия...

Розалиянең күңелендәге мәңге эремәс бозлары кыймылдап куйды кебек... Ул кәрҗиненә иеләрәк әйтте:

— Ни булган Батырга?

— Берни дә булмаган... Ләкин вакыт житте дим, аны өйләндерергә кирәк, димәкче булам инде...

Розалия ак-сары лаләләрен матур гына чигелгән бәз белән каплап куйды. Тураеп басты да:

— Әлбәттә, Тимержан, вакыты бик житкән! — диде.

— Безнең теге Ризаның кызын алырга дигән идек тә. Базар көнне насыйп булса, яучыларга бармакчы идек тә өйләренә. Батырның анасы бик кыюсыз хатын бит, авызы бар, теле юк дигәндәй... Безнең белән кыз сорарга бармассынмы дим?

Риза дигәннәре шәһәргә якын бакчалы бер өйдә яши иде... Ул — Кырымга иң беренче булып кайтканнардан... Урыслардан сатып алган иске өйне жимереп, аның урынына яңа өй салып куйган... Чөнки урыслар ул өйнең бакчасында еллар буена дуңгыз асраган икән. Ул өйгә дуңгыз исе сеңгән дип, Риза дуңгыз исен кырып-себереп түкте. Шул Ризаның кызы үсеп, буйга житкән ләбаса...

— Шәфика белән уйлаштык та шул кызны сайлаган идек. Батырга да бу турыда әйттек... Каршы килмәде.

— Батыр Жан кызны күргәнме соң?

— Әлбәттә, Розалия Ана, күрмәгән-белмәгән килеш булырмы?

— Машалла, Тимержан... Бергә барырбыз... Минем белән баруны хуп күргәнсез икән...

Базар көнне Розалия яхшы көннәр өчен дип саклаган ачык кызыл төстәге башлыгын вә мантосын киеп, Сәкинәнең ватык көзгесенә карады, бу көзгегә ничә айлар инде ул бакмады, кызыл башлыгы аның аксыл йөзен тагын да ачкан иде... Маңгаена төшкән чаларган бер учмасы һәм ачык капкадан кергән жил уйнаткан, чытлык кыз толымнары кебек чәчләре асылынып төшкән... Розалия теләгенә каршы пәйда булган толымнарны тиз генә башлыгы астына яшерде. Тышта Тимержанның хатыны Шәфика тавышы ишетелде:

— Розалия, Розалия күрше, син әзерме соң?

Соңра Батырның учак ялкыны янындагы кебек йомшак тавышы аңа кушылды:

— Розалия Ана, Розалия Ана...

Розалиянең йөрәге кайнар ана хисләре белән тулды. Ул чыраен көзгедән каерып алгандай аерды. Зур гына сумкасын кулына тотты. Калын кунычлы кара туфлиләрен киде.

Розалия Ана ашыга-ашыга өеннән чыкты. Баеп баручы кояш нурлары дала өстенә төшкән иде. Розалия Ананы шул нурлар чолгап алды.

**Төрекчәдән**
**Рабит БАТУЛЛА**
**тәржемә итте.**



**Булат СОЛТАНБӘК (1928) — тарих фәннәре кандидаты, халык мәгарифе кадрлары квалификациясен күтәрү Институтының мәдәният тарихы һәм теориясе кафедрасы мөдире. Ул халык мәгарифе тарихы, милли дәүләт төзелеше проблемалары буенча йөздән артык хезмәтен бастырды. Аның егерменче гасыр политологларының иң күренеклеләреннән берсе Мирсәет Солтангалиев турындагы «Генсекның беренче корбаны» («Первая жертва генсека») исемле китабын киң катлау укучылар югары бәяләде. Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре Булат Солтанбәк «Казан утлары», «Татарстан», «Казан» журналларында, «Республика Татарстан» газетасында шәхес культы чоры фаҗигаләрен ишле фактик материалга нигезләнеп ача торган мәкаләләрен, зыялыларыбыз турындагы очеркларын еш бастыра, моңарчы сер булып сакланган архив мәгълүматларын укучыларга җиткерүдә зур эш башкара.**

**Галимнең «Казан» журналы китапханәсе сериясендә чыккан «Бик тә яшерен» грифы белән» («С грифом «Совершенно секретно») исемле китабы шулай ук архив серләренә нигезләнеп язылган. Анда укучы Татарстан тарихының драматик сәхифәләре белән таныша. Күптән түгел Татарстан Республикасы тарихчы-архивчылары җәмгыяте оешты. Һәм Булат Солтанбәк шул җәмгыять идарәсе рәисе итеп сайланды.**

●

## Булат Солтанбәк

# КАНЛЫ ЭЗЛӘР

**1936** елның 21 ноябрендә ГУГБның яшерен-сәяси бүлеге (СПО) начальнигы икенче ранг дәүләт куркынычсызлыгы комиссары Г. Молчанов өстәленә әле генә кертеп салынган бер язуны дәртсенеп-кызыксынып кулына алды. Аны шул ук идарәнең Дүртенче бүлекчәсе начальнигы өлкән лейтенант М. Листенгурт язган иде. Хәер, бу иҗат җимешендә комиссарның үз өлеше дә зурдан. Чөнки моңарчы ул «Новаторлар» («Новаторы») операциясе турында өлкән лейтенант белән ике тапкыр җентекле әңгәмә корган иде инде. Ә әлеге операциянең барышында төрки халыклар зыялылары арасындагы «дошман разведкасы тамырларын һәм террор группалары»н юк итү максат итеп куелган.

Алга таба очраячак кайбер атамаларга һәм аермалыкларга аңлатма биреп тормас өчен, хикәяләүнең башында ук шул вакыттагы Лубянканың — озак елларга законсызлык һәм репрессияләр

гыйбрәте булып әверелгән Лубянканың үзендәге хәлләр турында берничә сүз әйтик.

... 1936 ел. НКВД системасы һәм аның үзәге — Дәүләт куркынычсызлыгы Дәүләт идарәсе (ГУГБ), илнең көч структуралары арасында инде урынынннан алынган Г. Ягода тырышлыгы белән, аерым хокукларга ия ителгән була. Бер нәрсәне искәртү дә житәдер — ГУГБда дәрәҗә һәм шуңа карап түләү хакы ике-өч баскычка югарырак менгерелә; алда телгә алынган өлкән лейтенант, мәсәлән, подполковник дәрәҗәсенә, ә майор комбригка, ягъни генералга тиңләнә. Ягода үзе исә Дәүләт куркынычсызлыгының Генераль комиссары итеп йөртелә. Купшы киеме формасын ул үзе сызып бирә һәм бу форма килеше белән маршаллар мундирын да «бәреп ега». Әлеге дәрәҗәнең тәкъдиренә котылгысыз хәтәрлек тә язылган икән — Ягодадан соң Генераль комиссар дәрәҗәсен йөрткән Н. Ежовның һәм Л. Берияның дә тормышы Ягоданыкы кебек тәмамлануы һәркемгә мәгълүм.

Кировны үтергәннән соң, репрессияләр тизләтелүгә һәм партиядән чыгарылып кулга алынучылар саны бик ишәюгә карамастан, бу темплар Сталинны канәгатьләндермәгән, күрәсең. Аннары Ягоданың югары сәяси даирәдән җәбергә эләккән кайберәүләр белән туганлык (аның хатыны — Свердловның туганы) һәм дуслык бәйләнешләре була һәм аңардан, ул аларның беришен коткарып калырга тели, дип шикләнәләр. Һәм Сталин белән Жданов Политбюрога Сочидан җибәргән, НКВД һәм аның башлыгы халык дошманнарын фаш итүдә дүрт елга соңладылар, дигән мәгълүм телеграмма репрессияләрне көчәйтүдә этәргеч ясый. Шул телеграммадан соң, Ягоданы эшеннән алалар һәм ялга җибәрәләр. Ә җәбергә эләгүче нарком уйлаган операцияләр тагын да казганыбрак дәвам итә — җәза машинасы кызуланып әйләнә бирә. Дөрес, ГУГБның бөтен житәкчелеге һәм коллегия әгъзалары сәяси офыкта ел дәвамында бер-бер артлы күренми башлыйлар, аларны аталар. Ягода үзе исә 1938 елның мартында Бухарин һәм Рыков процессында төп гаепләнүчеләрнең берсе урынында утыра, ягъни бу процесста дәрәҗәсе буенча өченче кеше була. НКВД житәкчеләренең иң ышанычлы кешеләреннән берсе, Зиновьевны кулга алучы Г. Молчанов моңа чаклы ук атыла. М. А. Листенгуртны, «Новаторлар» операциясе өчен, ГУГБның контрразведка начальнигы урынбасары итеп күтәрәләр. Ул 1937 елда Лубянкада чираттагы «сүтеп җыю» вакытында репрессияләнә.

Әмма 1936 елның ноябрендә — яңа нарком Николай Ежов үзенә варис булып калган ГУГБ аппаратын дикъкать белән өйрәнә башлаган вакытка кайтыйк әле. (Шунысын да әйтик, Ежовның партия эшендәге элекке дәрәҗәләре барысы да диярлек сакланып кала.) Лубянкада, дәрәҗә-урын һәм кешеләр язмышын хәл итүчеләр рәтендә булу өчен, гади күзгә күренми торган рәхимсез көрәш бара. Бу көрәштә җиңү — үз тормышыңны саклап калу, дигән сүз, шуңа күрә дә үтә аяусыз ул. Һәм шуңа күрә дә 1936 елның көзендә оператив активлык бик нык көчәя. Яңа нарком «чебен күзәдәй» хатаңны да хәзерендә үк күреп ала...

Әйе, Листенгурт Молчановка нәрсә турында язган соң? Менә бу язманың кыскача эчтәлеге. 1936 елның август-сентябрь айларында Татарстан НКВДсының яшерен-сәяси бүлеге, «Новаторлар» операциясе кысасында, әдәбият-нәшрият һәм редакция хезмәткәрләре арасындагы «зур контрреволюцион оешма»ны юк итә. Ә бу оешма тамырларын күптән инде тирәнгә җибәргән булган икән. Сәлах Атнагулов, Исхак Рәхмәтуллин, Фатыйх Сәйфи-Казанлы, Зәки Гыймранов, 1933 елда ук атылган Баимбетов һәм Әминев контрреволюцион оешмада катнашучы баш кешеләр итеп атала. Ләкин язма авторы, бу эш «басымсыз бара», дип басым ясый һәм урындагы функционерлар өчен куркыныч нәтиҗә чыгара: «беркетмәләр буенча фикер йөрткәндә, алар халык дошманнары кубызына биләр». Аннары Листенгурт тикшерүчеләрнең «либераллыгы»н дәлилләүче мисаллар китерә. Атнагулов, мәсәлән, «дошманнар өерендәгеләрнең бергә җыелулары» (боларга дусларча очрашуларны һәм бер табын артында утыруларны да кертәләр, әлбәттә) хакында сөйли, ләкин мондый очрашуларның эчтәлеген ачып бирми. Тикшерүчеләр гаепләнүчеләрнең гаепләрен тануларын зур җинаятьләрне тагын да ачу өчен файдаланмыйлар. Тикшерүче, аерым алганда, Атнагуловның үз вакытында Зиновьевның милли мәсьәлә буенча тезисларын тәрҗемә итүе турындагы сүзләренә әһәмият бирмәгән. Гыймранов гаебен тәгаен танудан качарга тырыша, ә тикшерүчеләр исә «басым ясамыйлар һәм оператив кискенлек» кылмыйлар. (Игътибар иткәнсездер, чекистлар ул чакта кулланган «басым ясамыйлар

һәм оператив кискенлек» кылмыйлар диган сүзләр «аз кыйныйлар» мәгънәсен аңлата.) Тагын язмада гаепләнүчеләрнең контрреволюцион китаплары һәм башка басмалары конфискацияләнмәве, гаепләнүчеләр даирәсенең тар булуы, өстәмә кулга алулар булмавы, ә шаһитларның җаваптан качарга тырышулары халык дошманнарына тикшерүчеләрне алдарга ярдәм итүе турында әйтелә. Бер уңайдан яшерен агент «Романов»ның — Атнагуловка якын булган кешедер, күрәсең — язмышы хәл ителә. Аны гаепләү менә болай яңгырый: мәгълүматны аз бирә, нигездә инде һәркемгә билгеле хәлләрне генә әйтә һәм бу «икейөзле» бәндәне кулга алырга һәм нык тап торып җавап тотрыга кирәк. Сексот тиздән гаепләнүчеләр язмышына төшә. Ләкин аның тәкъдире бу яман корпорациянең башка вәкилләренә сабак була. Чаксаң — үзәккә үтәрлек итеп чак, йомшак сыйпап кына, әштер-өштер генә маташма ягъни. Хуҗаларның сексотлар белән яшерен урыннарда уздырган инструктажларында шуңа басым ясалган булса кирәк.

НКВДның Татарстан буенча идарәсе начальнигы өченче ранг дәүләт куркынычсызлыгы комиссары Петр Рудь исеменә менә шундый язу килә. Ул кеше бу постта ГБ өлкән майоры Гаринны күптән түгел генә алыштырган була, ә Гаринны Мәскәүгә күчерәләр һәм озакламыйча кулга алалар.

Молчанов язмасына өстәмә хатта, эшкә җавапсыз карау аркасында, «Новаторлар» операциясенең Казан өлеше өзелү куркынычы астында икәнлеге әйтелә һәм Рудька, тикшерү барышын үз күзәтүендә тотып, аны тизләтергә, фаш итүче тану мәгълүматлары алырга һәм сүлпәнлек күрсәткән тикшерүчеләргә җәза бирергә кушыла.

Лубянка кабинетларыннан «Новаторлар» операциясе менә шулай күзаллана.

«Новаторлар» операциясенең төп «фигурант»лары һәм аларның «контрреволюцион оешма җитәкчеләре» сыйфатында алдан ук сайлап алынуына шул кешеләрнең биографиясендәге нинди вакыйгалар сәбәп булуы белән танышыйк. Бу «дүртлек»тә, әлбәттә, Исхак Рәхмәтуллин һәм Сәлах Атнагулов — иң зур сәяси шәхесләр. Алар электә милли хәрәкәтнең күренекле шәхесләре саналганнар, партия-дәүләт структураларында мөһим урыннарны биләгәннәр, дәүләт төзелешенең күп кенә хәлиткеч вакыйгаларында катнашканнар, аларны Ленин һәм Сталин шәхси аралашып белгән. Рәхмәтуллинның да, Атнагуловның да татар-башкорт проблемаларына турыдан катнашы бар. (1919 елда Сталин, ачуы кубып, бу проблемаларны «каһәр суккан татар-башкорт төене» дип атый һәм аннары бу «төен»не үзе белгән иң каты чаралар кулланып «чишә». Моның хакында алга таба берничә тапкыр телгә алыначак Зәки Вәлиди картаймыш көннәрендә шактый тәфсилләп хатеренә төшерә).

Һәм әлеге шәхесләр турында аерым-аерым сөйлик.

*Исхак Шиһабетдин улы Рәхмәтуллин. Татарстанның* Тау ягында мулла гаиләсендә туган. Әтисе эзлексез карашлы кеше була, тарихны әйбәт белә, язганнары татарча басмаларда даими басыла, бай китапханәсенә дөньяви әсәрләр дә җыя. Кызганыч ки, күп кенә талантияләрен кабергә керткән «чир белән авырый» һәм шуннан вафат та була. Аек чагында ул бик төпле акыл белән эш итә, аның янына хәтта Казаннан киңәшкә килеп йөриләр. Ике туган Исмәгыйл һәм Исхак Рәхмәтуллиннар белем алуга яшьләй тырышып керешәләр, тиздән аларның сәяси сәләтләре дә ачылып китә. Исмәгыйл башта искиткеч яхшы карьера ясый, 1917-1919 елларда зур урыннарда эшли һәм, татарлардан беренче итеп, ВЧКга җитәкче эшкә җибәрелә. Ләкин власть сынавын уза алмый һәм алтын коткысына бирелә. Эшеннән алына, хөкем ителә, һәм шуннан соңгы язмышы билгесез.

Исхак тагын да югарырак сәяси карьерага ирешә. 1917 елдан башлап, ул Казандагы сәяси вакыйгалар үзәгендә кайный. Большевиклар яклы беренче татар газетасына мөхәррирлек итә, ул Мулланур Вахитовның зур ихтирамын казана. Кыска гына вакыт булса да, 1918 елның җәендә Казанда оешкан мөселман коммунистлары партиясе җитәкчеләреннән була. Шәрык коммунистларының 1918 һәм 1919 елларда Мәскәүдә узган ике съездында делегат булып катнаша. Шул съездларда сайланган Үзәк Комитетлар составына керә. Сталин бу създларны, берничә елдан соң, гади генә итеп, киңәшмәләр, дип атый. Гражданнар сугышында җиңү яулангач, төрле милләтләр мәнфәгатьләрен кайгыртучылар белән тәкәллефсез кылансаң да ярый ягъни. Делегатлар алдында Ленин чыгышлар ясый, Сталин үзе дә кайбер утырышларда катнаша һәм чыгышлар ясый, «староста» Калинин Шәрыктә революция ялкынын дөрләтергә тиешле мөселман коммунистик партиясен тууыоешуы белән котлый. Сталин һәм Үзәк Комитетның кадрлар буенча секретаре

Крестинский акыллы һәм сабыр холыклы татар кешесенә шул чакта ук игътибар юнәлткән булалар, күрәсең. 1919 елның җәендә Совет Башкортостанын төзү башланганнан һәм иң авторитетлы милли эшлекле Зәки Вәлиди аның лидеры булганнан соң, ревком составына, аннары житәкче партия-дәүләт структураларына берничә татар кешесе эшкә җибәрелә. Аларга башкортларга бирелгән вәгъдәләрне житдигә санап кабул итүче һәм максималь мөстәкыйльлеккә омтылучы көчләрне сулпәнәйтү бурычы йөкләнә. Ләкин бу кешеләр үзәк теләген-ышанычын акламыйлар. 1920 елның маенда Мәскәү 1919 елда вәгъдә ителгән минималь автономия хокукларын да кыскач, алар, Башкортостан башлыгы белән бергә, дәүләт һәм партия постларын ташлыйлар. Протест белдерүчеләр арасында республика газетасы мөхәррире һәм өлкә комитеты бюросы әгъзасы Исхак Рәхмәтуллин да була.

Рәхмәтуллин кулга алына, сорау алулар Мәскәүдә оештырыла.

Контрреволюцион нияте исбат ителмәгәч, ул Сталинның шәхси күрсәтмәсе буенча азат ителә. Ләкин партия сафларына торгызу үтенечен кире кагалар. Хәер, юлбашчы:

— Эшләгез әле, аннары партиягә яңадан керерсез. Минем фикеремне сорасалар, мин каршы төшмәм,— ди.

Исхак, шундый үгет-нәсихәткә ышанып, Казанга кайта, бөтен тырышлыгын фәнни эшкә һәм журналистлык хезмәтенә бирергә ниятләнә. Һәм баштагы чорда ул моңа ирешә. Берничә ел комуниверситетның директор урынбасары булу һәм иҗтимагый фәннәр укыту аңа профессиональ белгеч дәрәҗәсенә күтәрелергә ярдәм итә. «Хуҗа» үз сүзен тоткандыр, күрәсең, Рәхмәтуллин 1925 елда партиягә алына. Егерменче еллар ахырында аның карьерасында яңа күтәрелеш башлана — мәгариф халык комиссары, ВКП(б) өлкә комитетының бүлек мөдире. Җөмһүриятнең идеология тормышына зур йогынты ясый торган урыннар болар. Исхак вакытлы матбугатта да еш катнаша...

Җәмәгатьчелек, Исхак Рәхмәтуллинны сәяси «терелтү» өлкә комитетының яңа секретаре Разумов белән бәйле, дигән фикер йөртә. М. Разумов моңарчы Башкортостанда шундый ук пост били. Ул килгәч, Татарстанның партия-сәяси структураларындагы югарырак урыннарга аңа хезмәте буенча электән таныш күп кенә кешеләр утыра. Әмма утызынчы еллар башында ук Рәхмәтуллин органнарның төбәлеп күзәтүен кабат сизә башлый. Өлкә комитеты секретаре булып Разумов эшләгәндә, хәл ярыйсы була әле. (Алар үзара дус була һәм гаиләләре якыннан аралашып яши.) Секретарьны Казаннан күчергәч, бәйләнүләр һәм гаеп ташлаулар тагын башлана. «Башкортлык» заманын да искә төшерәләр. Кулга алыныр еллар алдыннан ул редакцияләрдә һәм нәшрияттә кечкенә урыннарда эшли... 1936 елның 18 сентябрендә кулга алына. Моңа чаклы партиядән чыгарыла...

*Сәлах Атнагулов.* Башкорт. 1893 елда туган. Уфадагы «Галия» мәдрәсәсен тәмамлый. Бу мәдрәсә, Казандагы «Мөхәммәдия» һәм Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәләре белән беррәттән, шул заманның алдынгы уку йорты санала, анда белем бирү төгәл һәм нигездә дөньяви укыту планы буенча алып барыла. Бу өч мәдрәсә асылда хөр фикерле кешеләр тәрбияләп чыгара, аларның күбесе революцион хәрәкәттә катнашалар.

1917-1918 елларда Атнагулов, Рәхмәтуллин кебек, сәяси көрәшнең алгы сафына баса. Вәлиди һәм Манатов белән бергә, гомуммөселман дөньясында үз халкының милли хәрәкәте эреп югалуга каршы торучы күренекле башкорт лидерларыннан берсе санала. 1917 елгы мөселманнарның мәгълүм съездларында катнаша. Шул ук елның җәендә башкорт «Шура»сы рәисе итеп сайлана. Аннары татар һәм башкорт халыкларының акыл ияләрен туплаган «Милли мәҗлес»тә эшли. «Идел-Урал» җөмһүриятен төзү комиссиясе составында Уфадан Казанга килә. Сәясәттә ул эсерларга теләктәшлек итә, ләкин Г. Исхакый һәм Ф. Туктаров карашлары белән килешми, сул эсерлар позициясенә — аның вәкиле Галимҗан Ибраһимов позициясенә якынрак тора. «Идел-Урал» җөмһүриятен Россия Федерациясенең үзидарәле (автономияле) өлеше итеп игълан итү нияте тормышка ашмагач, Атнагулов Башкортостанга кайта һәм З. Вәлиди белән хезмәттәшлек итә. Башкорт гаскәрләренең кызыллар ягына аянычлы күчүен әзерләгәндә, ул, Кулаев һәм Алкин белән бергә, сөйләшүләр алып бару фикерен яклый. Фронт сызыгы аша үтеп, большевиклар белән элемтәгә керергә теләк белдерә, ә большевиклар арасында аның дуслары шактый күп була. Ләкин, фронт аша чыккач, Атнагулов, ниндидер сәбәпләр аркасында, бу йомыш-йөкләмәне үтәми. Моңа, бәлки, Вәлидинең шундый ук йомышны башкаларга да кушуы сәбәп булгандыр.

Вәлиди үзенең «Хатирәләр»ендә бу хәлне шактый ук тискәре бәяли.

1919 елның башында Атнагулов туган Бәләбәенә кайта, халык мәгарифенең мөселман бүлеге мөдире булып эшли, большевиклар партиясенә керә. Колчак белән сугыш вакытында Кызыл Армиягә алына, 5нче армиянең һәм мөселман хәрби коллегиясенең татарча «Кызыл Яу» һәм «Кызыл Армия» газеталарын редакцияли. Аның моннан соңгы хезмәте редакция-нәшрият эше белән нык бәйле. 1922-1925 елларда Мәскәүдә илнең барлык татар һәм башкорт халыклары өчен чыгарылучы, партия Үзәк Комитеты органы «Эшче» газетасын редакцияли. Казанда «Кызыл Татарстан» газетасы редакторы була, ә 1928-1930 елларда «Татакадемүзәк»не житәкли. Үзәк хәзерге Фәннәр академиясе, мәдәният министрлыгы һәм күп кенә башка идарә тармаклары вазифаларын үти. Һәм, нәтиҗәләргә караганда, эшләүчеләр саны аз булуга карамастан, әлеге вазифаларны уңышлы гына башкарган. Бу постта Атнагулов авыруы һәм сәяси сәбәпле Казаннан киткән Г. Ибраһимовны алыштыра.

С. Атнагуловка көндәлек актив иҗади эшчәнлек хас була. Егерменче елларда аның эшчәнлеге пропагандистик характерда булса (иҗтимагый-сәяси проблемалар буенча дистәләрчә мәкаләләре, берничә китабы басылуы — моңа дәлил), утызынчы еллар башында ул төп игътибарын татар тел белеменә һәм бигрәк тә аның терминологиясенә юнәлдерә. Әйе, шул замандагы күп кенә ялгыш фикерләрне ул да яклый. Аерым алганда, бу хәл интернациональ культурага урыс әлифбасына күчү юлы белән ирешү карашын яклауда чагыла. Әлифба мәсьәләсендә Ибраһимовка гел каршы чыга. Ләкин ул чакта югары житәкчелек, урыс әлифбасына күчәргә иртәрәк, дип саный. Кыска гына туктальш — латинлаштыру кәтелә.

Проблемаларга тирәнтен фәнни анализ ясап, Атнагулов «сул» карашларыннан акрынлап арына һәм утызынчы елларда ул татар әдәбияты һәм теле гыйлеме буенча зур белгечләрнең берсе булып танылa. Бу өлкәдә дәрәҗәле Г. Шәрәф, Ж. Вәлиди, Г. Нигъмәти, Нигъмәт Хәкимов, Г. Алпаров кебек галимнәр арасында ул күләгәдә калмый. Кызганыч, әлеге фәннәрдә ирешелгән дәрәҗә шуннан соң югала.

Атнагулов 1936 елның 2 сентябрендә кулга алына. Моңа чаклы партиядән чыгарыла. Тентү берничә көнгә сузыла, кече лейтенант Каменьщиковка тентү вакытында табылган язмаларның һәм китапларның исемлеген төзү өчен генә дә шактый тир түгәргә туры килә. Табылган әйберләр арасында, басылган һәм кульязма фәнни һәм әдәби әсәрләрдән тыш, күренекле җәмәгать эшлеклеләренең хатлары, күп документлар, шул исәптән, «Идел-Урал» җөмһүрияте төзү чорының бердәнбер материаллары була...

Шул ук көннәрдә булачак процессның тагын ике «фигуранты», контрреволюцион оешманың житәкчеләре итеп «билгеләнгән» М. Сәйфуллин (Ф. Сәйфи-Казанлы) һәм З. Гыймранов кулга алыналар. Аларның беренчесе — язучы һәм җәмәгать эшлеклесе, икенчесе — идеология эшендә танылган кеше, партия өлкә комитетының пропаганда бүлеге мөдире.

Әлеге дүрт кешенең эше Союз күләмендә үткәрелә торган «Новаторлар» операциясенә керүе әһәмиятен истә тотып, моңа күзәтчелек итү республика НКВДысының яшерен-сәяси бүлеге начальнигы Я. Веверска йөкләнә. Тикшерүне өченче бүлек начальнигы Марголин һәм инде укучыга таныш Каменьщиков алып баралар. Шул чакта «Казан новаторлары»ның язмышларын хәл итүчеләрнең үз язмышлары турында әйтеп узыйк.

Каменьщиков, «икейөзле троцкист» буларак, 1937 ел ахырында кулга алына, ләкин ике атнадан ирекка чыгарыла, шулай да инде аңа органнар кул астына эләгү юлы ябыла. Гадәттә андыйлар, бәлки, кирәге булыр, дип, кадрлар бүлекләренә җибәреләләр. Марголин 1939 елның башында, Л. Берия Союз күләмендә «ежовчылар»дан чистарту уздырганда, кулга алына. Казанда бу кампания барышында алты кешене ябалар. Аларның икесен — элекке халык комиссары һәм аның урынбасары Михайловны һәм Шелудченконы аталар, өчесенә төрле сроклар бирәләр. Марголин тикшерү барышында Мәскәүдә үлә. Бәлки, аны да үзе дә оста кулланган алымнар белән җәзалаганнардыр. Я. Веверска исә бәхет елмая. Ул хезмәтендәге күп сикәлтәләрне имин уза. Карьерасының ахырында Веверс Латвиянең Дәүләт куркынычсызлыгы министры дәрәҗәсенә күтәрелә, илленче еллар башында Ригада үлә һәм төп зиратның «почет аллеясы»нда күмелә.

«Новаторлар» эшен тикшерү вакытында Татарстан НКВДысының югары житәкчелеге турындагы тагын кайбер мәгълүматларны китерик. Бу эш дәүләт куркынычсызлыгы өлкән майоры Гарин заманында башлана. Һәм

аның язмышы турында әйтелде инде. Дәүләт куркынычсызлыгы өченче ранг комиссары П. Рудь заманында эш дәвам иттерелә. Аны 1937 елның җәендә Казаннан чакырып алалар, тиздән тотып ябалар һәм, «Ягода кешесе» булгарак, аталар. П. Рудьны алыштырган А. Алемасов ике ай чамасы гына — 1937 елның июнь-август айларында гына эшләп ала. Ләкин Татарстан житәкчелеген тар-мар итү өчен Сталин җибәргән Георгий Маленков, дошман белән көрәш Алемасов вакытында гына чын мәгънәсендә җәелдерелде, дип бәяли. Маленков Татарстан НКВДысы хезмәткәрләре киңәшмәсендә чыгыш ясый, халык дошманнарына карата алар лаек булганча эш кылырга куша. Һәм аның киңәшен тоталар. Бу хәл исә «либерал» Маленков образы белән һич тә тәнгәл килми.

Алемасов оператив эшкә шулкадәр бирелеп китә ки, хәтта шик астына алынучылардан үзе сорау ала һәм аларның кулларын сындыруга хәтле барып җитә. Сүз уңаеннан шуны да өстик, Алемасов тиздән өлкә комитетының беренче секретаре була, ләкин гадәте буенча берара «подвал»ларга төшкәләп йөри. Утыз жиденче һәм утыз сигезенче елларда канлы «өчлек»нең «чиксез котырынулары» вакытында ВКП(б) өлкә комитетының беренче секретаре Алемасовның, республиканың курчак башлыгы Динмөхәммәтовның һәм халык комиссары Михайловның имзалары бер утырышта гына да йөзләрчә кешеләрне теге дөньяга җибәрү теркәлгән беркетмәләрдә ялтырап ята. Алтмышынчы еллар башында Союз күләмендәге персональ пенсионер Александр Алемасов коточкыч явызлыклары өчен «җәза»сын да ала. КПССның Воронеж өлкә комитеты бюросы, утыз җиденче ел корбаннарының шикаятен карап, Алемасовка, Татарстан Эчке эшләр халык комиссары булган чактагы «дөрес булмаган тәртибе» өчен «на вид» куя, ягъни жиңелчә шелтә бирә. Динмөхәммәтов исә кадер-хөрмәттә үлә һәм яңа «әүлиялар» сафына бастырыла (андыйлар турында житмешенче-сиксәненче елларда «Халык бәхете өчен көрәшүчеләр» исеме астында без дә, ай-һай, күп яздык).

Әмма «Новаторлар» операциясенә әйләнеп кайтыйк. Беренче беркетмәләрдән күренгәнчә, ябулардан берничә көн үтүгә үк сорау ала башлыйлар. Киеренкелек урта чамада була. Шулай да беркетмәләрдәге тышкы яктан әдәпле тоелган, ләкин чынлыкта шомлы-дәһшәтле **«Сез һаман ялган сөйлисез!»**, **«Тикшерү алдында мондый коралыгызны ташлагыз!»**, **«Алдашу сезгә ярдәм итмәячәк!»** кебек сүзләрне яман саллылары алыштыра бара. Мәсәлән, «Черек күл»нең шул чактагы иң явыз җәлладларыннан берсе Сөнгатулла Корбанов кулга алынган кешеләр кергәндә әйтә торган мондый сүзләр: **«Француз фахишәсе кебек боргаланма! Хәзер менә чекист прессы аша үткәрәм үзеңне! Сөйләмичә кү... түгел!»** Шуннан соң ук шул «пресс-эскәнҗә»не кулланып та күрсәтә. Һәм тоткыннар сөйли башлыйлар. Авырту-сызлану нәтиҗәсендә, мәгънәсез сүзләр дә сөйлиләр. Шулай да сорау алуларның беренче материалларында буталу-мәгънәсезлекләр юк.

Рәхмәтуллин да, Атнагулов та инде үзләре җавап тоткан билгеле нәрсәләрне генә таныйлар. Нигездә, революция алдыннан мөселман хәрәкәте белән, З. Вәлиди житәкчелегендә эшләү һәм «Идел-Урал» белән бәйле хәлләр турында әйтәләр. Әмма болар турында матбугатта кат-кат язылган һәм алар инде тарихка калган итеп саналырга тиеш була. Төрле очрашуларда яшерен оешмага яңа әгъзалар тартырга тырыштыгызмы? Ләкин мондый очрашулар таныш-белешнең эчү мәҗлесләре яки шәһәр читенә ял итәргә чыгу гына булган икән. Моның өчен исә, күп дигәндә, әхлакый тотнаксызлык өчен шелтә бирергә мөмкин, шуннан уздырып булмый. Монда сәясәт юк. Дөрес, тикшерү астындагылар якын танышлары арасындагы әләкче-ошакчылар аркылы НКВДга килеп эләккән кайбер нәрсәләрне таныйлар. Алар уйлавынча, бу хәлләр зарарсыз, димәк, җинаятькә саналырга тиеш түгелләр.

Исхак Рәхмәтуллин, мәсәлән, 1921 елда, Мәскәүдә эшләгәндә, Зәки Вәлидигә хат язуын раслый. Вәлиди бу вакытта Фирганәдә була, басмачылар хәрәкәтендә катнаша. Рәхмәтуллин, бу хәрәкәтнең киләчәге өметсез, дип саный, Зәкигә монда кайтырга һәм гаебен танырга киңәш итә. Хат язу идеясе аңа югарыдан әйтелгән булгандыр, бәлки. Ул чакта бу хәрәкәтне таркату, аннан кайбер күренекле эшлеклеләрне аерып алу өчен шундый омтылышлар ясала. Сәлах Атнагулов исә Г. Зиновьевның әле Үзәк Комитет әгъзасы булганда язылган тезисларын татарчага тәрҗемә итәргә теләвен кире какмый.

Ләкин болар гына яшерен контрреволюцион оешма төзегән өчен бирелә торган «үлем җәзасы»на тартмый. Әбит «Новаторлар» операциясенә күпләрне нәкъ менә юк итү нияте белән керешелә. Зур оешманы ачуда тикшерүнең беренче айларда көткән нәтиҗәне бир-

мәве өчен, Мәскәү кискен шелтәли. Мондый канәгатьсезлек белдерелүенә көндәш оешманың — СССР Эчке эшләр халык комиссариаты ГУГБысы Махсус бүлегенең (начальнигы дәүләт куркынычсызлыгы икенче ранг комиссары Гай) халык дошманнарын тизрәк фаш итүнең «милли проблемалар» тармагында, ягъни яшерен-сәяси бүлек карамагындагы «сәяси территория»дә, зур уңышларга ирешүе дә сәбәп булуы мөмкин. (Махсус бүлек карамагында исә армия, оборона промышленносте һәм барлык төр транспорт була.) Ике бүлек арасындагы көндәшлек «Новаторлар» операциясе барышына, һичшиксез, йогынты ясый. Без бу хакта кыскача булса да сөйләргә тиешбез.

1936 елда бөтен СССР буйлап татар дин башлыкларын тагын күпләп кулга алалар, шул исәптән Уфадагы Мөселманнарның Үзәк дини идарәсендә эшләүчеләрне дә читтә калдырмыйлар. Дини идарә рәисе урынбасары Кәшшаф Тәрҗеманов, аның ярдәмчесе Зыя Камалетдинов, Русиядә ислам дине тотучылар тарихында беренче хатын-кыз казый Мөхлисә Буби, Мәскәү мәчете имамы Абдулла Шәмсетдинов, Омск мәчете имамы Гали Гыймуш һәм башкалар кулга алыналар. Үзәк дини идарә эше буенча гына да җәзага тартылучылар саны кырыктан арта. Мәскәү, Ленинград, Казан һәм кайбер Себер һәм Урал шәһәрләрендә татар инженерлары кулга алына. 1936 елның октябрендә барлык регионнарга җибәрелгән җиңү язмасында ГУГБның Махсус бүлегенең **«япон һәм герман разведкаларының татарлар арасында оештырылган диверсия-разведка оешмаларын юк итүе»** күрсәтелә. Реляция-хатта шулай ук әлеге разведкаларга, **«татар һәм башкорт халыклары арасында киң диверсия-шпионлык агентурасы булдырып, шул агентура аркылы хәрби һәм оборона промышленностена һәм тимер юл транспортына кереп урнашырга мөмкинлек тууы»** билгеләп үтелә. Хатка өч том тикшерү материаллары ияртеп җибәрелә. **Татар халкына каршы бу гаять зур провокациянең** чыганакларына киң тукталмыйча (авторның моның хакында үз юрамасы бар, һәм ул «Татарлар «Соловки»да һәм аннары һәр җирдә...» дигән әзер хезмәтендә бәян ителә), бер нәрсәне генә укучыга җиткерик.

Тикшерү материалларыннан аңлашылганча, Кәшшаф Тәрҗеманов бөтен герман һәм япон агентурасы белән шул илләрнең генштабларының шәхсән кушуы буенча җитәкчелек иткән икән. Ә Абдулла Шәмсетдинов Япония илчелеге секретаре Шимада алдында Мәскәүдә берничә диверсия акты башкарырга вәгъдә бирә. Җимерү эшләренең исемлегенә аңлатма кирәк тә түгел. Инде картайган мулла Япониягә менә нәрсәләр вәгъдә итә:

1. ЦАГИны *(самолет төзелеше үзәген)* яндырырга. 2. Мытище вагон төзү заводын яндырырга. 3. «ЗИС» заводын шартлатырга. 4. Тюфелеводагы химия заводын шартлатырга. 5. Әйләнеп үтә торган тимер юл күперен шартлатырга *(монда күперләр күп, материалда кайсы күпер икәнлеге төгәл күрсәтелми)*. 6. Перерва тимер юл күперен шартлатырга. 7. Белоруссия-Балтика юлындагы күперне шартлатырга. 8. Брянск вокзалы *(хәзерге Павелецкий вокзалы)* янындагы складны шартлатырга. 9. Люблино станциясе депосын шартлатырга.

Басым ясап әйтик, бу шпионнар турындагы кайбер романнарга пародия түгел, ә тикшерү эшеннән күчермә. НКВДның урыннардагы органнары моны кулланма итеп алырга һәм үз «мулла-террорчылар»ын табарга тиеш булалар. Көчле техникасы һәм мөмкинлекләре зур булган немец абверы һәм хәтта Мәскәүне бомбага тоткан бөтен немец авиациясе Абдулла хәзрәт «вәгъдә иткән» (документлар буенча фикер йөрткәндә, әлбәттә) нәрсәләрнең кечкенә бер өлешен дә кыла алмады. Чыннан да, кеше ышанмаслык хәл, әмма — факт.

Татар инженерларының «гаепләре»н танулары менә мондыйрак фактларга нигезләнә. Электрон эретмәсен сынаганда, АРФО заводының цехы яна — эшлексез слесарьның саксызлыгы аркасында яна. Сынап күрсәткәннәр икән, ишкәннәр икән ишәк чумарын, дип әйтеп куя фәлән. Ә гаепләү актына, ул үзе ут төртеп яндырган, дип языла. (Ул чакта КамАЗдагы кебек янгын була калса, йөзләрчә кешеләрнең чит ил разведкалары, хәтта Австралия яки Тринидад һәм Тобаго утраулары разведкалары белән элемтәләре булуын «таныттырылар» иде, мөгаен). Террор турында сүз барганда, Сталинга бомба ташларга җыендым, яки, Кировны үтереп әйбәт иттеләр, әмма Сталинны үтерсәләр, яхшырак буласы иде, кебек «гаеп танулар» тикшерү материалларында тулып ята. Бер уйлаганда, болар мәзәк кебек, ләкин һич тә көлке түгел шул — әлеге «гаеп танулар»да кешеләрнең фаҗигале язмышы чагыла.

Күп кенә «фактлар» чит илләрдәге эмигрант группалары эшчәнлегенә

бәйле. Хәзер без бу хакта чын-дөресен шактый беләбез. Табигый ки, Г. Исхакый, Ф. Туктаров, З. Вәлиди һәм эмиграциянең бүтән лидерлары СССРга җылы мөнәсәбәттә булмаганнар һәм була да алмыйлар иде. Ләкин аларның һәр нәрсәгә әзер киң таралган агентлары һәм террорчылары да юк иде, алар бу хакта хыял итә дә алмыйлар иде. Ә бит «новаторлар»ны шушы мөмкин булмаган эшкә «китереп бәйләргә» тырышканнар.

Молчанов та, Рудь та Ежовтан шелтә алганнардыр, күрәсең. Үзәк Комитетта эшләгәндә үк документларны яхшылап рәсмиләштерүнең бәясен белә Ежов, өстәвенә аның редакторлык сәләте дә була. Ежовның Гай барында Молчановка, татарлар турында әйбәт рәсмиләштерелгән өч томга күрсәтеп, менә шулай эшләргә кирәк, дип кисәтүе бик тә ихтимал. Алга таба, сорау алу һәм кара-каршы очраштыру беркетмәләрендә һәм башка тикшерү материалларында теркәлгәнчә, хәлләр үзгәрә. Листенгуртның, Казанда «Новаторлар» эшен тикшерүдә «басым һәм оператив кискенлек» җитми, дигәнен, ягъни «җитмәгәне»н... житкерә башлыйлар.

Инде кулга алынган Толымбайдан, Касыймовтан, Абдуллиннан, Нәҗмидән, «Дмитровлаг»тан китерелгән, ун елга хөкем ителгән Сәгыйдуллиннан һәм башка бик күпләрдән шаһитлар буларак сорау алалар. Беркадәр каршы торганнан соң, алар барысы да Рәхмәтуллинның һәм Атнагуловның Совет властена каршы иң әшәке җинаятьләрдә катнашуларын тулысынча раслыйлар. Бик аз исән калучыларның һәм хәтта шул вакытта ук азат ителгән (андыйлар берничә генә була) кешеләрнең берсе Кави Нәҗми, 1955 елда реабилитация башлангач сорау алганда, барлык күрсәтүләрен «басым ясау һәм куркыту-янаулар» аркасында биргәнлеген таный. Әйе, тикшерүчегә кирәк булган мәгълүматларны әйтәләр алар. Гражданнар сугышында үлемнең йөзенә курыкмыйча караган батырлар да сына хәтта. Намус һәм абруеңны төшермәү сыйфаты кечкенәдән үк күнелләренә сеңгән зыялылар да нахак сөйләргә мәҗбүрләр. Гомумән, таш капчыкка эләгүчеләрнең барысы да, барысы да...

Без аларны моның өчен гаепләргә тиеш түгелбез. Актык чиккә җиткерелгәч «гаебен танулар» тиздән ул кешеләрнең кайберләренә үлем китерә. Хәер, газап-җәфалардан тилмергәнче, үлүең хәерлерәк, дип теләүчеләр дә була... Бу хакта Казан мэры Павел Аксенов инде басылып чыккан истәлекләрендә кырыс, әмма бик тә дөрес итеп яза. Ул үзе дә «Черек күл»нең үлемгә хөкем ителгәннәр камерасында берничә ай утыра... Җәзалаулар чиктән ашканда, кешеләр холыклары (әйтик, ныклык һәм йомшаклык) арасындагы аерма җуеладыр кебек. Шуңа күрә Василий Гроссманның бер герое, төрмәдә намуслы кешенең намуссыз кешедән аермасы – беренчесенең кабахәтлекне теләмичә эшләвеннән генә гыйбарәт, дип раславы белән бик хаклыдыр да.

Рәхмәтуллин да, Атнагулов та «гаеп тану»да берничә баскыч үтәләр. Каткат кыйнаулардан һәм тикшерү эшенең шул чактагы башка алымнарыннан соң (бу алымнарны тәфсилләмибез, чөнки моны укыганда какшау нервлы кешеләрнең түзмәве мөмкин), алар, калтыравык кулларына каләм кыстырылгач, тикшерүче язган сүзләрне раслап имза куялар... Аннарына килгәч, ягъни үзләренә һәм якыннарына үлем карары чыгаруларын аңлагач, прокурор чакыруны таләп итеп һәм «гаеп тану»ларыннан баш тартып, камера ишеген төяргә тотыналар. Сүз сөйләшмәүче конвоирлар керә дә тагын тикшерүче бүлмәсенә алып китәләр. Җәлладлар исә күптән түгел генә кыйналган-тилмертелгән тоткыннарны усал һәм мыскыллы елмаеп каршылыйлар... Имзалар кабат куела, тик әүвәл тикшерүчеләргә «яла якканнары» өчен гафу үтенелә... Ә «гаепләр»ен танымаучыларга — җәза бер, үтерәләр андыйларны... Медицина институты директоры Еналеевның, язучы Шамил Усмановның һәм тагын уннарча күренекле кешеләрнең тормышы шулай өзелә...

Ачы язмыш прокурорларны да читләтеп узмый. Якуб Чанышевның, мине прокурор белән очраштырыгыз, дигән таләбенә каршы бер оперуполномоченный:

— Каян алыйм ди мин сиңа аны? Алар белән... подвал тулды,— дигән җавабы кылану түгелдер.

Эш урыннарында утырып калучылар исә, югарыдагыларның сүзләрен тыңлаучан бәндәләр булып, кулга алырга санкция бирәләр, булмаганны булган дип «эшләр» оештыралар. «Авыл хуҗалыгы эшләре» буенча белгеч булып китеп, бүген дә хөрмәткә ия бер пенсионер кебек, мәсәлән. П. Аксенов урындагы кешеләрнең гаепле саналып кулга алынучыларны кыйнауда үзләре дә катнашулары турында истәлекләрендә ышандырырлык итеп яза. **Респуб-**

**лика прокуроры Егоров кулы кычытуын гаепсезләрне кыйнап баса торган булган...**

Март башына Рәхмәтуллиннан һәм Атнагуловтан үзләренең һәм башкаларның гаепләрен ача торган «мәгълүматлар»ны алалар. Аларның эше буенча уннарча кулга алынучылар сорауга тартыла. Шаһитлар арасында Казанда партия-идеология өлкәсендә «ат уйнаткан» Г. Касыймов, З. Гыймранов, Б. Абдуллин, С. Борһан, Г. Әлмөхәммәтов һәм башкалар була. **Гаепләүләрнең коточкычларын ташлыйлар — террористик актлар әзерләү, Совет властен бәреп төшерергә чакыру һәм шул максаттан яшерен оешма төзү. Болар исә «социаль яклауның иң югары җәзасы»н, һичшиксез, куллануның нигезен тәшкил итәләр.**

Сак астында тотылучылар, газаплаулар туктатылганнан соң, акылга сыймаслык «танулар»ыннан тагын ваз кичәргә үзләрендә көч тапканнардыр, күрәсең. Әмма озакка түгел. Менә бер генә мисал. 22 апрельдә Рәхмәтуллин, Шәрык педагогия институты директоры Газыйм Касыймов белән кара-каршы очраштыруда, 1936 елның ноябрь-декабрь айларында үзе биргән мәгълүматларның барысыннан да диярлек баш тарта. Партия алдында бердәнбер «гөнаһ»ым — 1921 елда Әхмәтзәки Вәлидигә хат язуым, шуннан соң бернинди контрреволюцион эш алып бармадым һәм үземә, һәм башкаларга күрсәтүләрем ялган, ди ул. Беркетмәдә: «Кара-каршы очраштыру туктатылды», — дигән бик тә мөһим сүзләр сырлана. Сорау алуга бүлек начальнигы Веверс кушыла, «үҗәт адәм» белән ни кылуларын күз алдына китерү кыен түгел. Нәтиҗәдә, 27 апрельдә Рәхмәтуллин, тикшерүне алдарга теләве өчен, гафу үтенә һәм 1936 ел ахырындагы күрсәтмәләренең барысын да диярлек раслый. Ә 9 майда инде үзенә ташланган гаепләрнең барысын да танып имза куя. 20 майдагы кара-каршы очраштыруда Рәхмәтуллин, Абдуллин һәм Касыймов бер-берсен фаш итүче элекке күрсәтүләрен кабат раслыйлар. Димәк, каршылык күрсәтергә көч бетә.

1937 елның 2 июнендә тикшерүче Каменьщиков Рәхмәтуллинны тикшерү эше һәм СССР Югары судына тапшырылачак гаепләү акты белән таныштыра. Беркетмәдә: **«Рәхмәтуллин тикшерү эше белән танышырга теләми»,** — дип язылган, әмма Рәхмәтуллин имзасын салган.

С. Атнагулов эше дә шушы ук тәртиптә диярлек тәмамлана. «Новаторлар» даирәсенә кертелгән башка уннарча эшләрне тикшерүне дә шул ук вакытта ахырына җиткерәләр. «Халык дошманнары»ның соңгы өмет шәүләсе булып суд кала. Кайберәүләр, югары юридик орган хәйләле һәм мәкерле ниятнең асылына төшенер, партия идеяләренә үзләренең бирелеп хезмәт итүләрен (хәзер исә аларны нәкъ менә шуның өчен үлем җәзасына тартмакчы булалар) игътибарга алыр, дип өмет баглыйлар. Шулай да күбесе судның тикшерү материалларына штамп сугасын, хөкемнең инде күптән чыгарылуын төшенәләр. Ә судьяларның киңәшү бүлмәсенә кыланып чыгып китүләре чәй эчү өчен егерме минутлык тәнәфес ясаулары гына ич... Әмма өмет, кем әйтмешли, иң актыктан киселә...

«Новаторлар»ны Мәскәүдә Югары судның хәрби коллегиясендә хөкем итәргә булалар. Соңрак, «үлем машинасы»ның эш тизлеге арта барып, бөтенесен ахыр дәрәҗәдә гадиләштерәләр. **1938 елның маенда Казанда СССР Югары суды хәрби коллегиясенең күчмә сессиясе Татарстаннан йөздән артык һәм Мари республикасыннан унсигез кешене ике көндә үлемгә хөкем итә.** Бу котырынкы мәҗлестә корвоенюрист Матулевич рәислек итә, бригвоенюристлар Ждан һәм Колпаков аңа булышалар.

Аннары «өчлек»ләр утырышлары башлана. Инде эшләр белән танышып та тормыйча, тикшерүченең кыскача сөйләве буенча, гаепләнүчене чакырып та мәшәкатьләнмичә, бер утыруда йөзләрчә кешеләргә хөкем чыгаралар.

СССР Югары суды хәрби коллегиясенең диввоенюрист Я. Дмитриев, диввоенюрист Н. Голяков, бригвоенюрист С. Преображенский (безнең колакка сәер ишетелә торган мондый дәрәҗәләр, юриспруденция генераллары, дигәнне аңлата) составындагы 1937 елның 3 августы утырышы «татар көне» булгандыр, күрәсең. Бу көнне суд каршына «Новаторлар» операциясе барышында кулга алынган төп группа кешеләре баса. Аларның кайберләрен атап әйтик: И. Рәхмәтуллин, КДПИ директоры Г. Касыймов, «Известия» газетасы хәбәрчесе С. Борһан, сәнгать эшләре идарәсе (хәзергечә — мәдәният министрлыгы) начальнигы Г. Әлмөхәммәтов, партия өлкә комитетының элекке бүлек мөдире З. Гыймранов, КДПИның элекке директоры, аннары татар театры директоры М. Йосыпов, ВКП(б)ның Татарстан өлкә һәм Казан шәһәр комитетларының элекке секретарьлары Б. Абдуллин һәм А. Биктаһиров, күренекле тел галиме һәм этнограф Н. Хәкимов...

Алар барысы да, эшнең асылы кыскача гына әйтелгән, «социаль яклауның иң

югары җәзасы»на хөкем ителәләр, һәм, белешмәләрдән күренгәнчә, карар шул көнне үк җиренә җиткерелә... Ф. Сәйфи-Казанлыны ике көннән соң аталар...

Сәлах Атнагуловның әле тагын ике атна яшисе калган булган икән. Үзе белән бер «эш»тә гаепләнүчеләрнең үтерелүе турында ул белгәндер, күрәсең — төрмәдә дә хәбәр, бигрәк тә үлем җәзасының үтәлүе турындагы хәбәр, тиз тарала. Аны коллегиянең яңа составы — корвоенюрист Л. Плавнек, бригвоенюрист С. Преображенский һәм беренче ранг военюрист Ф. Климин хөкем итә. Утырыш 16 августта 13 сәгать 30 минутта башлана һәм 13 сәгать 50 минутта бетә. Егерме минутта, беркетмәдән аңлашылганча, гаепләү актын игълан итәргә, Эльвов, Рәхмәтуллин, Нәҗми, Абдуллин, Касыймов, Гыйммранов, Борһан һәм башкаларның күрсәтүләрен укырга, Атнагуловның үз күрсәтүләрен һәм аның соңгы сүзен тыңларга, киңәшергә чыгарга һәм хөкем карарын игълан итәргә «өлгерәләр»... Юстиция «стахановчы»лары менә шулай җәһәт эшлиләр! Атнагулов күпчелек гаепләрне кире кага, тануларының һәм күрсәтүләренең кайберләрен «рухи сәламәтлеге какшау хәл»дә бирүен әйтә, шаһитларның барлык күрсәтүләрен инкяр итә (аларның күбесе атылуын ул инде белгән) һәм соңгы сүзендә: **«Үземне гаепле санамыйм»,** — дип белдерә. «Бөтен мал-мөлкәтен алып, иң югары җинаять җәзасына — атарга» хөкем итү карары шул ук көнне җиренә җиткерелә...

«Новаторлар» эше менә шулай тәмамлана. Шартлы исем белән аталган йөзләрчә операцияләрнең — меңнәрчәмеңнәрчә кешеләрне подвалларда үтерткән һәм лагерь-төрмәләрдә череткән операцияләрнең монысы да күп, бик күп корбаннар китерә...

Ләкин, «Новаторлар» операциясенә турыдан-туры кагылышы булмаса да, тарихның (язмышның, дисәк тә ярыйдыр) бер шаяруы турында да сөйлик әле.

Шул көнге суд утырышының нәтиҗәләре турында кыскача информация икенче көнне үк берничә урынга җибәрелә. Беренче чиратта, Үзәк Комитетка, «хуҗа»ның секретаре Поскребышевка, әлбәттә. Икенче данәсе НКВДга, Н. Ежовка илтелә. Ежов электә Казан кешесе була, партия номенклатурасының түбәсенә таба Казанда менә башлый. Әлеге хәбәр хатындагы таныш фамилияләрне күргәч, кагыйдәгә әйләнеп баручы «этләргә — эт үлеме» дигән сүзләрне кабатлавы бик тә ихтимал аның. Чөнки юлбашчылар «хуҗа»га охшарга һәм ошарга тырышып, кыска һәм ачык сөйләргә өйрәнәләр. Наркомны яшьлегендә «Колька — книжник» дип йөртәләр. Шулай да ул 1921 елда Казанда тутырылган анкетада беркайда да беркайчан да укымавы турында дөресен ихластан яза. (Хәер, Үзәк Комитетта эшләгәндә, анкетаның әлеге графасына «түбән белемле» дип сырлый. Эш урыны күпмедер белеме булуын таләп итә ич...) Ләкин ул китап укырга ярата, хәтта ике чит тел — поляк һәм литва телләрен да белә. Шулай да Ежов, суд нәтиҗәләре турындагы язуны укыгач, С. Атнагуловка хөкем карары астында имзасы торган беренче ранг военюрист Федор Климин белән ике ел чамасыннан соң, күзгә-күз очрашырмын, дип уена да китермәгәндер, саташулы төшләренә дә кермәгәндер бу хәл...

1940 елның 2 февралендә, җомга көнне, СССР Югары суды хәрби коллегиясенең ябык утырышы уза. Анда совет юстициясенең кешеләр җанын күчереп тинсез дан яулаган, безнең бөтен сәяси элитабызны диярлек теге дөньяга җибәргән армюрист Василий Ульрих үзе рәислек итә. Ә бу утырышта безгә инде мәгълүм һәм инде бригвоенюрист дәрәҗәсенә ирешкән Федор Климин әгъза була. Кечкенә генә гәүдәле, таушалган гимнастеркалы, мәгънәсез күзләре ялтыр-йолтыр итүче, судьялар алдында соңгы сүзләрен бөтен көченә кычкыручы кеше исә — Николай Иванович Ежов. Югыйсә әле күптән түгел генә Дәүләт куркынычсызлыгы Генераль комиссары, Сталинның тимер наркомы, дошманнарның котын алучы Ежов, Сталинга иң зур мәдхия җырлаучыларның берсе Микоян әйткәнчә, ленинчыл стиль һәм «тимер Феликс йөрәге кайнарлыгы» эретмәсен-кушылмасын гәүдәләндерә иде...

Ежов халык дошманнарын юк итү өлкәсендә, шулай ук чекистлар башкарган эшләрне җәмгыятьнең аңламавына ризасызлык белдерә, түбәнгә тәгәрәве сәбәпләрен шәхси дошманнары мәкерле эш йөртүдә күрә, ул, әгәр ялгышларын судта хак-дөресләп таныса, әле кичә генә Бериянең, Сталин исеменнән, үзенә тормыш вәгъдә итүенә ышанып сөйли. Яшерен серләрен, хәтта интим серләрен ачып, артыгын тырышып җибәрә... Кешенең рухи халәте борылышлары сәер һәм серле шул...

Югыйсә Ягода да, Ежов та һәм сәяси зат буларак алардан бик күпкә өстен Берия да үзләре тудырган сәяси уен кагыйдәләрен гаҗәеп дәрәҗәдә әй-

бәт белгәннәр. Һәлакәткә дучар булуларын аңлый торып, алар, соңгы сызыкка җиткәч, шулай да могҗиза кылынуына өметләнәләр — үзләрен исән калдыруны үтенәләр. Чыннан да, өмет дигәнең иң актыктан җан бирәдер, ахрысы...

Һәм менә Ежов та үзенең хезмәтләре һәм Сталинның тормыш вәгъдә итүе турында кабат-кабат искәртә. Суд аны бүлдерми. Бу көнне башка эшләрне карау билгеләнмәгән була. Лефортово төрмәсенең кечкенәрәк кенә залы буш диярлек, анда сакчылар һәм комендант кына бар. Күп санлы зарланусыкранулардан соң, гадәти булып әверелгән гыйбарәне — Сталин исемен атап үләргә теләвен әйтә Ежов. Һәм әнисен, кызын һәм бертуганының улларын җәзага тартмаулары турында нигезле теләгән белдерә. Соңгы сүзендә упкын кырыена җиткәндәге кешеләрчә кызганыч тавышы яңгырый: «Бер нәрсәне үтенәм — мине тыныч кына, газап чиктермичә атыгыз!»

Суд, Ежовны атарга хөкем итеп, бу карарның кичекмәстән жиренә житкереләчәген дә күрсәтә. Ләкин аны ике көннән соң гына аталар... Сталинның карарны раславын көткәннәрдер, күрәсең.

Ежов өендәге өстәл тартмасында кеше тәненә тиюдән ямьшәйгән пуляларны саклаган була. Дүрт пуляны. Аларны Зиновьев, Каменев һәм Смирнов тәннәреннән алганнар икән. Смирновка ике пуля кирәк булган. Гадәттән тыш комиссиядә эшләгән бер ветеран (ул Мәскәүдә яшәде) безгә Ежовка ике пуля кирәк булмавын әйткән иде. Ләкин Берияның шундый истәлекләр саклавы-сакламавы турында ул белми иде. Югыйсә бу ветеран «атом эшләре» буенча Берияны әйбәт хәтерли һәм, «разведканың һәм галимнәрнең тырышлыкларын бик шәпләп килештермичә-яраштырмыйча торып, атом бомбасын шундыен да кыска вакытта булдыру — мөмкин түгел хәл», дип саный иде.

... Безнең көннәр төрле яктан, аеруча сәяси яктан, бик тә ыгы-зыгылы. Пуля сәяси аргументларның берсенә әйләнә бара. Хәвеф-хәтәрле үткәннәрне кабатлау мөмкинлеге калмасын иде. Теләк шундый. Һәм таләп тә шундый. Халык теләге һәм халык таләбе.

# «АҺ, ТУГАН КАУМЕМ ГАЗИЗ!»

ЭССЭ



Бер уйлаганда, Гыйләҗетдин Госманга туган-үскән Кытаенда яшәргә дә яшәргә иде. Тамагы тук, өсте бөтен, фатиры иркен һәм уңайлы, эше дәрәҗәле — ул Шинҗаң-Уйгыр автономияле районы башкаласы Өремҗедә берьюлы биш телдә басыла торган фәнни журналның баш мөхәррире, университет профессоры. Монда аны күпләр таный һәм хөрмәт итә. Туганнары, дус-ишләре шушында, ә аның үзен Уйгырстанда яшәр өчен генә яратылган диярсең, уйгыр, казакъ, үзбәк, кытай телләрен су кебек эчә, бу халыкларның һәм мондагы тагын кайбер милләтләрнең гореф-гадәтләрен, йолаларын, тарихларын һәм мәдәниятләрен белә. Белә дип әйтү генә дә аз — ул уйгырча, казакъча шигырьләр иҗат итә, чин (кытай) телендә фәнни хезмәтләр, дәреслекләр яза, кытайчадан төрки телләргә, яки киресенчә, тәрҗемәләр ясый. Саный китсәң, аның мактанырлык, горурланырлык казанышлары күп, һәм аларның барысына да ватаны Кытайда ирешелгән. Гыйләҗетдин кебек муллыкта, хөрмәттә яшәү, турысын әйтик, монда аның бик күп уйгыр яки чин яшьтәшләренә тәтеми. Гаиләсе тигез, хатыны һәм кызлары югары белемле, шулай ук дәрәҗәле һәм әйбәт хезмәт хакы түләнә торган урыннарда эшли, инде улы да мәшһүр Пекин университетына укырга кергән. Ата-бабасы шушында гүр иясе булган, шушында оныклары дөньяга килгән. Көннәрдән беркөнне менә шушы инде көйләнгән түгәрәк, житеш тормышны ташла да Татарстанга кайт, дәрте дә, моңы да, нуры да ташып тормаган, хәтта икътисадый яктан артка гына чүгә барган Казанда тамыр җибәрергә тырыш, имеш! Билләһи, аңламассың бу адәм баласын. Тукай әйтмешли, «ашыйсыларым килә әллә ни, ишегалдында торган арбаный!»

«Казан утлары» редакциясенә ул үзе килеп керде һәм папкасыннан татарча кульязма чыгарып:

— Мин — Гыйләҗетдин Госман. Кытай галиме Сюэ Цзунчжэннең «Төрек тарихы»н тәрҗемәли башладым. Бәлки ул сезне дә кызыксындырыр, беренче бүлекләрен тәкъдим итәм менә, — диде.

— Кайсы телдән тәрҗемәлисез?


— Кытайчадан. Кытайда төрки халыклар үткәнен тикшерүгә дә игътибар зур, гыйльми хезмәтләр чыгып кына тора. Бу китап — шуларның иң яңасы, 1992 елда гына басылып чыкканы.

— Тарихи хакыйкать, гаделлек бармы соң анда?

— Сюэ Цзунчжэн чин тарих фәнендә төркиләр турындагы соңгы карашларны чагылдыра,— диде кунагыбыз.— Ул элекке бик күп хезмәтләрне өйрәнгән һәм анализлаган, алардагы шактый кимчелекләрне ачып салган, хаталарны төзәткән.

— Мәсәлән?

— **Төрки халыклар тарихын өйрәнгәндә галимнәр өч төрле чыганакка таяна: чин телендәге елъязмаларга һәм борынгы дәвер әсәрләренә; гарәп-фарсы галимнәре һәм язучылары хезмәтләренә; Көнбатыш (Рим, Византия) шаһәдәтнамәләренә һәм тикшеренүләренә, Сюэ Цзунчжэн фикеренчә, Европа галимнәре чин чыганакларын бик аз файдалана, Кытайда исә Көнбатыш хезмәтләренә игътибар чамалы.** Шунлыктан, төрки халыклар тарихы Кытайда да, Көнбатышта да берьяклы яктыртыла. «Болай ярамый», ди Цзунчжэн. Ул үзе менә шул өч төрле чыганакны чагыштырып өйрәнә, алардагы каршылыкларны аңлата, таблицалар, диаграммалар, схемалар сызып, карталар рәсемләп, фикерләрен тәгаен хезмәтләргә таянып әйтә. Кыскасы, аның «Төрек тарихы» — чин фәненең яңа сүзе, объективлыкка дәгъва итә торганы. «Төрек» дигәндә госманлылар түгел, барлык төрки халыклар, аларның борынгы бабалары күздә тотыла.



«Тел вә тәрҗемә» журналы.

Төркиләр һәм тагын кайбер халыкларның ана ватаны — Үзәк Азия. Монда алар һәрвакыт Кытай белән дә күрше булып яшәгән. Кытай инде бик борынгы заманнарда ук утрак тормышта гомер иткән, шәһәр мәдәниятен барлыкка китергән, аның югары катламы арасында уку-язу да мең еллар элек үк киң таралган. Чин елъязмачылары борынгы патшалыклары һәм аның күршеләре турында мәгълүматлар теркәгәндә, төркиләр хакында да хәбәр биргән. Билгеле ки, күчмән төркиләр белән утрак чиннәрнең мәнфәгатьләре һәрчак туры килеп бетмәгән. Тыныч аралашу, сәүдә итү хәрби бәрелешләр белән чиратлашып торган. Мәдәни Кытай «кыргый» күчмәннәрне буйсындырырга, алардан ясак җыеп яшәргә омтылган. Күчмәннәр исә чиннәрне үзләреннән өстен дә, мәдәнирәк тә санарга теләмәгән, аларның зәгыйфьләнгән патшалыкларын яулап алып, озак вакыт Кытайның галиҗәнапләре булуга ирешкән, ләкин соңрак үзара көрәшләрдә көч-куәтләрен җуеп, сан ягыннан егерме-утыз тапкыр күбрәк чиннәр арасында эреп юкка чыккан. Тарихны җиңүче язганлыктан, аның элекке көндәше хакында чын хакыйкатьне сурәтләве икеле, хәтта, мөмкин түгел. Телиме, теләмиме, ул үзен аклап, бизәп күрсәтәчәк, башкаларны түбәнсетебрәк, ямьсезләтебрәк гәүдәләндерәчәк.

Сюэ Цзунчжэн дә, китабыннан аңлашылганча, шундыйрак мөнәсәбәттән азат түгел икән. Мисалга, ул борынгы төркиләрне — бүгенге төрки халыкларның ата-бабасы, безне сөннәрнең дәвамы итеп исәпләми, ә менә кыяфәтләре, килеп чыгышлары төрле, телләре үзара тылмачсыз аңлашылмый торган, әмма соңгы дәвердә чин дип атала башлаган кавем-кабиләләр «бер милләт» икән — алар меңьеллар буе чин булган һәм вәссәлам! Әлбәттә, мондый раслаулар белән тулган фән фән түгел, бары сәясәт ялчысы гына. Сәясәтнең максаты исә башкаларны йоту хисабына үзеңне көчәйтү, «бөгештерелгән тарихлар» ижат итеп, шуңа алшарт әзерләргә тырышу.

Ләкин чин тарихчысының безнең хакта язган хезмәте барыбер игътибарга лаек. Төркиләр турында урыс һәм Көнбатыш галимнәре, гарәп-фарсы һәм кытай елъязмачылары гел тискәре хәбәрләр генә язып торсалар да, аларны чагыштырып өйрәнү уңай нәтиҗәләргә китерү мөмкин. Берсенең ялганын яки ялгышын икенчесе фаш итәргә, өченчесе яңа хәбәре, фикере белән борынгы заманның томанлы хәлләрен ачыкларга һәм тулыландырырга, хакыйкатьне анykларга булышуы ихтимал. Санаулы гына татар тарихчыларының күпчелеге чит телдәге чыганаклар, бигрәк тә чин язмалары белән асыл нөсхәдә танышa алмаганлыктан, Гыйләҗетдин Госман кебек кешенең табылуы, аның кытайчадан татарчага турыдан-туры тәрҗемәсен «Казан утлары»на тәкъдим итүе үзе бер тансык хәл иде. Шуңа күрә мин аның белән кызыксынып:

— Ә сез кытайчаны кайдан беләсез?— дип сорадым.

— Шинҗаң университетының чин теле бүлеген тәмамладым, аннары озак еллар кытай әдәбияты классик әсәрләрен казакъчага тәрҗемә итү һәм редакцияләү белән шөгыльләндем.

Бу җавапны ишеткәч, без гаҗәпсенеп һәм кызыксынып кунакка төбәлдек, аны яңадан-яңа сораулар белән күмеп ташладык. Әнә шулай Кытайда яшәүче милләттәшләребез, андагы бүтән кардәш халыклар тормышы, Гыйләҗетдин Рәхмәтулла улы Госманның үзе һәм якыннары язмышы белән таныштык, ул Казанга алып килгән китаплар һәм журналлар Уйгырстанның бүгенге хәлен тулырак, ачыграк күзалларга мөмкинлек бирде.

Мин Дәрдмәнднең:


> Ни газизрәк — бу ватанмы?
> Аһ, туган каумен газиз,—

дигән шигъри юлларын кат-кат укысам да, аннан акыллы бер мәгънә чыгара алмый аптыраган идем. Нигә аларны бер-берсенә каршы куярга, янәсе, ватан белән халык бердәй зурлыктагы төшенчәләр ләбаса. Гыйләҗетдиннең Казанга килүе миңа татар язмышының бер ачы хакыйкатен Дәрдмәндчә күрергә этәрде һәм әлеге шигырьнең фәһемле фәлсәфәсен төшендереп бирде — синә үз халкың дәүләтчелеге булмаган ил дә ватан хисапланырга мөмкин ич. Хәтта халкыңны типкедә, җәбер-золымда тоткан мәмләкәт тә. Шулай икән, әлбәттә, туган халкы һәркемгә шундый ватаннан газизрәк тоелырга, аны данлау, аңа хезмәт итү һәр аңлы кешенең иң мөкатдәс бурычы саналырга тиеш. Гыйләҗетдиннең ерак бабасы Габдулла Госман — Казан сәүдәгәре, аны язмыш Кытай белән алыш-биреш эшенә баглап җибәргән. Ул Голҗага килеп урнашкан, уйгыр кызына өйләнгән, әмма улы Рәхмәтуллага (1890—1940) чын татар тәрбиясе бирергә омтылган. Казаннан К. Насыйри, Ш. Мәрҗани әсәрләрен, Оренбургтан «Шура» журналын, «Вакыт» газитен алдырган. Гайрәтле, кәсепчел зат Габдулла улына урысчаны да өйрәткән, шул заманда ук европача киенеп, галстуклар тагып йөрсә дә, баласына «Коръән», «Коръән тәфсире», «Пәйгамбәрләр тарихы» кебек кадими әдәбиятны да укыткан.

Рәхмәтулла да, яше җиткәч, атасы һөнәрен алган, кием-салым сәүдәсен көйләп җибәргән, шактый күп терлек асраган, умартачылык белән шөгыльләнгән. Татар мәктәбендә белем алганлыктан, ул туган телендәге матбугат һәм китаплар белән даими азыкланырга тырышкан, Г. Исхакый, Г. Тукай, Р. Фәхретдин, Һ. Атласый, З. Вәлиди әсәрләренә күңел биргән.

**Ватаныннан аерылган татарның иң зур бер кыенлыгы — милләтен саклау, ят халык арасында сибелеп яшәгәндә, милләттәшләре белән мөмкин кадәр тыгызрак бәйләнештә тору, катнаш никахларга кереп, җирле күпчелек тарафыннан йотылмау.** Әмма Уйгырстанга күчеп килүче татарлар бик үк күп булмаганлыктан, алар тиз арада үзара туганлашып бетә, нәселне сәламәт саклар һәм үстерер өчен, кардәш халыклар арасыннан да пар сайлау ихтыяҗы туа. Рәхмәтулла Голҗада әнә шунлыктан әнисе татар, атасы уйгыр булган кызга өйләнә. Шушы никахтан ике кыз, ике ир бала дөньяга килә, бу балаларның берсе — 1938 елда туган Гыйләҗетдин була.

— Әти миңа ике яшь тулганда ук якты дөнья белән саубуллашканлыктан, мин әнием тәрбиясендә үстем,— диде Гыйләҗетдин.— Әти ягыннан әбием — саф уйгыр, әнием — ярты уйгыр, үзебез Уйгырстанда яшибез, әмма гаиләбездә татар тәэсире зуррак иде. Әле дә гаҗәпләнәм: кайдан килгән икән аңа мондый ныклык?



«Татарларның кыскача тарихы китабы

Әңгәмә барышында моның сере дә ачыкланды — татарлар XIX йөздән башлап мондагы җирле төрки халыклардан һәм матди, һәм рухи мәдәнияте белән өстенрәк булган. Ул Шәркый Төркестанга яңа һөнәрләре, пакь һәм затлырак, европалашканрак көнкүреше, инде җәдитләшергә өлгергән мәктәп-мәдрәсәләре, киң колач алган матбугаты, үзешчән сәнгате, заманының актуаль мәсьәләләрен күтәрә һәм сәнгатьчә сурәтли алган бай әдәбияты белән килә, руханиларыбыз да ислам дине нигезләрен тирән белүләре, дини йолаларны җиренә җиткереп үтәүләре, иман ихласлыгы һәм ныклыгы белән Уйгырстан мөселманнарына тирән тәэсир иткән. **Тарихи үсешләрендә**

**алар XIX-XX йөзләрдә Идел-Урал буендагы туганнарыннан арттарак калганлыктан, тәрәккыйләре өчен татарлардан үрнәк алуны, аларның милли мәктәпләренә кереп укуны, татар әдәбияты белән танышуны, татар җырын җырлауны мәртәбәле һәм котылгысыз бер гамәл санаган. Уйгыр туйларын һәм мәҗлесләрен татарча гармун уйнап, җыр җырлап ачмасалар, туй да, мәҗлес тә ямен-тәмен җуя кебек тоела башлаган.** Сүзләрен белеп бетермәсәләр, көйләребезне көйләгәннәр. Татарның «Баламишкин», «Керфекләрең нигә кара» җырларын хәтта чиннәр дә яраткан, үз сүзләрен дә катнаштыргалап, шыңшыганнар. Гыйләҗетдиннең әнисе дә җырга-моңга һәвәс булган, улына: «Татарча җырла! Биш-алты җыр да белмәгән егет татар булмый ул»,— дип үгет бирергә онытмаган.

Дүрт бала белән тол калгач, Зөһрә ханым гаиләсен алып туганнары янына Голҗадан ике йөз чакрымдагы Түргән авылына күчеп китә. Гыйләҗетдин монда уйгыр-казакъ мәктәбендә укый, 1958 елда яңадан Голҗага әйләнеп кайткач, гимназиядә урта белем ала. Кайбер фәннәрдән татарлар сабак бирә, әмма укыту нигездә уйгырча һәм казакъча алып барыла. Университетны тәмамлагач, Гыйләҗетдин Өремҗе нәшриятендә уйгыр әдәбияты мөхәррире вазифасына тәгаенләнә.

1959 елда Үзәк Кытайдан Голҗага кадәр сузылган тимер юл салынып бетә, шуннан соң Шәркый Төркестанга чиннәр агыла башлый. Монда нефть, кыйммәтле төсле металлар табылу, аннары Лоб-нор күле буенда атом коралын сынау үзәге төзелү, 1966—1976 еллардагы «мәдәни революция», шул дәвердәге милли азчылыкларны кысу һәм йоту сәясәте Шәркый Төркестандагы икътисадый, экологик хәлне һәм милләтара мөнәсәбәтләрне кискен үзгәртә. Рәсми мәгълүматлар буенча, соңра Шинҗаң-Уйгыр автономияле районы дип аталган Шәркый Төркестанда уйгырлар 1953 елда бөтен халыкның 74,6 процентын тәшкил итсә, 1967 дә алар монда 61,8; 1978 елда исә йөздән 41,5 кә генә кала. Казакълар 1953 тә — йөздән 9,7; 1967 дә — 8,0; 1978 дә 6,1 дәрәҗәсенә төшә. Чиннәр монда 1953 елда 6,1 проценттан артмаса, 1967 дә 22,4 не тәшкил итте, 1990 еллар башында исә 56 процентка җитеп («Төрек күлтүре» ж., 1994, № 369. 29 б. Анкара), төрки халыкларны тарихи ватанында азчылыкка калдырды.

«Мәдәни революция» елларында укымышлыларны хезмәт белән «тәрбияләү» тормышка ашырыла, зыянсызрак саналган кайберәүләр, эшеннән куылмаса, хәтта хезмәт хакын алып торса да, чынлыкта һичбер шөгыльгә җәлеп ителми, алар төрле төркемнәргә оешып «сайраша» — бер-берсен фаш итә. Бу «сайрашулар» чин булмаган милләт вәкилләренә гаять кыйммәткә төшүен укучыларыбыз да белә дип уйлыйм.

Гыйләҗетдин Госман болгавыр еллар көрәшендә катнашмый, бөтен көчен һәм сәләтен чин телен һәм әдәбиятын өйрәнүгә багышлый. Бу эштә аңа киңәшләре белән әнисе аеруча зур терәк була.

Әйтергә кирәк, ул инде бу дәвердә төрки телләрне һәм әдәбиятларны шактый ук тирән үзләштерергә өлгерә, уйгыр, казакъ, үзбәк, татар язучылары әсәрләре, төрки телләргә тәрҗемә ителгән бүтән СССР халыклары китаплары аның рухи җитлегүендә әһәмиятле урын тота. М. Әүэзевнең «Абай», Айбәкнең «Нәваи», М. Шолоховның «Тын Дон», А. Пушкинның «Дубровский», Н. Гогольнең «Үле җаннар» романнары, С. Щедрин әкиятләре һәм хикәяләре аңа аеруча көчле тәэсир итә. Кытайга казакъ телендәге китаплар күп китерелә, татар әдәбияты исә бик сирәк килеп ирешә. Шуңа күрә аңа кайбер татар язучылары әсәрләрен казакъчага, хәтта уйгырчага һәм үзбәкчәгә тәрҗемәләрдә генә укырга туры килә. Әнә шулай ул Г. Тукай, Һ. Такташ шигырьләре, К. Нәҗминең «Язгы җилләр» романы белән таныша. Балачагы милләттәшләре юграк җирдә үткәнлектән, Гыйләҗетдиннең татарча сүз байлыгы гаиләдә генә туплана. Тукай шигырьләренең асыл нөсхәсен аңлау өчен аңа шагыйрьнең казакъча һәм үзбәкчә басмаларын янәшә куеп укырга туры килә. Еш кына уйгыр укымышлылары да теге яки бу таныш түгел сүзләрне, гыйбарәләрне аңлатып җибәрә. Бу аңа туган телен камил үзләштерергә ярдәм итү белән бергә, татарлык үзаңын ныгытырга да булыша.

1958 елда ул Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повестен кулына төшерә. Әсәр аңа шулкадәр ошый ки, ул аны яшьтәше Мәрфуга Габбас белән бергә уйгырчага тәрҗемә итә. 1989—1990 елларда исә Гыйләҗетдин Г. Тукай әсәрләрен гарәп шрифтендә аерым җыентык итеп басарга әзерли һәм аңа сүз башы да яза. Моннан беркадәр элегрәк исә ватанында әле телгә алырга да ярамаган

«халык дошманы» Һади Атласыйның Сөембикә»сен дә нәшер итүне кайгырта. Шинҗәң халык нәшриятендә 1988 елда дөнья күргән «Татарларның кыскача тарихы» китабы исә аның җитәкчелегендә бер төркем Шәркый Төркестан татар зыялылары иҗат иткән асыл хезмәт.

Әмма, алдарак язылганча, Гыйләҗетдин Госман — чин теле һәм әдәбияты белгече, шуңа күрә аның укыган китапларының да кимендә өчтән берсе — кытай телендә. Әлегә кадәр игътибар белән өйрәнгән һәм казакъчага, уйгырчага тәрҗемә иткән әсәрләре дә — чин әдәбияты хәзинәләре.

— Мин чин классик әдәбиятының өч бөек әсәрен казакъ телендә чыгаруда катнаштым,— диде Гыйләҗетдин әфәнде.— Ло Гуәнчжонның (1330—1400) «Өч падишалык кыйссасы»н һәм Шы Найанның (XIV—XV) «Су буенда» күләмле романнарын редакцияләдем, Цао Сюэциннең (1715—1762) «Кызыл сарайдагы төш» эпик романының өч китабын тәрҗемә иттем.

Кытай реалистик романы үсешендә әһәмиятле урын тоткан әсәрләрнең иң күренеклеләреннән исәпләнгән «Кызыл сарайдагы төш»тә бай аксөякләр гаиләсендә туып-үскән бер егет белән кызның фаҗигале мәхәббәте сурәтләнә. Автор байлар тормышының әхлаксызлыгын, хатын-кызларның хокуксызлыгын гәүдәләндерә һәм кешенең кыйммәте, хөрмәт казануы аның кайсы катламда туып-үсүенә бәйләнмәгәнлеген исбатларга тырыша. Әсәр төзек, мавыктыргыч сюжете, каһарманнарының психологик яктан тирән ачылуы, кешелекле хисләр уятуы белән бүгенге укучыны да әсир итә, шунлыктан ул байтак Европа телләрендә дә басылып чыккан.

Затлы нәсел баласы, укымышлы һәм талантлы шагыйрь, рәссам Цао Сюэцин бу әсәрен язуга гомер көзендә генә керешә һәм аны тәмамлый алмый үлеп китә. Романның 120 бүлегеннән соңгы кырыгын 1791 елда Гао Э язып бетерә. Әсәр асыл нөсхәсендә дүрт том, казакъча исә сигез китап рәвешендә басылып чыга.




Гыйләҗетдин Госман. Аударма нигезе белемдәре *(Тәрҗемә нигезе белемнәре)*.

Бу атаклы әсәрне асыл нөсхәдән тәрҗемә итү тәрҗемәчедән бик зур әзерлек сорый, чөнки имтихан тапшырганда чиннәрнең үзләре өчен дә борынгы һәм урта гасырлар кытай теле чит телгә бәрабәр санала, 1919 елдан бирле әдәби тел генә бүгенгегә тиңләнә. Гыйләҗетдин әфәнденең кыен эшне уңышлы башкарып чыгуы аның телләр өйрәнүенә балачагыннан керешүе, тырышлыгы һәм моңа тумыштан сәләтлелеге аркасында мөмкин була. Бүгенге чин матбугатында җиде-сигез мең иероглиф файдаланыла, аларның байтагын кытайларның да күбесе танып җиткерми. Гыйләҗетдин әфәнде биш меңләп иероглифне укый-яза, шунлыктан ул үзен шактый зур белгеч санаган чин укымышлылары белән дә артык кыенсынмыйча ярышып эшли ала.

Г. Госман 1976—1980 елларда Шинҗәң халык нәшриятендә чин классик әдәбиятын казакъчага тәрҗемәләү бүлеге мөдире булып билгеләнә. Шушы дәвердә ул казакъ телендә «Тәрҗемә нигезләре» китабын язып бастыра, аннары шуны үзе үк уйгыр теленә дә тәрҗемә итә. Милләттәшебезнең филология өлкәсендәге эшләре — теоретик һәм гамәли хезмәтләре җәмәгатьчелек игътибарын казана, 1981 елда аны Шинҗәң-Уйгыр автономияле районының тел-язу комитетына тел бүлеге мөдире урынбасары итеп чакыралар. Бу комитетта йөзләп укымышлы эшли, аларның җитмеше фәнни тикшеренү белән шөгыльләнә, калганнары гамәли йомышлар үти. Гыйләҗетдин монда да үзен тырыш, иҗади эзләнүче галим итеп таныта — 1984 елда аны «Тел вә тәрҗемә» журналының баш мөхәррире итеп билгелиләр. Бу журнал сигез басма табак күләмендә әүвәл өч айга, аннары ике айга бер мәртәбә, соңра ай саен нәшер ителә башлый. Башта уйгырча гына дөнья күрсә, аннары берьюлы кытай, казакъ, кыргыз, монгол телләрендә дә чыгарылырга керешелә. Бу җаваплы эшне Г. Госман 1991 елга кадәр дәвам итә. Бер үк вакытта ул университетта да укыта: монда ул 1983 елда — доцент, 1988 елда профессор дәрәҗәсен казана. Матбугатта игълан ителгән утызлап гыйльми мәкаләсе, аерым китап итеп басылган «Кытай балаларын укытыр өчен казакъ теле дәресләге» һәм алда

саналган бүтән хезмәтләре белән Гыйләҗетдин Госман Шәркый Төркестанда яхшы ук билгеле шәхескә әйләнә. Аның әле Мао Цзедун шигырьләрен казакъчага тәрҗемә итүен, ул әсәрләрнең ике тапкыр (1964, 1968) аерым җыентык төсендә басылып чыгуын да онытмаска кирәк. Шуларга татарларны оештыру, аларның мәнфәгатьләрен кайгырту һәм бүтән җәмәгать эшләрен дә өстик.

**Шәркый Төркестандагы милләттәшләребезнең бер өлеше илленче елларда Казагыстанга, Кыргызстанга һәм Үзбәгестанга кайтып урнашуы, Харбин ягындагы милләттәшләребезнең әүвәл Кореяга һәм Япониягә, аннары Төркиягә һәм, хәтта, Австралиягә, АКШка һәм Канадага көчеп китүләре аркасында Кытайдагы татар колонияләре кечерәеп һәм зәгыйфьләнеп кала.** Голҗада һәм Чәүчәктә калганнары өлешчә Өремҗегә җыйнала, байтагы төрле төбәкләргә сибелеп, юкка чыгу хәвефе астында яши. «Мәдәни революция» дәвере милли азчылыкларны йотуны тагын да тизләтә, татарлар бер-берсе белән бәйләнеш тотудан да хәвефләнә башлый, «Рәсәй шымчысы» дип гаепләнергә сылтау бирүдән сакланалар. Шуңа күрә атаклы Борһан Шаһидиның — Кытай хөкүмәтендә эшләү шәрәфенә ирешкән татарның, үзен «Шәркый Төркестанның Аксу шәһәреннән Идел буена барып урнашкан бер уйгыр гаиләсендә тудым», дип танытуы да гаҗәп яки сәер күренмәскә тиеш.

— Мин Борһан абзыйны 1964 елда Пекиндә очраттым,— диде миңа Гыйләҗетдин әфәнде.— Ул татарча, урысча, кытайча бик яхшы белә, әмма уйгырчасы алай ук саф түгел иде. Мин аның Өремҗедәге туганнары белән озак еллар аралашып яшәдем, аларның берсе дә үзен уйгыр санамый иде!

«Мәдәни революция» тончыккач һәм маочылар ил җитәкчелегеннән әкренләп кысырыклап чыгарылгач, Кытайның милли сәясәте дә үзгәреш кичерә: җәберкысымнар йомшый, төрмәдәгеләр һәм сөргендәгеләрнең исәннәре иреккә чыгарыла, азчылык халыкларның диннәрен, телләрен, мәдәниятләрен саклау һәм үстерүгә беркадәр мөмкинлекләр ачыла. Казакълар туган телләрендә дистәләгән исемдә матбугат чыгара башласа, уйгырлар тиз арада өч йөзләп исемдә гәзитжурналга нигез сала, хәтта аз санлы кыргызлар да бер гәзит, ике журнал нәшер итәргә керешә.

**Өремҗе радиосы бөтен Шәркый Төркестанга тәүлек буе уйгырча сөйләп тора, аннан тыш, ул бүтән программалар буенча тугыз сәгать — казакъча, ике сәгать кыргызча тапшырулар алып бара. Пекин радиосының уйгырча ике сәгатьлек, казакъча бер сәгатьлек программалары бөтен илгә ишеттерелә. Өремҗе телевидениесе биш сәгать буе бары уйгыр телендә генә эшли. Телләр тиңлеге турындагы канун нигезендә Шәркый Төркестанда җыелышлар уйгырча алып барыла һәм ул бер үк вакытта чин теленә тәрҗемәләнеп торыла, казакъ, кыргыз, монголлар күпчелек тәшкил иткән төбәкләрдә милли статусларына бәрабәр рәвештә ана телләрен куллану, җитәкчелектә нисбәтләренә тиң күләмдә үз вәкилләрен эшләтү хокукы бирелгән. Әле кайчан гына уйгыр һәм бүтән азчылык милләт балалары кытай мәктәпләренә кертеп тутырылган булса, хәзер аларны монда алу махсус карар белән тыелган.**

Хәтта шунысы да гамәлгә ашкан — мөселманнарга хезмәт күрсәтә торган кибетләрдә дуңгыз ите сатылмый, гореф-гадәтләрне саклар өчен әнә шундый яхшы мөнәсәбәт тә күрсәтелә.

Ләкин бу хокуклар милли статуслары кануный танылган, нииндидер административ автономияле берәмлеге булган халыкларга гына гарантияләнә икән. Ә татар — чәчелгән, сибелгән, мондый хәлдә аңа милли хосусиятләрен саклау өчен һичбер ярдәм, хәтта теләктәшлек тә күрсәтелә алмый икән. Нииндидер хокуклар дәгъвалыйсың килсә, бергә җыйналудан башка чара юк.

Менә шуны ачыклагач, Г. Госман һәм бүтән күзе ачык милләттәшләребез татар автономияле авылын корырга карар бирә — өч йөзләп гаилә бер җиргә җыйналып, Чишмәгә нигез салалар. Идарә бинасы, башлангыч мәктәп, шифаханә төзелә, юллар тәртипкә китерелә.

Төрле төбәкләрдә яшәгән татарлар бергә туплангач та, милли мәсьәләне уңай хәл итү кыенлык белән бара. Чөнки милләттәшләребезнең күпчелеге инде туган телләрен онытып өлгергән була. Аларның байтагы, үз хатын-кызларыбыз җитмәгәнлектән, казакъка өйләнгән, мондый никахлардан туган балалар тышкы кыяфәте белән татарга охшаса һәм үзен татар дип санаса да, телләре йә саф казакъча, йә катнаш шивәдә ачылган. Шулай да гармун уйнау, татарча җырлау онытылып бетмәгән. Аңлы милләттәшләребез әнә шул җырлар, көнкүрештәге татар гадәтләре аша милли рухны, туган телне тергезүгә өметләнеп, җиң сыз-

ганып эшкә тотынган. Бу омтылыш Өремжедән татар һәвәскәрләрен алып килеп концерт куюдан башланып киткән. 1986 лның июнендә инде Чишмәдә беренче мәртәбә сабантуй уздырылган.


Бердән, чишмәлеләрнең милли рухын уяту, икенчедән, хакимияткә татар автономияле авылы барлыгын күрсәтү өчен, сабантуйга ныклап әзерләнәләр, бүтән җирләрдә яшәгән милләттәшләребез дә бәйрәмгә чакырыла. Тантананы әйбәт уздыру өчен хөкүмәттән акча алуга ирешелә.

Чишмә сабантуена читтән биш йөзләп кунак килә. Алар арасында Пекин һәм Өремже вәкилләре дә, Гарифулла Еники, Рауза Рәүф кебек җырчылар һәм биючеләр дә, Мәрфуга Габбас, Рәкыйп Габбас, Илдан Исхак кебек галимнәр, җәмәгать эшлеклеләре дә була. Шинҗаң-Уйгыр автономияле районы Халык Корылтае башлыгы Һамудын Нияз уйгыр һәм чин телләрендә сабантуйны котлап сөйләгән нотыгында:

— Без татарларны мәдәниятле, мәгърифәтле бер милләт буларак таныйбыз. Аларның һәммәсе укый-яза белә, җан башына югары белем алу буенча татар бүген дә автономияле районыбызда беренче урында тора. Татар зыялылары Шинҗаңне алга җибәрүгә мул өлеш кертте, һөнәрле, тырыш, ярдәмчел булулары белән күпләрнең ихтирамын һәм мәхәббәтен казанды. Без аларның матур традицияләре киләчәктә дә дәвам итәсенә ихлас ышанабыз, иҗади сәләтләрен юмарт ачып, икътисадта, фәндә һәм мәдәнияттә яңа уңышларга ирешүләрен телибез! — дип белдерә.

Бүтән кунаклар да шушындыйрак рухта чыгыш ясаганлыктан, Өремже һәм Чишмә үзешчәннәренең саф татар телендә җырлаулары шулай ук бик көчле тәэсир иткәнлектән, соңгы дәвердә беренче мәртәбә шушында бергә җыйналган милләттәшләребез аңнарын кыршаулап, күңелләрен юшкынлап торган куркушөбһәләрдән арына, уеннарда һәвәсләнеп, дәртләнеп катнаша һәм татар булуы белән горурланырлык бер хәлгә килә.

Моннан соң инде ел саен гадәткә кергән Чишмә сабантуйлары Кытайдагы милләттәшләребезне бергә җыя торган якты бер бәйрәмгә әйләнә, аны оештыруда 1987 елда барлыкка килгән һәм рәсми теркәлгән Шинҗаң татар телеәдәбиятын өйрәнү җәмгыяте, аның җитәкчеләре Рәкыйп Габбас, Зариф Дәүләтләр дә актив катнаша, Гыйләҗетдин Госман, Габдерәхим Габбас, Илдан Исхаклар бу эшнең үзәгендә кайный, Шинҗаң-Уйгыр автономияле районы җитәкчеләренең татар азчылыгына да илтифат күрсәтүенә ирешә. Бөтен Кытай Халык Корылтае депутаты, Шинҗаң-Уйгыр автономияле районы сәламәтлек саклау министры Рәкыйп Габбас, Шинҗаң университетының Урта Азияне өйрәнү институты мөдире, фәлсәфә фәннәре кандидаты Зариф Дәүләт, Шинҗаң университетының чин теле белгече, филология фәннәре кандидаты, доцент Мәрфуга Габбас һәм бүтәннәр Татар җәмгыяте эшен җанландыруга чын күңелдән алына-



«Кызыл сарай төше».

лар. Алар тырышлыгы белән Өремҗедә «Татар халык җырлары» (1988), «Татар җырлары нота белән» (1990), «Татар ашлары» (1992) китаплары бастырыла һәм милләттәшләребез арасында таратыла. Илдан Әсгать улы Исхак Татар җәмгыяте хәбәрләрен туплаган бер кулъязма журнал чыгаруны башлап җибәрә.

Татарларны яңадан бергә җыеп туплау, Шәркый Төркестанның төп милләте уйгырларның һәм икенче күп санлы халкы казакъларның теләктәшлеге булмаса, тиз һәм ансат кына гамәлгә ашмас иде, билгеле. Әмма икенче хакыйкать тә мөһим: милләттәшләребез аларның бу хөрмәтен һәм теләктәшлеген тырыш, хезмәт сөючән, кәсепчел-һөнәрле, чагыштырмача укымышлырак булулары, Уйгырстанның мәгариф һәм мәдәният арбасын гасырдан артык төпкә җигелеп тартулары белән казанган.

— Уйгырлар хәзер үзләре дә көчәйде, укымышлы белгечләре дә күбәйде,— диде Гыйләҗетдин.— Әмма алар татар зыялылары хезмәтен онытмый, «уйгырларга мәдәният-мәгърифәт чырагын татарлар яккан», дип һәрвакыт искәртә килә. Мин аларның әллә кайчангы татар, чыгтай китапларын кадерләп саклауларына хәйран калган идем. Кызганыч ки, «мәдәни революция» дәверендә Рәсәйдән, СССРдан китерелгән әсәрләр белән бергә, ул китапларның да күпчелеге юк ителде... Уйгырлар төрки халыклар арасында иң борынгы һәм бай тарихка ия булулары белән билгеле кавем. **Татарлар безнең эрага кадәр сигезенчеҗиденче йөзләрдә генә телгә алына. Тик шунысы кызык: уйгыр теле күршесендәге казакъ, кыргыз, үзбәкнекенә караганда, меңнәрчә чакрым ераклыкта яшәгән Идел-Урал татарлары теленә якынрак. Фонетикасы да, сүз мәгънәләре дә. Чөнки уйгыр белән татарның тамыры бер. Уйгыр, татар әдәби телләре якынаюында, шик тә юк ки, Алтын Урда дәүләтендәге ата-бабаларыбыз хезмәттәшлеге гаять әһәмиятле урын тота. Бу хәл уйгырларның татарны үз күрүенә тагын да бер җылы хис өсти.**

Гыйләҗетдин әфәнденең бу фикерләре безнең өчен яңалык түгел. Әмма уйгырлар арасында үскән, Шәркый Төркестан халыклары, җөмләдән, чин мәдәнияте казанында да кайнаган, димәк ки, алар күз карашын, кытай һәм уйгыр төшенчәләрен дә чагылдырган фикер рәвешендә игътибарыбызга лаек.

— Төрек-татарлар чин белән борынгыдан аралашкан,— диде ул.— Ханнарыбыз, аксөякләребез кытай кызларына өйләнгән. Бер чин кызын бер атка алыштырып алган заманнар да булган. Яу чапканда инде әсирләрне меңәрләп кулга төшергәннәр. Әнә шулай кан кушылган, гореф-гадәтләр якынайган, мәҗүсилек һәм будда диннәрен тотканда рухи аңлашу да киңәйгән. Чин тарихчылары шуңа күрә төркиләрне дошман күзлегеннән карап кына сурәтләми. Аларның чин мөхитендә эреп югалуларын да төркиләр арасында сәяси-милли аң, үзара бердәмлек, татулык җитмәүдән килеп чыккан, дип аңлаталар. Минемчә дә шулай. **Тарих кабатлана, менә хәзер татарлар үз тарихи ватанында урыс күпчелеге чолганышында калган. Сәяси-милли аңнары зәгыйфьлеге, үзара бердәмлекләре җитмәү аркасында иң гади нәрсәләрне дә әле һаман көйләп җибәрергә ирешмәгән: телевизорны кабызасың — татарча тапшыру юк, радионы элдерәсең — туган тел ишетелми.** Мин Казанга килгәч, бу хәлдән тәмам гаҗизләндем, үземне бәхетсезлеккә очраган, диңгез уртасындагы кыргый утрауга килеп эләккән Робинзондай хис иттем. Урысчаны аңламыйм, уйгырча, кытайча тапшырулар да юк. Бер күнеккән кешегә дөнья хәбәрләрен ишетми тору әҗәлгә тиң ич ул, бары шуның аркасында гына минем Өремҗегә кире кайтып китәсе килгән минутларым булды. Югыйсә, берәр каналны бары татарча гына эшләтүне хәзер Мәскәү тыймый ич инде, татар үзен-үзе генә кыса!

Без Гыйләҗетдин белән Татарстан хәлләре турында гәпләшә башладык.

— Татарстанда ошаган нәрсә булдымы соң сезгә? — дидем мин.

— Шәһәр борынгылыгын саклаган: кремле бар, Кабан күле, Болагы, Иделе, бакча-парклары, тирә-ягындагы урманнары ямьле. Татарстанның мәдәнияте булуы сизелә — шәһәр чиста, кешеләре затлы, матур киенә. Аннары... трамвай, троллейбус, автобусларга керсәң — тәмсез ис юк. Халык пакь,

юынып йөри. Мин Алмата, Ташкент, Истанбулларда булдым, чисталык ягыннан берсе дә Казанга житми. Шәһәрдә зыялылар күп, бу яктан Татарстан Уйгырстаннан өстен, билгеле. Милли, дини хисләрнең үсә баруы да ошады миңа. Әмма милли башкаласында яшәүче татар яшьләре туган телен белми, белсә дә, җәмәгать урыннарында кулланмый икән. Шаклар каттым шуңа!

— Сезнеңчә, Татарстан ничек үсәргә тиеш соң?

— Ул, халкыбызның тарихи ватаны буларак, чын татар дәүләтенә әйләнсен иде. Туган телебез авыл баскычыннан шәһәрнеке дәрәҗәсенә күтәрелергә, җөмһүриятебезнең милләтара аралашу чарасына әверелергә тиеш. Кухнядан, юрган астыннан урамнарга һәм мәйданнарга чыгарга, күкрәк киереп югары уку йортларына, фабрикаларга, парламентка керергә, шунда бөтен егәренә эшләргә тиеш. Татарча белмәгәннәргә дәүләтебез идарәсендә вазифа бирү туктатылсын иде!

— Ләкин боларны тиз генә эшкә ашыру кыен.

— Уйгырстанда да уйгыр теле жиңел генә гамәлгә куелгандыр, дип уйламагыз,— диде Гыйләҗетдин.— Көрәшсез генә бернәрсәгә дә ирешелми. Татарстанда хәзер икътисадый бәйсезлек өчен күп тырышыла. Дөрес сәясәт бу. Әмма милли мәгариф, мәдәниятне үстерү дә иң соңгы нәүбәткә куелмаса яхшырак. Татарстанны халыкара таныту, Берләшкән Милләтләр Оешмасы әгъзасы итү өчен армый-талмый хәрәкәт итәргә кирәк!

— Моңа көчебез житеп бетми шул әлегә.

— Таркау милләттәшләребезне тарихи ватанына җыйса, Татарстан бик тиз көчәер иде. Менә мин үзем улым Галипне дә Казанга тартам. Ул беренче класстан ук кытай мәктәбендә укыды, кытай, уйгыр телләрен бик яхшы белә, бәлки Татарстанда да андыйларның кирәге табылыр?

— Ә хатыныгыз, кызларыгыз Идел буена килмәячәкләрме?

— Хатыным Ханзат — кытай теле белгече, филология фәннәре кандидаты, доцент, Өремже радиосында чиннән тәрҗемәләрне күзәтә, университетта укыта. Ул — уйгыр милләтеннән, бөтен туганнары шунда яши, Уйгырстанны ташлап китмәс инде, мөгаен. Кызларым Галия белән Хөршидә дә югары белемле, беренчесе — физик, икенчесе — химик, алар икесе дә фән кандидаты булырга әзерләнә. Беренчесенең кияве Гайрәт уйгыр белән татар кушылган катнаш гаиләдән, чин телендә физика укыта. Икенчесенең кияве Габделхәким — саф уйгыр, япон, инглиз телләрен белә, галим. Кызларым берәр ул үстерә, кендекләре Уйгырстанга береккән инде. Алар уйгыр милләтен үстерүгә хезмәт итәчәк. Читтә азчылык булып яшәү, милли йөзебезне саклар өчен күпме генә тырышсак та, татарны әнә шулай йота бара. Хәвефле дә, кызганыч та язмыш бу!

Гыйләҗетдин Госман бәхетенә Казан компрессорлар заводы вәкиле Ринат Ибраһимов 1992 елда сәүдә эшләре белән Өремҗегә килгән. Табигый ки, ул монда яшәүче татарлар белән дә кызыксынган. Табышканнар, дуслашканнар. Шушы дуслык тарихи ватанда яшәп калган нәселне барларга, Гыйләҗетдинне Татарстанга кунакка чакырырга ярдәм иткән. Монда инде Казан университеты, Г. Ибраһимов исемендәге ТӘҺТИ галимнәре белән дә танышкан, хәтта академик Мирфатыйх Зәкиевнең аны үз институтына эшкә чакыруына шарт туган.

Теләсә кайсы җөмһүриятнең төп халкы, аның туган теле һәм мәдәнияте сәламәт үсә алсын, чит-ят тәэсирләргә, басымнарга бирешеп йотылмасын өчен, төп халыкның анда мотлак күпчелек тәшкил итүе, бигрәк тә фән, мәдәният даирәсендә, административ идарә һәм белгечләр катламында критик саннан югары ашуы хаҗәт. Тоталитар совет режимының шовинистик милли сәясәте Татарстанда нәкъ менә шушы шартларны булдырмауга юнәлдерелгән иде. Нәтиҗәдә андагы татар өлеше җитмеш ел дәвамында шактый кимеде, югарыда саналган әһәмиятле эшчәнлек тармакларында исә ул һәрвакыт азчылык тәшкил итте. **Критик үлчәмнән кимрәк туплану, шул азчылыкның да сугышчанрак өлешенең туктаусыз эзәрлекләнеп торуы һәм кырып ташлануы аркасында, татар халкы милли иммунитетын югалтты, шуңа күрә ул бүген дә, иркәле үсеш өчен мәгълүм хөррияләр ачылган дәвердә дә, сәламәт юлга ышанычлы рәвештә аяк басып кереп китә алмый. Азчылыкның гаҗизлек синдромын җую өчен тарихи**

**ватанын ташлап китәргә мәҗбүр булган милләттәшләребезне Татарстанга кайтару, аны үз көченә ышанмау тойгыларыннан арындыру, рухи халәтен савыктыру өчен, саналган дәрәҗәле, әһәмиятле секторларда мөмкин кадәр тиз арада төп милләтнең мотлак күпчелек тәшкил итүенә беренче нәүбәттә ирешергә кирәк.** Моның өчен дә иң нәтиҗәле чара — читтәге укымышлыларыбызны республикабызга кайтару.

Әмма безнең әле бүген мондый программабыз да, аны тормышка ашырырлык көчебез, гайрәтебез дә юк. Без Г. Госман кебекләрнең мең михнәт чигеп ерак бабалары нигезенә кайтырга җөрьәт итүләренә битараф, хәтта кайберләребез сукранып карап торырга гына гаярь. Кадерләрен белергә, андыйларга ярдәм кулын сузарга иде, чынлыкта бу ярдәм үзебезгә ләбаса!

Гыйләҗетдин Госман җиңел генә җыймаган белемен һәм тәҗрибәсен тарихи ватанына бирергә дип ерак Кытайдан Казаныбызга кайтты һәм бүген Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында төрки халыклар үткәнен сурәтләгән чин галиме хезмәтен туган телебездә басарга әзерли башлады, бүтән гыйльми тикшеренүләренә кереште. Шәркый Төркестанга киткән меңнәрнең берсе бабалары мең еллар гомер иткән нигезгә аяк басты. Тамырлары тирән, иншалла, ул монда икенче сулышын ачыр, буын ныгытыр, бәлки әле еракларда каңгырып йөргән башкаларда да газиз Идел-Уралга омтылу хисләрен дөрләтер.

**Иң мөкатдәс, мәгънәле яшәлә торган гомер — тарихи ватанда узганы, иң зур ихтирамга, мактауга лаек хезмәт — туган халкыңа багышланганы!**

**Тәүфикъ ӘЙДИ.**

Тәлгат Галиуллин



# КИЧЕРЕРЛӘР БЕЗНЕ, КИЧЕРЕРЛӘР...

(ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬЧЕ ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИННЫҢ ИҖАТ ПОРТРЕТЫНА ШТРИХЛАР)

Шыксыз көзге көннәрнең берсендә Татарстан Язучылар берлегенең рәис урынбасары Фәрваз Миңнуллинны «ак йорт»ка, дөресрәге, өлкә комитетының партия комиссиясе дип йөртелгән бүлегенә дәшеп алалар. Кулы белән буйый, теле белән сөртә торган бу дәһшәтле оешмага беренче чакырылуы. Ни өчен икәнен тәгаен белмәсә дә, күңеле белән чамалый: язучылардан берәр саксызы — Баттал, Батулла, Баянов кебек, фамилиясе «б» хәрефенә башланган берәрсе — матбагада уңышсыз шаярткандыр, мөгаен. Хәтәр хәлләр каләм әһелләрен мәкерле төлке төсле сагалап кына тора иде ул елларда. Кылмаган гөнаһларыңны сыларга да күп сорамыйлар иде торгынлык чорында.

Ни өчен рәиснең үзен чакырмаганнар, диярсез инде сез. Хикмәт шунда. Язучылар берлеге рәисе Гариф Ахунов СССР дип аталган илнең югары берлегенә икенче мәртәбә депутат булып сайланган. Аны һич «эләктереп» булмый. Шуңа да җаваплы келәмгә күпвакыт урынбасар эләгә.

Кесәсендә КПСС билеты йөрткән кешеләр өчен иң җайсыз бүлек хезмәткәре Валентина Липатникова була. Хәл-әхвәл сорашуга, аңлашуга, танышуга вакытны әрәм итмичә, ул төрле имзалар белән чуарланган бер бит кәгазьне өстәлгә сала. Чыраенда — тәкәббер тантана. Әйтерсең лә, рейхстагка кызыл әләм кадаган!

— Сез язган хатмы? Сезнең имзамы?

— Әйе. Язучылар оешмасы үтенече. Минем кул тамгасы аста,— ди, үрелеп карап Фәрваз Миңнуллин.

— Сезнең мондый хат язарга, әлеге үтенеч белән мөрәҗәгать итәргә хакыгыз юклыкны уйладыгызмы? Законнарны белмисез икән шул.

«Биш бирең алты аласым юк» дип фикер йөртә дә, язучыларны һәм үзенең имзасын аклау юлына баса Мөхәммәдулла улы.

— Ни өчен әле хакыбыз булмасын, ди. Без мөстәкыйль иҗади оешма, язучыларга мөмкин булган ярдәмне оештырырга тырышабыз. Бу — изге бурычыбыз.

— Дустыгыз өстеннән күп язалар. Ул хатларны укый-укый күзләремне бетердем.

— Эт өргәндә сандугач тик торыр, ди татар халкы. Аннан килеп, эте дә кешене өркетер өчен генә өрми, үзе куркып та шаулый.

— Сез иптәшегез эшчәнлегендә бер гаеп тә күрмисезме?

— Суның кадере кое кипкәч беленә,— ди шул ук халык мәкале. Кемнең хаклыгы соңрак күренер.

— Бу очракта, барыбер, хокукларыгызны арттыргансыз. Сезне, коммунист буларак, җәзага тартырга тулы нигез бар.

Начар атка кыңгырау такмыйлар. Фәрваз Миңнуллинның усал тәнкыйтьче, дәртле, өлгергән ир-егет вакыты, эше дә гөрләп бара. Ни өчен дип әле ул ясалма чәчле, иреннәре кебек үк калын пыялалы күзлекле, юан ханымнан үзен сүктереп, әрләттереп утырсын, ди?! Тузга язмаганны. Өлгергән карбыз төсле шартлый Ахунов ярдәмчесе. Аксыл чырае тагын да агара, чигә тамырлары ярсып тибәргә тотына.

— Язучыларның эчке эшенә тыкшынырга сезнең хакыгыз бармы соң? Бездә һәрнәрсәне идарә хәл итә. Алабугада яшәүче язучыга Зеленодол районыннан өч сутый җир биргәнбез икән, монда киртәгә сыймаслык бернәрсә күрмим.

Олы маңгаендагы сырларны бер тирәгәрәк туплап, бар усаллыгын соргылт-күгелҗем күзләренә төйнәп, нәтиҗә ясый.

— Сезнең оешманың башка, житдирәк эшләре юкмыни, туннан бет эзләп утырасыз!

Комсомол, фирка оешмаларында шактый тәҗрибә тупласа да, үз каршысындагы адәми затның гел дә салкын судан чыккан тавык төсле калтыранып утыруына күнеккән, ыржыктай байтак ирләрнең умыртка баганасын сындырган ханым бер мәлгә югалып кала һәм ялгыш җөмлә ычкындыра:

— Нинди оешмада утырганыгызны, кем белән сөйләшүегезне онытып җибәрәсез булыр, иптәш Миңнуллин.

— Мине куркытырга уйлыйсызмы? Өлкә комитеты — безнең төп йорт, язучылар белән турыдан-туры житәкчелек итүче культура бүлегендә мин көн аралаш булам. Ахыр чиктә мине аның мөдире Мөдәррис Мусинның гына чакыртып алырга хаккы бар. Сүздән ботка куертып утырырга вакытым юк минем.

Ханым, аптырагач, чөйне икенче яктан кага.

— Сез минем сорауларга җавап бирмичә, Алабугадагы иптәшегезне авыр хәлгә куясыз!

Ханымның тәкәбберлегенә елан агуы тамызып, ташының парын бераз чыгарган, сүз уңае килгәндә, сүтеген ямап алган Фәрваз, урындыкка иплә бр әк утыра. Янәсе, бер дәкыйка вакыты булмаса да, ул, мәсьүл кеше буларак, әңгәмәне дәвам иттерергә риза. Бу оешманың әле иблисне авызлыкларлык куәтле дәвере икәнен онытмый. Артык шаярырга ярамый.

— Сезнең ярдәмегез аңа начарлык булып чыкты,— дип дәвам иттерә сүзне Липатникова.

— Сез шулай уйлыйсызмы?

— Әйе, иптәшкә Казан яныннан дача салырга җир биреп, зур хата эшләгәнсез. Безгә бу хакта аның «дуслары» хәбәрне вакытында җиткерде.

Сүз көрәштерү, мантыйк кануннарын эшкә җигү мәсләгендә тәнкыйтьченең яшерен, эчке мөмкинлекләре турында хәбәрдар түгел иде шул парткомиссия әһеле. Фәрваз, килешле юан бармакларын бөгә-бөгә санап китә.

— Бердән, танылган әдәбият галиме һәм язучы безгә үтенеч-гариза белән чыкты. Язучының гозерен үтәү, ярдәм кулын сузу — безнең төп бурыч. Икенчедән, җирне без аңа айдан да, сез әйткән Казан яныннан да бирмәдек. Үзебезнең республикадан, Зеленодол районыннан өлеш чыгардык... Өченчедән, үзем булганым, күргәнем юк, ишетүемчә, җире кечкенә, ифрат начар, тимер юлдан да, Иделдән дә ерак. Шундый начар участокны алган, үзләштергән өчен без аңа рәхмәтле булырга тиешбез. Татар язучысы болай да саилче хәлендә. Дүртенчедән, аның йорты төзелеп бетмәгән, яшәрлек түгел, диләр... Бүлдермәгез, мин сезне игътибар белән тыңладым. Бишенчедән, язучы халкы ял вакытында, җәй айларында иҗат эше белән кайда шөгыльләнсен?! Язучылар йорты салып бирергә ярдәм итәр идегез, хет. Тыңлый белегез, үзегез чакырдыгыз.

Ниһаять, Евтушенко, Вознесенскийларның Кырымда да дачалары бар. Бабасы татар булган Бэлла Ахмадуллина Мәскәү янындагы Переделкинода берүзенә ничәмә гектар җир, урман алган. Йомшак авызлы бозауларга берничә ананы имү ярый. Ә сез монда сусыз, уңдырышсыз бер җирдә, мәхлук татар язучысына бирелгән Биктимер чикмәне чаклы җир өчен олыдан кубып утырасыз. Белүемчә, иптәш иманасын түләде, ике шелтә алды шуның өчен, сезгә ни кирәк тагын?!

— Кемнәр белән чагыштырасыз! Алар бит дөньякүләм атаклы язучылар.
— Аермасы юк. Барысы да СССР язучылары. Кемнең илгә файдасы күбрәктер әле, әйтүе кыен. Ярый, хушыгыз!

Тора да чыгып китә Фәрваз Миңнуллин. Липатникова шунда ук жалоба белән Мөдәррис Мусин кырына йөгерә, әмма үз кабинетына кабат чакыртырга җөрьәт итми.

Бүгенге ноктадан караганда сүз бик вак бер нәрсә — миңа Васильево яныннан бирелгән җир кисәге хакында бара. Аның өчен миңа фирка ике шелтә бирде!

Үз сәерлеге үзенә җиткән торгынлык чоры иде бу. Һәр елны диярлек йөз миллион тонна татар нефтен суырып алганга ияк йонын да селкетмәгән җирле фирка оешмасы бармак астыннан кер эзләүдән, иске туннан бет чүпләүдән тәм таба, дөресрәге, халыкны ана теле, милләте юкка чыгу кебек афәтләр турында уйланудан читкә алып китү юлларын эзли иде.

Узган эшкә салават дигәндәй, әлеге вакыйганы да мин Фәрваз Миңнуллин холкының бер үзенчәлеген ассызыклау максаты белән генә китердем. Бу сыйфат — авыр сәяси бүрәнә белән ярга китереп кысылган язучы халкына азмы-күпме җиңеллек эшләргә тырышу, иң явыз оешма якадан алганда да, бәйсезлекне югалтмаска омтылу, үз иманыңа тугры калу.

Әйе, ул һәр адымында җаны-тәне белән язучы халкын яклады, аның көнкүрешен азмы-күпме җиңеләйтеп булмасмы дип җанын фида кылырдай күрәште. Чөнки каләм иясендә Фәрваз Миңнуллин халык намусын, аның тарихын һәм киләчәген күрә.

Аның бөтен тормыш юлында һәм әдәби, әхлакый эзләнүләрендә максатлылык ачык ярылып ята. Арчадан 20 чакрым ераклыкта урнашкан Ишнарат авылында укыганда, бигрәк тә Арча педагогия училищесында белем эстәгәндә, ул киләчәген татар әдәбияты белән бәйләргә дигән ныклы карарга килә. Ә бит сугышка чаклы һәм, аннан кайткач та колхоз рәисе булып эшләгән әтисе Мөхәммәдулла юлыннан китеп, үзен хуҗалык, партия, совет эшләрендә дә күрсәтә алган булыр иде ул. Юк шул, күңеле башка юлга тарта.

Фәрваз Миңнуллин шул иманына, эчке чакыруына хәйран тугры калып, кырык ел дәвамында тәүге мәхәббәте өчен рухи ясак түләвен дәвам итә.

Университетта уку чорында ук фәнни-әдәби түгәрәкнең танылган җитәкчесе, старостасы була ул. Шул чорда ук эзлеклелеге, сүз сәнгатен үзенчә аңлавы, өстән төшерелгән әзер өлгеләрне, трафаретларны кабул итмәве белән аерылып тора. Гыйлем юлын сайлау өчен бөтен мөмкинлекләре бар иде аның.

Шуңа да татар әдәбияты кафедрасы мөдире Хатип Госманның аны аспирантурага чакырып алуын табигый, хак гамәл дип кабул иттек без — шул дәвер студентлары. Бу профессорның татар бүлеген калтыратып торган, данлыклы һәм үз шөһрәтенең иң түбәсенә менгән вакыты иде. Әмма холкы-фигыле белән үзенчәлекле кеше булып чыкты Хатип Госман. Гомерен шигырь өйрәнүгә багышлаган, хискә тиз бирелүчән бу шәхеснең эчендә кем утыруын күпләр белмәде. Дөресрәге, бу галим кул астына килеп кергән яшь галимнәрне ничек тә үзенчә, үзе теләгәнчә калыпларга ярата иде. Килешмәдеме, андыйлар белән араны өзә. Башын «имән бүкән»гә куйган Фәрваз язмышы да кагыйдәдән чыгарма булмады.

Сүзнең матурлыгы, яңгырашы, әдәбиятның үз эчке хасияте белән сокланып яшәгән аспирантны профессор марксизм-ленинизм кочагына өстери, партияле әдәбиятны өйрәнүгә көчли. Узаманнар заманасы булмаса да, Казан арты егете бирешми, үҗәтләнә, җитәкчесе белән арасын, алыш-бирешен кискен өзеп, язылып беткән диссертациясен ташлап, гамәли эшкә чума. Дус-ишнең күпме үгетләвенә, нәсихәтенә карамастан, бу мәсьәләгә кире әйләнеп кайтмый Фәрваз. Шик юк, тырышса, аңардан җитди фән әһеле, иң юк генә әдәбият укытучысы да чыгар иде. Чалбар төбен кызганмаса, иң кимендә урта кул прозаиклар рәтендә дә мөхтәрәм урынны алыр иде.

Виктор Шкловский: «Яхшы тәнкыйтьче кеше укырдай роман яза ала», — дигән. Ә Фәрвазга исә Ходай тәгалә язучы өчен иң кирәкле сыйфатны кушучлап биргән. Ул татар телен бик нечкә тоя, аңлый, аның иң тирән хасиятенә үтеп керә ала, аның тәмен, ләззәтен тулы сиземли. Бу илаһи байлыкны сатып алып та, гыйльми һәм гамәли дәреслекләр ятлап та үзләштереп булмый. Каләм иясе өчен беренче шарт булган бу сыйфат җыр һәм бию сәләте кебек үк, табигать бүләге. Фәрваз Миңнуллинны әдәби тәнкыйть юлына алып чыккан хәзинәсе дә әнә шул иде. «Казан утлары»нда бүлек мөдире, Язучылар берлеге рәисе урынбасары, Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият бүлеге мөдире, шул ук оешманың баш мөхәррире кебек әдәбият язмышына бәйле хезмәтләре аңа эчке табигатен камилләштерүгә мөмкинлек бирә. Әйе, тел, сүз — аның өчен могҗиза, халыкның

төп байлыгы, серле хәзинәсе. Шул ышаныч Джек Лондонның «Мартин Иден», Герберт Уэллсның «Күренмәс кеше» кебек ул тәрҗемә иткән әсәрләрдә, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники, Мирсәй Әмир, Мөхәммәт Мәһдиев, Аяз Гыйләҗев, Рафаил Төхфәтуллин, Нурихан Фәттах кебек сүз осталары иҗатына багышланган хезмәтләрендә җете чагыла. Тәэсирле һәм бер үк вакытта җыйнак тел тәнкыйтьчегә дә ярап куя икән, дип уйлыйсың. Аның мәкаләләре әдәби әсәр кебек җиңел, бер тын белән укыла. Ул корама, ясалма җөмләләр белән язылган әсәрләрне әйләнеп үтәргә тырыша. 1960 елда дөнья күргән «Нәби Дәүли» исемле тәүге чыгышында ук аның зәвыгы төсмерләнә. Язучыга биргән бәясендә дә ул матурлыкны юлдашы, маягы итеп ала, рухи балкышка-тел бизәкләренә ифрат игътибарлы. Әмирхан Еники иҗатына мөнәсәбәте аеруча җылы. Аның турында язганда холкы үзгәреп, яңарып, пакьләнеп китә төсле тәнкыйтьченең. Сугышны үзәккә алган әсәрләрендә дә «Әмирхан Еники күбрәк хисләр киеренкелегенә, рухи һәм психологик халәткә игътибар юнәлтә»,— дип яза ул.

Әсәрләрнең тәэсир көчен тәнкыйтьче шигъри ялкын, табигый сизгерлек белән ачып бирә: «Күздән яшь китерә, бәгырьне телгәли аның әсәрләре... гүяки алар каләмне язу карасына түгел, ә бәлки хискә-моңга-сагышка манып язылганнар. Аның әсәрләрендә, моң-сагыш белән бергә, сине сафландыра һәм пакьләндерә торган, сине баета, зур эшләргә дәртләндерә һәм канатландыра торган рухи көч тә бар...»

Мавыктыргыч вакыйгалы, чытырман сюжетлы, холыклар кискен чәкәләшкән әсәрләргә бәя биргәндә дә ул, беренче чиратта, язучының тел байлыгына, эслүбенең җырлап, җөе җөйгә ятышып торуына игътибар бирә.

Моннан килеп, тәнкыйтьче инде әдәбиятта тәгаен үз урынын тапкан, мөхтәрәм һәм абруйлы язучылар чапанына гына ябышып йөри икән, бәхәсле, катлаулы әсәрләрне әйләнеп үтә икән, ифрат хәйләкәр абзый икән, дигән фикер калырга тиеш түгел. Үзенең «Үр артында үрләр бар», «Хикәя һәм хикәячеләр», «Реаль хәлләргә күз салыйк» кебек мәкаләләрендә әдәбиятчы шактый катлаулы, четерекле мәсьәләләрне үзәккә ала, мисалларга таянып, гомумтеоретик фикерләр калкыта, татар прозасының үсеш юлларын, ачышларын һәм күләгә төшкән аланнарын барлый.

Аның «Романга ни булды?» исемле чыгышында М. Хәбибуллин, Җ. Рәхимов романнарына биргән кискен бәясе бүген дә заманча яңгырый, производство, колхоз-совхоз тәртәсеннән авырлык белән чыга килгән прозаның катлаулы халәтен аңларга булыша. Ләкин биредә дә Ф. Миңнуллин гадел шәхес булып кала алган. Ул әлеге язучыларга бәһасен, томанга төрмичә, ачык һәм төгәл итеп ярып сала, ярымтөсләргә урын калдырмый.

Татар телен бөтен камиллеге белән үзләштерүне таләп итә ул каләмдәшләреннән. «Язучыларның унынчы һәм унберенче съездлары арасында безгә 17 роман басылган,— ди ул «Кичермәсләр безне, кичермәсләр» мәкаләсендә.— Кода-кодагыйлыкны оныта төшеп, таләпчәнлекне аз гына арттырганда, аларның санын җиңел генә 10га җиткереп булыр иде. Чиле-пешле 10 роман басылмый калганнан, билгеле, татар прозасы берни дә югалтмас иде».

Язучылар союзын төрле юллар белән графоманнар басып китүенә гарьләнеп, әрнеп, ул шундый сораулар куя: «Ходаем, кая барабыз? Әйтегез әле, кемгә кирәк бу?».

Җаны әдәбият белән яшәгән кеше генә шулай сыкрана ала. Табигый тыйнаклыгы аның усал тәнкыйтьче булуына зарар китерми. Сорылык, халтура белән очрашканда ул янына дошман килгән керпе кебек энәләрен тырпайта.

Әйтик, үзенең Г. Әпсәләмов иҗатына битараф булуын яшерми («Безнең прозада сугыш темасы»). Әдипнең ясалма романтик, кабарынкы рухлы романнары тәнкыйтьченең күңел кыңгырауларын хәрәкәткә китерә һәм хисси дөньясын баета алмый. Ә бу — Г. Әпсәләмов романнарын бөтен ил ябырылып укыган чор иде.

Тәнкыйтьче сугышны яшәеш ваклыклары, нечкә психологик күзәтүләр аша тасвир кылу юлына баскан Хисам Камалов әсәрләрен яклап чыга, бу төр прозаның киләчәген шунда күрә.

Сугышны бизәмичә, фаҗигале авырлыгы, көндәлек мәшәкатьләре белән күрсәткән өчен Виктор Некрасов заманында («В окопах Сталинграда») илдән сөрелде. Дөньяны танып-белү, сурәтле күзаллау алымнары, психологизмы белән урыс язучысына якын юлдан атлаган, артык җылауда, әрнүдә, балавыз сыгуда гаепләнгән ~~Хисам~~ Камалов эзләнүләренә дөрес бәяне Ф. Миңнуллин бирде.

Х. Камаловның төп үзенчәлеге «Бик тә гадиләштереп һәм гомумиләштереп әйткәндә, аны сугыш турында дөресен язу, сугышның кырыслыгын һәм рәхимсез-

леген күрсәтү, кырыс буяулар белән язылган хакыйкать дип атарга булыр иде». Хәлбуки, тәнкыйтьче Х. Камалов теленең шактый катлаулы булуын, урыны-вакыты белән тәрҗемәгә охшап китүен искәртүне дә кирәк саный.

Тарих сугыш темасына иҗат иткән язучыларны үз киштәләренә утыртып чыкты. Шул ук вакытта Ф. Миңнуллин көн кадагына суккан, вакыйга сөйләү, каһарманнарны маңгайга-маңгай терәп, күз яше чыгару юлына баскан яисә башкача булдыра алмаган язучыларга да әдәбият ишеген шап итеп ябып куймый. Тик алар сүз осталары — затлы язучылар, сүз рәссамнары рәтенә дәгъва гына итмәсеннәр, түрдән урын дауламасыннар.

Тәнкыйтьченең игътибар үзәгендә хәзерге әдәбият булса да, ул мирасны да читләтеп үтми. Бу яктан аның Галимҗан Ибраһимов иҗатына бәясе үзенчәлекле, гыйбрәтле.

Әдипне тоташ мактап, олуг революционер, большевик, күренекле җәмәгать эшлеклесе, һәрьяктан үрнәк-өлге шәхес итеп күкләргә чөеп йөргән чорда Ф. Миңнуллин аңа карата шактый четерекле башкорт сүзе — «узаман»ны кулләнә.

Һәр өлкәдә алда, беренче, узаман булырга омтылуы Г. Ибраһимовның иң төп сыйфатларыннан, ди тәнкыйтьче. Ләкин замана, «власть өчен көрәш узаманнарны да аяп тормаган. Аларны бигрәк тә аяп тормаган төсле... Кайчакларда Галимҗан Ибраһимов күз алдына революция солдаты булып түгел, ә бәлки аның корбаны булып килеп баса. Хәзер без аларның барысын да уптым-илаһи шәхес культы корбаннары дип йөртәбез. Хәлбуки, термин төгәл түгел...»

Г. Ибраһимовның иҗатын һәм шәхесен яңача бәяләргә омтылыш бүген бәхәс уятмый. Ә тәнкыйтьче әзер калыплардан, коры социологик бәяләрдән арынырга омтылышны инде күптән ясады.

Тәнкыйтьченең иҗат юнәлешен әдәбиятта матурлык, ләззәт эзләүгә, нечкә зәвыкка, халтураны, сорылыкны, уртачалыкны кабул итмәүгә генә кайтарып калдырсак, бу ифрат берьяклы булыр иде. Ул «әдәбият — тормыш агышына тәэсир итәрлек, аны уңай якка үзгәртерлек олы иҗтимагый көч» дигән ышанычта яши, шуңар да язучының дөньяга карашын, позициясен ачуга әһәмият бирә. Мисал рәвешендә аның вакыт ягыннан иң соңгы мәкаләләреннән — «Балта явызлар кулында» язмасына тукталасы килә. Тәнкыйтьче Аяз Гыйләҗев иҗатына шактый төпле, нигезле һәм әтрафлы бәяне берничә биткә сыйдыра алган. Сүз күренекле прозаик, үзенчәлекле драматург, үткен каләмле тәнкыйтьче, очеркист, кыскасы, шактый күләмле әдәби әсәрләр тудырган шәхес турында бара. Тәнкыйтьче А. Гыйләҗев иҗатының буеннан-буена сузылган үзәк сәяси юнәлешне эзли. «Коммунистик диктатура һәм шәхес, социализм һәм гаделлек кебек мәсьәләләр А. Гыйләҗев иҗатында төп урынны алды. Шул чордагы норматив әдәбият иске тормыш күренеше, капитализм калдыгы дип раслап килгән гарип күренешләрнең (икейөзлелек, әхлаксызлык, имансызлык, эчкечелек, караклык һ. б., һ. б.) байтагын ул совет чынбарлыгы үзе тудырды, алар социализмның үз җимеше, дип барды. Шуның белән партия алга сөргән лозунгларның дөреслеген, без табынган идеалларның изгелеген шик астына алды. Утны капитализм өстеннән социализм өстенә күчерде. Безнең әдәбиятка Аяз Гыйләҗев алып килгән иң зур яңалык шул иде».

Биредә язучының төп иҗат казанышы, тормыш маддәсе ачык ярылып ята: яратып тасвирлаган кыйбласын да тәнкыйтьче берничә җөмлә белән ярып сала. «А. Гыйләҗев үз иҗатында Галимҗан һәм Хәбибрахман карт, Шәмсегаян һәм Бибинур карчык кебек саф күңелле, намуслы, тырыш, уңган хезмәт кешеләренә күп урын бирә. Шулай да аның аеруча яратып, үз итеп һәм җан җылысын салып тудырган геройлары — яшьләр. Алар арасындагы мәхәббәт хисләрен тасвирлаган төшләр аның әсәрләрендәге иң матур урыннардан санала».

Мәкаләне тулысы белән үзегез укырсыз. Әмма шул ике өзектән дә үзенең фәлсәфи дөньясы, сәяси-икътисадый хәлләргә бәясе, уңай һәм тискәре каһарманнары, илаһи мәхәббәтләре белән, сокландыргыч вакыйга-хәлләр аша ачылган җанлы кешеләр килеп баса. Кемнәрдер шул кечтеки мәкаләдәге фикерләрне киңәйтеп, җәеп, тирәнәйтеп, А. Гыйләҗев иҗаты турында китаплар, диссертацияләр язар әле.

Еш кына Ф. Миңнуллин үз мәкаләләренең исемендә үк язучының бер үзенчәлеген калкытып куя. Әмирхан Еники иҗатына багышланган мәкаләне «Затлылык» дип атый икән, тәнкыйтьче матурлык кануннарына юл ала, әсәрләрне нәкъ менә шул ноктадан килеп тикшерә.

«Яшьлекне сагыну» гыйбарәсе Мөхәммәт Мәһдиевнең иҗатына яңача күз салырга юл ача. Чыннан да, аның бөтен язганнары диярлек яшьлеген җырлауга,

малай, үсмер, егет чаклары үткән 30—50 еллар татар авылы тормышын, татар рухын, моның нәзакәтен, фикерләү рәвешен аңлауга багышланган икән. Кызганыч, әмма яшьлеккә хәтер канатында гына кайтып була шул.

Әхсән Баяновның шагыйрьлеге аның прозасын «кыерсытып», рәнҗетеп килде. Язучының чәчмә әсәрләрен җентекле, тәфсилле өйрәнгән, прозасына анык бәя биргән кеше Ф. Миңнуллин булды. Ул Ә. Баяновны прозаик буларак ачты.

Татар тарихи романына яңа рух, җан өргән Нурихан Фәттах иҗатына «Үткәннәрдән гыйбрәт ал» дигән билгеләмә дә бик муафыйкъ, килешеп тора.

Дөнья әдәбиятыннан хәбәрдар булса да (тәрҗемә өчен инглиз-америка әдәбиятын алуны искәртик) Фәрваз Миңнуллин өчен татар сүз сәнгате — бөекләр арасында тигез хокуклы. Кайберәүләр төсле ул «кыргызның Чыңгыз Айтматовы, Башкортстанның гел абруйда йөртелгән Мостай Кәриме, Дагыстанның йөзек кашы Рәсүл Гамзатовы бар, без хәзерге әдәбиятка кемне бирдек, ни өчен безләрне танымыйлар, санга сукмыйлар?» — дип лаф ормый, вакланмый, урыс әдәбияты казанышларына мөкиббән китеп, татар язучыларын кимсетү, түбәнәйтү юлына төшми. Һәр милли әдәбиятның үз казанышы булу өстенә, язучыларга ранглар биргәндә, бүләкләр таратканда олы сәясәтнең катнашы барлыгын да аңлый һәм аңлатырга тырыша.

Шул ук вакытта ул, кайбер талымсыз тәнкыйтьчеләр кебек, теләсә кем турында язмаган, ә үз рухын белгән, эчке дөньясын тетрәткән әсәрләрне генә тикшерү, өйрәнү үзегенә алган. Аз язуы, сан һәм күләм кумавы — бәлки аның нәзберклеге, сайлануы, әсәрләрне җиз иләк аша уздырып бәяләве белән аңлатыла торгандыр. Бәлки бу сүзнең кадерен белеп, иң кирәген, күңелдә, йөрәктә җәрәхәт, шатлык калдырганнары турында әйтми калу мөмкин булмаганда гына каләмгә тотыну галәмәтедер? Тәнкыйтьне җитди иҗади шөгыль дип караудандыр бәлки... Кистереп әйтүе кыен. Сибгат Хәким әйтмешли, белгәннәр тик тора. Шунысы хак: ул үзенә тыңгы бирмичә эзләнә. Гомере буена яхшы әсәр һәм үз бәхетен эзли.

Гадәти кануннарга буйсынып һәм шома, «шыпырт» кына яши белмәве аңа тормышында мәшәкатьләрне аз тудырмады. Матавыкны гүя ул үзе эзли. Дәрәҗәлерәк эшкә күчтеме, аның бераз эреләнеп, иркәләнеп, мендәр өстенә аягын бөкләп утырып аласын көт тә тор. Теләсә кем алдында түгел, иң якын дуслары, туганнары белән мөнәсәбәттә булыр бу хәл. Анысы да, бәлки, рыясызлыктан, һәрнәрсәне чынга кабул итүдән килә торгандыр. Каен тузы тиз яна бит... Фәрваз да тиз арада җиргә төшеп, үз гадәти халәтенә кайта һәм үзенең «Малайлар, бу дөньяда без — бер генә тапкыр, әлегәчә начар яшәмәдек, киләчәктә дә шулай булсын»,— дигән атаклы җөмләсен кабатлый.

Күбебездән аермалы буларак, аңа көнләшү хисе, кемнеңдер уңышына, байлыгына, табышына яки сөяркәсенә кызыгу дигән нәрсә хас түгел. Менә шул асыл сыйфаты белән ул мәгънәсезлек, мокытлык, хөсетлек чорында да үзен саклап кала алды. Җилгә карап бөгелмәде, сыгылмады, **тәнкыйтьче Фәрваз Миңнуллин** булып кала алды.

Дуслары күп булса да, сәлам бирмичә әйләнеп үтә торган дошманнары юктыр аның. Әлбәттә, үпкәләп йөрүчеләре булыр, ансыз дөнья сансыз. Күрәсең, бу аның киң холыклы булуыннан һәм ихласлыгыннан килә торгандыр.

Язучыларның 1989 елгы корылтаенда ясаган нотыгын ул шагыйрь сүзләре белән «Кичермәсләр безне, кичермәсләр» дип атаган иде. Берәүне дә кызганып тормыйча, шулай хак сүзне ярып әйтте ул. Ә Фәрваз Миңнуллинның үзенә карата «Кичерерләр безне, кичерерләр» дип үзгәртсәсе килә бу җөмләне. Шулай дөресрәк булыр.

**Фәрит Яхин,**
филология фәннәре кандидаты

# ӘХМӘТ ЯСӘВИНЕҢ МИРАСЫ

Әхмәт Ясәви һәм аның иҗаты белән кызыксынуым күптәннән килә. Хикмәтләре белән беренче тапкыр танышкач та исем китте: мин боларны беләм түгелме соң! Күңелемнең кайсыдыр төпкелендә аларның нуры бардыр төсле иде. Таныш, бик тә таныш иделәр миңа ул хикмәтләр. Әмма кайдан, кайчаннан бирле? Борынгы китаплар укыганда, колагымны куеп тыңлап торырлык әби-бабаларым да булмады, күрше-күлән арасында да андый кеше юк иде. Безнең очта — яшь гаиләләр башында — күренгән өлкәнрәкләр дә «советский»лар. Авылыбыз да әллә ни зур түгел. Сарман төбәгендә Дүсем дип атала. Мәгънәсен һичкем төшенми. Үсә-үсә генә белдем: «Дусмөхәммәт» дигән сүздән кыскартылган икән, Әлмәт кебек. Ул да бит Әлмөхәмməттән алынган. Авылда бер кыйсса йөри: имеш, борын заманда өч туган безнең якларга ислам динен китергәннәр, әүлияләрдән булганнар. Авылга каршы тауга күмелгәннәр алар. Шуларның берсе — Дусмөхәммәт, икенчесе — Әлмөхәммәт икән. Соңыннан бу сүзләрнең «Тәварихы Болгария» китабында да язылганлыгын белдем. Әүлияләрнең чишмәләре дә булган, әмма ул җиргә киткән, ташлары булып, алар да югалганнар. Кем белә, бәлки Әхмәт Ясәви әүлияләре булганнардыр алар, Дусмөхәммәт белән Әлмөхәммәт (Әхмәт)?

Бер сөйләшүдә авыл картларына Әхмәт Ясәви хикмәтләрен китаптан укып күрсәттем, ни-нәрсә икәнлеген әйтмәдем. Аларның сак колаклары үрә торды. Күзләре яшьләнде. Чөнки таныш әйберләре иде. Нигә дип таныш булмасын ди, аларның ата-бабалары яттан укыган хикмәтләр бит алар. Соңрак бу авылдан кемнәр генә капчык-капчык китап алып китмәгән? Әмма ул нөсхәләрнең яңгырашы-авазы күңелләрендә калган.

Әхмәт Ясәвинең иң бөек хикмәте дә шунда дип беләм мин: гасырлар аша килеп тә, аның иҗаты үз көчен, үз әһәмиятен, үз киләчәген, үз кадерен югалтмаган. Нөсхәләре югалса да, хисе-моңы халыкның күңелендә калган һәм буыннан буынга күчеп бара. Китапны кулына алып укый башлаган һәркем моның шулай булуына инаныр.

Әхмәт Ясәви иҗатын өйрәнүчеләр, беравыздан диярлек, аның хикмәтләрен реакцион юнәлештә дип билгелиләр, чөнки ул Ахирәт көне белән яшәргә чакыра, чөнки ул «үлемгә» таба дәшә, чөнки ул бу фани дөньяны ташларга куша, байлыклардан, рәхәтлекләрдән йөз чөерүне өстен күрә, ул диндар. Әйе, өстән-өстән генә тикшергәндә, бәлки бу шулайдыр, әмма аның фәлсәфәсенең асылына төшеп карасаң, бүтән нәтиҗәләргә киләсең һәм кайбер галим-голәмәнең никадәр ялгышканлыкларын күрәсең. Социаль-дарвинизм теориясе буенча «кеше кешегә дошман, яшәү өчен көрәш бара һәм кем кемне» дигән максаттан чыгып, хайваният вә вәхшилек кануннары белән яши кешелек. Дарвин үзенчә моны дәлилләп кенә чыккан, әмма бу караш дөньяның үзе кебек үк иске. Бу караш яшәешнең асылы булып торыр иде дә, әгәр дә адәм балаларында намус, вөҗдан, рух кебек хәзинәләр булмаса... Димәк, рухи дөнья үсеш ягыннан артка кала башлый икән, ул вакытта хайваният вә вәхшилек кануннары өстен чыга һәм кешелекне харап итәчәк. Ә рухи дөньяның кадере артса, һәлакәт артка чигенәчәк.

Суфичылыкның һәм бөек Суфи Әхмәт Ясәвинең төп фәлсәфәсе менә шуңа нигезләнгән, ул — һәлакәттән котылу һәм кешелекне коткарып калу тәгълиматы, ул — ислам диненең тирәнлеген аңлауда олуг бер баскычка күтәрелү. Аннары кешелекне саклап калуга һәм аның үсеше өчен хезмәт итәргә юнәлдерелгән иҗат һич тә реакцион була алмый. Юк, Ясәви үзе Дарвин дәверендә яшәмәгән, әмма хайваният вә вәхшилек кануннарының Җир йөзендә хөкем сөргән күрми калмаган. Чөнки дәүләтара сугышлар, мал өчен тарткалашулар, үтереш вә суешлар ул вакытларда мәрхәмәтсезрәк вә аяусызрак булганнар. Күңел күзе ачык кеше аны күреп торган һәм бу һәлакәттән котылу юлын эзләгән, эзләгән һәм тапкан: ул — таянычсыз вә мәгънәсез дөньядан баш тарту, Ахирәт кеше белән яшәү, Аллаһе Тәгаләгә коллык итү, ягъни ялтыравык тышкы дөньялыктан рухият дөньясына күчү, бәхет-сәгадәтне шунда табу!

Әхмәт Ясәви үзенең дини-суфичылык карашларын «Фәкыйрьнамә, яки Беренче дәфтәр»ендә бәян итеп бирә һәм шәригать таләпләрен тәгәл үтәми торып, дин юлына, мөселманлыкка керү мөмкин түгеллеген аңлата. Дин юлына керү һәм гомерең буе шул юлдан тайпылышсыз хәрәкәт итү, яшәү белән генә Аллаһе Тәгаләнең мәгърифәтенә төшенергә мөмкин. Ә бу исә Җир йөзендәге күренгән һәм күренмәгән барлык серләрне аңлауга, ягъни хакыйкатькә китерә. Шул вакытта гына дин иясе мөселман чын мәгънәсендә диндар, кирамәт иясенә әверелә һәм Аллаһе Тәгаләгә якынлаша.

Суфичылык карашы буенча, Аллаһе Тәгаләгә ирешү ул — дөньядан ваз кичү, байлыктан, гаиләдән, һәртөрле теләкләрдән баш тарту, үлгәнгә кадәр үлү белән олуглык вә бөеклек табу. Суфичылыкның иң югары баскычы — «фәна филлаһ», ягъни үлем белән Хак Тәгаләгә ирешү. Әмма бу үлем төшенчәсен физик һәлакәт белән турыдан-туры янәшә куеп карарга ярамый. Һәркем үлә. Падишаһ та, фәкыйрь дә, әүлия дә, пәйгамбәр дә, денсез дә, динле дә һ. б. Бер генә бәндә дә үлемнән котыла алмый. Әмма ничек итеп үләсең соң? Кяфер хәлендәме, әллә инде чын мәгънәсендәге Аллаһе Тәгалә колы дәрәҗәсендәме? Берәүләрнең үлеме тәмугка китерә, икенчеләрнеке исә — җәннәткә. Җәннәтле булу, шуның өчен бар көчне, акылны, хыялны һ. б. сарыф итеп һәркемнең тырышырга хакы бар. Суфичылык исә шушы мөмкинлекнең иң нечкә вә катлаулы юлларын өйрәнгән һәм шуның өчен көрәшкән.

«Фәна филлаһ» мәсьәләсен аңлатканда, иң беренче, Мөхәммәт пәйгамбәрнең мигъраҗын искә төшерергә кирәк. Бу мигъраҗ вакытында Мөхәммәт галәйһиссәлам җиде кат күкләргә, җиде кат тәмугка, Аллаһе Тәгалә хозурына сәяхәт кыла. Бу вакытта ул әле Мәккәдә яши (622 ел). Шушы мигъраҗыннан соң мөселманнарга үткәннән һәм киләчәктән, күкләрдән, җирләрдән, галәмнән төрле-төрле серләр ачыла. «Фәна филлаһ» та нәкъ менә шундый «мигъраҗ»дан дип исәпләргә кирәк. Әмма бу гына мәсьәләнең барлык якларын да ачыклап бетерә алмый. Моның өчен суфичылык тарихына бераз сәяхәт итеп алырга кирәк.

Беренче суфилар, оешма буларак, 815 елларда (һиҗри белән 200 елларда) Мисырда барлыкка килә. Билгеле булганча, Мисыр — Йосыф пәйгамбәрнең яшәгән җире, Муса пәйгамбәр шушында туган, башка пәйгамбәрләр дә монда булып киткәннәр. Нил елгасының түбәнге агымы — тәрсә-җәһүд, ягъни христианнарның һәм бигрәк тә монахларның бишеге булган. Ислам дине бу төбәкләрдә җиңүгә ирешкәч, күп кенә монахлар, христианнар диннәрен алмаштырган һәм мөселман булып киткәннәр. Суфичылык исә нәкъ менә шушы җирлектә яхшы үсеш алган да. Беренчедән, шәригатьне тәгәл белү һәм аны мөкәммәл рәвештә үтәр һәм үтәтер өчен суфичылык идеологиясе көчле этәргеч ясаган, иманга килгән бәндәләргә ислам кануннарын күңелләрендә ныгыту өчен терәк рәвешендә калкан булып күтәрелгән. Әмма чын мәгънәсендәге беренче суфилар Мисыр казые Ибен Әл-Мөнкадир (вафаты 827—829 еллар) яклавы астында булган Габдеррахман Суфи вакытында ныклы җирлеккә баса башлыйлар. Үзләренең оешмаларын суфиййа дип атыйлар. Габдеррахман Суфи аларның идеологына әверелеп, шәехләре дәрәҗәсен ала, аңа иярүчеләр мөридләр булып китәләр һәм, хаҗ сәфәренең бер үзенчәлеге буларак, Мисыр иленә, ягъни суфилар оясына баруны алар кертәләр һәм үзләрен чын мәгънәдә Хак Тәгалә коллары итеп күрсәтәләр. Җир йөзендә кылынган барлык гөнаһлары өчен тәүбә итү, үз-үзләрен физик җәзага тарту, кыйнау, җәберләү аша рухи чисталыкка һәм Аллаһе Тәгаләнең ярлыкавына өмет итәргә мөмкинлек юлын да шушы суфилар ачыклыйлар. Мисыр химаячысы, әлхимик Зөн-Нун (859 елда вафат) суфичыларның идеологиясенә бик зур этәргеч ясый. Моннан соң суфичылыкның чәчәк аткан урыны Багдад тирәсенә күчә. Бу яклардан дистәләгән олуг шәехләрне атап үтәргә мөмкин. Бигрәк тә Әс-Сари Әс-Сакатины күрсәтеп үтмичә мөмкин түгел. Беренче буларак, ул

Тәүхид, Хакаикъ, Мәкамәт, Әхваль гыйлемнәрен бәян итеп чыга. Тәүхид гыйлеме Аллаһе Тәгаләнең Берлеген вә Барлыгын тану аша, аның белән генә яшәү рәвешен, ягъни Хак Тәгалә әмере белән генә Ахирәткә фикер куеп яшәү рәвешен бәян итә. Ул гына да түгел, бер Аллалык гыйлемен фәлсәфи аңлау юлын ачыклап бирә. Хакаикъ гыйлеме исә диннең яшерен һәм күпләргә аңлаешсыз булган серләрен төшенергә өйрәтә. Хакаикъ — күренүче вә күренмәүче барлык серләрнең фәлсәфи нигезен аңлатуга багышланган фән өлкәсе. Мәкамәт — Аллаһе Тәгаләгә камил рәвештә ирешү һәм лаеклы булу баскычларына багышланган фән. Әхваль гыйлеме исә — «Гыйльме халь», ягъни мөселманлылыкның биналарын төгәл өйрәтә торган өлкә. Бу рәвештә системага салу суфичылар өчен шактый файдалы булып чыга һәм диндарлыкка ирешү өчен туры юллар ачыкланылып күрсәтелү аркасында суфичылык ислам илләрендә тагын да киң җәелеш таба.

Суфичылыкта тышкы яктан үз-үзеңне тоту белән бергә эчке сафлык та аеруча зур әһәмияткә ия булган. Беренче буларак, Мөхәммәт ибне Ибраһим Әбу-Хәмзә Әс-Садафи (882 елда вафат) тарикатьтә үзара дуслык, фикер сафлыгы, теләкләр берлеге, Аллаһе Тәгаләгә мәхәббәт һәм Ахирәт тормышы белән сагышлану хакында ачык төшенчәләрне эшли һәм аларның үзенчәлекләрен, чикләрен һәм әһәмиятләрен билгели. Шушы вакыттан әдәбиятка да мәхәббәтнең ишарәте буларак, «мәст булу», ягъни «исерек булу», төгәлрәк һәм ачыграк әйткәндә: «Аллаһе Тәгаләгә мәхәббәттән исерү» символикасы килеп керә. Әгәр дә суфи шагыйрь, Әхмәт Ясәви төсле, Хак Тәгаләгә мәхәббәт савытыннан мәй-шәраб эчеп исердем, дип белдерә икән, бу әле чын мәгънәсендә шәраб-аракы эчеп исердем дигән сүз түгел, бәлки чын мәхәббәтемдә шәраб эчеп исергән төсле исердем, дигән сүз. Әмма монда Аллаһе Тәгаләгә мәхәббәтнең дәрәҗәсе дә аңлаешлы итеп белдерелгән.

Суфичылыкта озак еллар буена «Фәна филлаһ» төшенчәсе фанатизм мәгънәсендә кулланылып киленә. Аның серен беренче булып Зөн-Нунның мөриде Әбу-Сәгыйть Әл-Харраз (890 елда вафат) ачыклый, үз-үзеңне «бетерү» идеясенең тирәнрәк мәгънәгә ия булуын күтәреп чыга һәм «фәна филлаһ» ул Аллаһе Тәгалә эчендә эрү икәнлеген төшендереп бирә. Һәрхәлдә ул Аллаһе Тәгаләнең янына ирешү булса да, моннан соң тагын да тирәнрәк аңлашыла башлый.

Унынчы гасырда суфичылык төркиләрдә дә киң җәелеш таба. Тугызынчы гасыр ахырында Хорасан төркиләре арасына Муса Әл-Әнсари (932 елларда вафат) суфичылык нигезләрен тарата. Мөхәммәт ибне Карраман мөридләре исә Сыр-Дәрья һәм Әмү-Дәрья буйларында беренчеләрдән булып хилка (яки хәлка), ягъни суфичыларның чатырларын коралар һәм монда төркиләр арасында уңышлы рәвештә суфичылык гыйлемен җәелдерәләр. Бүгенге көндә татарлар яшәгән җирләрдә Карамалы, Карамал кебек исемдәге авыллар бар. Һич шик юк, бу исемнәр Кара мал, яки Карама дигән сүзләрдән алынмагандыр, бәлки Карраман мөридләре төзегән сумга-чатырлар белән бәйледер. Чөнки ул мөридләр үзләрен каррамәнлы, ягъни Мөхәммәт ибне Карраман суфилары дип атап йөрткәннәрдер.

Карраман суфилары исә үзләре төзегән чатыр-хилкаларга җыелышып, Аллаһе Тәгаләгә зикер әйтә торган булганнар. Шушы зикер әйткән вакытларында алар Дәфтәр укыганнар. Бу яктан Әхмәт Ясәви һәм яссәвичеләр белән тәңгәллекләре күзгә бәрелеп тора. Шулай ук каррамәнлылар хәерчелек белән яшәүне, байлыклардан баш тартуны, Ахирәт хәсрәтендә булуны бар нәрсәдән өстен күргәннәр. Аллаһе Тәгаләдән курку һәм фанатизм дәрәҗәсенә җиткерелгән диндарлык — болар да Ясәви өчен хас.

Суфиларның хилкалары шәһәр читендә төзелгән, яки ул чатыр хәлендә, яки җимерек йорт, куыш кебек булган. Әмма бу урын иң изгеләрдән саналган һәм рибат (кала) дип тә йөртелгән.

Суфилар башкалардан үзләренең киемнәре белән дә аерылып торганнар. Өсләрендә мөселманнарның матәм төсендәге зәңгәр киез халат, башларында юка түбәтәй, яки нәзек кенә чалма, болар өстеннән лента чүпрәк чолганган, яисә лента үзе генә баш өстенә уратылган — фута, сакаллы һәм чәчле, әмма мыеклары кырылган. Суфи һичвакыт ризыгын соңгы бөртегенә кадәр ашамаган, азыклангач та бер кисәген кошларга калдырган, бу — Ахирәт ризыгы. Аз, яки бөтенләй дә йокламаска тырышканнар, утырып кына йоклау гадәте өстен саналган. Башкаларның аны мактавы яки түбәнсетүе — суфи өчен икесе дә бер мәгънәгә ия. Алар һәр кушылган эшне үтәгәннәр һәм баш тартуны Аллаһе Тәгаләгә каршы төшү дип исәпләгәннәр. Могҗизалар күрсәтү дәрәҗәсенә ирешкән суфи әүлиядән саналган.

Әхмәт Ясәви үзенең хикмәтләрендә суфиларның иң өстеннәреннән итеп Мансур Халлажны (921 елда Багдатта җәзалап үтерелә) күрсәтә. Аның «Әнәл-Хак!» (Мин — Аллаһ!) дигән сүзен кат-кат китерә һәм заманында бу сүзләрнең хикмәтен төшенмәүләрен билгеләп үтә. Асылда «Әнәл-Хак!» — «фәна филлаһ»ның бер мәгънәдәш төшенчәсе генә. «Фәна филлаһ» Аллаһе Тәгалә эчендә эрү булса, «Әнәл-Хак!» исә Аллаһе Тәгаләгә «әверелү» булып тора. Моның фәлсәфи нигезен аңлау өчен бәндәләргә шактый күп мәгълүмат вә гыйлем кирәк. Әгәр дә Гайсә пәйгамбәрнең Аллаһе Тәгалә хозурына күтәрелүен искә төшерсәк, бераз ачыклык та керер. Мансур Халлаж кяфер булмаган, христиан динендә дә түгел, әмма Гайсә пәйгамбәрнең Аллаһе Тәгалә тарафына китүендә зур мәгънә күргән һәм шуның белән аны башка пәйгамбәрләрдән өстен куйган. Мәгәре Гайсәне Хак Тәгалә үз янына алган икән, димәк Гайсә дә Хак Тәгалә дәрәҗәсенә ирешкән, дигән сүз.

Мансур Халлаж Гайсә пәйгамбәрне Аллаһе Тәгалә белән кушылган дип бара һәм үзен дә шундый дәрәҗәдә дип исәпли. Ислам фанатизмы моның фәлсәфи тирәнлеген аңламый һәм кабул итми, шунлыктан Мансурны дар агачына асып үтерәләр. Әмма ул суфиларның идеалына әверелеп китә.

Мансур Халлажның фәлсәфәсе буенча, кеше рухи сафлыкка Аллаһе Тәгаләгә буйсынып кына ирешә ала. Ул гына да түгел, кеше, суфи буларак, иң соңгы дәрәҗәдә, иң югарыдагы мәкамдә аталыктан тәмам сафланып җитәргә, нәфседән бөтенләй баш тартырга тиеш. Әгәр аның тәнендә бер генә бөртек тә аталыктан килгән сыйфаты калмаса, ул кешегә илаһи җан иңә, анда инде адәм балаларына хас булган җан түгел, бәлки илаһи җан яши башлый. Мондый бәндә Гайсә пәйгамбәр кебек булачак, кылган эшләре вә фигыльләре бары тик Аллаһе Тәгалә әмере белән һәм аның үз әмерләре дә Хак Тәгалә әмере буенча булачак. Бу фәлсәфәнең практик әһәмияте, кешелек һәм тормыш өчен кирәклеге гаҗәеп зур була. Моңа таянган суфилар аркасында кешелек һәлакәттән котылып кала. Бер халыкның икенчесе тарафыннан, яки башка бер сәбәптән һәлакәте шулай итеп, диндарлык, суфилык ярдәмендә булдырылмый калына. Әгәр дә халык кайгысында йөрүчеләр булмаса, үз файдасын онытып, нәфседән баш тартып миллә мәнфәгатьләрен кайгыртучылар булмаса, халык өчен Аллаһе Тәгалә каршында гыйбадәт кылучылар булмаса, аларның үтенеч вә тәүбә сүзләре Хак Тәгалә хозурына барып ирешмәсә, халыкны һәлакәт көтә. Кемнең кемнең, әмма татарның үз тарихы да моны ничә кат раслады булса кирәк. Шуның өчен садаканы дәрвиш-суфига бирү Хак Тәгалә каршында мәртәбәлерәк саналган, шуның өчен зәкәтнең өлешен мәсҗет шундыйларга тараткан. Мохтаҗ булганлыклары өчен генә түгел, олуг һәм башкалардан мең кат өстен булганлыклары өчен.

Әхмәт Ясәви чорына суфичылык менә шушындый дәрәҗәдә килеп ирешкән. Мансур Халлажның фәлсәфәсе аңлашыла башлаган дәвер булган ул. Әхмәт Ясәвидән «дөньяны яңартучы» фәлсәфәне эзләп азаплану кирәк тә түгелдер. Чөнки аның тарихи урыны башка. Әхмәт Ясәви — төрки халыклары үсешенең юлларын, әдәбияты нигезләрен, рухи халәтен, максатын, әхлак сафлыгын билгеләп вә күрсәтеп калдырган даһи. Шул исәптән безнең татарныкы да ул. Чөнки тарихыбызда, рухи халәтебез үсүдә вә ныгуда аның кебек зур роль уйнаган шәхесләр бармак белән генә санарлык. Аларның иң беренчеләренең берсе — ул. Әхмәт Ясәви мирасы булмаган булса, монгол яуларыннан соң төрки-татарлар исән-сау кала алырлар идеме? Шуңа күрә халык арасында: «Мәдинәдә — Мөхәммәт, Төркестанда — Хуҗа Әхмәт!» — дип әйтәләр. Әхмәт Ясәвинең «Алтмышынчы хикмәт»ендә дә моңа аваздаш сүзләр бар:

Мәккәдә бар Мөхәммәт,
Төркестанда — Хуҗахмәт,
Ярлыкагай ул Әхәд (Бердән бер)...

Әхмәт Ясәви суфичылык фәлсәфәсендә Мансур Халлажга таяна, әмма аның кебек хаталанмый. Мансур үзенең инануларында Гайсә пәйгамбәрне Мөхәммәт галәйһис-сәламнән өстен куйган булса, шул рәвештә иманын какшаткан булса, Әхмәт Ясәви Мөхәммәт пәйгамбәрнең өстенлеген тәкрарлый. Мәсәлән, икенче хикмәтендә ул 63 яшендә «фәна филлаһ»ка ирешүен белдерә һәм фәрештәләрдән сабак алуын, Мөхәммәт пәйгамбәр белән очрашуын сөйләп уза һәм аның Аллаһы Тәгалә өчен иң сөекле Хәбибе, Мостафасы булуын белдерә. Хикмәтләренең башыннан ахырына кадәр Мөхәммәт пәйгамбәрнең барчадан өстен булуын раслап бара, аннан өстенә, әлбәттә — ярлыкаучы Хак Тәгалә.

Пире муган — хак Мостафа, бишик белең...

Мәхәббәт савытыннан мәхәббәт шәрабен бүлеп бирүче — Мөхәммәт пәйгамбәр, шикләнмичә белергә кирәк! Димәк, дин шәрабе — ислам, аны бирүче — Мөхәммәт.

Әхмәт Ясәвинең башка суфилардан өстенлеге менә шунда күренә дә. Ул Мансур Халлаҗны тәнкыйтьләми, ул гына да түгел, аны яклап чыга, әмма иң зур ялгышын төзәтә һәм шуның аркасында туры юлдан тайпылмыйча, «фәна филлаһ» фәлсәфәсен алга таба үстерүгә ирешә. Бу аның, әлбәттә, иң зур казанышы.

Кол Хуҗа Әхмәт Ясәви — төркиләрнең иң олуг әүлиясе һәм аның дәрәҗәсе күп вакыт пәйгамбәр белән тиңләштерелгән, татарлар тарафыннан Мөхәммәт галәйһис-сәламнән бер дә ким каралмаган. Кичке ашларда аның хикмәтләре әбиләр һәм абыстайлар тарафыннан көйләп укылган, шәехләр вә мөридләр аның «дәфтәр»ләрен укып, күңелләре вә уйлары белән Хак Тәгалә хозурына эри торган булганнар. Халык иҗатының үзенчәлекләрен үзенә җыйган, үлчәме гади, әһәңе аңлаешлы булу сәбәпле һәм дә рифманың оста рәвештә катлы-катлы кабатлануы аркасында Әхмәт Ясәви хикмәтләре дөнья хәсрәтләреннән ваз кичеп, Ахирәт тормышы тарафына эрү өчен бик кулай булганнар. Әхмәт Ясәви «Җәһрия тарикате»нә нигез салучы хәким исәпләнелә, аның өйрәтмәләрен күңелләрендә тоткан һәм шул юлда йөрүчеләрне, китаплы халык дигән төсле, дәфтәрлеләр дип атап йөрткәннәр. Дәфтәрле татарлар Җаек (Урал), Зәй, Минзәлә буйларында таралып яшәгәннәр. Көнчыгышка таба Иртеш тирәләренә кадәр шул ук дәфтәрле татарларның эзләре сакланып калган. Бу дәфтәрлеләрнең типтәрләр белән катнашы бармы-юкмы, әйтүе кыен, һәрхәлдә махсус тикшеренүләр таләп ителә.

Әхмәт Ясәви үзе Төркестанда, Урта Азия төркиләре арасында, Яссы дип аталган калада туып үскән. Әдәби тәхәллүсен дә шушы туган җиренә нигезләнеп Ясәви дип алган. Атасы Ибраһим Яссы исә бу тирәдә мөридләр тоткан һәм фикер иясе булган, үзенең диндарлыгы белән дан казанган. Бу тупланмага кертелгән 153 нче хикмәттә мондый юллар бар:

Аслы ирер ханидан,
Белмәс аны күп надан...
Исхак баба ярыгы,
Шәйх Ибраһим колыны,
Мөшәехләр олугы
Шәйхем Әхмәт Ясәви.
Яссы суның арасы,
Ятыр гәүһәр парәсе...

Бу юлларны укыгач, Әхмәт Ясәвинең бабасы Исхак, атасы шәех Ибраһим булуын белүе авыр түгел. Әмма Әхмәт Ясәвинең кайчан туганлыгы билгеле түгел, бары тик 1166 елда вафат булуы гына мәгълүм. Хәбәрләргә караганда, ул 130 ел гомер кичергән һәм чама белән 1036—1043 еллар арасында туган булса кирәк. Хикмәтләрендә ул үзенең бала чагын һәм дә үсмер вакытларын бәян итеп китә һәм аның бик яшьли ятим калып, Арыслан баба дип йөртелгән шәех тәрбиясендә яшәгәнлеге күренә. Суфиларга хас рәвештә ул үзен хурласа да, яшьтән үк белемгә һәм дингә омтылышы аңлашылып тора. Ни хикмәт, Ясәви үзенең әнкәсе Карачәч хакында бер дә телгә алмый һәм моның сәбәбе дә аңлашылмый.

Баба Арыслан шәехтән белем алганнан соң Әхмәт Ясәви, укытучысының васыятен тотып, Бохарага китә һәм Хуҗа Йосыф Һәмәдани шәех хозурында була, монда ишанлык мәртәбәсенә ирешеп, кабат Яссыга кайта һәм үзе дә шәкерт вә мөридләр тәрбиясенә керешә. Аның иң мәшһүр укучысы — Сөләйман Бакыргани күчмә төркиләрдән була һәм үзенең шигырьләре белән дан казана.

Әхмәт Ясәви 63 яшендә гүргә кереп ята һәм шушы яшьтә вафат булуны сөннәт дип белдерә, чөнки бу яшендә Мөхәммәт пәйгамбәр Аллаһе Тәгалә хозурына ашкан булган. Аның бу рәвешле үз-үзен тотуы Мөхәммәт галәйһис-сәламне олылавыннан һәм аныңча булырга тырышудан гына түгел, бәлки, күреп үткәнебезчә, суфичылык фәлсәфәсеннән үк килә.

Хәбәрләрдән күренгәнчә, Әхмәт Ясәвинең шәкертләре бик күпләп Идел буенда һәм Болгар илендә үз вакытында ук таралалар. Болгар шәһәрендә мәсҗет манарасы ачу сәбәпле, мөселманнар моның фалын Әхмәт Ясәвидән сорыйлар һәм ул аларга, шәкертләре аша, Болгар иленең тиздән харап буласын белдерә. Төркиләр өстенә киләчәк афәтнең никадәр аяныч булачагын ул алдан сизенгән һәм дин ярдәмендә котылу юлы барлыгын күрсәтеп калдырган.

1395—1397 елларда Аксак Тимер Алтын Урданы җимергәч, риваятьләргә караганда, төшендә Әхмәт Ясәвинең ачулы йөзен күргән һәм үзенең нинди олуг гөнаһ эшләгәнлеген аңлап алган. Алтын Урданы калдырып чыккач, Әхмәт Ясәвинең кабере өстенә олуг мәсҗет-төрбә салдырырга әмер биргән һәм төзеттергән.

Әхмәт Ясәви хикмәтләре борынгыдан татарлар арасында кулдан кулга күчерелеп йөртелгән. XIX гасырда һәм XX йөз башында алардан төрле-төрле басмалар әзерләнгән һәм бастырылып таратылган. Төрек һәм үзбәк басмалары да үзенчәлекле. 1991 елда Ташкентта басылып чыккан «Әхмәт Ясәви. Хикмәтләр». китабы асылда төрек вариантларыннан алынган. Ә без исә Казанда, университет типографиясендә кат-кат дөнья күргән Әхмәт Ясәвинең «Диваны хикмәт» китабына таянып эшләдек һәм үзбәк, төрек басмаларыннан аермаларның шактый булуын күрдек. Казан басмаларыннан бигрәк тә 1904 елда Казан университетында чыккан бишенче басмасы аеруча пөхтә итеп эшләнелгән. Әмма хикмәтләрнең сан тәртибендә генә бераз буталыш күренә, аларына төзәтмә кертелде.

Казан басмаларыннан «Диваны хикмәт»нең аеруча кызыклы тагын бер вариант басмасы бар. Ул Уральск өлкәсе Гурьев өязе Бишенче номерлы татар казаклары авылының Манкышлау Танышлык угылы тарафыннан тәкъдим ителгән текст буенча бастырылган. Бертуган Кәримовлар нәширлегендә чыккан. 1905 елда дөнья күргән бу китап үзенең төзелеше, хикмәтләрнең тагын да күплеге, имля һәм шигырьләрнең төзеклеге белән игътибарга лаеклы. Күренеп тора, басма башка бер нөсхәдән эшләнелгән. Алга таба эзләнүләр шактый катлаулы мәсьәләләрне кузгатыр һәм күп кенә башка сорауларга да җавап бирер дип ышанасы килә...

# Әхмәт Ясәви

(XI йөз ахыры — 1166)

Хушламайдур галимләр сезне — айган [1] төркине.
Гарифләрдән [2] ишетсәң, ачар күңел мөлкине [3].

Айәт, хәдис мәгънәсе төрки булса муафикъ.
Мәгънәсигә йиткәнләр йиргә куйар бүркине.

Казый, мөфти, муллалар — шәригъәт зәкя рәһни [4].
Гариф гашикъ алыбдур тарикъәтне(ң) [5] иркине.

Гъәмәл кыйлган галимләр — динемезне(ң) чырагы [6] —
Борак менәр мәхшәрдә, игре куйар [7] бүркине.

Гъәмәл кыйлган галимләр дин вә айын йарукы [8] —
Күрсә булур аларны(ң) рәңг [9], руйи күркине[10].

---

[1] Айган — әйткән.
[2] Гариф — белемле.
[3] Мөлкине — байлыгын.
[4] Зәкя рәһни — акыллылык, күрәзәлек таянычы.
[5] Тарикъәт — дини юнәлеш, юл.
[6] Чыраг — яктылык, шәм.
[7] Игре куйар — әйләндереп кияр.
[8] Йарукы — яктысы, нуры.
[9] Рәңг — төс.
[10] Руйи күркине — матур йөзен.

Гъәмәл кыйлмай къәл гъилмен [1] уку белмәй калганлар
Аркасыга күтәрүр кырык ишәк йөкине.

«Хуҗамән!» — диб лаф орма, ошбу дөнйа бипайан;
«Беләмен!» — диб әйтмә сән күңелдәге чиркине.

Рәһнәмадур [2] Хуҗа Әхмәд, гөлстане мәгърифәт [3], —
Сүзләр сүзе хәкъикъәт, ачар күңел мөлкине.

Мескен зәгъиф Хуҗа Әхмәд, йите пөштеңгә [4] рәхмәт:
Фарси телне белүбән [5] хуб итәдүр төркине.

* * *

Тотуг(ы) руза тотар, халкъларга шәйехлек сатар,
Гъилме йук гамидин [6] бәдтәр [7] ахырзаман шәйехләре.

Билегә фута [8] чалур, үзене кеше санур,
Гарасатта уфтанур ахырзаман шәйехләре.

Башыга дәстәр [9] урар, гъилме йук нигә йарар,
Укы йук йәсен корар[10] ахырзаман шәйехләре.

Әляндин[11] аль кыйлур[12], могамәләне мал кыйлур,
Иссез[13] гъөмрен йил кыйлур ахырзаман шәйехләре.

Шәйехлек олуг торур, Хәзрәткә[14] илткән эш торур:
Аш бирмәс бәгъре таш торур ахырзаман шәйехләре.

Мескен Әхмәд, канда[15] сән, хак[16] йулында нәдә сән,
Гъилмең йук нә санда сән, ахырзаман шәйехләре.

* * *

Мәркәб[17] лягыр, йөгем агыр[18], үзем гъәмкин[19].
Хәсрәт белән гакыл-һушым китте, тәмккин[20].
Үтеб кәруан, күздин гъәйеб булды[21] сакин[22], —
Барур җайым беләлмәсмән кайан имди.

---

[1] Къәл гъилмен — сүз гыйлемен.
[2] Рәһнәма — юлбашчы.
[3] Гөлстане мәгърифәт — белем бакчасы.
[4] Пөштеңгә — бабаңа.
[5] Белүбән — белеп.
[6] Гамидин — наданнан.
[7] Бәдтәр — начаррак.
[8] Фута — пута, билбау.
[9] Дәстәр — чалма.
[10] Йәсен корар — җәясен корыр.
[11] Әляндин — хәзердән үк.
[12] Аль кыйлур — гаилә корыр.
[13] Иссез — аңсыз, аңламастан.
[14] Хәзрәткә — бирелә: аллага.
[15] Канда — кайда.
[16] Хак — алла.
[17] Мәркәб лягыр — бирелә: «атым арык» мәгънәсендә.
[18] Агыр — авыр.
[19] Гъәмкин — гамьле.
[20] Тәмккин — мөмкинлек, көч-куәт.
[21] Гъәйеб булды — югалды.
[22] Сакин — бер урыннан китми яшәүче.

Гыйас үтте иссез гъөмрем рәсуалыкта [1],
Һич булмадым заман торсе ходалыкта.
Даим йөререм нәфсем өчен гәдалыкта [2],—
Һәр нә кыйлган сәүдәләрем зийан имди.

Бу халәттә ул Газраил килсә нәгяһ [3],
Асигъ [4] тәндин җанны алса — биргел пәнаһ [5]!
Шәйтан алыб иманымны, кыйлса рәсуа —
Борадәрләр, ароа йулда калгам имди.

Бу халәттә сүз әйтергә йукдур фәрман,
Үчеб калгай вөҗүд әчрә шәмгъе иман,
Кызыл гөл дик ошбу йөзең булур саман,—
Йакын булың йир астыга нәһан [6] имди.

Зән-фәрзанд [7], ага-энең йыглыб торгай,
«Мирас!» дибән [8] мал-милкең бүлеб алгай,
Илтеб сәне кара йиргә тыкыб күмгәй,—
Тәгъмә [9] кыйлгай Кырыш атлыг йылан имди.

Кил, әй хаиф[10], бу эшләрдин хәбәр алгыл,
Тәүбә кыйлыб, дөнйа куйыб, хакны сөйгел.
Кол Хуҗа Әхмәд, бу дөнйадин үтеб йангыл,—
Шайәд, кыйлгай нәзар[11] пире-моган[12] имди.

---

[1] Рәсуалык — хурлык.
[2] Гәдалыкта — хәерчелектә.
[3] Нәгяһ — көтмәгәндә.
[4] Асигъ — файдасыз.
[5] Пәнаһ — таяныч.
[6] Нәһан — яшерен.
[7] Зән-фәрзанд — хатын һәм бала-чага.
[8] Дибән — дип.
[9] Тәгъмә — азык.
[10] Хаиф — куркак.
[11] Нәзар — күз салу.
[12] Пире-моган — шәехләр, изгеләр.

# Г. ТУКАЙ ИҖАТЫНДА ДИНИ ҺӘМ МИФОЛОГИК МОТИВЛАР

Габдулла Тукай әсәрләре үз заманында ук зур уңыш казана. Моның бер сәбәбе — шагыйрьнең күп гасырлы әдәби традицияләребезгә таянуында. Тукай, туган әдәбиятыбызга яңалыклар алып килүче реалист буларак танылса да бөтен тамырлары белән борынгы татар әдәбиятына, Көнчыгыш әдәбиятларына һәм тулаем ислам мәдәниятенә, аның олы казанышларына — эчтәлегенә, сюжетларына, мотивларына һәм форма-шәкелләренә тоташа, шулардан үсеп чыга. Кече яшьтән үк гади халыкның иң самими ышану-хыялларын, мәҗүсилек чорыннан ук килгән мифологиясен, соңрак мәдрәсәләрдә ислам динен һәм аның риваятьләрен үзенә сеңдереп, меңәр еллык тарихы булган ислам әдәбиятын укып үскән Тукай иҗатында шуларны кодрәтле каләме аша үткәреп, элекке җирлектә, әмма яңа, югарырак дәрәҗәдә гүзәл әсәрләр тудыра алды.

Тукай иҗатында борынгы әдәбият мотивлары дигәндә, иң элек күз алдына ислам мәдәниятенең бөек китабы Коръән күз алдына килеп баса. Алланы бер вә бар дип белгән Тукайның Коръәнгә ихтирамы чиксез зур, ул Коръәнне укып әсәрләнә, аннан үзенә чиксез илһам ала. Мисал өчен 1908 елда язылган «Тәәссер» («Әсәрләнү») дигән шигырен генә алыйк:

Гомернең иң читен, җайсыз, уңгайсыз бер минутында,
Әгәр янсам каты хәсрәт вә кайгының мин утында,

Укыйм тиз-тиз күңелдән бер гаҗәиб сүрә Коръәннән,—
Газаплар мәгънәви бер кул илән алынадыр җаннан.

Оча дилдән бөтен шик-шөбһәләр, һәм мин җылый башлыйм:
Яңакларны мөкаддәс күз яшемлә энҗели башлыйм.

Бөтенләй сафлана күңлем: укыйм иман, булам мөэмин;
Килә рәхәт җиңеллекләр: хәлас булам[1] авыр йөкдин.

«Ходайа! Син тыйган эшләр тәмам экътагъ[2] вә әбтәр[3]», дим;
Иям баш сәҗдәгә: «Аллаһе хак! Аллаһе әкбәр!» — дим.

Ә инде 1909 нчы елда «Васыятем» исемле шигырендә ул менә нәрсә ди:

Әһле тәкфир[4] бер гаҗәпләнсен, күреп актык сүзем:
Күр, нә рәсмә[5] тулган иман берлә Коръән садремә![6]

Шулай садренә, ягъни күңеленә Коръән урнашкан шагыйрь, андагы илаһи аятьләрне шигъри юллар белән, чын татарча итеп әйтеп бирергә омтыла. Коръәннән кергән сюжетлар, мотивлар, персонажлар аның гаҗәп күп шигырьләрен-

[1] Хәлас булам — котылам.
[2] Әкътагъ — өзелгән, беткән.
[3] Әбтәр — киселгән.
[4] Әһле тәкфир — диннән аеручылар, көферлектә гаепләнүчеләр.
[5] Нә рәсмә — ни рәвешле.
[6] Садремә — күкрәгемә, күңелемә.

дә урын алган. Ә инде аерым шигырьләр тулаем Коръән аятьләренә багышланган. Әйтик менә:

Ярты төн булган чагында, китте Мәккә ялтырап:
Нур тоташты җиргә күктән, инде нурдан бер пырак[1].

Хәзрәти Җибрил[2] бәшарәт әйләде[3], дип: «Йа Расүл,
Хак тәгалә хәзрәте тәгъйинләде[4] бу кич вөсул[5].

Мөнтәзыйрләр[6], ля мәкәннәр[7], бар мәляикләр[8] сиңа,
Гарше әгъля[9] килде, атлансаң, аягың астына,—

дип башланган «Мигъраҗ» шигыре Коръән Кәримдәге 17 нче сүрәне эченә алган һәм башка китаплардагы риваятьләрне кабатлаган. Татар әдәбиятында мигъраҗ, ягъни Мөхәммәт пәйгамбәрнең Мәккәдән Коддөскә (Иерусалимга) сәфәре, әл-Әкъса мәчете гөмбәзеннән күккә ашуы турындагы сюжет Рабгузиның «Кыйссасел-әнбия»сеннән (14 гасыр) башлап XX йөз башына кадәр күп әсәрләрдә кабатланган популяр сюжет. Кечкенәдән үк пәйгамбәрләр тарихын укып үскән Тукайны бу сюжет юкка гына илһамландырмаган, билгеле; шуңа да гаҗәеп матур яңгырашлы шигырь дөньяга килгән.

Шагыйрьнең «Кадер киче» дип исемләнгән әсәре дә турыдан-туры Коръәнгә барып тоташа, ул андагы «Кадр» дип аталган 97 сүрәне шагыйранә тасвирлап биргән. Шагыйрь күңел күтәренкелеге, тирән ышаныч, пафос, матур, җинел тел белән бу кичәне бер монументаль картина итеп сурәтли. Шигырьнең язылу тарихын композитор Мансур Мозаффаров түбәндәгечә ачыклый: «Бервакыт әнием Тукайдан: «Менә Кадер киче җитә, балаларга җырлар өчен бер шигырь булмасмы икән синдә, Габдулла?» — дип сорады. Тукай берничә көннән безгә «Бу Кадер кич елда бер кич...» дип башлана торган шигырен үз кулы белән язып, чәчәк ябыштырылган открытка алып килде.»

Коръәндә телгә алынган пәйгамбәрләр, алар белән бәйле риваятьләр, ул вакыйгаларда катнашкан төрле персонажлар Тукай шигырьләренә бик табигый кереп, тыгыз үрелеп баралар, шагыйрьнең әйтәсе килгән фикерен үтемлерәк, тиз барып җитәрдәй итеп бирергә ярдәм итәләр. Чөнки ул заманның дин тоткан, дини кагыйдәләрне үтәп барган, Коръәнне белгән кешесенә ул мотивлар бик якын булган. Менә «Могҗиза» дип исемләнгән шигырьне генә алып карыйк:

Пәйгамбәрнең вафатыннан соң асла могҗиза булмас:
Ярылмас ай икегә, һәм кара таштан төя тугмас,—

Диләр безнең гыйлем әһле.— Ышанмаыз, бу ялгандыр;
Үзем күрдем бүген, безнең заманда могҗиза бардыр:

Бүген иртүк миңа шактый бурычлы иптәшем килде,
Ялындырмый, талашмый, вәгъдәсендә акчасын бирде.

Хәзерге заман укучысы бу шигырьдәге «ярылмас ай икегә», «кара таштан төя тугмас» дигән сүзләргә артык әһәмият бирмичә, тирәнлегенә төшенеп тормыйча гына узып китә. Ә Коръәнне һәм дини мифологияне белгән шул заман кешесенә бу гыйбарәләр күп нәрсә аңлаталар. Риваять буенча, кяферләр Мөхәммәт пәйгамбәрнең җирдәге могҗизаларына ышанмыйча, аны «сихерче» дип атап, аннан күктә могҗиза күрсәтүен, мәсәлән, үз кодрәте белән айны икегә ярып, ике кисәген ике якка җибәрүен, аннары аларны ике җиң очыннан чыгарып, үзенә сәҗдә иттерүен сорыйлар. Мөхәммәт исә моны үтәп чыга. Тукай менә шуңа ишарәли.

---

[1] Пырак (Борак) — Аллаһтан килгән ат сыман җанвар.
[2] Җибрил (Җәбраил) — хәбәрләр китерүче фәрештә.
[3] Бәшарәт әйләде — сөенче бирде.
[4] Тәгъйинләде — билгеләде.
[5] Вөсул — күрешү, кавышу.
[6] Мөнтәзыйр — көтеп торучы.
[7] Ля мәкән — һәр урында булучылар.
[8] Мәляикләр — фәрештәләр.
[9] Гарше әгъля — бөек тәхет.

«Кара таштан төя тугмас». Риваять буенча, сәмуд халкын хак дингә өндәргә килгән Салих пәйгамбәрдән аның Алла вәкиле икәненә ышандыру өчен могҗиза күрсәтүен сорыйлар: «Менә шул кара таштан дөя чыгар»,— диләр. Салих таягы белән сугуга, бер зур ана дөя пәйда була. Ләкин сәмудиләр барыбер Аллага иман китермиләр, пәйгамбәр китү белән үк дөяне суеп ашыйлар. Әлеге сүзләре белән Тукай Коръәндәге шушы риваятькә ишарәли.

Тәэсир көчен арттыру, күренешләрне җанландырып, көчәйтеп бирү өчен Тукай еш кына мифологик мотивларга да мөрәҗәгать итә. Хәтта табигать күренешләрен тасвир иткәндә дә бу мотивлар бик табигый рәвештә әсәр тукымасына үрелеп китәләр. «Яз» шигырендә язгы ташуны шагыйрь болай сурәтли:

Кисәктән җанланып, бозлар агалар;
Чабалар, берсене берсе кагалар.

Белерсең син боларның мәхшәре дип,
Бу бозларны — үлекләр гаскәре дип;

Өрелмеш дип белерсең санки мөгез,
Вә яки мөгезен селкеткән үгез.

Болар әлло бара дәһшәтле судка,
Беленми: кайсы — җәннәт, кайсы — утка.

«Бәдәвам», «Ахыр заман», «Нәһҗел-фәрадис» китапларында сурәтләнгән, һәр татар укучысына таныш булган кыямәт көне, бер мәрхүмнәрнең терелеп бер урынга җыйналулары, ягъни мәхшәр, Исрафил фәрештә быргысының бөтен дөньяны тетрәткән авазы, җәннәт һәм тәмуг картиналарын күз алдына китереп бастырып, Тукай гади генә бер табигать күренешен дә кешене әсәрләндерерлек итеп тасвирлап бирә.

Шагыйрь шулай ук еш кына татарның элек-электән укылган, балачактан ук хәтеренә сеңгән борынгы классик әдәбиятка мөрәҗәгать итә. «Кыйссаи Йосыф», Рабгузиның «Кыйссасел-әнбия»се, Хуҗа Әхмәд Ясәви, Сөләйман Бакырганый, Суфый Аллаһыяр шигырьләре һәм бигрәк тә «Мөхәммәдия», «Бакырган»нан алынган мотивлар Тукайда күп очрый. Шагыйрь һәммә татарга таныш, сөеп укылган шигырьләрнең тышкы шәкелен, үлчәмен, көен, рифмаларын алып, аерым сүзләрен кабатлап, бөтенләй яңа әсәр, Тукайның үз чоры кешеләрен, тормыш картиналарын сурәтли торган, бөтенләй көтелмәгәнчә яңгырый торган әсәрләр иҗат итә. Күп вакытта ул борынгы җитди шигырьдән бөтенләй киресен: йә бер көлке, йә бер ачы сатира китереп чыгара. Менә «Һазиһи касыйдәтен фи мәдхи Мостафа» («Бу Мостафаны мактау шигыре») дигән сатирасын ул 14 нче йөз әдибе Рабгузыйның «Пәйгамбәрләр тарихы»ндагы Мөхәммәт пәйгамбәрне мактауга багышланган шигырьне үзгәртеп, ул үз заманындагы мәгълүм шәхескә — әзәрбайҗанлы Мостафа Лотфи Ширванскига багышлый, мәдхия урынына мыскыллау шигыре ясый. Рабгузида ул шигырь болай башлана:

Дин, шәригать рәйәтене[1] гали кылган[2] Мостафа,
Көфер, золмәт тулар[3]ыны җиргә салган Мостафа.

Каумена дин күрсәтмичә күккә ашкан — Гайсә ул,
Өммәтенә булышубән җирдә калган Мостафа.

Тукайда исә аның замандашы Мостафа болай сурәтләнә:

Төркиядә бер теләнче сухтә[4] булган Мостафа;
Монда кайтып ил казасы, фетнә булган Мостафа.

Юл-юаш, муйның бөгеп йөргән сарыклы бер сарык,—
Монда кайткачтын симергән, чучка булган Мостафа.

Рабгузидагы Мостафа белән Тукайдагы Мостафа арасында шундый зур аерма бар ки, бу гиперболик аерма, гротеск ирексездән укучыда көлке тойгысы, мыскыл, хәзерге заман Мостафасына нәфрәт уята.

---

[1] Рәйәт — байрак.
[2] Гали кылган — биек иткән.
[3] Ту — байрак.
[4] Сухтә — мескен.

Ә менә «Мөхәммәдия» китабының керешендә Мөхәммәт Чәләбинең үзе турында язган гаять җитди юлларын алып, аны һич көтелмәгән җирне — трактирны, сыра эчеп, мәлҗеп утыручы татарны сурәтләгәндә файдалана. «Мөхәммәдия»дә шигырь болай бирелгән:

Мәгәр көннәрдин бер көн әмре тәкъдир
Утырмышдем Кәлибулидә сирра[1].
Әлеме чикмешдем җөмлә халыктан,

Телемдә зикер иде, кальбемдә зикра.
Кәлибулинең ул гашыйкларындин
Тезелделәр килеп катыма торра...

«Ысулы кадимче» дә исә Тукай шул ук шәкелне, шул ук сүзләрне бөтенләй икенче якка борып җибәрә:

Мәгәр көннәрдә бер көн, әмре трахтир,
Утырмыштым ки бер пивнойда сирра.

Кулымны селтәдем фани җиһаннан,
Агызда папирос, алдымда сырра.

Трахтирларның ул гашыйкларыннан
Тезелделәр килеп катыма торра.

Шулай итеп, күренешне бөтенләй икенче урынга күчереп, Тукай һәркемне елмаерга мәҗбүр итәрлек мәзәк күренеш тудыра.

Шагыйрь бигрәк тә «Бакырган» китабындагы әсәрләрне сөеп файдалана. Ни өчен дигәндә, «Бакырган китабы» халыкчан телдә, гади, самими, шул ук вакытта гаҗәеп тәэсирле язылган. Шуңа да ул киң таралган, ә Тукай исә аның яратып укылуыннан үзенчә файда ала.

«Бакырган» да шундый шигырь бар:
Нә кылырсың, мескен адәм,
Тотса Газраил якаң?
Ничек җавап бирерсең,
Тотса Газраил якаң?

Тукай исә 13 гасырдагы «Бакырган»ны XX йөз башына алып керә, «Тотса мәскәүләр якаң» шигырен шул рефренга кора:

Ни кыйлырсың, хаҗи абзам, тотса мәскәүләр якаң?
Как ты будешь отвечать там, тотса мәскәүләр якаң?

Сыгмаз ирдең киң җиһанга, малыңа мәгърур булып:
Даже в тюрьму сыярсың, тотса мәскәүләр якаң?

Безнең заман халкы «Бакырган»ны белми диярлек, әмма Тукайның «тотса мәскәүләр якаң» гыйбарәсе канатлы сүзгә, әйтемгә әйләнеп, бүгенге көндә киң кулланылышта йөри, ни өчен дигәндә, Мәскәүнең каты кулы әле дә якадан җибәрми.

Тукайның борынгы әдәбиятыбызның зур бер язма дастанын алып, андагы сюжетны, үлчәмен, тәгъбирләрне тулысынча үз максатында кулланып иҗат иткән зур әсәре бар. Бу «Печән базары яхуд яңа Кисекбаш» поэмасы. Шагыйрь монда XIV гасырның героик дастаны «Кисекбаш»ны бөтенләй икенче характердагы, сатирик пландагы әсәре өчен бик уңышлы куллана. Борынгы «Кисекбаш»ны яхшы белгән татар укучысында Тукайның «Кисекбаш»ы гаҗәеп тәэсирләр уята, заманының бөтен проблемаларын тагын да калкуырак, үтемлерәк итеп җиткерә.

Җыеп шуны әйтергә була: Тукайның иҗаты борынгы әдәби мирастан аерылгысыз. Шагыйрь шул олы мираска таянып, шул элекке әсәрләр ярдәмендә , әмма аларны һич тә кабатламый торган, яңа, асыл әсәрләр иҗат иткән. Г. Тукайның әсәрләре шуңа күрә дә бик халыкчан, вакыт сынауларын җиңел үтә торган үлемсез әсәрләр.

**Нәҗип ИСМӘГЫЙЛЬ**

---

[1] Сирра — яшеренеп.



**Фирдүс Фәтхелисламов,**

«Татарстан — Төркия» дуслык җәмгыяте президенты

# «ТЕЛДӘ, ФИКЕРДӘ, ЭШТӘ БЕРЛЕК»

Татарлар, ЮНЕСКО мәгълүматлары буенча, Җир шарының төрле төбәкләрендә яшиләр, татар теле исә күп кенә башка халыклар белән аралашу мөмкинлеген бирә. Шуңа күрә, татар телен галимнәр инглиз, алман, гарәп һәм башка киң таралган ундүрт тел рәтендә күрсәтәләр. Татарлар чит җирләргә төпләнеп, үзләренең тырышканлыклары белән югары мәртәбәләргә ирешәләр. Күп кенә илләрдә татардан чыккан галимнәр, дәүләт вә җәмәгать эшлеклеләре, эшмәкәрләр, язучылар лаеклы, хөрмәтле кешеләр булып саналалар.

Билгеле булганча, Кырым, Идел-Урал вә Көнбатыш Себер — татарның төп ватаны. Татар, милләт буларак, шушы киңлекләрдә оеша башлый. Әмма Алтын Урда таркалып, аның җирләрен урыслар басып алгач, бу процесс сүлпәнләнә.

Чит ят-җирләргә татарның зур бер төркеме үз дәүләте исән-имин чагында ук китеп бара. XIV гасыр ахырында Литваның бөек кенәзе кыю, батыр татар гаскәриләрен хезмәткә чакыра һәм ялгышмый. Атаклы Грюнвальд явында татарлар хәлиткеч роль уйныйлар. Милләттәшләребез җирле халыкның мәхәббәтен яулап, шунда төпләнеп калалар.

Татар ханлыклары җимерелгәч, читкә китү киң колач җәя. Моның төп сәбәбе — урыс залимнәре тарафыннан милли вә дини җәберләүләр була. Рәсәй халыклар төрмәсе буларак танылa. Шул рәвешле, кайчандыр Мәскәүдән күпкә көчле дәүләте булган татарлар еш кына физик юк ителәләр. Рәсәй империясе алар өчен карцер була, ягъни зиндан эчендәге зиндан. Татарлар күпләп казакъ далаларына, аннан уйгур җирләренә, Анадолу кардәшләре янына качалар. Бүген фарсы йә гарәп мәмләкәтләренә күпме татар килеп чыкканын төгәл әйтеп тә булмый инде. Әмма бүгенге төрекләр, гарәпләр, фарсыларның тамырларында татар каны да агуы бәхәссез.

Татарларның күпләп күченүләрен өч өлешкә бүлеп карарга мөмкин.

1897 елда Рәсәй Манчжуриядә Чин шәрекъ тимер юлын (КВЖД) төзүгә керешә. Татарлар төзелешкә күпләп китә, башта Шәркы Русиядән, соңрак үзәк төбәкләрдән. XX гасыр башында алар Корея белән Япунга да үтеп керәләр, әмма мөһаҗирләрнең язмышы аяныч була. Икенче бөтендөнья сугышы азагында бу

жирләргә совет гаскәрләре бәреп керә, татарлар күпләп үтерелә, башкалары исә Төркия һәм АКШка качып котыла.

Мөһаҗирләрнең икенче зур бер төркеме Финляндиядә тупләнә. XIX гасырның икенче яртысында Финляндия Рәсәй империясенең бер өлеше булып тора. Суоми мәмләкәтенә беренчеләрдән булып Нижгардан Сергач мишәрләре килә. Бүген татарлар Хельсинки, Тампере, Турку һ. б. шәһәрләрдә яшиләр. Мәсләкләре — мишәрләргә хас булган сәүдәгәрлек. Араларында галимнәр, укытучылар, табиблар да юк түгел. Төрле чыганаклар буенча, аларның гомуми саны 1000 нән алып, 4—5 меңгә чаклы.

Өченче зур күченеш шулай ук XIX гасырның икенче яртысы белән бәйле: татарлар күпләп Төркиягә китә. Соңрак, 1945 елдан соң, аларга Ерак Көнчыгыштан качаклар кушыла. Шул сәбәпле милләттәшләребезне гади төрекләр берникадәр вакыт чин төрекләре дип тә атыйлар. Төркиянең 90 процент татары тарихи ватанын 1917 елдан соң ташларга мәҗбүр булды дип яза Ф. Хәкимҗанов («Мирас», 1992, 5 сан, 116 б.).

35,9 процент Төркия татары Рәсәйдә, 45,9 проценты Кытайда, 18,2 проценты Төркиядә, Японииядә, Кореядә туган.

Шулай да Төркия татарларының төгәл санын күрсәтү бик кыен. 1917 елга кадәр төркиләрнең үзара багланышлары нык була. Алар арасында татар, казакъ, үзбәк вә башка халыкларга бүленеш булмый, алар бербөтен «мөселман», «төрек» халкын тәшкил итәләр. Әдәби тел дә уртак була. Истанбул, Каһирә, Бакчасарай һ. б. шәһәрләрдә нәшер ителгән китап вә гәҗитләр Казанда укыла һәм, киресенчә, Казан басмалары башка регионнарга тарала. Ул чорда Урта Азия вә Казакъстан төрекләренең балаларын, нигездә Казан төрекләре укыта. Үз нәүбәтендә, казанлыларның угланнары югары белемне Госманлы дәүләтенең Истанбул, Каһирә һ. б. фәнни үзәкләрендә ала. Патша хөкүмәтенең каршылык күрсәтүенә карамастан, безнең фикеребезчә, төрек этносы әкрен, әмма дугру интеграция юлы буенча үсә.

Гомумән, барлык эре этник берлекләрдә ике якның каршылыгын күрсәтергә мөмкин. Ике үсеш юнәлеше — дифференциация (аерылышу, бүленү, таркалу) һәм интеграция (берләшү, кушылу) — үзара көрәштә яши. Этнос оешу чорында Бөек Төрек каханлыгы төрекләрне бергә туплый. Соңрак, Евразия континентында төрекләрнең киң таралуы аркасында, таркалу юнәлеше өстенлек ала. Мөстәкыйль каханлыклар барлыкка килә. XIII гасырда бүленү тәмамлана. Алтын Урда чорында төрек тарихы биеккә үрмәләп, интеграциянең югары ноктасына килеп җитә. Шуннан соңгы елларда үзәкләштерелгән дәүләтнең таркалуы башка этнос вәкилләренә төрек җирләрен басып алу өчен уңай шартлар тудыра. Бу вакыйга төрекләрнең тарихына кире йогынты ясый. Ләкин шуңа да карамастан, этносның алга таба үсеше дәвам итә. Рәсәй яулап алган җирләрдә төрекләр үз тормышлары, үз дөньялары белән яшиләр. Алар дүрт гасыр эчендә яулап алучылар арасында югалмыйлар, чөнки Рәсәй төрекләренең үз... дәүләтләре була. Шундый дәүләт булып Ислам торган. Исламны дин буларак кына карарга ярамый. Ислам ул тәгълимат кенә түгел, ә кешенең яшәү рәвеше. Ул мөселман тормышының барлык якларын үз эченә ала, аның һәр адымын билгели. Рәсәй төрекләре урыс патшасының кул астында булганнар, әмма Исламга буйсынганнар. Ислам һәм төрек дөньясы белән тыгыз элемтәләр этносның бәхетсез өлешен саклап калырга ярдәм иткән. Шуның белән бөтен төрек дөньясының бөтенлеге сакланып калынган. Безнең уебызча, XX гасыр башында этносыбызның югары үсеш чорына җитүе өчен барлык шартлар да тудырылган иде. Гарәп милләте бер, әмма гарәп дәүләтләре күп. Бербөтен төрек милләте дә төрле дәүләтләрдә яшәп, үзенең бөтенлеген саклап кала алыр иде.

Ул вакытта Госманлы дәүләте бөтен төрекләрнең уртак дәүләте булып саналуын да онытмаска кирәк. Илнең үзәк өлешенең бер илчәсендә (районында) шундый күренеш күз алдына килеп баса. Чифтеләр илчесе Искешәһәр вилаятендә урнашкан, ә Искешәһәрдән Әнкарага автобус белән бару өчен 2—3 сәгать вакыт җитә. Илчәдә 30дан артык шәһәр вә авыл бар.

1914 елда Болгариядән күчеп килүчеләр Аббасхалимпаша авылын төзиләр. Агларҗа авылын Кавказдан килгән чиркәсләр төзи, бүгенге көнгә кадәр анда яшәүчеләр бабаларыннан калган гадәтләргә тугрылыклы булып калганнар, Кавказ мәдәниятенең күп кенә өлешләре сакланган. Акдерә авылы картада 1880—1890 елда пәйда була, анда төрекмәннәр яши. Акхисар авылы крестьяннары кавказлылар нәселеннән, алар 1887 елда Анадолуга күчәләр. Арсланлы авылының тарихы ерак гасырларны эченә ала (бу турыда арслан таш һәйкәле дә раслый), авылда яшәүчеләр үзләренең бабалары төрекмәннәр булуын яхшы

хәтерлиләр. 1892 елда Башара авылына нигез салына. Әмма тиздән аңа нигез салучылар ул авылны ташлап китәләр. Кавказдан чиркәсләр килгәч кенә, тормыш яңадан башлана. Башкурт авылы үзенең яшәү урынын берничә тапкыр үзгәртә. Бу авылга Румыниядән килгән татарлар нигез сала. Авылны төзүдә 1928—1929 елларда Болгария вә Румыниядән качкан төрекләр дә үз өлешләрен кертәләр. 1898—1905 елларда Кавказдан качкан карачайлар Бәлпынар авылын төзиләр, алар шулай ук бабаларының гореф-гадәтләрен саклап калу өчен зур тырышлык куялар. Гаилә кешеләре арасындагы мөнәсәбәтләрдә бернинди үзгәрешләр юк диярлек. 300 ел элек Анадолуга килгән төрекмәннәр Чатмапынар авылына нигез салалар. Хәзерге вакытта анда 300 ләп кеше яши.

Дикиликайа авылында яшәүче аксакаллар түбәндәгеләрне сөйлиләр: 1848 елда төрекмәннәр Урта Азияне калдырып, Анадолу буенча йөргәннән соң, кемдер тарафыннан язылган гаять зур мәрмәр кыя янында тупланергә булалар. Менә шуңа күрә бу авыл шулай дип атала (кайа — кыя, таш; дикили — корылган). Болгариядән килгән мөһаҗирләр 1887 елда Дикмән авылын нигезлиләр. Бер-береннән ерак булмаган Янтуган, Ортакөй вә Доганай авылларына Ганжадан килгән әзәри төрекләре нигез сала. Соңга таба бу авылга Болгариядән килгән качаклар күчә, күрше авылдан төрекмәннәр дә килә. Әминәкин авылы 1630 елдан ук билгеле. 1920 елда монда Селаникадан (Греция) мөһаҗирләр күчеп килә. XIX гасырның ахырларында күрше Хан шәһәрендә яшәүчеләр Гюкчекуйу авылына нигез салалар. Авылның әйләнә-тирәсендә хетт заманыннан калган һәйкәлләр бар. Хан шәһәре — Анадолуның иң борынгы шәһәрләреннән. Византия (Бизанс) заманында «Каккабокане», госманлы дәверендә «Хан Барчунлу» дип аталган. Совет кешесе күзлегеннән караганда, Ханда яшәүчеләр чын төрекләр. Алар сәлҗүкләрдән килеп чыкканнар, ә моның белән, күргәнебезчә, һәрбер төрек тә горурлана алмый. Әмма Хан Караагач авылындагы халыкка соңгы сүзләр кагылмый. Аларның борынгы бабалары сәлҗүкләр күчмә тормыш алып барганнар, 1815 елда гына бер урында тупланганнар. Хәйрия авылында яшәүчеләрнең бабалары кырым татарлары булып, алар Госманлы җиренә 1902 елда күченеп киләләр. 1874 елда солтан Абдулхәмит II Кырымнан килгән татарларга үз җирләренең бер өлешен бүлеп бирә һәм Ылыҗабашы авылы барлыкка килә. Болгар регионнары булган Тырнов һәм Шумладан качкан төрекләр 1892 елда Исканкуйу авылына нигез салалар. Кадыкуйусу авылының тирән тарихы турында тирә-яктагы язылган ташлар сөйли. Анда яшәүчеләрнең буыннары — Анадолу җирләрен византиялеләр белән көрәшеп алучылар. XIX гасырның икенче яртысында Урта Азиядән күчеп килүчеләр Кайы авылын төзиләр. Көрхасан поселогының тарихы үзенең тамырлары белән 1200 елга барып тоташа. 1939 һәм 1950 елларда анда яшәүчеләрнең саны Болгариядән килгән мөһаҗирләр хисабына тулылана. Орхания авылында башта 7 йорт була, 1892 елда Румыниядән качкан кешеләр шунда урнашалар. Османия авылының килеп чыгышы турында ике риваять-юрама бар. Беренче риваять: авыл 1877 елда урыс-төрек сугышы вакытында Идел-Урал татарлары тарафыннан төзелгән. Мондый хәбәрне илчә идарәсендә алырга мөмкин. Бу сугышта татарлар күпләп төрек армиясе ягына күчәләр, сәбәбе билгеле — алар урыс колонизаторларының файдасына көрәшергә теләмиләр. Әмма анда яшәүчеләр үзләре авыл 1893 елда салынды, диләр. Печәнә авылы моннан 100—120 ел элек барлыкка килә. Садыроглу авылы 1950 елларда Бәлпынар авылыннан аерылып чыга. Соңрак аларга карачайлар һәм Румыния, Болгария эмигрантлары килеп кушыла. Сәетхәлимпатша авылына 1913 елда нигез салына, Румыния, Болгария, Грециядән киләләр, мөһаҗир-төрекмәннәр җыела. Сарыкафак авылының барлыкка килүен 1848 ел белән бәйләп күрсәтәләр. Анда чын төрек халкы яши. Язылыкайа авылында яшәүчеләр үзләренең килеп чыгышларын түбәндәгечә аңлаталар: 1883 елда Кавказдан качкан чиркәсләр, 1886 елда монда килеп урнашалар. Янтуган авылында төрекмәннәр өстенлек ала. Кырымның Күкташ авылы татарлары 1902 елда Йолдызәрән авылын төзиләр. 1894 елда румын төрекләре Заферхәмит авылына нигез салалар. 1920 елда аның халкы Болгария, Румыния, Кырымнан күчеп кайтучылар белән тулылана.

Чифтеләр илчәсе дә, гомумән, Искешәһәр вилаяте дә без караган мәсьәләдә башкалардан аерылмыйлар. Бөтен Төркия буенча шундый ук күренеш. Идел-Урал регионыннан булган татарлар тагын Кутахья, Конья, Акшәһәр, Илгын, Измир вилаятьләрендә, шулай ук Истанбул һәм Әнкара шәһәрләрендә урнашалар. Төркиядә Кырым татарларын бүгенге көндә 5 миллионга якын дип әйтәләр. Төньяк-көнчыгыш районнарда нигездә Әзербайҗан һәм Төньяк Кавказдан килүчеләр урнашкан. «Чын әзербайҗан» шәһәрләре дә бар; мәсәлән, Ыгдыр шундыйлардан. XIX гасырның икенче яртысында һәм XX гасырның башында Госманлы

дәүләте хәзерге Израильне хәтерләтә. Урыс-төрек сугышлары нәтиҗәсендә төрекләр күпләп Балканны ташлап китәргә мәҗбүр булалар. Төньяк Кавказ һәм Урта Азиянең колонизацияләнүе бу регионнардан күп кенә кешеләрнең качуына сәбәп була. Рәсәйнең үзәк районнарындагы төрекләр дә, милли-дини изүгә чыдый алмыйча, Анадолуга бик күпләп күченәләр.

Иң кызыгы шунда ки, чуар, күп телле, төрле-төрле халык, Госманлы жиренә җыенып, тиздән бербөтен төрек милләтенә әверелә. Могҗизамы? Юк. Югары дәрәҗәгә, милләт дәрәҗәсенә күчү бөтен төрек этносының бөтен узган үсеше белән билгеләнгән иде. XX гасыр башында төрекләр уртак әдәби телгә ия булып, бер гомуми дәүләткә берләшәләр. Дифференцация вә интеграция мөнәсәбәтләре диалектикасы, эре этнослар үсешендәге бу капма-каршы процесслар күрәше тиздән төрекләрнең берләшүе һәм яңа дәүләт барлыкка килүе турында сөйли иде. Һәм чыннан да, 1923 елда Төркия җөмһүрияте барлыкка килә. Төрекләрнең берләшү тенденциясе, ниһаять, җиңүгә ирешә, әмма бик тар кысаларда, фәкать яңа дәүләтнең чикләрендә.

Тарихи закончалык тулы күләмдә үз хезмәтен башкара алмады. Аның сәбәпләре билгеле, алар 1914 елдан соң булган вакыйгаларга бәйле. Алар төрек тарихына кискен борылыш ясый. Госманлы җирләре басып алына, Рәсәй сугышта җинелә һәм тиздән канга чума. Шушы чорда Кытайның да дәүләт төзелеше үзгәрә. Төрекләр Рәсәйдә большевиклар тарафыннан бүлгәләнәләр һәм башка илләрдәге кардәшләреннән генә түгел, ә бәлки бер-береннән дә изоляцияләнәләр. Алар этник-мәдәни үсештә артка алып ташланалар, чөнки бүлү инде үлеп беткән кабилә (нәсел) үзенчәлекләре эзләре буенча алып барыла. Төрек этносын тәшкил итүче элементлар үзләре мөстәкыйль берлек дип игълан ителәләр. Аларның һәрберсенә аерым әлифба, аерым исем бирелә. Милли дәүләтчелек исә, аз хокуклы булуына да карамастан, бөтенесенә дә тәтеми. Аннан соң Кытайда да төрекләргә шундый ук мөнәсәбәт кабатлана. Нәтиҗәдә, этносның табигый үсеше бозыла. Төрекләр үзләре таралган мәйданда бербөтен милләт булып оеша алмыйлар. Этнос үзенчәлекле рәвештә берләшә — үзе яшәгән туфракларны берләштерү насыйп булмагач, ул туфраклардан вәкилләр уртак бер җиргә җыела. Гаспралының бөтен төрекләрне берләштерү хыялы тормышка аша, ләкин миниатюр күләмдә. Шулай итеп, XX гасырның беренче чирегендә гомуми төрек милләте оеша. Төрек телендә «төрки» дигән төшенчәнең булмавы юкка гына түгел, «төрек» дигән термин бөтен төрекләрне үз эченә ала. Мәсәлән, безне Төркиядә Казан яки кузәй төрекләре дип йөртәләр. Әрмәннәрнең дә барыбызны да төрекләр дип атавын билгеләп үтик. «Төркия җөмһүрияте» дигән исем, мәгънәсе буенча, урысның «Тюркская республика»сына тәңгәл килә. Урыс теленә «тюрк» һәм «турок» төшенчәләренең кайчан һәм кем тарафыннан кертелүе тарихына тукталмыйбыз инде. Бары тик шуны әйтеп үтәргә кирәк, асылда ул «бүлгәлә һәм хакимлек ит» сәясәтенең чагылышы булып тора. Тел чаралары аша шундый фикер үткәрелә ки, төрек, татар, казакъ, үзбәк — төрле милләтләр. Шулай итеп, төрек милләте — бөтен төркиләрнең берлеге, ә төрек теле — бөтен бүгенге көндә татар, казакъ, үзбәк һәм башка «телләр» буларак билгеле төрки диалектларының, төгәлрәк итеп әйткәндә, аларның иске вариантларының — иске татар, иске казакъ, иске үзбәк һ. б. синтезы. Шушы принципиаль нәтиҗәдән аңлашылганча, Төркиядә татарларның күпме булуы турындагы сорау төпле түгел. Сүз бары тик, нәкъ Израильдәге сәвит яһүдиләре кебек, күптән түгел шунда барып урнашкан һәм гомумтөрек байлыкларын үзләштереп өлгермәгән якташларыбызның саны турында гына булырга мөмкин. Сәвит иленнән киткән яһүдиләр дә беренче вакытта аерылып торалар икән. Ф. Хәкимҗанов китергән саннар буенча, 1917 елга кадәр Анадолуга качкан татарларның күпчелеге этник төркем үзаныннан арынып, гомумэтник үзаңны үзләштергән.

Төркиядә яшәүче татарларның тормышлары белән танышу, очрашу һәм сөйләшүләр шуны күрсәтә ки, аларны тел һәм мәдәният проблемалары борчымый. Алар бары тик Рәсәй төрекләре өчен генә хас. Төркиядә бу турыда белмиләр дә. Татар төрекләре төрек, ягъни ата-бабалары телендә сөйләшәләр, аларның гореф-гадәтләре буенча яшиләр. Төрек теле (укы: иске татар теле) — аларның туган теле. Соңгы елларда тарихи Ватаннары белән үзара бәйләнешләр киңәю йогынтысында татарлар үзләренең оешмаларын төзиләр. Безгә ике берләшмә билгеле. Истанбулда Идел-Урал төрекләренең мәдәният һәм ярдәмләшү җәмгыяте бар. Аны Синан әфәнде Отрав җитәкли. Оешма әгъзалары үзләренең төп бурычларын Татарстанга мөстәкыйльлек яулап алуда, анда яшәүче халыкның телен һәм мәдәниятен торгызуда һәрьяклап ярдәм итүдә күрәләр. Алар Татарстан Президентының Төркия җөмһүриятенә визитын тормышка ашыруда зур ярдәм күрсәттеләр. Рәсәй татарлары, ял көннәрендә бергә җыелып, үзләренең туган телләрендә сөйләшергә мөмкинлек тапканга шатланалар. Туган тел турын-

да балаларына аз гына булса да мәгълүмат бирү өчен, аларны якшәмбе мәктәпләренә илтәләр. Туган тел моңнарын ишеткәч, анда җыелучы кешеләрнең күзләренә яшь тула... Менә шундый очрашулардан соң, чарасызлыктан, көчсезлектән күңелдә авыр тәэсир кала. Милләтебезнең урыс, христиан массасында эреп баруын күрү бик кызганыч ич.

Синан әфәнде Отрав оешмасының җыелышлары иң якын туганнар җыелган зур бер бәйрәмне хәтерләтәләр. Анда Рәсәйдәге татарларның тормышы турындагы хәбәрләр тыңлана. Чәй янында сүз, нигездә, экономик проблемалар турында бара. Тарихи Ватан белән элемтәләрне ничек итеп киңәйтергә? Татарстанда товарлар белән сату-алуны ничек җайга салырга? Базар мөнәсәбәтләренә күчеп барган җөмһүрияткә чит илләрдән акча кирәк. Анда күп акчалар тотып тәвәккәлләргә буламы соң? Татар төрекләрен бүгенге көндә менә шундый сораулар борчый. Шушы проблемаларны чишү өчен Төркиядәге татарларның мәркәзе булган Искешәһәрдә 1992 елның 2 январенда Казан Мәдәният җәмгыяте төзелә. Аңа нигез салучылар булып Чифтеләр илчәсенең Османия авылы кешеләре санала.

Авыл картларының сөйләүләре буенча, аларның әти-бабалары Анадолуга Урал якларыннан килеп урнашканнар. Урал (Җаек) елгасының исеме белән бәйләнгән күп кенә фамилияләр моны исбатлыйлар — «ЦАҮИК», «ЦАҮИКИИ», «ЦАҮИКДАН» һ. б. Авыл урнашкан урын Ырынбур панорамасын хәтерләтә. Авыл калкулыкта ята, шуңа күрә аның элекке исеме дә «Куруһүйүк», ягъни «Коры калкулык» дип атала. Табигать шартлары да бик охшаш. Җәй көне монда коры һәм эссе, кышларын исә, бик кырыс, суык була. Яшьләр авылдан шәһәргә күчеп китә. Илчәдә беренчеләрдән булып ачылган башлангыч мәктәптә бары тик ике укытучы гына эшли. Статистика буенча, 1985 елда авылда 249 кеше яшәгән, бүгенге көндә аннан да азрак.

Бик матур мәчет эшли. Өйләр тыштан ялтырамый, әмма эчләре гүзәл. Авыл үзенең төрекмәннәрдә булмаган мунчалары белән танылган була. Хәзерге вакытта бер генә мунча калган. Татар булган җирдә ызгыш-талаш. Авылдашлар ике төркемгә бүленгән — хәзерге мухтар (авыл башлыгы) Йөзҗан Яфай яклы кешеләр һәм аңа каршылар.

Казан җәмгыяте эчендә дә төрле каршылыклар бар. Турыдан-туры күрешүләр күрсәткәнчә, бу җәмгыятьтә иҗтимагый-сәяси карашлары буенча якын кешеләр җыелган. Күпчелек татарлар бу берләшмәләр турында беләләр, ләкин аларның эшчәнлегендә катнашмыйлар. Төркиядә милли проблема юк, бөтенләй башка тел гаиләсенә караган көрдләр һәм төрек массасы арасында аңлашылмаучанлык кына бар. Икътисади һәм иҗтимагый-сәяси проблемаларны хәл итү өчен гражданнар анда төрле оешмалар төзиләр. Татарлардан чыккан кешеләр төрле сәяси партияләрдә торалар, күп очракларда алар капма-каршы максатны күздә тоталар.

Искешәһәрдәге киемнәр кибетенең хуҗасы Абдулла Яваш миңа бик кызыклы тарих сөйләде. 1982 елда аның әтисе ниндидер могҗиза ярдәмендә СССРга килеп чыга. Ырынбур өлкәсендәге туган авылын эзләп таба, анда кардәшләре белән очраша. Шул хәлләрдән соң, авылда КГБ хезмәткәрләре еш күренә башлый. Алар Абдулланың туганнарын милләтчелектә, төркичелектә, төрек бозкуртлары («күк бүреләр») белән элемтәләр урнаштыруда, Ырынбурны Төркиягә кушу планнары эшләүдә гаепләләр. Иң кызыгы шунда ки, төрекләрнең яшерен полициясе — МИТ тарафыннан Абдулланың әтисе дә эзәрлекләнә. «Күләгә кебек артыннан йөриләр иде»,— ди ул бу хакта исенә төшереп.

— Әллә сездә дә милли билгеләр буенча эзәрлекләүләр бармы? — дип сорамыйча булдыра алмадым. Чыннан да, бу елларда КПСС Төркия коммунистларын бик юмарт финанслый, шул акчага алар төрле тәртипсезлекләр оештыралар, шәһәр һәм авылларда башка карашта торган кешеләрне кыйныйлар. Илдә курку мохите тудырыла. Мәскәүдә партия җитәкчеләре властька коммунистлар килүен һәм Төркиянең «социалистик лагерьга» кушылуын көтгеләр. Аңлашыла ки, СССР белән һәр элемтә бу болганчык елларда төрек властьларында шик тудыра. 30 нчы еллар ахырыннан Казан төрекләре Союздагы туганнары белән хат алышу мөмкинлегеннән дә мәхрүм ителәләр.

Бүген инде мондый коточкыч нәрсәләр артта калды. Төркиядәге татарлар өчен беренчел үзенчәлекле проблемалар юк. Алар үзләрен төрек халкының аерылмас бер өлеше итеп карап, аның шатлыклары һәм мәшәкатьләре белән яшиләр. Искешәһәрдә канализация системасы үткәрә башладылар, элек ул анда юк иде. Шәһәр урамнарындагы күп урыннар казылу уңайсызлыклар тудыра, әлбәттә. Бүген гаиләләрдә шул турыда сөйләшүләр өстенлек алып тора...

# ИБРАҺИМ БИККУЛОВ



Ул әлеге фотога 1926 елда Кисловодскига ял итәргә баргач, кавказлылар киемен киеп төшкән. Миңа аны туганнары җибәргән иде.

Кем соң ул Ибраһим Биккулов? Ул зыялы гаиләдән чыккан мөгаллим, журналист, тәрҗемәче: 1884 елда Сембер губернасы Буа өязе Яңа Тинчәле авылында Җамалетдин хәзрәт гаиләсендә дөньяга килә. Абыйсы Касыйм Биккулов — мулла, язучы, дәреслекләр авторы. Башка туганнары да укымышлы кешеләр булган.

И. Биккулов, Буа мәдрәсәсендә белем алганнан соң, Казанга килеп, 1908 елда атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлый. Ф. Әмирхан аның шәриктәш дусты.

«Мөхәммәдия»не тәмамлагач, И. Биккулов Томскига мөгаллим булып китә. Томскида нинди кыенлыклар белән балалар укытуы турында ул Ф. Әмирханга хатлар язып тора. Салкын Себергә үз теләге белән мөгаллим булып китүчеләр ул вакытларда сирәк була. Андыйларны «Караңгы Себергә мәгърифәт нуры сибүчеләр» дип атаганнар. И. Биккуловның журналистлык эшчәнлеге дә Себердә укытканда башлана. Ул 1914 елда Казанга кайта. «Шура», «Мәктәп», «Сөембикә», «Аң», «Ак юл» журналларында, «Казан мөхбире», «Йолдыз», «Әльислах», «Ил» газеталәрендә языша. «Сибирия» газетәсенең үзхәбәрчесе була. «Кояш»та, Ф. Әмирхан белән бергә, газетәнең төп хезмәткәре булып эшли. Аның «Хәзрәт», «Әкмәли», «Мөгаллим», «Ислам улы» дигән яшерен имзалары билгеле.

Февраль һәм Октябрь революциясе чорларында И. Биккуловның иҗтимагый эшчәнлеге тагын да активлаша төшә. Сембер шәһәрендә «Җөмһүрият» дигән атналык газетә чыгара. Бу газетә соңыннан буржуаз милләтче басмалар исемлегенә кертелә. И. Биккулов Уфада үткән «Милли мәҗлес»тә Сембер губернасы вәкиле булып катнаша. «Милли мәҗлес»нең «Хокук комиссиясе» әгъзасы итеп сайлана. «Уфа хәбәрләре» газетәсенә языша.

Шулай да И. Биккуловның язмышы Казан белән бәйле. Ул 1923—1924 елларда Ф. Әмирхан белән берлектә Казан татар театры техникумында татар теле дәресләрен алып бара. Татар телен гамәлгә кую курсларында да укыткан булырга тиеш дигән хәбәрләр йөри. 1925—1929 елларда рус теленнән биш исемдә китап тәрҗемә итә. 1926 елда үзенең «Мәктәптә тән тәрбиясе» исемле китабы чыга. 1929 елда да И. Биккулов әле Казанда яши. Шуннан соңгы язмышын мин ачыклый алмадым. Мәрхүм Рашат Гайнанов Г. Ибраһимовның сигез томлык «Әсәрләре» җыелмасында аның үлгән елы итеп 1938 елны күрсәтә. «И. Биккулов шәхес культы чоры корбаны булырга тиеш»,— Рашат Гайнанов шулай дия торган иде. Бәлки Вакыт галиҗәнаблары бу гоманлауларга ачыклык кертер. Һәрхәлдә, өметләнеп яшик.

Быел әлеге журналистның юбилей елы, тууына 110 ел тула (туу көне генә билгесез). Бу кечкенә язма һәм әлеге фотоны дөньяга чыгару, шушы мөхтәрәм шәхеснең рухын искә алу максатын да күздә тота.

**Фатыйма ИБРАҺИМОВА**



## РОССИЯ ПРЕЗИДЕНТЫ ТАТАРСТАНДА

30 майда Россия Федерациясе Президенты Б. Н. Ельцин Чаллы шәһәренә килде. Бигеш аэропортында аны Татарстан Республикасы Президенты М. Ш. Шәймиев, ТР Югары Советы Рәисе Ф. Х. Мөхәммәтшин, ТР Премьер-министры М. Г. Сабиров, Татарстанга алданрак килгән Россия Федерациясе эчке эшләр министры В. Ф. Ерин, Россия Федерациясенең милләтләр һәм региональ сәясәт эшләре министры Н. Д. Егоров, Чаллы шәһәре мэры Р. З. Алтынбаев һәм башка рәсми кешеләр каршылады.

Б. Ельцин һәм М. Шәймиев Чаллы шәһәренең эчке эшләр идарәсендә, «КамАЗ» заводларында, «КамАЗ» фәнни-техник үзәгенең күргәзмә мәйданчыгында булдылар.

Шул ук көнне Б. Н. Ельцин, М. Ш. Шәймиев Казанга кайттылар.

31 майда Россия Президенты Казанның балалар учреждениесендә, «Майский» совхозында, Мәрҗани мәчетендә, Петропавел соборында булды, хезмәт ияләре белән очрашты. Аннары Казан Кремлендә визитка йомгак ясалды.

## ФРАНЦИЯДӘ ОЧРАШУЛАР

Татарстан Республикасы Вице-президенты В. Н. Лихачев 2—5 май көннәрендә эш визиты белән Франциядә булды. Ул анда промышленность, телекоммуникация һәм тышкы сәүдә министры М. Лонге, тышкы эшләр вице-министры, Европа континенты департаменты директоры П. Пудоле, Милли ассамблеянең тышкы эшләр комиссиясе әгъзасы М. Денио, Париж Академиясе ректоры һәм Сорбонна университеты канцлеры М. Жандрео-Массалу һәм башка рәсми кешеләр белән очрашты.

Француз ягы, Татарстан Республикасы икътисадының тотрыклы һәм перспективалы булуын билгеләп үтеп, безнең җөмһүрият белән төрледән-төрле үзара файдалы мөнәсәбәтләрне үстерүгә әзер булуын белдерде.

## М. Г. САБИРОВ — ТӨРКИЯДӘ

Төркиягә эш визиты белән килгән Татарстан Республикасы Премьер-министры М. Г. Сабировны 28 апрельдә бу ил Президенты С. Дәмирәл әфәнде кабул итте. Дустанә шартларда үткән әңгәмә барышында ике дәүләт арасында үзара файдалы сәүдә-икътисадый һәм мәдәни хезмәттәшлекне тирәнәйтү, Татарстан икътисадына реформалар ясауда Төркия тәҗрибәсен куллану мөмкинлекләре турында сөйләшенде.

Шул ук көнне М. Сабиров Төркиянең Бөек Милли Җыены Рәисе Х. Чиндорук белән очрашып сөйләште.

## ҖӨМҺҮРИЯТЕБЕЗДӘ — КОРБАН БӘЙРӘМЕ

Мөэмин-мөселманнарның иң зур, иң кадерле бәйрәмнәренең берсе саналган Корбан бәйрәме алдыннан, 20 майда — изге Гарәфә көнендә — Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев Казанның Ленин районындагы Болгар мәчетендә булып, дин әһелләре белән очрашты.

Җөмһүриятебез Илбашы барча мөселманнарны олы бәйрәм белән кайнар котлады, һәркайсына саулык-сәламәтлек теләде.

* * *

21 майда, иртән, мәркәзебезнең Мәрҗани, Әҗем, Печән базары, Кабан арты, Солтан, Рамазан һ. б. мәчетләрендә, шулай ук Татарстанда теркәлгән 300дән артык мәчетмәхәлләләрдә дә бәйрәм намазлары булып узды. Елдагыча, Сөембикә манарасы янындагы мәйданда да күпләгән халык Корбан бәйрәмен зурлап билгеләп үтте. Бирегә җөмһүриятебезнең күп төбәкләреннән, күрше республикалардан да килгәннәр иде.

## МАТБУГАТ БӘЙРӘМЕ УҢАЕННАН

6 май көнне — Татарстанда Матбугат бәйрәме уңаеннан — Татарстан Республикасы Президенты М. Ш. Шәймиев массакүләм матбугат чаралары житәкчеләрен кабул итте. Очрашу барышында бүгенге матбугат алдында торган бурычларны хәл итү юллары хакында житди сөйләшү булды.

Шул ук көнне 16 сәгатьтә башкалабызның Бауман, Кави Нәҗми, Муса Җәлил һ. б. урамнарында Матбугат бәйрәме башланды. Анда республикабызда чыгучы күп төрле газета-журналлар редакцияләре хезмәткәрләре, танылган язучылар, сәнгать осталары чыгыш ясады.

Матбугат бәйрәмендә Татарстан Югары Советы Рәисенең беренче урынбасары З. Р. Вәлиева, ТР Премьер-министры урынбасары И. К. Хәйруллин, Мәгълүмат һәм матбугат министры И. Г. Әхмәтҗанов катнашты.

## ПРЕЗИДЕНТ ӘДИПЛӘРНЕ КАБУЛ ИТТЕ

30 май көнне Татарстан Республикасы Президенты М. Ш. Шәймиев Кремльдә бер төркем татар язучыларын кабул итте. Әлеге

очрашуда ул әдипләрдән Гариф Ахуновка, Аяз Гыйләҗевка, Мөхәммәт Мәһдиевка «Татарстан Республикасының халык язучысы», Илдар Юзеевка «Татарстан Республикасының халык шагыйре» дигән мактаулы исемнәрнең таныкнамәләрен һәм билгеләрен тапшырды.

Очрашу барышында республикабызның мәдәният һәм иҗтимагый тормышындагы көнүзәк мәсьәләләр күтәрелде.

Бу җыелы һәм ихлас сөйләшүдә әдипләрдән Г. Бәширов, Ә. Еники, Ш. Галиев, Г. Зәйнашева, Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Р. Батулла, М. Маликова, А. Әхмәдуллин, З. Мансуров, Татарстан китап нәшрияты директоры Х. Әшрафҗанов, Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев һәм башкалар катнашты.

## КЫРЫМЛЫЛАР КАЙГЫСЫН УРТАКЛАШУ

Моннан 50 ел элек, 1944 елның 18 маенда, Сталин фәрманы белән Кырым татар халкы үз җирләреннән рәхимсез төстә читкә сөрелгән. Шул уңайдан, Кырым Республикасында матәм көне билгеләп үтелде. Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары И. К. Хәйруллин, Югары Советның даими комиссиясе рәисе, язучы Р. И. Вәлиев Кырым Югары Советы һәм Министрлар Кабинетының кайгы утырышында һәм кайгы митингысында катнаштылар.

Кырым татарлары һәм башка милләт халыклары чит җирләргә сөрелгән тимер юл вокзалларында мемориаль тakталар ачылды. Кырым татарлары Милли Мәҗлесе дә, әлеге фаҗигале вакыйгага ярты гасыр тулуга багышлап, күп чаралар үткәрде.

## БАЛТАЧТА — ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ КӨННӘРЕ

17—18 май көннәрендә Татарстанның Балтач районында татар әдәбияты көннәре үткәрелде. Бирегә Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев җитәкчелегендә 12 әдип килде. Алар районның Куныр, Борбаш, Карадуган кебек төбәкләрендә булып, авыл эшчәннәре, мәктәп укучылары белән очраштылар. Балтач халкы Г. Ахунов, А. Гыйләҗев, М. Мәһдиев, И. Юзеев, Ш. Галиев, Г. Зәйнашева, Р. Фәйзуллин, Р. Гатауллин, Р. Харис, М. Галиев кебек язучыларның чыгышларын яратып кабул итте.

Каләм осталары Шодадагы Мирхәйдәр Фәйзи музеенда һәм Г. Тукайның әнисе Мәмдүдә абыйстай күмелгән Сосна Пүчинкәсе зиратында да булдылар.

## ТУКАЙ МУЗЕЕНДА — «КАЗАН УТЛАРЫ» КӨНЕ

18 майда мәркәзебезнең Г. Тукай музеенда «Казан утлары» журналы көне» үткәрелде. Аңа Казандагы татар гимназияләре мөгаллимнәре һәм шәкертләре, республикабызның төрле төбәкләреннән журналны алдыручылар, чит җирләрдә яшәүче милләттәшләребез, дин әһелләре килгән иде.

Очрашуда «Казан утлары» журналының җаваплы сәркатибе Наис Гамбәр, бүлек мөхәррирләре Тәүфикъ Әйди, Шаһинур Мостафин һәм басмабызның даими авторларыннан саналган Батулла, Зәки Зәйнуллин, Фәрит Яхин кебек каләмдәшләребез чыгыш ясады. Алар тыңлаучыларның күп санлы сорауларына җавап бирделәр.

Билгеле булганча, 18 май — Кырым халкын туган илләреннән сөрүнең 50 еллыгы көне. Шул уңайдан, әлеге матәм көненә багышлап, Ташкент өлкәсенең Газалкент шәһәреннән килгән Әмирханиф хәзрәт Галиев, сөрелгәндә вафат булганнарны искә алып, залдагы барча халык белән бергә, алар рухына дога кылды.

1990—1991 елларда Кырым татарларына матди һәм рухи ярдәм күрсәткән язучыларыбыздан Батулла һәм Зәки Зәйнуллин исә үз истәлекләре белән уртаклаштылар.

## ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫ — ЯҢА БИСТӘ ЗИРАТЫНДА

27 нче майда, җомга көнне, бер төркем татар язучылары — танылган драматург Туфан Миңнуллин, «Казан утлары» журналыннан Шаһинур Мостафин, «Идел» журналыннан Ркаил Зәйдулла, Марат Закир, «Салават күпере» журналыннан Зиннур Хөснияр, Ләбиб Лерон, «Татар иле» газетасыннан Газинур Морат һәм Татарстан Язучылар берлегенең хуҗалык мөдире Шамил Бәдертдинов Яңа Бистә зиратында булдылар. Алар биредә төрле елларда күмелгән татар әдипләренең каберләрен тәртипкә китерделәр. Шул ук көнне күренекле татар шагыйре, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Нури Арслан һәм балалар язучысы Әминә Бикчәнтәева каберләренә ак мәрмәрдән эшләнгән язулы ташлар һәм чардуган куелды. Чардуганны Т. Миңнуллин үз хисабына махсус эшләткән иде.

## ШАГЫЙРӘ ЮБИЛЕЕ

Әлмәт районының Габдрахман авылында гомере буе балалар укыткан шагыйрә Энҗе Илалетдин кызы Мөэминовага 70 яшь тулды. Шул уңайдан, Әлмәт нефтьчеләренең мәдәният һәм техника сараенда юбилярның иҗат кичәсе үткәрелде. Э. Мөэминованы Татарстан Югары Советы Рәисенең беренче урынбасары Зилә Вәлиева, юбилярның күп санлы шәкертләре, каләмдәшләре, шигърият сөючеләр, сәнгать осталары, район һәм шәһәр хакимияте җитәкчеләре һ. б. олуг бәйрәме белән кайнар котладылар.

## ГАКЫЙЛ СӘГЫЙРОВНЫҢ ИҖАТ КИЧӘСЕ

Самараның Металлурглар мәдәният сараенда көчле рухлы шагыйрь һәм рәссам Гакыйл Сәгыйровның иҗатына багышланган хәйрия кичәсе уздырылды. Аны өлкәдә татар телендә чыгучы «Бердәмлек» газетасы, «Туган тел» мәдәни үзәге һәм «Азатлык» яшьләр берлеге оештырды.

Әлеге кичә тамашачыларны 51 ел гомереңнең 40 елга якынын түшәктә ятарга мәҗ-

бүр булган Г. Сәгыйровның «Кабатланмас мон» исемле яна шигырьләр җыентыгы һәм рәсемнәре күргәзмәсе белән таныштыруга багышланды.

Кичәдә Казаннан килгән кунаклардан — шагыйрь һәм драматург Рөстәм Мингалим Гакыйл Сәгыйровка Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы билетын тапшырды һәм аңа күңел көрлеге, иҗат уңышлары теләде.

Язучылардан — Татарстан китап нәшрияты мөхәррире Фәнзаман Баттал, «Аргамак» журналының баш мөхәррире Айдар Хәлим, «Салават күпере» журналы баш мөхәррире Зиннур Хөснияр чыгышлары да шагыйрьнең иҗат кичәсенә нур өстәде.

## КИТАПХАНӘГӘ — ӘДИП ИСЕМЕ

Фаҗигале төстә вафат булган талантлы әдип Фаил Шәфигуллинны якташлары онытмый. Аңа багышлап, туган ягында — Зеленодол районында әледән-әле китап укучылар белән очрашулар, әдәби-музыкаль кичәләр булып тора. Күптән түгел генә районның милли китапханәсенә Ф. Шәфигуллин исеме бирелде.

## КАЗАН КҮГЕНДӘ — БАЛЕТ ЙОЛДЫЗЛАРЫ

Татарстан башкаласында опера җырчыларының данлыклы якташыбыз Федор Шаляпин исемендәге XIII Халыкара фестивале моңнары тынарга өлгермәде, 13 майда М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры бинасында балет осталарының VIII Халыкара фестивале ачылды. Атаклы милләттәшебез — XX гасырның мәшһүр биючесе Рудольф Нуриев исемен йөртүче әлеге мәртәбәле фестивальдә ун көн буе, дөньякүләм танылган балет осталары белән бергә, татарстанлылар да тамашачыларга бәхетле мизгелләр бүләк иттеләр.

Фестиваль 22 майда гала-концерт белән тәгәлләнде.

## ТЫЛСЫМЛЫ МОҢНАР ДӨНЬЯСЫНДА

Мәскәүнең Глинка исемендәге Музыка музеенда композитор Рәшит Кәримуллинның «Шәрекъкә юл» дип исемләнгән яңа концерты премьерасы булды. Анда талантлы авторның соңгы елларда иҗат иткән әсәрләре яңгырады.

* * *

Германиянең Штауфен шәһәрендә дөньяда тиңе булмаган уен коралы — органны презентацияләү оештырылды. Анда Татарстан вәкилләре дә катнашты. Скрипкачы Рөстәм Абязов, органчы Людмила Камелина, виолончельдә уйнаучы Ирина Лаптева кебек казанлылар Зигфрид Люстиг җитәкчелегендәге оркестрда чыгыш ясадылар.

* * *

Кукмара районында күренекле композитор Фасил Әхмәтов призына «Яшь талантлар» фестиваль-конкурсы үткәрелде. Бәйгедә мәктәп укучыларыннан 130 лап бала катнашты. Соңыннан район авылларында сәнгать осталары белән очрашулар булды. Якташлары янына Ф. Әхмәтов үзе дә кайткан иде.

## БАШЛАП ЯЗУЧЫЛАР КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

25 апрельдә Минзәлә районында башлап язучыларның бишенче конференциясе үткәрелде. Анда әдәби ел йомгаклары турында шагыйрь Рәшит Гәрәй чыгыш ясады. Район газетасы игълан иткән иҗади бәйгедә җиңгән һәм быел Татарстан китап нәшриятында «Кояшка хат» дип исемләнгән беренче шигъри җыентыгын чыгарган 5 нче сыйныф укучысы Энҗе Афзаловага һәм аның каләмдәшләренә истәлекле дипломнар, бүләкләр тапшырылды.

## ГАРМУНЧЫЛАР БӘЙРӘМЕ

Республикабызда ике елга бер мәртәбә май аенда гармунчыларның Фәйзулла Туишев исемендәге бәйгесен үткәрү матур бер гадәткә әверелде. Бу конкурсның быелгысында катнашу өчен Казанга республикабыз районнарыннан йөздән артык гармунчы җыелды. Әлеге бәйгегә осталыкта көч сынашырга чит җирләрдә яшәүче милләттәшләребез дә килгән иде.

## КАЛӘМДӘШЛӘРЕБЕЗ САФЫНА

Башкортстандагы татар язучылары берлегенең идарә һәм ревизия комиссиясенең киңәйтелгән утырышында үзләрен иҗади оешмага алуны сораган әдипләрнең гаризалары каралды. Салават Рәхмәтулла, Альберт Котыев, Рәис Риян, Вил Казыйханов һәм Гали Гатауллин Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул ителделәр.

## КОТЛЫЙБЫЗ!


Татар музыка сәнгатен пропагандалаудагы уңышлары өчен Башкорт дәүләт филармониясенең эстрада җырчысы Фән Гавис улы Вәлиәхмәтовка «Татарстан Республикасының атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Музыка сәнгате өлкәсендәге зур казанышлары өчен, Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе артисты Рөстәм Гали улы Маликов «Татарстан Республикасының халык артисты» дигән мәртәбәле исемгә лаек булды.

* * *

Әдәбият һәм сәнгатькә караган актуаль мәсьәләләрне иҗади яктыртканы өчен, «Ватаным Татарстан» газетасының бүлек мөдире Асия Шәйхразый кызы Юнысовага, 1993 ел дәвамында басылган иң яхшы язмалар авторы буларак, Татарстан журналистларының Х. Ямашев исемендәге премиясе бирелде.




# КИҢЛЕК

Татарстан сынлы сәнгате өлкәсендә дистәләрчә ел җиң сызганып, армый-талмый мәдәниятебезнең абруен күтәрү өчен чын ихластан хезмәт итеп килгән рәссамнар бар. Җөмһүриятебезнең иреге өчен барган көрәш елларында алар бер-бер артлы калкып чыгып, халыкка, җәмәгатьчелеккә үз фикерен җиткерә башладылар.

Сүз шуларның берсе — Шамил Шәйдулла турында.

Ул — үзсүзле, тынгысыз, зур профессиональ хәзерлекле рәссам. Петербург сәнгать академиясендә Моисеенко остаханәсендә укыган, Казанда элекке СССРның халык рәссамы Х. Якупов аспирантурасын бетергән, әсәрләрен өер-өер таплар, төсле нурлар белән тамашалаучы Ш. Шәйдулла безнең сәнгатебезгә традицион рәвештә миллилекне, халыкчанлыкны туплаган «авыл темасы» белән килеп керде.

Ләкин, аксакалларның иҗатыннан аермалы буларак, Ш. Шәйдулланың нәфис тукымаларында — бер-берен көрәш мәйданнарында «шырт»-«шырт» аударучы пеләш батырлар, яисә ял вакытында кырда тамак ялгап утыручы кояшта каралып беткән кыр батырлары, күлмәк-майкалары астыннан көчле мускуллары беленеп, күкрәк киереп, масаеп басып торган механизаторлар урынына — авыл табигатенең бетмәс-төкәнмәс нәфислеге, табигать белән аралашып яшәгән кешеләрнең инсафлыгы, халык гореф-гадәтләренең матурлыгы, шомырт җыю, печән чабу, богыл кую кебек хезмәт йолаларының җанлы күренеше сурәтләнде. Борынгы белән бүгенгене бәйләп, тарих төбеннән чыккан Сабантуйларны халык моңы белән ямьләүче курай моңнарының мәңгелек авазлары яңгырады...

Шунысы әһәмиятле, бу — рәссамның тема белән уйнап, ул елларда модага кереп киткән урбанистик дөньядан, «тын халәткә», табигать кочагына омтылу кебек күренешләрнең чагылышы, Руссо яки Гоген корган тормыштан качу утопияләренең чагылышы түгел иде. Бу — шәһәрдә туып үскән егетнең аңлы рәвештә корган сәнгать концепциясе, тормышка ашырасы миллилек позициясе булды. Шул карашлар аны Тукай темасы белән тоташтырды; Босх, Гойя дәрәҗәсендә тасвир кылынган җансыз табигать белән җанлы табигатьнең самимилеген, хөрлеген яклап, кеше күңелен андагы табигать чәчәкләредәй гүзәл тел, милли кичерүләр, ата-баба йолаларыннан гыйбарәт үзгәлекне күтәреп чыккан «Уяну» памфлетлары учагына алып керде.

Татар тормышы нindидер күләмдә яктыру, яңару, тупас тапталудан ирек дәгъвалау, үзенә хокук тәэмин итү юлларына чыккан бер чорда гына, Ш. Шәйдулла киң сулыш алды һәм күптәннән йөрәгендә кайнаган, кеше фигуралы картиналарына бөркелеп чыккан пейзаж, табигатьне сурәтләү стихиясенә кереп чумды. Кызык, аның элеккеге пейзажларында шундый бер гаҗәеп «тизлек» күзгә ташлана иде: анда агачлар, әйтерсең, кәүсәсез, ябалдаш кроналары, тамырның үзеннән үсеп чыга сыман, яшеллек чатный-чатный тереклек итә, аның астындагы җир дер селкенә: елгалар тизрәк ага, көн белән төн дә ашыгып бер-берен куып җитәләр кебек.

Соңгы пейзаж серияләрендә мондый сабырсызлык, кабалану юкка чыккан. Аларда классик салмак ритм, табигатькә хас төсләр, җисемнәр, аларның бер-берсенә бәйле рәвештә гармоник агышы, алмашынышы тасвирланган... Нindидер тынлык, уйлану хөкем сөрә аларда.

Бу киң келәмнәргә карыйсың да, «мәңгелек», «чиксезлек» дигән әйберләрнең мәгънәсен тоясың... Ш. Шәйдулланың йөрәге дә шул күкләрдә, иксез-чиксез ефәк киңлекләрдә, тирән алсулык тарафларында тирбәлә. Уйлары халык уйлары, моңнары белән тоташа. Безнең гомер кыска, халык гомере озын... Ахры, асыл мәгънә дә еракларда, киләчәктәдер. Халык гомере шул мәгънә белән тоташыр...

Розалина ШАҺИЕВА,
сәнгать белгече.

Тышлыкның 1 битендәге фотосурәт «Туран» фонды коллекциясеннән алынды.

**Тышлыкның беренче битендә:** Шамил Шәйдулланың «Кичке азан» картинасыннан фоторепродукция.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** танылган әдип һәм җәмәгать эшлеклесе Разил Вәлиев.

Р. МӨХӘММӘТҖАНОВ фотосурәте.

# ЯҢА КИТАПЛАР

АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ. Әсәрләр, дүрт томда. 1 том: *Хикәяләр. Повестьлар.*— Казан: Тат. кит. нәшр., 1994.— 574 б. Тиражы 5000 данә.

Татарстанның халык язучысы, Г. Тукай премиясе лауреаты Аяз Гыйләҗевнең дүрт томлык әсәрләр җыентыгы дөнья күрә башлавы татар әдәбияты өчен куанычлы бер вакыйга. Безнең алдыбызда аның беренче томы. Әлеге томга язучының иң яхшы хикәяләре һәм повестьлары кергән. Тирән фәлсәфәгә, анык фикерләүгә бай, геройларның моңлы, шул ук вакытта каршылыклы да булган эчке дөньяларын, авыл, хезмәт кешесенең авыр тормышын бөтен тулылыгы белән ачып бирә алган әлеге әсәрләр киң катлам укучыларга юллана.

РАШАТ НИЗАМИЕВ. Кызыл кар яугач. Казан: Татар. кит. нәшр., 1993 ел, 221 б. Тиражы 25 000 данә.





Рашат Низамиев әдәбият сөючеләргә күбрәк шигырь китаплары авторы буларак билгеле. Яңа китабында исә ул төрле елларда язылган хикәя һәм повестьларын тәкъдим итә.

Геройларның психологиясен, күңел кичерешләрен язучы якты төсләрдә тасвирлый, шул ук вакытта фаҗигале хәлләрне дә читләтеп узмый. Әйтик, китап исеменә күчкән «Кызыл кар яугач» повестенда авылда туып-үскән татар егете, аның мәхәббәте һәм Әфганстанда төгәлләнгән һәлакәтле язмышы тасвирлана. «Беренче мунча» дигән хикәя исә үзенең яңалыгы, көтелмәгән тәэссоратлары белән укучыларны, һичшиксез, җәлеп итәчәк.

Бәясе 330 сум

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал (на татарском языке)

Журнал включен в центральный каталог